# казан утлары

12
ДЕКАБРЬ-1971

# Безнең юбилярлар

*Шушы елның декабрендә М. Горький, Г. Тукай исемендәге премияләр лауреаты, шагыйрь Сибгат Хәкимгә һәм Г. Тукай исемендәге премия лауреаты, күренекле язучы Габдрахман Әпсәләмовка 60 яшь, Татарстан язучылар союзы председателе, шагыйрь Зәки Нуриға һәм драматург Юныс Әминовка 50 яшь тула.*

*Күп меңләгән укучыларыбыз исеменнән без аларны олы бәйрәмнәре белән чын күңелдән котлыйбыз һәм, киң илебезнең барлык почмакларыннан килгән хатлардагы, телеграммалардагы җылы тәбрик сүзләренә кушылып, аларга иҗади уңышлар һәм сәламәтлек телибез.*

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**12**

ДЕКАБРЬ
1971


## Бу санда:

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ПОЭМА, ШИГЫРЬЛӘР


**С. ХӘКИМ.** Кырыгынчы бүлмә. Поэма . . . . 3
**Г. ӘПСӘЛӘМОВ.** Идел хикәяте. Повесть. . . 11
**З. НУРИ.** Лирика һәм юмор. Шигырьләр . . . 42
**Ш. МАННУР.** Күңел дәфтәреннән. Шигырьләр . 50
**Ә. БАЯНОВ.** Ут һәм Су. Роман . . . . . . . 57
**Ф. ЯРУЛЛИН.** Ат сайладым... Шигырьләр . . . 91
**Х. ӘЮПОВ.** Атлар. Шигырьләр . . . . . . . 92
**Р. БАТУЛЛА.** Көтелмәгән кунак. Хикәя . . . . 96


ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ


**Р. НИЗАМИЕВ.** Һаман калды. Шигырьләр . . . 101
**С. РӘХМӘТУЛЛИН.** Бер мизгелгә... Шигырьләр . 102
**Ә. ИБӘТУЛЛИН.** Саумы, апрель! Шигырьләр . . 105


ОЧЕРКЛАР


**Р. МАКСУДОВ.** Шәйморза кешеләре . . . . . 107


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


**Г. МӨХӘММӘДОВА.** Гуманизм җырчысы . . . 113
**Ә. МАЛИКОВ.** Утта чыныккан дуслык . . . . 125
**А. ГЫЙЛӘҖЕВ.** Ак нур белән... . . . . . . . 130
**С. ХӘКИМ, Т. ГАЛИУЛЛИН.** Халык язмышы — шагыйрь язмышы . . . . . . . . . . 135


ӘДӘБИ МИРАС


**Н. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.** Язучы һәм көрәшче . . . 140
**К. НӘҖМИ.** Автобиографиядән өзекләр. Мәкаләләр . . . . . . . . . . . . . . 141


ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ


**Г. ХАЛИТ.** Халыкчан һәм тормышчан сәнгать өчен . . . . . . . . . . . . . . . . 150



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. МОСТАФИН. һ. Такташ һәм аның чоры . . 160
Р. ГӘРӘЙ. Карлыгачлар саны ишәя . . . . . . 162

ПУБЛИЦИСТИКА

Ш. ХАММАТОВ, Ш. ЗӘБИРОВ. Матбугат һәм язучы . . . . . . . . . . . . . . 164

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. ГАЛИЕВ. Эш кушып булмый... Шигырьләр . . 174

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

М. ӘГЪЛӘМОВ. Студент кунагы. Шигырьләр . . 178

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 180

1971 елда журнал битләрендә басылган әсәрләр 184

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вәхит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 6/IX-1971 ел. Басарга кул куелды 29/X-1971 ел. ПФ 04150.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 79100 экз.
Заказ И-617. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1971 ел.

## Сибгат Хәким


# Кырыгынчы бүлмә

поэма

Эти Этнә базарыннан — бәйрәм,
Чана башын тизрәк актардым,
Ат печәне, салам арасыннан,
Арасыннан чиста ак карның
Күмәч чыкты, китап — Тукай чыкты,
Әкиятләре белән, кар белән
Тукай керде өйгә, казанда аш,
Бөтен дөнья тулган пар белән.
Тукай керде өйгә, түргә узды,
Күңелләргә эфсун-ут өрде,
Малайлыкның алтын тәхетендә
Таҗын киеп Тукай утырды.

Җитте яшьлек, янда Тукай, бездә
Мыек та юк, бары яшь төкләр,
Икебез дә егет, икебез дә
Тик егерме җиде яшьлекләр.
Бәхетле чак, яшь чак, ялкынлы чак
Күңелләрне сүзсез эреткән,
Гомер алда, мәхәббәтем алда,
Бар да алда: хыял, өметләр...
Янда Тукай... Рухы кагына өстә,
Йөрәк сизә, тоя, сикерә,

Аның белән мин барырга риза
Җир читенә, дөнья читенә.
Берсе сөя, берсе суга торган
Тәкәббер һәм горур канатлар
Җилпенәләр бертуктаусыз өстә,
Тукай җигеп биргән «Пар ат»лар
Илтә алга, чокырларны күрмим,
Куллар минем аңа тотынган,
Очам алга, исергәнмен тәмам
Илаһи рух — Тукай рухыннан.
Туйдан туйга чаптым, күңел чуар,
Атлар чуар, туйлар чуар күк,
Ак күбеккә төшергәнче чаптым,
Күбекләрен җилләр юар күк.



Кердем чабып, алда чиксез киңлек,
Бүтән дөнья алда бар сыман,
Нәкъ уртада юлда атларымның
Тотты тормыш ныклап башыннан;
Төш, җиргә бас, җәяүләп бар, йөгер,
Үт тиешле ике араны...
Ике ара: бишьеллыклар, чорлар,
Без гел бергә: эне-агалы...
Ике ара — сугыш... Үрмәләп уз,
Укмаштылар каннан ак карлар...
Кайсы фронт бураннарында сез
Адаштыгыз, минем чаптарлар...
Калдырдыгыз ташлап мине кырда,
Пулеметлар кайнар, туп кайнар...
Янда һаман Тукай, мин аңладым:
Язмышларда икән Тукайлар...
Фронтта да бары бер генә чир —
Тукай чире белән чирләдем;
Ул чир миңа газаплары белән
Алып килде туган җир ямен.
Дәвасы юк, гомер буе бер чир,
Гомер буе миндә өч исем:
Бөек Пушкин, Лермонтов һәм Тукай,
Тукай белән килде очлыйсым.
Вакыт, вакыт, йомгакларга вакыт,
Изге сәгатендә җомганың

Мин сүз бирдем, дидем: иҗатымның
Тукай белән ясыйм йомгагын.
Гомерләре читтә узганнар да
Әйләнеп бер кайта, хәл белә;
Якыная картлык, якыная
Күңел һаман Тукай каберенә.
Еракларда тарта бөек рухы,
Соңгы сулыш — соңгы тынынны
Алган көнгә кадәр озата бара
Сине, мине, һәрбер буынны...
Үз-үземә урын тапмаганда,
Авырайгач каләм кулларда,
Казан буйлап йөрим-йөрим дә мин,
Тукай торган йортка — «Болгар»га
Килеп чыгам искәрмәстән чаттан,
Вәгъдәләшкән кеше шикелле
Карыйм озак, көтәм... Чат, иске йорт
Минем өчен мәңге сихерле,
Минем өчен мәңге изге бу йорт,
Бүлмәсендә, күрәм, бар уты...
Чатта «Болгар», почмагына аның
Тиеп узган Сәйдәш табуты...

Тукай белән һаман бара кебек
Алыш-биреш, хөкем-эш әле,
«Болгар» ишегеннән күренгәнен
Көтә гүя көфер почмагы...
Мәчет исән, манарасыз ләкин,
Сәламеңне алмый баш исәң,
Шавын ишетәм Печән базарының
Бер минутка чатка бастисәм.
Тынгысыз чат, ыгы-зыгылы чат,
Печән сатып күргән зарарның
Кайгысыннан эчеп юанган чат,
Күчәр башы монда заманның
Бертуктаусыз килеп сугылган чат.
Халык монда җанын бушатты,
Кырлай юлы, ерак Җаек юлы,
Шагыйрь юлы урый бу чатны.

Җәен килдем, йортлар соры, моңсу,
Моңсу вакыт, беләм, таң алды,
Мине монда чорнап, һәр чак авыр,
Үкенечле уйлар талады.
Килдем кышын, ачу белән чаттан
Иске дөнья бәрде карларын;
Бәрде биткә, бәрде минем йөзгә,
Аның саен ныграк каргадым...
Тынгысыз чат, тынгы бирмәс җанга,
Үзем тынгач, шушы чат тынар,
Тукай тавышы, кычкыра күк Тукай,
Бер генә сүз яңгырый: саттылар...
Базарларда печән, он сатылган,
Җыр сатылган, кеше сатылган...
Актарам бай тарихымның битен
Карап данлы Болгар чатыннан.

Әрнеттереп искән җилләргә түз,
Борчуларың белән кал чатта,
Зур тарихым Болгар булып басты,
Моңнар булып басты кайчакта.
Басты Шиһаб Мәрҗанилар булып,
Халкымда бар гүзәл сыйфатлар;
Җан богавын, фикер богауларын
Башлап өзде бездә Шиһаблар.
Кем кабатлый: сүнде безнең тарих,
Сүнде шәмнәр, сүнде, янмаслар,
Яктыртып зур юлны, озын юлны
Яна Тукай, яна Ямашлар...
Иң бәхетле хис дим халкым белән
Горурланып язган чагымны;
Шул хис икән — җиз кыңгырау җанда,
Шул яшәтә икән шагыйрьне,
Киләм, торам, төн, берүзем калам,
Почмагына җилләр кар өйсен,
Күмә алмас, текә борылыш ясый
Шушы чатта минем тарихым...
Сыен аңа, таян аңа һәр чак,
Берәүгә дә, шагыйрь, карама,
Яз, горурлан эчтән, ул безнеке,
Тамырыннан безнең кан ага.

Елның төрле чакларында килдем,
Алларында йөрим елларның;
Гаҗәпсенеп карап, алларында —
Валларында йөрим Болгарның.
Тарихымның ишекләрен кагам,
— Нәрсә кирәк сезгә, я, диләр.
— Беләсезме, Тукай кирәк миңа,
Әмирханнар кирәк, Рәмиләр...
Бер ишектән бер ишеккә туктап,
Башлап йөрде алдан зур кайгы,
Йорты белән сискәнәләр кебек
Мин сораган саен Тукайны...

Өем тыныч, Аккош күле тыныч,
Тыныч түгел нигә бу җаным?
Чорны чорга якын куеп карыйм,
Вөҗданына аның — вөҗданым.
Өч гомерен аның яшәп җирдә
Чагыштырыр эшем бармы соң?
Җырны җырга якын куеп карыйм,
Намусына аның — намусым,
Хакыйкатькә — хакыйкатьне, җанны,
Эзли күңел үзенең иясен,
Әйләнәмен аның тирәсендә
Галәмдәге гади иярчен.
Эзли күңел, ник ул җитми һаман?
Ник борчуда уза күп айлар?
Калдырып зур мирас, нәрсәнедер
Алып китте кебек Тукайлар...

Чатта «Болгар», баскыч, сары идән,
Куптарсалар, кабат басалмам,

Әйтерсең лә тауга менә юллар,
Юллар иске, юллар ашалган,
Уелганнар, уеп кергән чорлар,
Хет музейга берсен сайлап ал;
Тукай эзе, Әмирханнар эзе,
Бөеклеккә юллар — сайгаклар...
Безгә син ят кеше дигән төсле
Узган заман миңа карыйдыр,
Коридордан Тукай заманына
Атлап керәм, тап-тар коридор.
Мин мөсафир... Номерларын «Болгар»
Ачар миңа, кайсын алсам да...
Яңгыратты коридорны кемдер:
— Ишеттеңме, Тукай Казанда.
Кычкырды ул үзен-үзе онытып,
Шатлыгыннан ярсып тиле күк,
Казан кинәт күтәрелде сыман,
Бөеклеген Казан тойды күк,
Сигез гасыр — сигез баскычны ул
Менде атлап, җырла дан аңар,
— Ишеттеңме, ишеттеңме... Ташка
Гайрәт белән суга дагалар.
Ишеттеңме, бер хәбәр бар, кардәш...
Җыям, туплыйм бөтен аңымны,
Бар да көтә, бар да тыңлый тынып,
Коридорда Тукай адымы...

Бишенче ел юри тукталды күк
Яшь Тукайга, тапты Җаекны,
Алды берне сайлап, чөйде биек
Үз халкына тугры, лаекны.
Татар бәхете өчен чөйде биек,
Сорадылар юлда: ул кайдан?
Бишенче ел: ул — тагардан, диде...
Татар үзе? Татар — Тукайдан...
Артта Җаек, казакъ далалары,
Көймәләре ярда Чаганның [1]...
Көз, октябрь, җил дә давыл җирдә,
Чаганнары яңа заманның...

Килде шагыйрь, битарафлык бетте,
Сөйләр Казан, ярлы, бай сөйләр,
Ярты гасыр үтсә дә, бер алыр
Әтиләре үчен Вәйсиләр.
Килде шагыйрь, өметләре якты,
Ак кәгазьгә тамган уй якты,
Шигырьне ул, язын зур мәйданда
Ат уйнаткан кебек, уйнатты.
Килде шагыйрь, халык килде телгә,
Нинди зур җан ябык, чандыр да,
Бөтен гомерең буе көнлә аны,
Бөтен гомерең буе сал җырга.
Чандыр, ябык, сабак баласы күк,
Малайлыгы һаман узмаган,
Тузан өереп кайнак пролеткалар
Арасына очкан кузналар.

[1] Чаган — елга исеме.

Вула хиснең юләр минутлары,
Вула шаян, күңел көр чаклар,
Заман үзе бөтерелгән юлда,
Бөтерелгән юлда көпчәкләр,
Көпчәкләр күк бөтерелгән уйлар,
Пролеткадан: шагыйрь әфәнде!
Елаган һәм көлгән шагыйрь, дөнья
Уртасында язган әсәрне...

Килде шагыйрь, Тукай килде җиргә,
Язганнары — безгә бүләге.
Күрсәт, тарих, бар кайгысы белән
Татар халкы сыйган бүлмәне.
Йозагы юк, ачкычы юк, ачык,
Карый икән кеше — карасын.
Үзе юкта һәркем алып чыккан
Я көзгесен аның, карасын.
Бу — бердәнбер биксез бүлмә җирдә.
Урындык һәм өстәл, кәрзине...
Урлатасы әйбере юк, хөрлек
Һәм азатлык, шигырь һәр җире.
Тар, кечкенә... Монда Казан, Җаек,
Монда Уфа, дуслар еш кергән,
Бу бердәнбер бәйсез дәүләт, шуңа
Үзенеке иткән Пушкиннар,
Лермонтовлар үзенеке иткән,
Рухы белән бүлмә бай булган,
Греция кырларында гына
Калмаганнар туктап Байроннар...
Яши монда батыр, горур җаннар,
Туры килсәң кичке сәгатькә,
Тәрәзәгә кара, яна утлар,
Яна охшап утлар шәфәкъка,
Әйтерсең лә яна миллион шәмнәр,
Бер уфтана заман, бер көлә!
Төрле телдә шигырьләрен ишетәм,
Бәхәсләре тышка бөркелә...

Елның төрле чакларында килдем,
Караватта ничек тирбәнеп
Утырганын мин кичердем уйдан
(Маңгаена чыккан тир бәреп),
Тордым шигырь чакырганын карап,
Күзләр генә төрткән юрганнан,
Ул көн җирдә Шәрифәләр [1] елый,
Шәрифәләр аңа юл ярган.
Язмышына иелә-иелә көйли,
Кил син, шигырь, кил син, кил, кабын,
Ул көн җирдә Зөләйхалар елый
Тотып кулга «Йосыф китабы»н.
Үзеңнән биз, дөньядан биз ул көн,
Сораганга, диген, хастамын,
Ул көн җилләр төннәр буе елый
Зиратыннан килеп Сасңаның.

---

[1] Шәрифә — Тукайны бала чакта асрамага алган хатын.

Бу шагыйрьләр шигырьләрен мәңге
Чакырырга шулай мәҗбүрләр,
Халык булыша, тарих булыша, барыбер
Сирәк килә «Ләйлә-Мәҗнүн»нәр...

Чатта «Болгар»... Тәрәзәгә карлар,
Тәрәзәгә җилләр — Кабаннан,
Төн Кабан күк әллә нинди төпсез,
Болытлары җирнең кабарган.
Язмышына иелә-иелә көйли,
Көйләп аргач, ята ул тыңлап,
Кыса ике стенасын аның
Кабандагы бозлар шытырдап,
Бүлмә кыса, дөнья кыса, суык
Төшә бәгырь, төшә бавырга,
Ул номердан номерларга күчә,
Ул шәһәрне ташлап, авылга
Җылы эзләп чаналарда кача,
Кача язмыш-бизгәк-салкыннан,
Бармы, дөнья, синең җылы төшең?
Толыбың сал өскә, сал, туңам...
Тукай кебек туңган юктыр җирдә,
Суыктан да күрде язмавын,
Ашыкты күк бөтен яшәеше,
Бар халәте белән язга ул.
Авырып аргач, кешеләрдән аргач,
Номерында ятып тыгызда,
Яз каршына поездларда чапты
Казакъ даласына, кымызга...
Күп тотмады җәннәтендә дөнья,
Күрдең, китәр, сау бул гомергә!
Казанына озатты ул кабат,
Һаман да шул салкын номерга...

Йозагы юк, ачкычы юк, ачык.
Үлгәнче бер номер ул биләр,
Урлатасы әйбере юк, ләкин
Шигырьләрен, җанын урлыйлар.
Җылы эзләп яз каршына чапты...
Ята уйлап: җиргә буш килмә...
Ул Пушкинга килде, үзе салган
Тукай юлы белән — Пушкинга.
Ята уйлап: кыса дөнья, ярый,
Үлгәнче бер вакыт, җай таптым...
Үз өстендә, халкы өстендә күк
Тояклары «Бакыр Җайдак»ның.
Колакта моң... Ерак, тонык, нәзек...
Петербур, яз... Әнә рәт-рәткә
Тезелгәннәр, «Туган тел»ен аның
Җырладылар шунда мәктәптә.
Уникенче елны Петербурда
Җырладылар, башлар иелгән,
Бары кәгазь калынлыгы гына
Ачылганнар куркып иреннәр...
Колакта моң... Ерак, тонык, нәзек,
Язгы сагыш... «Болгар», «Амур»да,
Клячкинда гел ишетте шуны,

Рәхәт тә күк аңа, авыр да...
Гөнаһсыз саф тавыш... Сабыйларча
Көйләделәр сузып хор белән,
Ә Тукайның сунә барган йөзе
Соңгы тапкыр тулды нур белән...

Тырыш та син, ярлы да син, халкым,
Күршеләрең нинди, бай бар да,
Бер үзенә утыз өч бүлмәле
Йорт бирләгән Гёте Веймарда,
Күр, ни хәлдә синең бөек улың!
Үлде Тукай, олы җеназа
Узды сүзсез, гаҗәпмени күңел
Язмышына карап еласа...
Үлде Тукай... Әмирханга калды,
Кулы белән тотып ул башын,
Кычкырды бар дөньясына әрнеп:
«Моннан соң дип болай булмасын».
Үлде бөек токым... Кем дә әйтмәс:
Улларыңнан син, дип, уңмадың,
Халкым, алда улларыңны сакла,
Авыр чорлар кичерә улларың...

Мәктәбем дә, телем дә ул Тукай,
Тукайдагы кебек тел кайда?
Мең елдан соң да бер синең, илем,
Кайтасыңны беләм Тукайга.
Шуны ләкин син онытма, «Болгар»,
Кырыгынчы бүлмә барлыгын,
Тукайның зур мәңге тере җаны
Шунда ята, кара, бар, энем...
«Болгар»га мин эчем пошкан саен
Барып чыктым Болак буеннан,
Хыялымда ничә тапкыр күрдем,
Җилләр үтте улап уемнан.
Хыялымда күрдем, өндә күрдем,
Ярларыннан үтеп Болгарның,
Әкияттәге төсле ак пароход
Чәчәкләрен алып меңнәрнең,
Аваз салып безнең чорга керде...
Бөек эшләр илдә кылганда
Күтәрелә ул да, аның бүген
Казан мәйданында, Кырлайда
Һәйкәлләргә әйләнгәнен күрдем
(Яңа буын, көн дә кил монда),
Тукай васыять иткән «Туган тел»нең
Әйләнгәнен күрдем гимнга,
Шул гимнда мәңгелеген күрдем,
Мәңгелеген раслап, йомгакла.
Җепләр — юллар, юллар йомгак, йомгак,
Чакырдылар еллар еракка...

1971

≈≈≈≈≈≈

## Габдрахман Әпсәләмов

# ИДЕЛ ХИКӘЯТЕ

ПОВЕСТЬ

I



Ул, тәрәзә янына утырган килеш, Иделгә бик озак карап тора. Әйтерсең ул пароходта утырып бара, Идел суы биш-алты адымда гына. Чынлыкта Иделгә чаклы илле-алтмыш адымнар бардыр. Рушадларның дачасы калку урынга салынган, тәрәзәлән караганда астагы тау бите дә, андагы тәбәнәк рәшәткәләр, вак куаклар да, хәтта дача каралтылары да күренми, ә алтындай кызгылт кәүсәле биек, төз наратлар гүя су эченнән калкып чыгалар. Әлбәттә, торып аякка бассаң яки террасага чыгып карасаң, күренеш беркадәр үзгәрә үзгәрүен, тик Рушад күбрәк утырып торырга мәжбүр, йөрү, бигрәк тә яр буйларыннан әйләнеп керү, кыенрак аңа. Шуңа күрәдер, ахрысы, аның күз карашында да...

Әгәр бу күз карашын сүз белән әйтеп булса, бик җиңел язар идең. Аның күзләре соры, вакыт-вакыт карасуланалар, хәтта төпсез сыман тоелалар. Аларны хәзер Рушад карап торган Идел белән чагыштырсаң гына, бәлки, дөреслеккә беркадәр якын булыр.

Әнә елга нинди киң, мәһабәт, кояшта ничек җем-җем итә, төсе нинди тиз үзгәрә. Аны гадәттәгечә соры яки зәңгәр димәссең, анда художник күзе генә аера ала торган әллә никадәр үзенчәлекләр, күчәнешләр бар. Әллә Иделгә генә хас тынычлык һәм олылык аңа шул бихисап төрлелекне бирәме? Шундый минутлары була, ул гүя сине үзенә тарта, чакыра, сиңа нәрсәдер яшертен генә вәгъдә итә. Аннары шулай серле шаяра-шаяра кичке эңгер караңгылыгына күмелә, төсләре куера. Бераздан дулкыннары ай-йолдызлар белән күз кысыша башлый, балыклары, көмеш тәңкәләре белән ялтырап, уйный-уйный, җәйге томанлы таңны тыныч кына каршы ала.

Менә Рушадның күзләре шундый. Тик былтыргы кебек җилле-яңгырлы җәйдә Иделдә үзгәрешләр тагын да күбрәк шикелле: әле генә кояшта мең-миллион тәңкәләре белән ялтырап җемелдәп торган су җәймәсе кая китте диярсең, әллә шаян су кызы серле шәлен тартып алып яшердеме? Күр, Идел өстендә инде чал сыртлы дулкыннар йөгерә, Идел бер каралып китә, бер ачыла төшә, ул да булмый, аны тоташ соры җәймә кап-



лап ала, аргы яктагы яшел һәм сары яр күздән югала, бөтен дөньяны су туфаны баса шикелле, син инде төссез судан башка бер нәрсә дә күрмисең, тик җил сызгыра да наратлар гына шаулый, ә Идел гүя ачулангап, котырынган, ярларыннан сикереп чыгар төсле.

Рушад һаман тәрәзә янында утырып тора, күз карашын сүндерер өчен дигәндәй керфекләрен түбән төшерә. Ул вакыт үткәнен сизми, тик кан тамырлары сулкылдап тибә дә йөрәгә кага. Уйласаң, вакыт шулай үтә. Кинәт исерекләр җырынамы, әллә туктаусыз мөңгерәүгәме охшаш бер тавыш ишетелә. Рушад беркадәр вакыт бу тавышны аера алмый тора. Аннары зиһене ачылып киткәндәй була. Ул белә: бу исерекләр җыры да, акыру да, мөңгерәү дә түгел. Бу — моннан бер чакрымдагы авылда торучы мескен Хайбас килә. Аның чын исеме — Хәйбулламы, Хәйрулламы — әйтүе кыен. Үзе, нечкә авазларны әйтә алмаганга, Хайбас ди. Аңа унҗиде-унсигез яшьләр булыр. Бала вакытта ул, ми авыруы белән авырып, акылга җиңеләеп калган. Өстәвенә, уң кулы, уң аягы һәм арка сөяге зәгыйфьләнгән. Моннан берничә ел элек аны гел букча күтәреп йөргән дип сөйлиләр, мәктәпкә бара, янәсе. Билгеле, ул яшьтәшләре кебек укый алмаган. Хәзер көн саен иртән гел бер вакытта урман эчендәге пионер лагерена йөри. Лагерьга керми, юлдан ерак түгел бер агач төбенә утыра да уенчык өйләргә охшаган лагерь йортларына карап тора, үзе авыз эченнән һаман нидер мыгырдана: әллә инде үз алдына шулай сөйләнә, әллә шулай җырлаган була. Кайчак вак-вак ташлар җыеп, юл буендагы сулы чокырга ата. Анда берәр нәрсә күрәме — белмәссең.

Лагерьдан ерак түгел «Водоканал» дигән бер оешма бар. Шунда Хайбасның әтисе каравылчы булып эшли. Ашыйсы килсә, Хайбас әтисе янына сугыла. Ә кич белән, шулай ук бер вакытта, әлеге аңлашылмас җырын суза-суза өенә кайта. Бала-чагага, кешеләргә, мал-туарга, бакчаларга кагылмый. Дачадагы карчыклар, кызганып, аңа җиләк-җимеш, алма-фәлән чыгарып бирәләр. Хайбас кайчак ала, кайчак алмый да, бер кулын күкрәгенә куеп, икенчесен «кирәкми-кирәкми» дигән шикелле селкә генә.

Рушадны берәр җирдә очратса, туктап аңа карап тора. Әллә инде үзләре арасында ниндидер уртаклык күрә — Рушад та аксап йөри,— әллә инде үзенчә кызгана. Кайчак телен чыгарып үчекләп тә ала, кычкырып көлә дә. Рушад аны кумый, башын селкеп, сүзсез генә аңа карый. Тиле дә кемнән көләргә ярый икәнен белә, ахрысы. Рушадның йөреше тилене дә көлдерерлек булып калганмы?

Рушад, башын иеп, үз юлына китә. Уң кулы белән уң аягы йөрмәсә дә, аның акылы сәламәт. «Мин әле Хайбас хәленә калмаган. Хайбас үзенең фаҗигасен аңламый, шуңа күрә ул турыда уйламый, уйлый алмый, ә мин аңлыйм лабаса»,— ди ул үз-үзенә.

Ләкин Рушадка чиксез авыр булып китә. Аңлап ни кырасың? Ул ничәмә-ничә мең кеше эшләгән заводның баш инженеры, гәүдәгә мәһабәт, төскә-башка ярыйсы чибәр бер кеше иде. Хәзер нәрсә калды? Эх, тормыш, тормыш! Нигә болай шаярдың? Сәламәт чакта барысын булдырып була, ә син менә авыргач кеше исеменә тап төшермә диденме? Бар иде вакытлар, Рушад бер көн эшкә чыга алмаса да, йөз тапкыр шалтыраталар, шундук килеп житәләр иде. Ә хәзер ни? Берсе-бер килми, шалтыратмыйлар да. Өй халкы да кич кенә кайта. Иң авыры шул: балалар укулары, хатыны завод хәлләре турында ләм-мим сөйләмиләр. Ә Шәрифә завод хәлләрен бик яхшы белә, ул аның нәкъ үзәгендә — план бүлегендә эшли. Сорасаң да бер-ике сүз белән генә җавап кайтара. Күрәсең...

Рушад кешеләргә дә, өйдәгеләргә дә артык үпкәләми. Кешеләр дөнья мәшәкатьләре белән авыру кешене ялыктырырга теләмиләрдер, шул гына. Аның каравы, Рушад үзе дә, бик авырган чакларында да, моны өйдәгеләрдән яшерергә тырыша. Тик түзәрлеге калмаганда гына балаларына яки хатынына: ник бүген бик озакладыгыз? дип рәнҗеп әйтеп куя. Исән чакта уйга да кереп чыкмый торган юк-бар нәрсәләр аның җанын актара. Күбрәк сөйли башласаң, сиңа тагын әллә ничек итеп карыйлар.

«Күрәсең, кешеләр шулай акылдан да яза торганнардыр», дип уйлый Рушад. Тыныч буласы иде дә, тик бөтен җан көче моңа каршы күтәрелә. Әмма кем белән яки ни белән сугышырга?

«Юк, болай ярамый, һич ярамый, нәрсәдер эшләргә кирәк. Булмастайны булдырырга, җиңмәстәйне җиңәргә!» дип уйлый Рушад. Шунда ук күңелендә сорау туа: нәрсәне булдырырга, нәрсәне җиңәргә?

Элек мәсьәлә ачыграк иде, ул авыруы белән көрәште, бик күп физкультура күнегүләре ясады — монысы төп нәрсә диделәр врачлар,— саф һавада утырып торды, бакчада йөрде. Башта врачлар аны гел юаталар иде, берничә елдан тәмам аякка басарсыз, диләр иде, әллә нихәтле гыйбрәтле мисаллар китерделәр. Хәзер инде юатмыйлар да, андый мисаллар да китермиләр, Хайбас хәленә калмагансың, шуңа шатлан, югыйсә, андый хәлнең булуы да бик мөмкин иде бит, диләр. Болар гына сине шатландырмавын күргәләр, өстәп куялар: пенсия аласың, Идел буенда дачаң бар, семьяң үзеңне яхшылап карый, тагын ни кирәк? Эчең пошса, бакчага чыгып утыр, я урманга бар, Идел буена төш,— әкрен генә булса да йөри аласың ич. Газета-журналлар укы, радио тыңла, телевизор карарга ярый, тик чамасын онытма, диләр.

Ни әйтсәң, болар бар да дөрес, кемнән булса зарлану яки врачларга үпкәләү ахмаклык булыр иде. Алар кулларыннан килгәннең барысын да эшләделәр. Бүген кайбер авыруларны җиңә алмыйлар икән, фән андый баскычка күтәрелмәгән икән, нишләмәк кирәк?! Шуңа күрә, кайчак азрак турсаеп ала икән, ул зарланумыни? Юк, бу җан борчуы гына. Аның яшисе килә, ә яшәү күп нәрсәне таләп итә. Исәннәр шуның нечкәлекләрен аңламыйлармы икән? Хайбас хәлендә булмасаң да, бу кадәресе көн күрергә генә ярый, ә Рушад моның белән канәгатьләнми. Нәрсә бу, кендегеннән югары сикерергә маташумы? Яшен яшәгән булса, бер хәл, югыйсә, аңа алтмыш та юк бит әле, ә бу яшьтә кеше үкертеп эшләргә тиеш.

Тиеш! Әгәр дә ул эшли алмаса? Шуңа күрә җәмгыять бер дә кызганмыйча аңа пенсиясен бирсә? Җәмгыятьнең авыруларны ташламавы бик яхшы, бу бары тик социалистик җәмгыятьтә генә мөмкин булган

хәл. Ләкин кеше җәмгыятьтән алу белән генә канәгатьләнми, мөмкин булганча үзе ана файда китерергә дә тырыша. Менә кайда хикмәт.

Яшәүнең башы — эш, хезмәт. Хезмәттән бөген иҗади дөнья барлыкка килә, тирә-як нурлана, мәгънә чыга. Хәзер Рушад теләсә нинди хезмәткә риза булыр иде, баш инженер булган кешегә нигә андый вак эш тәкъдим итәсез, дип бер дә каруланмас иде. Әмма моны әйтүе генә ансат шул, бер кул, бер аяк, ярты як гәүдә белән нәрсә майтарып була? Үзеңне карарга да кеше кирәк әле! Врачлар да кисәтеп әйттеләр: һичбер очракта да дулкынланмаска, диделәр. Ә эшләгәндә дулкынланмый буламы? Тормыш пыяла калфак астында түгел шул, анда селкенергә кирәк.

Рушад ачы итеп көлемсерәп куя, Шәрифә әгәр аның бакчада кыймылдавын, бер кулы белән булса да түтәлләргә су сибеп азаплануын күрсә, дау күтәрә. Нигә бөгеләсең, нәрсәгә кирәк ул? Чәчәкләрдән бераү дә алтын сарай салмаган әле. Үзем эшләрмен, балалар килгәч булышырлар, ди.

Рушад көрсенә, дәшми. Шәрифә алтын сарай турында бөтенләй буш нәрсә итеп, хәтта бераз мыскыллый төшеп әйтә. Моны ул элек тә, Рушад чертежлар өстендә төннәр буе утыра башласа да, әйтә торган иде. Ул чакта Рушад җан рәхәте белән көлә генә иде, ә хәзер шул алтын сарайга рәхәтләнеп таш ташыр иде!

Заводта эшләгән чагында Рушад андый «алтын сарайларны» таш ташымыйча да бик күп салды һәм шул яраткан эшемне гомер буе дәвам итәрмен дигән иде. Булмады! Ирдән мәтәлеп төште, эшсез, дөресрәге — эшкә яраксыз булып калды. Моның никадәр аяныч булуын, хезмәткә никадәр сусавыңны сәламәт кешеләргә, бәлки, аңлатып та булмый торгандыр. Чын менә. Ичмасам, эш һавасын сулыйм дип, Рушад партбюрога да шалтыраткалап торды. Ниһаять, бер көнне аны партия җыелышына ала килделәр. Әй, шатланды Рушад, түбәсе күккә тигәндәй булды. Кемнәрнең кисәтүе буенчадыр инде ана күп сөйләргә кушмадылар. Рушад моны беркатлы итеп, җыелышта чыгыш ясама, дип аңлады.

— Юк, юк. Кая ул чыгыш ясау. Элеккеләрне сагынып утырырмын. Җыелыш саен сөйли идем бит,— диде.

— Сез ни... Рушад Һилалович,— диде ала килгән кеше, ә Шәрифәнең күз кысуын Рушад үзе күрмәде.— Сүздән ботка пешми, авырга килә күрмәсен дигәнем...

Ниһаять, Рушад бу кешенең тел төбен аңлады. Монда җибәрер алдыннан аңа әйткәннәр булса кирәк, ул үзе яшь, таза кеше, авыру белән ничек сөйләшергә кирәген дә белми. Тузга язмаганнарны сөйләмәсен дип сагаеп кына тора.

Рушадның кәефе кырылды. Ул иптәшләренең яхшылыктан чыгып саклык күрергә тырышуларын аңламыйча, гаделсезлек кенә күрде. «Мин ул кадәр беткән кеше түгел бит!» дип кычкырасы килде.

Җыелышның доклад өлешен тын гына тыңлады, чырае яктырмады. «Монда инде сине, Рушад, сызганнар, исәптән төшереп калдырганнар», дип уйлады әрнеп. Шуңа күрә үзен беренче тәнәфестән соң ук кайтарып җибәрергә җыенуларын күргәч, каршы сүз әйтмәде. Парторг машинага кадәр озата чыкты. Ул Рушадның дусты һәм яшьтәше иде.

— Рәхмәт, дус,— диде Рушад аңа үпкә белән.

— Нишлисең бит,— диде парторг.— Күңелеңне төшермә, Рушад. Якты көннәр дә бер килер әле. Өметсез — бер шайтан ди идең түгелме?

Күңел күтәренкелеге урынына Рушад җыелыштан кайткач үзен начар хис итте, аннары урынга ук ятты.

— Менә тыңламыйсың бит, Рушад. Парторг телефон аша да хәлеңне сорашты, эш бетәр алдыннан яныма да килде. Хәлеңне килеп белергә теләде,— диде Шәрифә.

— Юкка алып килмәгәнсең, Шәрифә. Мин ана әйткән булыр идем. Кеше турында чынлап кайгырту матур сүз генә сөйләү түгел шул.

— Рушад, син хаксыз... Күңелең борчылганга гына әйтәсең.

— Бәлки, шулайдыр. Күрәсең, мин...

Рушад сүзен әйтеп бетермичә стенага таба борылды һәм бик озак эндәшми ятты. Иртәгесен үпкәсе бераз кайта төште, иптәшләренә артык рәнҗеми башлады. «Юк, болай вакчылланырга ярамый, я эштә янарга, я...»

Рушад уен тәгәлләмәсә дә, нәрсәне күз алдында тотуы билгеле иде. Тик моның өчен егетлек кирәкми, бетү, югалу — ул авырлыклардан качарга тырышу гына. Коммунист исеменә бигрәк тә лаек түгел. Әйе, бу кадәресе ачык, ә калганы? Рушад тере килеш уларга дә теләми иде. Кешеләргә өстәмә йөк булу нигә, аларның тормыш юлында тартасы йөкләре болай да аз түгел.

Шәрифә күптән инде ут йотып йөри иде. Ниһаять, түзмәде, иренең караваты янына утырып, агара башлаган чәченнән сыйпады да мөмкин кадәр йомшак тавыш белән:

— Рушад, син элекке яхшы сыйфатларыңны оныта башладың бугай. Кешенең ихтыяры, рухы авыруын җиңәргә булыша дип сөйли идең. Хәзер киресен итәсең,— диде.

Рушад кызарды һәм, сүзсез генә, хатынының кулын тотып иреннәренә китерде. Аның иреннәре кипшенгән, яргаланган иде.

## 2

Рушад Вәлишин тормышын эзгә салынган, аны үзгәртергә һич тә кирәкми дип уйлый иде. Ана, инженер кешегә, ашмас хыяллар эчендә йөзү ят нәрсә, яше дә ул түгел. Хатыны һәм буйга җитеп килә торган балалары бар, аларны шулай ук онытып булмый. Инженер һөнәре ана тормыш итү өчен бөтен мөмкинлекләрне бирә: семьяның яшәү җирлеге нык, квартирасы яхшы, үзе эшеннән тулысынча канәгать. Дөрес, вакы-ты-вакыты белән аңа шактый авырга туры килә, заводның планы, техникасы үскәннән-үсә, катлауланганнан-катлаулана бара, баш инженерга монда уйларга да, иҗат көчен куярга, хыялланырга да мәйдан зур. Ул бер вакытта да күктән йолдыз чүпләмәде, бөтен ирешкәне тырышлыгы, түземлеге, эш сөючәнлеге аркасында булды. Алдашмады, туры юлдан барды. Аның холкындагы бу үзенчәлекләрне җитәкчеләр дә, эшчеләр коллективы да бик яхшы күрә һәм шуның өчен аны хөрмәт итәләр. Шуларның барысы өстенә ул гаҗәп тыйнак кеше, һаваланмый, аракы эчми иде.

Бу яхшы сыйфатлар аңа баш инженер булгач кына килмәде. Ул эш сөючән тату семьяда үсте. Аның әтисе тимерче иде. Биш улының бишесенә дә югары белем бирәм дип хыялланды. Әмма төпчеге Рушадны гына дипломлы итә алды. Ул да, институтны тәмамлагач ике ел да эшләргә өлгермичә, фронтка китеп барды. Фронтта чакта башта әтисенең, аннары әнисенең дөнья куйганлыгын ишетте. Абыйларының да икесе туган ил өчен башларын салдылар. Рушад үзе бәхетле булды, өч мәртәбә контузия белән генә котылды. Ул бронетанк частьларында хезмәт итте. Япон самурайларын тар-мар иткәч кенә кырык алтынчы ел башында Казанга кайтты һәм тагын заводта эшли башлады. Шәрифә исемле плановик кызга өйләнде. Ун елга якын Рушад заводта цех начальнигы, аннары участок начальнигы булып эшләде. Шуннан аны баш инженерга хәтле күтәрделәр.

Рушад кечкенәдән үк рәсем ясарга ярата иде. Ләкин бу сәләтен үстерергә аның мөмкинлеге дә, вакыты да булмады. Заводның культура

сараенда аның буяу белән ясалган өч-дүрт картинасы эленеп тора иде. Аларны завод тормышын һәм туган шәһәрнең күренешләрен чагылдырганга алганнардыр инде, югыйсә, сәнгать әсәре буларак кыйммәте әллә ни юк иде. Рушад үзе дә аларга шуннан югары бәя бирмәде. Аңа эшләү кадәресе кыйммәт, ул иҗат минутларының ләззәтенә чума, гүя онытылып китә, гүя бик зур, бик мәгънәле эш башкара, арыган булса арыганнары, борчылган булса борчулары сыпырып алгандай юкка чыга. Икенче көнне ул заводка ашкынып бара, бу көнне аңардан да көләчрәк, аңардан да шагыйрәнә кеше булмый заводта, башка чакта җан тирләрен чыгара торган эшләрне бүген гаҗәп җиңел хәл итә. «Бүген Рушад Һилаловичның гашыйк булган көне», дип шаярталар иде Рушадның эштәге иптәшләре. Рушад үзе дә моның нәрсәдән икәнен анык кына белми. Рәсем ясауны ул бер вакытта да житди нәрсәгә санамый иде, ясыйсы килгән, ясаган, менә шул гына. Дөрес, картина ясарга утырса, ул бераз сәерләнә төшә, уйлары да тизрәк йөри, күзләре үткенрәк күрә төсле. Бу инде иҗаттыр, тик чын художникларда ул бермә-бер көчлерәк булырга тиеш. Рушад бит бер вакытта да иҗат ширбәтен тустаганы белән эчми, авыз гына итә. Шуңа күрә ул турыда бүтәннәргә ләм-мим дими, барысын күңелендә калдыра, хәтта Шәрифә белән дә уртаклашмый. Шәрифә болай да аның буяуларын яратып бетерми. Анысы аңлашыла да: Шәрифә театрга, концертка барыйк яки бакчага чыгып утырыйк, Идел буена төшик дисә, Рушад, оялчан гына елмаеп, башлаган картинамны бетерим, бу арада болай да кул тидерергә вакыт булмады, дип каһәр төшкән шул буяуларына тотына. Шуннан соң Шәрифәгә нәрсә кала? Бер атаклы шагыйрь, художник яки композитор булса, түзәр идең, ә болай нәрсә,— үзешчән буяучы. Баш инженерга килешәме? Һич килешми! Житмәсә, Шәрифә шуны иптәшләреннән яшерергә тиеш. Иптәшләре культура сараенда аны ялгыз очратсалар:

— Ә Рушад Һилалович кайда? — дип сорыйлар.

— Баш инженерның башы буш буламыни, нindидер чертежларын карый,— дип жибәрә Шәрифә, тик бик якын дусларына гына: — Шул буяуларын Иделгә чыгарып атмасам, тынычлык күрмәм, ахрысы,— дип, яшерен серләрен ачып сала. Ичмасам, чәчәкләр яки табигать күренешләре, ясаса, стенага элеп куяр идең, юкса, гел цехларны, спецовка дигән эшчеләрне генә ясый. Ни тәм таба торгандыр шулардан, алла белсен. Бер тапкыр сабыр Шәрифәнең дә ачуы чыгып:

— Булмаса, әйдә үзем завод күренешләренең ямьлесен табып бирим,— диде.

Рушад каршы килмәде:

— Әйдә барып карыйк, хатыннарның күзләре үткен күрә дип сөйлиләр,— диде.

Тузынырга житкән Шәрифә ирен завод ишек алдының бер почмагына алып килде. Хәзер бит күп жирдә завод ишек аллары менә дигән бакча. Монда да гаҗәеп декоратив агачлар үсеп утыра, газоннар ясалган, якында гына Идел ялтырап ята...

— Бик теләсәң, әнә ачык тәрәзәдән спецовкалы эшчеләр дә, станоклар да күренә,— дип чәнчеп алды Шәрифә.

Рушад елмайды.

— Кемнәргәдер бу — гаҗәп матур почмак, артыгын эзләргә дә кирәкми,— диде ул, әллә икенче, әллә өченче тапкыр тәрәзәләргә карап. Шәрифә аның ирониясен аңлап житкермәде бугай.

— Шул шул. Әнә кара ул пионнарга, георгиннарга. Җитмәсә, Идел өсте ничек ялтырап ята, күз явын алырлык. Ә синең Иделне бер дә ясаганың юк. Аяк астындагыны күрмиләр, дип юкка әйтмәгәннәр.

— Әйе,— диде Рушад сузып,— мәшһүр художник булса, моннан бәлки берәр нәрсә чыгарыр иде, ә мин нәрсә, үзешчән генә бит..

Ниһаять, Шәрифә иренең көлүен анлады, муенына салган җинел ак шарфын тартып алды да, шуны йомарлый-йомарлый, нәфис борын яфракларын киереп:

— Булдыра алмагач, ни пычагыма киндер буйыйсың соң? — диде.— Әллә баш инженерга шалапай булу килешә дип беләсенме? Барлык акыллы кешеләр артында көләләр. Тора-бара ачыктан-ачык та көлә башларлар...

— Ярый, Шәрифә, көлгәннәр көлә бирсен, авызларын каплап булмый.— дип, Рушад кинәт үзе дә кычкырып көлеп җибәрде.

Шәрифә аңа күзенең агы белән генә карады.

— Болай карама, җаным. Синнән дә, башкалардан да көлмим, үземнән көләм...

— Ярар, кая төрттерүенне сизмиләр димә.

Бу кичне Рушад тырышып-тырышып караса да, Шәрифәнең күңелен ача алмады. Күрәсең, хатыны чынлап торып үпкәләде. Ә Рушадка Шәрифәнең үпкәләве түгел, шулай әз генә мыскыллый төшеп чәпчүләре кирәк, шуннан соң ул заводта да, өйдә дә җан атып эшли ала. Берәр катлаулы агрегатны ходка җибәргәч, хатынын иңбашларыннан кочып:

— Рәхмәт, Шәрифә. Алтынчы цехтагы теге җанҗаллы агрегатны ходка җибәрдек бит. Кулны тотып торган узел проблема булудан тукталды,— ди.

— Минем моңа ни катнашым бар?

— Турыдан-туры катнашың юк та... Кыскасы, тагын бер тапкыр рәхмәт. Син булмасаң, мин әле газапланыр идем.

— Әллә нәрсәләр сөйлисең, Рушад,— ди Шәрифә көлемсерәп. Ул иренә нәрсәдәдер рухи көч бирүен сизә, иренең моны һәрвакыт югары санавын да белә. Шул нәрсә аларның гомер буена сузылган мәхәббәтләрен гүя янартып җибәрә. Алар бер вакытта да бер-берсенә тирән үпкәләмиләр иде. Ә бу юлы...

Юк, хатынының тойгыларын артык тирән санамыйча Рушад ялгышкан, берничә көннән Шәрифәнең йөзенә тагын кояш чыкты. Ул арада заводта тагын ниндидер яңалык белән мавыга башладылар. Гадәт буларак Рушад үзенең буяуларын онытты, башы белән шул яңа эшкә чумды. Билгеле, ул көндәлек эшләрен дә башкара, тик яңалык аның тормышында гүя төп нәрсә, бөтен авырлыкларны хәл итә. Ул төшендә дә шуны күрә башлый. Заводта Рушадның янып, дәртләнеп, мавыгып эшләве турында күп сөйлиләр. Шәрифәнең исә андый нәрсәләргә колагы үрә тора, ул эченнән аның белән горурлана.

Шәрифә ире белән бер заводта эшләгәнгә андагы хәлләрне көн саен белеп тора. Заводта эшләнгән һәр яңалык ахыр килеп хезмәт житештерүчәнлеген арттыра. Монысы инде плановик Шәрифәгә аеруча таныш. Хәтсез күп саннар арасыннан меңнәрчә эшчеләрне, мастерларны, инженерларны гына түгел, иренең хезмәтен дә күрә ул.

— Менә ул чын иҗади хезмәт, киндер буяу түгел инде,— дип үз алдына елмая Шәрифә.

Еш кына аңа цехларга чыгып керергә туры килә. Соңгы елларда заводта хезмәт эстетикасына зур игътибар бирәләр, ишек алларын гына түгел, цехларны да һаман бизиләр, озын-озын пролетлардан нәкъ бакча уртасыннан барган кебек барасың. Җитмәсә, музыка да кертәбез, диләр. Рушад бу турыда аеруча кайгырта, диләр. Бу кадәресенә Шәрифә һич ачуланмый. Баш инженер техник проблемалар турында гына түгел, эшчеләрнең хезмәт шартлары турында да уйларга тиеш. Планны ахыр килеп эшчеләр үти. Заводта баш художник та бар. Бик яхшы, ләкин ул баш инженер түгел, аның эшенә тыгылмый да.

Шәрифә иренең эш кабинетына тиктомалга кереп йөрергә яратмый. Үзе дә эш кешесе булганлыктан, бик үзенчәлекле итеп бизәлгән — монда

яктылык һәм пакьлек аеруча мул иде — бу иркен кабинетта житди сөйләшүләр, мөһим киңәшмәләр барганын белә. Кечерәгрәк икенче бүлмәдә утыручы секретарь хатын эшсез кешеләрне кертми дә. Рушад килгәнче завод территориясендә дә, цехларда, бүлекләрдә дә эш вакытында эшсез йөрүчеләр — тырай тибүчеләр бик күп иде. Рушад моңа каршы чын-чынлап көрәш башлады. Иң элек үз кабинетында тәртип куйды. Хәзер инде завод ишек алдында да, цехларда да, бүлекләрдә дә бушка вакыт уздыручыларны күрмәссең. Һәр минут — эшкә бирелгән. Әгәр башка завод-фабрикаларда да шуңа ирешә алсак, хезмәт житештерүчәнлеге никадәр артыр иде. Шәрифә бер тапкыр, Рушад соравы буенча, исәпләп тә караган иде. Саннарның чамасыз зур чыгуыннан үзе дә куркып:

— Рушад, бу бит әллә нәрсә,— диде.

— Әйе, әллә нәрсә шул. Без хуҗалык итәргә өйрәнмәгәнбез, шуңа күрә көн саен миллионлап-миллионлап халык акчасын җилгә очырабыз. Мондый ачык авызлыкка чик куярга вакыт! — диде Рушад, житди итеп.

Шәрифә иренең күз карашыннан курыкты. Чыннан да, бу караштә куркырлык нәрсә бар иде шул. Шәрифә эше төшсә дә, ире янына кермәс булды. Күрәсең, Рушад моны принцип итеп куйган, ә принцибыннан ул бер вакытта да чигенми иде.

Шулай да бер тапкыр аларны баш инженер кабинетына җыйдылар. Ә кич белән, өйгә кайткач, Шәрифә көлемсери төшеп ирен:

— Бер елга якын кабинетында булганым юк иде, яңаргансыз, мин ялгыш кермәдемме дип торам,— диде.

Бу вакытта өйдә Шәрифәнең кунакка килгән дуслары бар иде. Семьяда чит кешеләр алдында завод турында бер нәрсә дә сөйләмәү гадәт булып урнашканга, Шәрифәнең бу турыда сүз ачуы Рушадка ошамады. Ул сүзне йомып калдырды, бары кунаклар киткәч кенә:

— Шәрифә, мин сине аңламый башладым. Нигә башкалар алдында завод турында сүз ачасың? — диде.

— Гафу ит, Рушад, завод турында өйдә сөйләргә минем башыма тай типмәгән. Мин кабинетың турында гына...

— Ә ул завод түгелмени?

— Ярый, бетте. Ул вакытта бер дә керешсез генә әйтергә рөхсәт ит: бу шимбәдә заводның ял йортына барыйк. Анда бик күңелле, диләр. Катерда да йөрербез. Идел буенда яшәп көймәдә йөрмәү — җинаять.

— Шулай, шулай, бир кирәген баш инженерның,— диде Рушад, ачы елмаеп.

Шәрифә аның елмаюының мәгънәсен аңлады. Рушад тагын рәсем ясарга җай эзли иде.

— Буяуларың әллә кая китмәс әле. Яңгырлар башлангач, Иделгә чыгасың килсә дә чыга алмассың.

Авырыр алдыннан заводта ел бик мәшәкатьле килде. Заводның иске өлешен реконструкцияли башладылар. Рушад көн-төн диярлек цехлардан чыкмады, хәтта ял көннәрендә дә шул эш белән утырды. Бу кадәресенә Шәрифә, билгеле, ачулана алмады, чөнки завод эшен күрә, мөһим икәнлеген аңлый. Цехлардагы эшне туктатмыйча реконструкция алып бару бер баш инженерга гына кагылмый, аның белән бөтен коллектив яна, бөтен житәкчелек шул турыда уйлый, кайгырта. Шундый чакта баш инженер адресына җылы сүзләр әйтәләр икән, Шәрифә сөенмәс җирдән сөенә. Ләкин Рушадның коңгырт чәчләрендә көмеш бөртекләр торган саен күбрәк күренә башлады. Бу инде хатынны борчымый калмый. Ул ирен вәсвәсәгә салмас өчен эчтән тынып йөрде-йөрде дә, тавышына юри көрлек һәм гамьсезлек биреп:

— Рушад, быел әллә нишләдең син. Картаюны белмим дип мактанып йөрдең-йөрдең дә бер ел эчендә онга төшкән таракан булдың,— диде.

— Менә яхшы булды,— дип көлемсерәде Рушад.— Югыйсә, солидный түгелсен дип гел тенкәгә тия иден.

Рушад хатынының эчке борчуларын ачык сизде, шуна күрә мәсьәләне уенга борды.

— Әйтерсең инде,— диде Шәрифә, нечкә кашларын җыерып.— Сина яхшылап ял итәргә кирәк. Реконструкциягез бетәме инде?

— Реконструкция бетәр дә...

— Тагын нәрсә?

— Бер эксперимент уйлап торабыз.

— Озаклыкмы?

— Башламас борын каян беләсең?..

Бу инде эшнең житдилеген күрсәтә иде. Билгесез тонда сөйләшүне Рушад үзе дә яратмый. Әгәр ул ихтыярсыз үзе шул тонда сөйләшә икән, димәк, күп нәрсә аның үзенә дә ачык түгел әле.

— Алайса, ял ал! — диде Шәрифә, катгый итеп.— Кайткач, яна көч белән эшкә тотынырсың. Сентябрь бетеп бара бит инде. Күп уйларга вакыт калмаган.

— Гаграда яки Яна Афонда ноябрь-декабрьда да ял итеп була, диләр.

— Тәрәзәдән дингезгә карапмы? Рәхмәт. Синең аркада мин дә җәйнең яхшы вакытында ял ала алмадым.

— Анысы чыннан да җайсызрак килеп чыккан. Ярый, беренче октябрьдан сина путевка табарбыз.

— Бер үземәме? Рәхмәт. Синнән башка бер кая да бармыйм. Мин барында да син вакытында ашка утыра алмыйсың.

— Эш бит, Шәрифә.

— Эш, эш! Партия вакытында эшләргә, вакытында ял итәргә өйрәтә, ә без һаман искечә сәгатьләрне сузабыз. Әйтерсең аңа карап тәүлек озая. Кайчан искедән арынырбыз икән?

— Син хаклы, Шәрифә, артыгы белән, бәхәсләшмим. Күрәсең, яңалыкны әйтүе, мактавы ансат, эштә ул жинел генә кулга бирелми. Быел ял әллә ничек булды шул, киләсе елга нәкъ июльдә Иделдә ял итәрбез. Нәкъ бер айга ашарга алабыз да шәһәргә борылып та карамабыз. Табигать кочагында табигать балалары булып, ә? Хәтта мольбертымны да алмам!

Аларның үз катерлары бар иде. Ятып ял итәргә дә, кояшта кызынырга да, домино сугарга да, радио тыңларга да була. Элеккерәк елларда алар бөтен семьялары белән — өч малайлары, ике кызлары һәм Шәрифәнең карчык әнисе — шул катерда Иделне айкыйлар иде. Кайчак Әстерханга кадәр барып житәләр, кайчак Идел буйлап югары менеп китәләр иде. Карчык дөнья куйгач, малайлар практикага йөри башлагач, бу сәяхәтләр сирәгәйде, ә быел заводның ял йорты тирәсендә берике йөрделәрме икән?

— Киләсе елда асыл кошны аягыннан тотабыз дип юатмакчы буласыңмы? Рәхмәт, мин андый беркатлы бәндә түгел. Хатын буларак та, балалар анасы буларак та мин сине ялга алып китәм. Шул. Иртәгә үк директор янына керәм. Үзе ял итте ич, сине дә җибәрергә тиеш. Болай сөйләсәң, ирләр яхшылыкны белмиләр!

— Ай-һай, каты тотасың, Шәрифә. Яшьрәк чакта мондый түгел иден шикелле. Директор да, завком да, хәтта партком да берни эшләтә алмый. Бер атнадан барыбер чакыртып алачаклар.

— Көлмә, Рушад. Бу көлке түгел. Без бүгенге көн белән генә яшәмибез. Иртәгәге көн өчен дә таза-саулык кирәк.

Шәрифә нык характерлы, үз дигәнен буллыра торган хатын иде. Әмма Рушад ничек итсә иткәндер, Шәрифә бу юлы да ялга бер үзе китәргә мәҗбүр булды.

Ул ялдан кайтканда Рушад тагы да ябыга төшкән иде. Хатынының күңелен күтәрергә теләп шат күңелле булып күренергә тырышса да, Шәрифәне алдау кыен иде. Икенче көнне үк заводта реконструкциянең инде бетеп килүен, экспериментның да шәйләнә башлавын күреп тагын да тәвәккәлрәк итеп Рушадны ялга җибәрүләрен таләп итә башлады.

— Бөтенләй егыла язган бит,— диде ул директорга.— Кешеләрне аяктан екканчы эшләтү безнең принципларга каршы килә ич.

Аның белән бәхәсләшмәделәр. Директор бер атнадан Рушадны ялга чыгарырга сүз бирде, Мәскәү янындагы санаторийга путевка да булыр диде. Директордан чыккач, Шәрифә беркадәр тынычланды. Әмма бер атнадан путевка булмады, тагын бер атнадан һичшиксез була диделәр. Шәрифә, ачуланып, директорга шалтыратырга торганда директор үзе шалтыратты, минем яныма кереп чык әле, диде.

— Шулай даулашмасаң, алар бер вакытта да кеше турында чынлап кайгыртмыйлар,— дип уйлады Шәрифә.— Мөгаен, путевка килгәндер, шуны минем кулыма тоттырып, директор үз гаебен капламакчы була торгандыр.

Директор Шәрифәне кабинетында аяк өсте басып каршы алды. Аның йөзе ап-ак иде. Шәрифә бер секунд эчендә тәмам үзгәреп, бер адым артка чигенде.

— Рушад Һилалович...— диде директор.— Сез, зинһар... утырыгыз. Әле яңа гына аны ашыгыч ярдәм машинасы белән больницага алып киттеләр.

Рушад эксперимент эшләренең барышы турында киңәшмә үткәргән. Утырыш бетеп, кабинетында бер үзе генә калгач, кинәт аңын югалткан...

Шәрифә инде боларны тыңлый алмады. Директорның машинасы ишек төбендә көтеп тора иде. Директор белән Шәрифә чыгып утыргач, туп-туры больницага китте. Шәрифә күзләрен йомды. Аның күз алды караңгыланган иде.

### 3

Көтмәгәндә-уйламаганда килгән бу авыруның бөтен фаҗигасен Рушад үзе дә, Шәрифә дә, заводта да берьюлы ахыргача аңламадылар. Врачлар белсәләр дә, берни әйтмәделәр, бары тик юаттылар гына, була торган хәл, диделәр. Хәзер аңа тынычлык кирәк, завод эшләре белән дә, семья мәсьәләләре белән дә борчымагыз, барысы да яхшы, тизрәк терел, сине көтәләр дип әйтегез, диделәр.

Врачлар боларны күбрәк Шәрифәгә карап әйтәләр иде, чөнки башкаларны авыру янына кертмиләр дә диярлек. Шәрифәнең медицина эшләрендә әллә ни белеме юк, башка кайбер хатыннар кебек белмәгәнен дә беләм дип кыланмый, врачларны әрләми, әмма хатын-кыз йөрәге башта ук аны алдамады. Рушадның уң кулы һәм аягы бөтенләй диярлек эшләми, сөйләшүе дә баштарак бик авыр иде, сүзен һич аера алмадылар, соңга таба теле рәтләнде, гомуми сәламәтлегендә исә һич үзгәреш күренмәде.

— Анысына бик борчылмагыз, бу авыру бик әкрен кайта,— диделәр врачлар. Шәрифә аларның әйткән киңәшләрен тыңласа да, кушканнарын җиренә җиткереп үтәп барса да, эчтән ут йотып йөрде. Рушад аның кичерешләрен күрде, сөмсерләрең коелмасын, Шәрифә, ике-өч айдан терелләм, диде. Әйе, әйе, тереләсең, җаным, тик, зинһар, күп сөйләмә, сиңа ярамый әле, дип юрганын рәтләде, вакытында даруларын бирде. Ләкин ике ай да, өч ай да, алты ай да үтеп китте, сәламәтләнү күренмәде. Дөрес, Рушад хәзер торып утыра ала иде инде, аннары уң аягын сөйри-сөйри палатада йөри башлады, физкультураны иренми ясады, һәркөн массажистканы көтте. Ниһаять, өйгә кайткач та физкультура белән массажны туктатмады. Көннәр яхшыргач, Шәрифәгә ияреп, Шәрифә эштә булса, балаларның берәрсенә тотынып бакчага чыкка-

лады. Иң кыены баскычлардан менү иде. Өченче катта гына торсалар да, сездерә икән. Рушад тәмам тиргә бата. Ләкин ул сер бирми. Хәер, балалар монда артык игътибар да итмиләр. Шәрифә исә аны басма саен туктата, ашыкма, безне бер нәрсә дә кумый, ди иде. Ул бик нык үзгәрде, холкы да алмашынды кебек. Элек аның телгә шуклыгы бар иде, вакыт-вакыт арттырып та җибәргәли иде. Рушадның холкы сабыр булганга семьяларында бер генә тапкыр да җәнҗал чыкканы булмады. Хәзер, озак авыру аркасында, Рушадның сабырлыгы какшый төшкән иде, аның каравы, Шәрифәнең холкында яңа сыйфатлар артты. Тату семьяда мондый хәлләр еш була, алар үзләре дә сизмәстән семья матурлыгын, кыенлыклар алдында таралып төшмәүләрен тагын бер кат раслыйлар иде.

Бакчада, кеше арасында, Рушад үзен ярыйсы яхшы хис итә иде. Заводтагы иптәшләре дә гел килеп йөрделәр. Иң шатландырганы шул — заводтагы реконструкция уңышлы тәмамланган, экспериментның да нәтиҗәсе бик яхшы. Рушад Шәрифәнең сүзләренә генә ышанып бетми иде, инде заводтагы иптәшләр дә раслагач, бертөрле дә шик калмады. Баш инженер вазифасын Рушадның ярдәмчесе үтәп бара иде. Үзе яшь булса да, шактый тәҗрибәле, кыю да.

— Кара, туган, традицияне үзгәртмә, бер чыгырыннан чыкса, соңыннан рәткә кертүе кыен була,— диде Рушад.

— Тырышабыз, Рушад Һилалович. Тик сез тизрәк кайтсагыз иде, юкса, минә авырга килә.

— Озак ятмаска тырышам да...

Пенсия турында Рушад ишетергә дә теләмәде. Әмма бюллетеньны мәгълүм вакытка кадәр генә түлиләр икән. Срогы үткәч, Рушад врачлардан эшкә чыгарга рөхсәт итүләрен үтенде. Комиссия кискен рәвештә каршы килде, әгәр сәламәтләнәсегез килсә, сезгә кимендә бер-ике ел ял кирәк, диделәр. Озак тартышып та мәсьәлә уңай якка хәл ителмәгәч, теләмәсә дә, вакытлыча пенсиягә чыгарга туры килде. Ләкин эш шуның белән генә дә бетмәде. Рушадны әйтерсең алмаштырып куйдылар. Ул үз эченә бикләнде, азрак сөйләшә торган булды, массажын да, физкультурасын да туктатты. Димәк, аның элекке сәламәтлеге инде һичкайчан кайтмас, ул баш инженер булып кына түгел, гади инженер булып та эшли алмас. Аның техник акылы да шактый зәгыйфьләнгән иде. Туктаусыз техник прогресс барган заводта мондый кешенең ни кирәге бар? Буш урын биләп торыргамы? Монда юл да куймаслар, Рушад үзе дә риза булмаячак.

Иренең кәефе начарланганнан-начарлана баруын күреп килгән Шәрифә, үз борчылуларын тирән яшерен:

— Рушад, физкультураңны нигә ташладың? Бөтенләй яхшыра башлаган идең бит. Врачың да гел алга барасың дип сөйли иде,— диде.

— Башкасын әйтерлеге калмагач... Мин инде бөтенләй терелә яздым. Тагын бераз булса...— дип, Рушад иреннәрен кыйшайтып алды.

Шәрифә дә үзен артык тыя алмады, ахрысы, сыгылып төшеп елый башлады. Теләсә ни булса да күз яшьләрен иренә күрсәтмәскә, аның җанын яраламаска кирәклеген акылы белән белсә дә, бу минутта Шәрифә үзен тыюдан көчсез иде. Рушад аның бөтен газапларын аңлады һәм үзенең шуңа сәбәп булуын бөтен ачыклыгы белән төшенде. Аның кашлары җыерылды, йөзе үзгәрде.

— Син мине гафу ит, Шәрифә,— диде ул бераздан.— Мин җебеп төштем, моннан соң андый әшәкелеккә юл куймам. Шимбә көн дачага чыгабыз. Син борчылма, Идел буенда мин тиз савыгырмын. Шулай бит?

Шәрифә елавыннан туктады.

— Мине дә гафу ит,— диде ул.

Алар завод ял йортында бүлмәләр алып торалар иде. Берничә көн эчендә Шәрифә үзләренә дача салу мәсьәләсен дә хәл итте. Ул Рушад-

нын завод ял йортына бик үк теләп чыкмавын белә, анда шау-шу, авыру кешегә бик үк җайлы да түгел. Быел ярый, ничек булса да җайне үткәрерләр, ә киләсе елга үз дачалары булыр. Урынның бик яхшысын бирделәр, завод ял йортыннан әллә ни ерак та түгел, тын, күршеләр биш-алты гына йорт, үзе Идел ярында, урман да күршедә генә. Иң мөһиме шул — Шәрифә, дача салу артыннан йөри-йөри, гүя яшәреп китте. Ләкин көтмәгәндә бер күңелсезлек килеп чыкты. Баш инженер урынына яңа кеше билгеләделәр. Бу бик табигый булса да, Рушадка моны ничек итеп әйтергә? Әйтми дә ярамый, ана барыбер ишеттерәчәкләр. Кешедән ишетсә... «Юк, башкалардан ишеткәнче үзем әйтим», дип бер көнне Шәрифә сүз җаен китереп иренә шул турыда җиткерде.

Рушад көлемсерәп куйды.

— Гомер иткәнбез, ә бер-беребезнең холык-фигылен белеп бетермәгәнбез. Бу кадәр сак кыланып мине әзерләмәсәң дә ярар иде. Мин инде моны күптән беләм. Ниһаять, яңа кеше билгеләп дөрес иткәннәр. Завод хәтле заводны баш инженерсыз тотып булмый. Анда атна саен түгел, көн саен, сәгать саен җитди мәсьәләләр килеп чыга.

— Син... — Шәрифә иренә туры карады,— моңа рәнҗемисеңме?

— Рәнҗер идем дә, Шәрифә, аннан бер нәрсә дә үзгәрми. Тормыш дәвам итә, берәүләр китә, икенчеләр килә. Кичә дә шулай булган, бүген дә шулай, иртәгә дә шулай булачак.

— Бу — фәлсәфә. Шулай да син, Рушад, һич борчылма, торырбыз әле. Киләсе елга улыбыз институтны тәмамлый, аннары кызыбыз. Үзебезнеке үзебезгә җитәр.

— Әлбәттә,— диде Рушад.— Дөрес, яшьләр үз ояларын кора башларлар, безгә алардан ярдәм көткәнче, үзебезгә ярдәм итәргә туры килмәгәе. Ләкин тормышның тагын да зуррак мәсьәләсе бар...

Рушадның күзләре карасуланып китте. Кеше көн үткәрү турында гына уйласа, аңа бүтән бер нәрсә дә кирәкмәс иде. Әнә пенсия бирделәр ич, җитмәсә — персональ пенсия. Дөрес, ике елга гына дигәннәр. Ике елда бәлки терелер, терелмәсә тагын бирерләр.

— Нинди мәсьәлә, Рушад?

Ул чакта Рушад ачык кына әйтмәде. Атналар, айлар үтте, алар яңадан шәһәргә кайттылар. Озакламый кар-бураннар котыра башлады. Синең эчке дөньяң ничек — табигать аның белән санашмый, таң ата да кич була. Бер вакыт кояш җылытып җибәрә. Күбрәк өйдә утырырга мәҗбүр булган Рушад Иделне сагына, анда барып җитә алса, бөтенләй терелер иде төсле. Быел үз дачалары өлгерде, теләсәң кайчан чык. Шәһәр өе, ни әйтсәң дә, кысан, теләгәнеңне эшли алмыйсың. Анда, дачада, күбрәк үз иркеңдә буласың, балалар укулары бетмичә анда бара алмаслар, Шәрифә дә көн саен йөри алмас. Дөрес, Рушадны бер үзен калдырмыйлар да, төрле чаклар була бит.

Кояш көләчрәк карый башлагач, Рушадка җиңелрәк булып китте. Югыйсә, кышкы көннәрдә аңа чамасыз авыр була иде. Шәрифә вакытында эштән, балалар укудан кайтмасалар, ул борчыла-борчыла шашар хәлгә җитә иде. Хәтта өйдә тавыш чыгарган чаклары да булды. Гомер башка керми торган уйлар газаплады. Кеше — җаны бар икән — уйлый, рәтле үе булмаса да уйсыз тора алмый. Шуннан төрле чүп-чар башка керә. Мәгънәле эшең булса, юк-бар белән чуалыр идеңме? Көн үткәне дә сизелмәс иде.

Бер көнне ул ничектер онытылып беткән буяуларын күрде. Аларны тузан баскан, кипкәннәр. Пумаласын кулына алды, буяп карады. Кулы аңа буйсынмады. Хәтта пумала сабын да сизмәде. Шуннан Рушад ачынып куйды, күзләренә яшь килде.

Икенче көнне өйдә бер үзе генә калгач, буяуларын тагын тартып чыгарды. Рамга тарткан киндерен мольбертына куйды һәм бик озак

шуна карап торды, үзе аңсыз рәвештә бармакларын кыймылдатты. Тәрәзәдән биек наратлар күренә. Әнә нинди матурлар. Шуларны ясасаң! Ләкин кул пумаланы да, карандашны да рәтләп тота алмый, камыр кебек лып итеп өстәлгә төшә...

Дачага чыкканчы да, дачага чыккач та Рушад, үзсүзләнеп, үз кулын күнектереп карады, врач белән дә киңәште. Үң кулы ныгымады, хәтта аз гына алга китеш тә сизелмәде. Күрәсең, бөтенләйгә булмаса да, бик озакка ибе югалган. Рушад ана әрнеп карап торды. Аның ачуы килде, мөмкин булса ул кулын суырып алып, күз күрмәгән җиргә ташлар иде. Икенче секундта ул фараз иткән картинасын элеккедән дә ачыграк күрә, бөтен төсләре, нечкәлекләренә кадәр күз алдына китерә, тик пумаласы гына кулында юк. Рушадның йөрәге сызланып куя, ул күзләрен йома, тешләрен кыса. Авыр аңа, бик авыр.

— Рушад, нигә болай башыңны идең? Әле бүген генә сине заводта сагынып телгә алдылар, ял көнне хәлеңне килеп белергә булдылар,— диде Шәрифә, Рушадның сыгылып утырганын күреп. Башка чакта заводны телгә алсалар, Рушад беркадәр җанланып китә иде, бүген чыраен гына сытты.

— Кирәге бар кулсыз-аяксыз кеше аларга...

Соңгы вакытта заводта Рушадны бераз оныта башлаганнар иде. Нишлисең, тормышның үз катгый законнары бар. Анда тормыш кайнап тора, кешеләр эш-тормыш хакында туктаусыз кайгырталар, бәхәсләшәләр, кирәк икән ачуланышалар да. Авыру кеше белән вакыт уздырырга аларның вакытлары да юк. «Сагынып телгә алдылар», дип Шәрифә бераз хәйләләп кенә әйтте. Әллә шул алдашуны Рушад сиздеме? Авыру кешенең сизгерлеге бик көчәя диләр. Ничек соң Шәрифә бу кадәресен абайламаган?

— Син аларга үпкәләмә, Рушад. Эштән башлары әйләнгәндер.

— Эш кешеләренә һич үпкәләмим, шулай ук үземә игътибар сорап вакытларын алырга да теләмим,— диде Рушад бераздан.— Завод эше шау-шулы эш, ул тын бүлмәләргә сыя алмый. Көн саен эчендә кайнамасаң, ул сине кызыктырмый да.

Рушадның тавышында моңарчы булмаган өметсезлек һәм салкынлык бар иде. Гүя рәхимсез кар яуган да аның барлык яшел үрентеләрен өшетеп киткән.

Шәрифә иренә еррактан карап алды:

— Күптән заводка барганың юк, менә оныта да башлагансың. Шулай шул, һәркем иң элек үзе турында уйлый,— диде.

— Дөрес түгел, һәрхәлдә, миңа карата дөрес түгел. Син дә, Шәрифә, моны уйламый әйтәсең.— Хатынының сүзсез үзенә карап торуын күреп, Рушад тагын кыза төште: — Әйе, уйламый әйтәсең, бәлки башка сүз таба алмаганга шушы таш белән минем башыма орып мингерәүләтә торгансыңдыр.

— Гафу ит, Рушад, мин, бәлки, чыннан да уйламый сөйли торганмындыр, хатын-кыз шундый инде.

Шәрифә бар гаепне үз өстенә алырга тырышса да, аның гаебе ул кадәр бар идеме соң? Авырганчы булса, ул чынлап торып бәхәсләшер, үз сүзендә нык торыр, болай гына килешмәс иде. Ә хәзер барысын үз өстенә алып, бәхәсне тизрәк йомарга тырыша. Димәк, ул Рушадка авыру кеше, ә икенче төрле әйтсәң, бала сымак итеп карый. Ә бала белән кем чынлап сөйләшә? Менә нинди хәлләргә калды бит баш инженер!

Рушад берничә көн караңгы чырай белән йөрде. Күңегүләрен тагын ташлады. Эш юктан, ичмасам, тизрәк вакыт үтсен дип, кулына китап алды. Баштарак уку кыен булды, бик тиз күзләре талды. Күрәсең, озак укымагангадыр, элек ул бик җиңел укый торган иде. Әллә күзләре дә начарланганмы?

Юк, Рушадның бу борчылулары бушка булган. Ул әкренләп көнегеп китте һәм рәхәтләнеп укый башлады. Рушад һаман да күзлексез укый иде. Димәк, күзләренең егәре бетмәгән. Монысы яхшы, бик яхшы!

Өйдә аларның бай гына китапханәләре бар. Соңгы вакытларда аннан Шәрифә һәм балалар гына теләгәнчә файдаланалар иде. Рушад күбрәк техник әдәбият белән кызыксына иде. Хәзер матур әдәбиятка чумды һәм көннән-көн аның эченә тирәнрәк керә барды. Аннары, яңа дөнья ачкандай, китап булмаса, акылдан язар идем, дип куйды.

Бер китабы беткәч, Шәрифәдән икенче, өченче китапны китертте. Хәзер ул бик талымламый да, китергән бер китапны йота бирә. Күңеле дә шактый ачылып китте, күз аллары яктырды. Идел ярында, карт нарат төбендә, китап укулары аңа рәхәт иде.

Бер көнне Шәрифә аңа Репин томын алып кайтты. Бу китапны күргәч, рәсем белән мавыгулары исенә төшеп, Рушадның йөрәге өзелеп киткәндәй булды. Ул, ичмасам, рәсем дә ясый алмый! Аңа әллә нинди рәсемнәр кирәкми, өйрәнчек рәсемнәр генә булса да ярар иде. Ул бит мәшһүр художник булырга җыенмый.

Һәр китапның кешенең кәефенә карап үзгәрә торган бер хасияте бар икән. Рушадның Репинны элек тә укыганы бар иде. Ә рәсемнәренең репродукцияләрен кат-кат карады. Мәскәүдә Третьяков галереясендә оригиналларын да сокланып күздән кичерде. Бер тапкыр Ленинградта Пенатида булу бәхетенә иреште. Кем белә, ихтимал, бөек Репин тәэсирендә ул, юк вакытын бар итеп, картиналар язгандыр. Хәзер китапны кабат укырга керешсә дә, аңардан әллә ни яңалык көтмәде. Алай гына түгел, бу юлы ул беркадәр сүрелебрәк укыды. Ләкин аяк астында алтын ятмас димә! Бөек художник, уң кулы Рушадныкы кебек эшләми башлагач, озак көнектергәннән соң сул кулы белән рәсем ясарга керешкән! Элекке картиналарыннан бер дә ким ясамаган. Рушад каршында бу гаҗәеп бер ачыш иде. Кара инде, нәрсә бу, элек моңа игътибар итмәгәнме, әллә бу битләрен йөгереп үткәнме? Булса була икән шундый хәлләр. Рушад төне буе йокламады, ә иртән карандашны сул кулына алды.

## 4

Бу бәхетле бер табылдык яки шаккатыргыч могҗиза булмады. Вакыт-вакыт Рушад шул кадәр интекте, ул юкны эзли, ак белән караны аермый булып тоела башлады аңа. Юк, ул уң кулы белән уң аягын гына түгел, газиз башын да югалткан, ул шыр тиле, шуңа күрә аяк астындагы комны да алтын бөртеге итеп күрә.

Халыкта бер-бер мәгънәсез эш эшләсәң, куй, тавыклар көләр, дигән әйтем бар. Нәкъ Рушад турында мең ел алдан әйтеп куйган кебек. Ни хәл итәсең, Рушадның кабат күңеле төшкән, җан ачысы белән уфтанган чаклары да, күтәрелеп бәрелергә җиткән минутлары да булды. Бәхетенә каршы, аның холкында яхшы бер сыйфат бар иде: ул күргән бер кешесенә уңышсызлыкларыннан зарланмады, кан-яшь түгеп еламады да, шулай ук мин алай итәм, мин болай итәм дип алдан мактанмады да, бөтен яну-көюләре, никадәр авыр булмасын, эчендә калды. Шуңа күрә читтән караган кешеләр Шәрифәгә: синең Рушадың бик һәйбәт холыклы кеше икән, китап укый да Иделгә карый, гүя дөньясы түгәрәк, дип сөйләнделәр. Шәрифә дә, чын кичерешләрен яшереп, әйе, әйе, Рушад алай төшенкелеккә бирелми, дип чит кешеләрнең сүзен расла-ды. Тик бер үзе булганда гына:

— Рушад, нигә шул хәтле Иделгә карыйсың? Әллә кайгыңны суларга агызасың киләме? — дип сорый иде.

Моңа каршы Рушад оялчан гына елмая, я үзенең Идел өстендә ниләр күрүен сөйли. Рушадның елмаюларында, бигрәк тә сөйләшүендә

күңел төшенкелеге бик сизелми. Кайчак тəненнəн ычкынгалый торган моң-зарлары аның бəгыреннəн чыкмыймы икəн, əгəр шулай булса, ялгыз уйланган чакларында, я ихтыярсыз елмайганда бер чагылмаса да бер чагылыр, ул аларны бик тирəн яшерə алмас иде.

Шəрифə Рушадның кеше юк вакытта гына тырышып-тырышып күнегүлəр ясавын, əлбəттə, белə иде. Ул иренең буяуларына сəламəт чагында да житди бер нəрсə игеп карамады, хəзер дə алардан берни көтми иде. Лəкин Рушадка юаныч өчен ярый икəн, бик яхшы, Шəрифə элеккечə чəпчемəс. Иренең рухын ныгыту — аның бурычы. Əле шушы аралар-да гына бер күренекле галимнең нəкъ Рушадныкы төсле авырудан үлеп киткəнен ишеткəч, бу уе тагын да ныгый төште. Бүген эштəн кайтуга иренə:

— Рушад, мин заводта сөйлəшеп кайттым, əгəр телəсəгез, Иделдə сəяхəт итəргə путевкалар бирəбез, диделəр. Минемчə, урын алмаштыру сиңа килешер, югыйсə, иртə-кич һаман бер күренеш, туйдыра торгандыр,— диде.

— Кайгыртуың өчен рəхмəт, Шəрифə,— диде Рушад бу хəбəргə бер дə шатланмыйча.— Идел суы моннан да бик яхшы күренə, хəтта яр буена төшеп битем-башымны да юам. Пароход палубасыннан карасаң да шул ук Идел өсте, ə шəһəрлəрендə туйганчы йөри алмам. Анысыннан да бигрəк — син минем янымда утырырга мəжбүр булачаксың. Болай да ябыгып беттең инде син. Бу дача да синең күп җилегеңне суырды. Аннары завод эше дə, балалар мəшəкате дə бар. Юк, Шəрифə, каршы килмə, сиңа быел чын-чыннан ял кирəк. Хəзер син семьябызның бердəнбер терəге.

— Юк, минем синең белəн генə буласым килə, Рушад. Синең кəефең яхшы булса, миңа артык берни дə кирəкми. Синнəн башка минем күземə магнолиялəр дə, кипарислар да, диңгез дə күренмəс.

Шəрифə рияланмый иде. Рушад моны яхшы белə, шуңа күрə аның тəкъдименə кире какканда да ул үтə сак кыланды. Быел Идел буенда үземне яхшы хис итəм, бер кая кузгаласым килми, диде. Докторлар да вакытлы-вакытсыз урын алмаштырырга кушмый. Əстерхан якларында бик эссе була, башка кабуы да бар. Килəсе елга күз күрер анда, диде.

Билгеле, бер-ике сөйлəшү белəн генə бу мəсьəлə хəл ителмəде. Лəкин ничек итсə итте, Шəрифə ялга тагын бер үзе китəргə мəжбүр булды. Вокзалга төшəр алдыннан Рушадның күзлəренə туры карап:

— Балалар гел синең яныңда булырлар, азык завод кибетендə дə бар, мин сөйлəштем, кызларны да таныштырдым. Син күп эшлəмə, түтəллəргə балалар су сибəр, онытмасыннар өчен ислəренə генə төшереп тор. Күнегүлəреңне дə чама белəн генə ясa,— диде.

— Ярый, ярый, барысын да нəкъ син кушканча эшлəрбез, бер дə борчылма. Менə Ай-Петридан кояш чыкканын карарга тырыш. Бик матур була, дилəр. Хəтерлисеңме: Фатих Хөсниие ничек сокланып укыган идек?

Шəрифə киткəч, Рушад тагын үзенең күнегүлəрен дəвам иттерде. Хəзер аңа комачаулаучы бөтенлəй юк иде. Балалар беренче көннəрдə генə əтилəренə күп эшлəмə дип əйткəлəделəр, аннары Идел буеннан да кайтмый башладылар, кайчак ашны да Рушад үзе җылытты, чəйне дə үзе кайнатты.

Сул кулы Рушадка бераз буйсына башлады. Өмет йолдызы якынрак килеп җемелдəргə тотынды. Ə кара төндə җемелдəгəн утка каршы бару күп мəртəбə җиңел икəн. Кайчак, эшлəп аргач, Рушад ике кулын да өстəлгə куеп, аларга озак кына карап тора. Тыштан караганда куллары һичбер аерма юк: авыру кулы ябыкмаган да, шешмəгəн дə, тик карандаш яки пумала тотарлык ибе юк. Ул кашык тотарга гына ярый, анда да кайчак шулпасы чайпалып китə. Элегрəк Рушад ашны да сул кулы белəн ашый иде, хəзер ял итə-итə булса да, уң кулы белəн

тотып азаплана. Шулай да сул кулы аңа кадерлерәк булып китте. Ул гүя хыялының, теләкләренең дәвамы, ул акыл кушканны каршылыксыз башкара. Бүген карандашны яки пумаланы күнел теләгәнчә үк йөртә алмый икән, анысы яшьтән күнекмәгәнгә генә шулай. Вакыт үткәч, җиңеллек үзеннән-үзе килер. Һәм ул күнегүләрен тагын да арттырды. Рушадның кәефе күзгә күренеп яхшырды.

Хәзергә ул күбрәк карандаш белән генә эшли, буяуларына сирәк кагыла. Мондый чакта пумала алмыйча да түзүе авыр. Ахыр килеп, барлык күнегүләре дә шул пумала тотар өчен бит. Картиналарының эчтәлеге хәзергә кызыксындырмый аны. Вакыты килер, эчтәлек беренче планга күчәр, бүген күнегү, күнегү мөһим. Күз алдындагы бер үк күренешне ул биш-алты тапкыр эшли. Эшләгән саен ниндидер үзенчәлекләрне, нечкәлекләрне тырышыбрак, төгәлрәк башкара. Ул инде кулын махсус күнектерү турында уйламый, анысы үзеннән-үзе эшләнә. Кайчагында гына башлангыч эше исенә төшкәч, үз алдына елмаеп куя, күз карашындагы үз-үзеннән канәгатьсезлек кими бара.

Билгеле, күнеленнән ул әле дә картиналар яза, кайчак аларны төшендә дә күрә иде. Шунысы кызык: төшендә ул көндез таба алмаган композицияне дә, буяуларны да бик җиңел таба, ә уянгач караса — картинасы да, буяулары да юк, бүлмә эче әле яңа яктырып кына килә. Билгеле, төшендә күргәннәрне киндергә күчерү кыен була иде. Аның каравы, хәзер инде хәл башка: житди картиналары булмаса да, натурадан алган күренешләрне ярыйсы яхшы эшли ул. Әллә эшнең җитдирәкләренә тотыныргамы? Шәрифә кайтканчы берне эшләп куйсаң, шәп булыр иде дә. Ул нәфесен тыйды, күнегүләрен дәвам иттерде, гүя өйрәнү мәктәбен әле тулысынча үтмәгән иде. Ә аны үтми торып, җитди укытучы зуррак эшкә тотынырга рөхсәт итмәс. Бу билгеле алым. Әлек Рушад үзешчән художник булу турында гына хыялланса да, хәзер күнел төбендә зуррак омтылыш бар шикелле. Бәлки ул артыграк хыялланып җибәрәдер, хыялда һәркем шулай арттыра торгандыр инде. Әгәр хыялың кечкенә булса, аңа ирешү сиңа зур канәгатьлек бирерме?

Рушадның аяк белән дә рәсем ясаучы художниклар турында укыганы бар иде. Кеше үз алдына максат куйса, шуңа ирешергә теләсә — ирешә икән. Тик күп вакытта без максатны чынлап куймыйбыз һәм шул максатка ирешү өчен чынлап тырышмыйбыз. Күрәсең, ихтыяр көчебез җитенкерәми, кыенлыклар куркыта. Әйе, һәркем дә батырлык эшли алмый. Аның каравы, чын батырларның даны ни тора!

Күптән түгел журналда бер рәссам-шагыйрь турында укыды. Шул кеше урыныннан да тора алмый, ике кулы икесе дә эшләми. Рәссам-шагыйрь карандашны авызына кабып рәсем ясый икән. Аны хәтта изотехникумга укырга алганнар! Журналда аның берничә рәсемен дә биргәннәр. Рушад аларны бик озак карады, аннары үзе турында уйланды. Хәле никадәр мөшкел булмасын, аның бер кулы исән, ул торып утыра, бераз йөри дә ала. Аннан тыш ул тормышны белә, кешеләрне аера — художник өчен монысы да бик әһәмиятле бит. Әһәмият бирмәсә дә, рәсем ясарга аның табигый таланты да булган. Хәзер ул эш арасында рәсем ясауларына шатланып бетә алмады. Хәтерендә әле: заводның культура сараенда әле дә эленеп торган бер рәсемен карагач, бер шактый танылган художник: монда чын орлык бар, сезгә табигый талантыгызны үстерергә кирәк дигән иде. Ул вакытта Рушад инженерлык эшен өстен күрде. Ярый, үткәнне кире кайтара алмыйсың инде, әгәр Рушадның ихтыярында булса кайтарырга тырышмас та иде әле. Тормыш үзе аның юлын шул якка борган икән, Рушад туктап калмас.

Уйлаганың үзеннән-үзе эшләнсә икән! Элекке рәсемнәре аның уң кул белән эшләнгән, ягъни табигый хәлендә эшләнгән. Сул кул шундый көчкә ия булырмы? Моны тәгаен әйтеп булмый, эшләп карарга кирәк. Бер кешенең аяк белән эшләгәне дә, карандашны авызга кабып эшләгән

рәсеме дә яхшы чыгар, икенче бер кешенең кул белән эшләгәне дә бер нигә дә ярамавы мөмкин. Сәнгать ташламаларны белми, художник авыру булганга бу җирен яхшылап эшли алмадым, дип әйтә алмый, андый хокук аңа бирелмәгән. Әгәр һәр яктан камил сәнгать әйбере ижат итә алмыйсың икән, теләсәң кемгә үпкәлә, әмма әйбереңкүргәзмәгә куелмас.

Шәрифә курорттан кайткач, ирендә зур рухи үзгәреш күрде. Бу хәл аны әйтеп бетергесез шатландырды. Югыйсә, хатынның ялы ял булмады. Кырымның искиткеч матур табигате дә, диңгез буеның хозурлыгы, мул кояшы да күзенә күренмәде, һаман Рушадны уйлады, ике-өч көн өйдән хат алмый торса, үзенә урын тапмады. Ярый әле, балалар көн аралаш хат язып тордылар. Шулай да күңеленең бер читен хатын-кызга гына хас шикләнү кимерде: ул кайтып төшкәндә Рушады, нәкъ теге вакыттагы кебек, егылып ятмасмы? Бу шикләнү, ихтимал, ирен артык яратудан килә торгандыр. Шәрифә яшьрәк елларында да яратам дип купшы сүзләр сөйләмәде, антлар эчмәде. Бергә кушылгач, сулаган сулышлары да бер булып киткәч, кәгазь чәчәк кебек буш сүзләр нигә кирәк? Ә күңеленнән Рушадны яратканнан-ярата барды, эчке борчуларын үзе генә белде.

— И Рушад, сиңа Идел быел чыннан да килешкән,— диде ул елмаеп.— Әллә минем китеп торуым хәерлегә булдымы? Кайчак ирләр хатыннарыннан туеп бетәләр, хатыннары киткәч, иркен сулыш алалар.

— Андый хәл була диләр, ләкин миндә башка,— диде Рушад.— Ничек әйтим сиңа: Идел миңа тылсымлы хикәят сөйли башлады димме. Мең дә бер кичә түгел түгелен дә, Идел тылсымы мине тәмам биләп алды.

— Хыялланасың?

— Хыялсыз яшәп булмый бит, Шәрифә.

— Күренеп тора. Тик бик кума, Рушад. Я өзлегеп куярсың, я башка бер-бер хәл булыр.

— Начарга юрама. Дошман көйсен, без яшәү матурлыгын кичерик.

Бу сүзләр Шәрифәгә бик үк ошап бетмәгәнлеге сизелеп тора иде, аның кояшта янган йөзенә әйтерсең күләгә иңде.

— Я инде, Шәрифә, ачуланма миңа. Әзрәк тилерергә дә кирәк ләбаса. Баш инженер булган чагымда, дәрәҗәмә карап, бераз тыелып тора идем, хәзер кем миңа бармак янасын? Сер итеп кенә әйтим үзеңә: бер көнне мин төш күрдем. Төшемдә чабып йөрим, имеш. Кулым да, аягым да авыртмый, нәкъ яшь чагымдагы төсле, имеш. Шундый шатланам, шундый шатланам, ничек әйтергә дә белмим. Ә син биек кыя башында басып торасың, имеш, бирегә менә алмыйсың, мин үзем түбәнгә төшәм, дип кычкырасың. Менәм, менәм, дим, үзем һаман югарырак үрмәлим, имеш.

— Тавык төшенә тары керә.

Рушад көлеп җибәрде.

— Хәзер кошчылык фермаларында да тавыкларга тары сибәләрме икән? Ә синең, гомумән, тавыкларга җим сипкәнең бармы?

Шәрифә ире сөйләгәннәргә ышанмый. Гүя аның күз карашы: «Мине юатыр өчен шулай тырышасыңмы? Мине шул кадәр беркатлы дип уйлыйсыңмы?» — дия иде. Телдән берни әйтмәде, Рушадның хәтерен калдырырмын дип курыкты. Бәлки уйнап әйткән сүзләрендә нәрсә булса да бардыр, турысын әйтергә батырчылык итмәгәнгә генә шулай сүз уйната торгандыр.

— Ярый, тавык мәсьәләләрен калдырып торыйк, югыйсә, тагын әллә нәрсәләр казып чыгарырбыз. Әйдә үзеңне Кырым күчтәнәчләре белән сыйлыйм,— дип, Шәрифә урыныннан торып, икенче якка чыкты.

Шәрифәнең холкындагы сабырлык билгеләре торган саен ачыграк сизелә бара иде. Менә хәзер дә ул, сүзне иң кызык җирендә өзеп, вино-

град, груша, анар алып керде. Табигый, сүз дә шул җимешләргә күчте. Шәрифә телдән җимешләр турында сөйләсә дә, күңеле белән тагын баягы темага кайтты. Хәзер аңа мәсьәлә җитдирәк сыман тоелды. Ул ирен яхшы белә: Рушад такылдавык түгел, төш турында авыз ачарга кирәк тапкан икән, димәк, нәрсәдер бар. Бер-бер реаль нигезе булмаса, ул хакта авыз күтәреп сөйләр идеме? Бая Шәрифә Рушадның күзләренә текәлебрәк карамады, ахрысы, ә карарга кирәк булган, бәлки серләрен дә ачкан булыр иде. Курорттагы борчылулары тәмам чыгып бетмәгәндер шул, шуңа күрә күп нәрсәне абайламагандыр.

Ялдан соң Шәрифә эшкә чыкты, иренең йомышын үтәп бер көнне буяулар алып кайтты. Ярлыга якты чырай күрсәтсәң, ямаулык сорый дигәндәй, Рушад, оялчан гына елмаеп, пумалалар һәм киндер дә алып кайтуын үтенде, таныш кибетчесенең исемен әйтеп, кемгә кирәк икәнен искәртергә кушты. Шәрифә боларны да сүзсез үтәде, хәтта яхшы булганмы, кирәклесен биргәнме? дип тә сорады.

— Нәкъ үзләре! — диде Рушад елмаеп.

Бер көнне иренең үтенече буенча Шәрифә столяр чакырып китерде. Үзе, сезгә комачаулыйм дигәндәй, бакчага ук чыкты. Ул иренең кирәксез чакта арага кысылуны яратып бетермәвен, төрле сораштыруларны җене сөймәвен белә иде. Вакыты җиткәч, Рушад үзе дә барысын сөйли, ә хыяллары белән уртаклашырга ашыкмый.

Рушад белән мастер бик озак сөйләштеләр. Рушад аңа бер китап алып күрсәтте. Анда ул куша торган нәрсәләр барысы да бар иде бугай. Мастер, заводта да Рушад белән бергә эшләгәнлектән, аның әйткәннәрен ярты сүздән аңлый иде.

## 5

Рушадның тормышында тышкы яктан әллә ни зур үзгәреш юк иде. Киресенчә, көзге салкыннар башлангач, бераз суык тидереп алды, бер ай чамасы больницада ятып чыкты, әмма күңеле төшмәде. Врачлар кулына бер эләксәң, алар бөтен яктан тикшермичә җибәрмиләр бит. Рушад каршылыксыз түзде, кушканнарын барысын да төгәл үтәде.

— Пенсионер кеше — врачларга хәзинә ул, аның өчен берәү дә җавап сорамый, ул үзе дә бер җиргә шалтыратмый, үзенә аерым игътибар таләп итми, чыгарсалар — чыга, ят дисәләр — ята бирә,— диде бер көнне Рушад шаяртып.

Күктә түбәнтен генә болытлар агыла, кояш бер күренә, бер болытлар астына кереп кача. Яңгыр катыш кар сибәли. Хәзер Идел буенда җил сызгыра, тәрәзә капкачлары шакылдый, бер кем юк, су өсте дә буп-буш, балыкчы көймәләре дә каядыр киткәннәр. Шулай да авырмаса, кар төшмичә Рушад дачадан кайтмас иде. Аларның дачалары мичле, ягып җибәрсәң, май кебек җылы була. Аш җылытыр өчен газ да бар. Әллә ни мәшәкате юк, ул кадәресен Рушад үзе дә булдыра ала. Шәрифә көз көннәрендә еш килә алмый, Рушадның ялгыз кунган чаклары да була. Дөрес, хатыны моңа юл куймаска тырыша, ләкин тормышның үз агымы бар, күп вакыт ул синең теләкләреңә буйсынмый. Киләсе елга яз башыннан ук эшләргә җай булсын өчен Рушад махсус бүлмә ясата башлады. Аның стеналары гына түгел, түбәсе дә пыяладан булырга тиеш. Репин мастерское шикелле түгел түгелен дә, шуңа бераз охшаган.

Рушад больницада яткан арада, мастерлар бүлмәне эшләп тә бетерделәр. Заводтан булышмасалар, билгеле, бу эш шактый озакка сузылыр иде, заводтан булгач, шактый кызу тоттылар. Монда инде Шәрифәнең роле дә зур булса кирәк, чөнки Рушад үзе мондый вак эшләр белән завод җитәкчеләрен борчырга кыймас иде.

Больницада, бүтән эш булмаганга, Рушад хатыны турында күп уйланды. Шулай да кызык бу Шәрифә. Бер яктан, Рушадның буяуларын эшкә дә санамый, рәсем ясауны ул бары тик буяу гына дип атый, икенче яктан, Рушад өчен шундый мастерской ясый, андый мастерской чын художникларның да күбесендә юктыр әле.

Сер түгел: авыргач Рушад беркадәр вакчыллана төште. Бик тиз турсая, үпкәли, кайчагында әрләп тә алгалый, гүя аның гына бик мөһим эше бар, башкаларның юк, алар гүя Рушад турында гына кайгыртырга тиешләр. Билгеле, мондый метаморфозалар тиз үтүчән булса да, алар эзсез узмый торгандыр. Кылыч ярасы китә, тел ярасы китми, диләр. Рушад соңыннан үкенә дә, тик тересәкне тешли алмыйсың.

Хәзер инде Рушад үзенең эскизлары, рәсемнәре турында элеккечә беркадәр көлә төшеп сөйләми. Алар турында ул торган саен житдирәк уйлана. Менә синең алдыңда ике-бүе бер метр-метр ярымлы полотно. Син шул мәйданга бөтен бер дөньяны сыйдырырга тиешсең. Производствода син унар метр, хәтта артыграк мәйданнар турында да әллә ни баш ватмыйсың, монда һәр квадрат сантиметр кадерле. Иң мөһиме — монда актык ноктасына кадәр камил килгән гармония туарга тиеш, шунсыз синең әсәрең сәнгать җимеше булмаячак. Элек Рушад бу турыда артык кайгырмый, хәтта күп буш вакытлары булган художниклар гына шулай язганнар, аларга эшләми үткәргән вакытларын ничектер акларга кирәк булган, дип уйлый иде. Никадәр тирән ялгышкан, дөресрәге, никадәр беркатлы өйрәнчек булган! Хәзер дә аның телгә алып сөйләрлек картиналары юк, ләкин ул житдирәк әйберләр ясарга җыена. Бетмәс-төкәнмәс күнегүләре дә хәзер кулын йомшарту гына булып түгел, ә художникка тиз генә бирелми торган осталыкка ирешү баскычлары булып күренә. Әйе, сәнгать инә белән кое казу икән ул! Инженер буларак ул канау казыганда экскаватор кулланыр иде, художник буларак... Художник буларак башка үлчәүләр кирәк икән.

Больницадан чыккач, берничә айдан Мәскәүгә кабат җибәргән гаризасына җавап килде. Хәзер инде пенсия «гомерлеккә» диелгән иде. Кара, Рушадның авырый башлавына ике елдан артык вакыт үткән икән, ә ул әле яңа житди эшкә керешергә уйлый. Кулында «гомерлек» пенсияң булгач, йолдызларга үрелү юләрлек түгелме? Аның күпме гомере калган соң? Рус әйтмешли, стоит ли огород городить?

Хәер, мондый икеләнү минутлары, җәйге болыт кебек, тиз үтә иде. Бераздан Рушад үзендә тагын чикләнмәгән омтылыш сизә. Өйдә, кысан бүлмәләрдә, буяулар белән эш итүе кыенрак, буяу исе бөтен өйгә тарала. Син үзең, күнеккәч, артык сизмисең, балалар яки Шәрифә кайтып керсә, абау, бүлмәләрне сасытып бетергәнсең, дип кычкыралар. Шуңа күрә Рушад күңеле белән һәрвакыт дачага тартыла, канаты сынган кош кебек, тәрәзәдән тышка карый. Быел кар күп түгел, әмма кыш үтә зәһәр. Шәрифә эшкә киткәндә еш кына:

— Рушад, бүген урамга чыга күрмә, балаларга да мәктәпкә бармаска дип радиодан әйттеләр,— дип кисәтә.

Шундый көннәрнең берендә — шимбә көн иде — Шәрифә ирен башын салындырып утырган хәлдә күрде. Тиз генә аның янына килде дә кулын башына куйды. Ул аңлый иде — эшсез утыру бик авыр. Эшләгәч кенә ялның рәхәте, ләззәте була, көннәр, атналар буе берни эшләмичә тәрәзәдән карап торсаң, тәмам туйдыра.

Рушад, хатынының кулын тотып, сүзсез генә үпте дә:

— Бу салкыннар мине изә. Менә өстемә никадәр киенеп тә уң аягым туңа, шуннан йөрәгем дә өши...— диде.

— Кирәкми, Рушад. Тиздән бу салкыннар үтәр дип сөйлиләр. Аннары дачага барып кайтырбыз. Синең инде мастерскоеңны күрәсең килә торгандыр, әйе бит, Рушад?

Рушадның йөзе яктырып китте: бу Шәрифә әллә күнелләгеләрне укый, иренең башында шундый уйлар кайнавын каян белгән? Рушад бәс сарган агачларга бер карап алды да:

— Әйе, Шәрифә. Мин, валлаһи, ятим бала кебек нәүмизләнәм,— диде.

Шәрифә елмайды.

— И минем балакаем! Бәлки ялга кадәр көн жылытыр. Мин, алдан барып, өйне дә ягармын, мастерскоеңны да...

— Кирәкмәс, мин тун киярмен.

Рушад телдән әйтмәде, ләкин монда аны чиксез шатландырган нәрсә дачага барып кайту гына түгел иде. Шәрифә бер кичтә ике тапкыр «мастерскоең» дигән сүзне кулланды. Бу инде тикмәгә генә түгел. Рушад аның тавышындагы үзгәрешләрне нечкәлекләренә кадәр өйрәнеп беткән иде. Димәк, Шәрифә аның буяуларына башкачарак күз белән карый башлаган! Рушад, билгеле, Шәрифәне сәнгать өлкәсендә белгечкә санамый, ләкин аның хәлендә Шәрифәнең уңай карашы жан тынычлыгы өчен бик кирәк. Кеше бит кемгәдер таянырга тиеш. Шул таянычы булса, ул киләчәк жил-давыллардан да курыкмый. Ә сәнгать юлында ачы жилләр еш исә.

Пәнжешәмбе һәм жомга көннәрдә үк көн жылытып жибәрде, Шәрифә эштән кайтканда күбәләк-күбәләк кар ява башлады. Ул нурланып киткән күзләре белән шәһәр урамнарындагы наратларга карады. Күпме торып туган шәһәрен шундый матур хәлдә күргәне юк иде. Әгәр художник булса...

Шәрифә исе китеп тирә-ягына каранды: художник булса... Кешенең башына сәер уйлар бер дә искәрмәгәндә килеп китә икән. Моңарчы аның алай уйлаганы юк иде. Гомумән ул табигатькә художник күзе белән карамый иде. Әллә аның матурлык тойгылары йомык идеме, әллә ул үзе шул ләззәтне тою югарылыгына күтәрелмәгән идеме? Ахыр килеп, һәр кеше художник була алмый, монысы табигый, моңа тумыштан сәләт һәм талант кирәк, зур хезмәт кирәк, ә матурлыкны һәр кеше диярлек тоярга тиеш. Әйе, тоярга тиеш, акыл белән генә белү житми. Ә Шәрифә моңарчы аны акыл белән генә белгән. Рушадка сөйләргәме? Әйе, сөйләргә кирәк, көлсен, шатлансын!

Шунда ук Шәрифәнең башына башка уйлар килә. Рушадка һич сөйләргә ярамый. Рушад бит хәзер шикләнүчән булып китте. Шәрифә боларны Рушадның күңелен күтәрү өчен генә сөйли дип уйлар. Сәнгать янында алдашып утыру — түбәнлек, Рушад моны гафу итмәс. Юк, күңелдә генә калсын. Соңыннан бер жае чыкса сөйләр, чыкмаса, шулай калыр. Кешенең кечкенә генә серләре булса да, ул үз күз каршында үскәндәй булып күренә бит.

Шимбә көнне Шәрифә бик тиз хәзерләнде. Башта ул кызы белән генә барып мичләрне ягып кайтты, аннары Рушадны алып барды. Ярты сәгатьтән алар куе нарат урманы эчендә иделәр инде. Машинадан төшкәч, Рушад иркен сулыш алды. Тирә-якта аклык һәм пакьлек, һава жылы, жил бөтенләй юк, кар явудан туктаган, болыт астыннан гына кояш карап тора, кар мендәрләре астыннан наратларның яшел ботаклары күренә. Идел ярына чыккач, яктылык тагын да арта төшкәндәй булды. Кар, кар! Әнә, кара ноктала да күренә. Нәрсә булыр икән?

— Анда балыкчылар утыра. Мин сөйләштем, кич балык китерергә булдылар,— диде Шәрифә.

— И-и,— дип сузды Рушад.— Менә кайда икән ул дөньяның рәхәте! Ә без шәһәрдә бикләнеп ятабыз.

Шулай да Рушад мастерскоена ашыга иде. Мастерскойның тышкы күренешеннән ул бик үк канәгать булмады, тәбәнәгрәк ясаганнар кебек. Өс киемен дә салмыйча һәм бүлмәләргә тукталмыйча, туп-туры пыяла террасага үтте. Ишек төбендә туктап калды. Нинди иркен, якты! Тыш-

тан кар басканга гына тәбәнәк булып күренгән икән. Уртада мольберты һәм әйләнә торган кечерәк өстәле тора. Идән сарыга, тәрәзә рамнары акка буялган. Дөрес, хәзергә әле монда кеше жылысы да, ижат атмосферасы да юк, ләкин алар булыр, булыр!

— Тырышканнар бит, Шәрифә,— диде Рушад, бүлмә уртасындагы гади урындыкка утырып.— Хәзер инде минем шәһәргә кайтасым да килми. Кыш буена шунда калыр идем.

— Сиңа ошагач, мин бик шат. Яратып бетмәссең дип котым очкан иде.

— Ни сөйлисең, Шәрифә! Син бит миңа нәрсә кирәген минем үземнән дә яхшырак сизәсең.

— Ярый әле, без мескеннәрне дә мактаучылар бар. Әйдә теге якка, анда жылы. Иртән мичкә ашымны куеп калдырган идем, хәзер өлгергәндер.

— Ярый, син табыныңны әзерлә, мин монда әзрәк утырып торыйм. Монда якты уйлар туа.

Шәрифә залга чыгып өстен-башын чишенде. Иртән килеп яхшы иткән, кичтән килсә тагын да яхшырак буласы икән дә, өлгерә алмады, хатын-кызның эше тавык чүпләп бетерерлек түгел бит. Бераздан тагын мичне ягарга кирәк булыр. Озак кеше тормаганлыгын сиздерә. Урын-жирне барысын алып китмәгәннәр иде, аларга салкын сеңгәндер, жылытырга кирәк.

Өстәлгә ак ашъяулык жәеп, табын әзерләгәч, Шәрифә һаман терраса уртасында утырып торган ире янына чыгып:

— Туңмадыңмы, Рушад? — диде.

— Мин монда бүтән жылылык тоям, Шәрифә.

— Һаман хыялланасың. Ярый, әйдә тамакны туйдырыйк. Сәгать ике булды, өченчегә китте. Бүген бераз режимың да бозылды.

— Анысы берни түгел.

Урман эчендәге жылы өйдә аш гажәп тәмле тоелды, Рушад шәһәрдәгедән күбрәк ашады, тик чәен генә бер стаканнан артык эчмәде. Хәзер кан басымы нормаль булуга карамастан, ул күнеккән гадәтен бозмый иде.

Сөйләшә-сөйләшә табын янында утыргач, алар урманга чыктылар. Урман эчендә дә кар тирән түгел. Шуның өстенә, алар икесе дә киез итекләрдән иде. Култыклашып, әкрен генә атладылар. Менә шулай кышкы урманда алар бер генә тапкыр йөргәннәр иде. Мәскәү янындагы санаторийда булган иде ул. Кайсы елны әле? Күптән инде, Рушад ул чагында сәламәт иде әле, күбрәк техник проблемалар турында сөйләштеләр бугай, бер дә хәтердә калмаган. Бары якты шәүлә генә күңелдә уйный.

Шәрифә иреннән әледән-әле: «Арымадыңмы? Ял итмибезме?» дип сорады. Рушадның күнеле гажәп күтәренке иде. Ару кая! «Их, һавасы ла һавасы, яңа пешкән күмәчмени!» дип барды. Аннары кире борылдылар, бер кеше, бер эз очрамады, күрәсең, монда кошлар да юк.

— Табигатьнең шигъриятенә бер нәрсә дә тормый шул. Юкка гына табигать бөтен матурлыкның чыганагы димәгәннәр,— диде Рушад.— Ә без күп вакытта табигать кочагыннан качабыз.— Кинәт Рушад кычкырып көлеп жибәрде.— Хәзер фәлсәфә сатып була, әйтерсең элек урманга чыгарга вакытым булган да чыкмаганмын. Тормыш арбасының юллары сикәлтәле шул. Бу жирләрдә гомер булганыбыз юк иде бит. Уйласаң, тирәбездә нинди гүзәл урыннар бар икән!

— Авырып яхшы иттем димәкче буласыңмы? — Шәрифә, кара пальтосының якасына алсу йөзен яшереп, иренә күз сирпеп алды.

— Юк, алай димим. Кеше эшләргә тиеш. Хезмәт аркылы гына без тормышның ямен һәм мәгънәсен тоябыз.

— Ял да итәргә кирәктер,— диде Шәрифә көлемсерәп.— Югыйсә...

— Әйе, югыйсә минә минем хәлгә каласың... Анысы дөрес, без ял итә белмәдек һәм әле дә, атнага ике ял булгач та, кадерен белеп бетермибез. Күрәсең, канга сеңгәннәр тиз чыкмый.— Рушад агач башларына карап бераз эндәшми барды да көлемсерәп куйды: — Шәрифә, син миңа карап гаҗәпләнә торгансыңдыр инде. Әйтерсең мин инженер да булмаган, завод та күрмәгән, гел сәнгать турында такылдыйм.

— Үзеңә дә шулай тоеламы?

— Сөйлим икән, тоела, күрәсең. Ә синең башыңа икенче уй килгәне юкмы?

— Нинди уй?

— Мин тумыштан художник буласы кеше икән дә, ялгышып, инженер булып гомер үткәрә язганмын?

— Алай уйлаганым юк.

— Аңлашыла. Син минем инженер булуымны күбрәк ярата идең шул.

Шәрифә әле кичә генә шәһәр урамнарына художник күзе белән каравын исенә төшерде, шул турыда Рушадка да сөйләп бирә язды. Актык минутта тагын бу уеннан кайтты.

— Соң, Рушад, мин балалар анасы ич, хозяйка. Инженерлык һөнәрең тормышны алып барырга барлык мөмкинлекне бирә иде. Аннан канәгать булмаска минем нинди нигезем бар?

— Буяуларым бер тиен дә акча китермәде, шулаймы?

— Минемчә, Рушад, иллегә якынлашып килгән хатын-кыз ул яктан реалист булырга тиеш. Үпкәләргә урын юк шикелле.

— Мин үпкәләмим дә.

Алар дачага кайтып керделәр. Әллә инде һавада булганга, өй эче бигрәк тә җылы тоелды. Шәрифә форточканы бераз ачык калдырган булган, иң элек шуны япты. Рушад чишенде. Киез итекләренә ябышкан карны баскычта ук каккан иде. Хәзер киез итекләрен бөтенләй салды.

— Син бик батыраеп китмә әле, Рушад. Идән салкын,— дип, Шәрифә иренә җылы чүәкләр ташлады.

Кояш болыт астыннан чыгып бетүгә өй эче тагын да яктырып китте, ә тыштагы яңа кар җем-җем итә башлады, урман эченә сузылган күләгәләр күренде. Әгәр аз гына җил дә булса, күләгәләр җанлы сыман тоелырлар иде.

Урманда йөри-йөри тамак бераз кипшегән иде. Тәмләп чәй эчтеләр. Күр инде, кара карлыган вареньесы да монда үзенчә тәмле икән. Шәһәрдә ничектер тәме башкачарак тоела. Бигрәк тә өйдә кайнаткан варенье. Әллә картаю билгесеме? Сәламәт чакта Рушад мондый ваклыкларга бөтенләй игътибар итми иде, кибеттән алган варенье ни дә, өйдә кайнатканы ни. Баксаң, аермасы — җир белән күк шикелле икән.

— Валлаһи, урманда кыш үткәрсәм, савыгып китәр идем тәсле. Балаларга куна калырбыз дип әйттеңме? Борчыла күрмәсеннәр.

— Әйттем, шофер белән дә иргәгә сәгать өчтә-дүрттә кил дип сөйләштем. Син бераз ятып тормыйсыңмы? Урманда йөреп арыгансыңдыр бит.

— Арымадым. Ә син, Шәрифә, ничек барысын алдан хәстәрлисең? Теге куркынычсызлык бүлегендәге озын инженерны хәтерлисеңме? Шул минем хатын бер нәрсә дә эшли белми дип ул чакта ук зарланган иде.

— Син шул кадәр вакыт шуны исеңдә тоттыңмыни?

— Тотмаска! Хатының алтын булу бәхет ич. Синең шундый булуыңа шатланып бетә алмыйм.

— Харап, мактаган бул инде,— диде Шәрифә көлеп.— Ирләр авырмасалар, хатыннарының кемлекләрен дә белмиләр.

— Анысы растыр. Синең белән дә чәпәләшкән чакларыбыз булды бугай. Хәтерлисеңме?

— Юкны сөйләмә әле. Яратып кемнәр әйтешми.

— Менә, менә. Беләсеңме мин сине ни өчен ярата идем?
— Яратканга яраткансыңдыр инде.
— Юк, белмәдең. Артиска Шәфика Котдусовага охшаган өчен.
— Әбәү, син... син артискаларны ярата идеңме әллә? Әйтәм, миңа да Шәрифә диясе урынга еш кына Шәфика дип җибәрә идең.
— Җырчы буларак ярата идем. Ә болай таныш та түгел идек. Пластинкаларын радиода уйнатсалар, хәзер дә рәхәтләнеп тыңлыйм. Кызганыч, дөньядан бик иртә китеп барды.
— Әллә шуның өченме миңа үзешчәннәр концертына катнаш та катнаш дип бәйләнә идең?
— Хәзер белдеңме? — дип, Рушад рәхәтләнеп көлде.
— Тагын урманга чыгып бер исереп кайтсаң, әллә нинди серләр сөйләрсең әле.
— Их, Шәрифә,— дип көрсенде Рушад.— Картаябыз, ахрысы. Искә төшерүләр күбәеп китте. Иртәрәк түгелме икән? Яшисе иде бит әле. Искә төшерүләр әби-бабай булгач та качмас.
Рушадның тавышыннан сагыну да, өмет-ышаныч та сизелеп тора иде.

## 6

Кешегә күп кирәкмени? Бигрәк тә Рушад Вәлишин кебекләргә. Аның баш инженер чагы булса, меңләгән коллективның башында торса, алар уе белән генә янса, аларча гына кильәчәккә караса, билгеле, анардан аз сорамаслар иде, ә хәзер нәрсә, хәзер ул — пенсионер, менә шул. Җитмәсә, картаю сәбәпле дә түгел, авыру сәбәпле сафтан чыккан кеше. Ярый, ул үз алдына максат куеп, сул кулы белән аз-маз рәсем ясарга өйрәнгән. Моннан кем нәрсә көтә? Аның бит рәсемнәрен хәзергә берәүгә дә, хәтта завод культура сарае каршындагы рәсем түгәрәге членнарына да күрсәткәне юк. Хатынына да кат-кат әйтте:
— Минем буяулар турында заводта, зинһар, чынлап торып сөйләмә, көләрләр,— диде. Дөрес, бу сүзләрне әйткәндә аның күзләре ничектер сәер карый, аларда сер дә, үз эшеннән тартыну да бар иде кебек. Чынын әйтмәве, нидер яшерүе ачык иде.
Рушадның рәсемнәренә әллә ни житди карамаган, аларны бары юану билгесе итеп санаган Шәрифә бу турыда авыз күтәреп заводта сөйләргә җыенмый да иде. Хатынны икенче бер нәрсә гаҗәпләндерде: бу эшкә чынлап торып тотынырга хәзерләнгән Рушад ни өчен болай яшерен булып китте? Хәзер бит аз-маз сөйләсә дә аның хакы бар, яхшымы, яманмы ике-өч картина язды, тагын уйлап йөри. Уйлаганнары байтак булса кирәк, тик шуларның кайсына алдан тотынырга белми бугай. Шәрифә рьялану яки ялагайлану өчен түгел, чын күңеленнән әйтеп куя:
— Менә бу рәсемең, Рушад, миңа да ошый, анда нәрсәдер бар кебек,— ди.
— Тырышкан булам инде, тик осталык җитми, күрәсең, шулай да яшьтән тотынырга кирәк булган, картаеп каткач буыннар... Тукай, үзе картаймаса да, иҗат чишмәсенең кайчан ыргылуын белгән.
— Әйе, соң да, кирәксез дә. Мин ихтыярсыз ычкындырып җибәргәнмен икән, гафу ит. Күңелгә төрле чуп-чар кергәнгә генә иде.
Чынында Рушад бер нәрсәдән бик канәгать иде. Ул завод тормышы бу кадәр рухи азык бирер дип һич уйламаган иде. Нинди генә күренешне алмасын, шигърият ташып тора. Дөрес, күп очракта ул аны картинасында тиешенчә бирә алмый, тоньк чыга. Шуннан икенчесенә, аннары өченчесенә тотына. Завод тормышын яхшы белгәнгә, аның эчке механикасын тирәнрәк ачуы кирәклеге ярылып ята. Икенче төрле әйткәндә, нәрсә эшләргә кирәклеген белгәнгә, кыенлыклар аны куркытмый, кире-

сенчә, эшләү дәртен генә тудыра. Әйе, җилгә каршы куйсаң, утлы күмер кыза!

Дачага ул апрельнең икенче яртысында ук чыкты. Иделнең үзен буып торган кышкы зынҗырлардан котылуын күрү аның иҗат көчен яңарта иде. Табигать үрнәк бирә, чакыра, аңарда никадәр энергия бар. Шул актарылып торган ыргылышны күргәндә җанлы кеше ничек тик ятсын. Оят, түбәнчелек булыр иде бу.

Рушад баш күтәрми эшләде. Шәрифә аның дәртенә каршы тора алмыйча һәм хәзер бик үк каршы торырга да теләмичә: «Кара, Рушад, өзлегә күрмә», дип кенә әйтә иде. Шул ук вакытта Рушадның ялтырап торган күзләрен күреп эченнән генә сөенә: әллә илһам уты шулай кабынган инде. Сәнгать кешеләре мең еллар буе илһам дигән нәрсәнең серле булуы турында язалар, әллә дөрес микән? Әлек Шәрифә бу турыда бер дә уйламый иде, аңа кешеләр бары тик җәмгыять алдындагы бурычларын гына үтиләр, ә илһам турында, башкаларга охшамас өчен, шагыйрьләр генә сайрыйдыр дип уйлый иде. Баксаң, яшәүдә адым саен сер тулып ята икән!

— Юк, Шәрифә, хәвефләнмә: мин моңарчы кичергән авыруларымнан да котыла барам кебек. Мин үземне язгы Идел кебек сизәм, дәртем ташый.

Шулай да Рушад нәрсәдәндер канәгать түгел. Тыштан караганда бу бөтенләй күренми, моны бары тик яраткан хатын-кызның гына сизүе мөмкин. Йөрәге гүя шуны аңа пышылдый.

Әгәр комачауламасалар, Рушад вакыт-вакыт уйга кала, бер ноктага төбәлеп карап тора: берәр нәрсә күрәме ул, әллә берни дә күрмиме? Бәлки, шулай хыял чоңгылыннан берәр нәрсә эзли торгандыр? Авыз эченнән үз алдына сөйләнәме, әллә булмаса шулай җырлавымы? Кара, җыры бөтенләй мескен Хайбас мыгырдавы кебек бит. Ярабби, бичара Хайбас хәленә генә калмасын!

Үзенә әйтсәң, хәтере калуы бар. Һәм Шәрифә барысына түзә. Кайчагында үзенең моңлы тавышы белән, иренең мыгырдауларын күмеп, кычкырып җырлап җибәрә. Рушад юкка гына үзешчән концертка катнаш дип әйтмәгәндер шул — Шәрифәнең тавышы ярыйсы ягымлы. Бигрәк тә кичке сәгатьләрдә, тын Идел өстенә карап, ачык террасада җырлаганда тәэсире көчле була. Рушад моңа ачуланмый, нәрсәдер аңлаган кебек тартынып кына елмая. Ул бер вакытта да Шәрифәне көнче дип уйламый иде. Баксаң, кызыл шәфәкъка карап моңланып җырлавы шул көнләшүенең бер билгесе түгелме? Хатыннарның алтыны да көнләшә икән, хәтта үлгәннәрдән дә көнләшә! Әллә нефтькә ияреп газ чыккан кебек, яратуга ияреп көнләшү туамы? Яратмаган кешесен кем көнләсен?

Рушад, урыныннан торып, хатыны янына чыгам дигәндә генә өенә кайтып баручы Хайбасның җыры ишетелде. Тукта, нигә кешеләр аның җырын гел мәгънәсез диләр. Аның җаны нәрсәдәндер җырлый бит. Ярый, без моны аңламыйбыз, төшенмибез, безгә ул хәтта кыргый булып тоела, ләкин шулай тоелган өчен генә аңа андый хөкем чыгара алабызмы? Монда тирәнрәк сер юкмы?

Кичке кызыл шәфәкъ нуры тулган пыяла мастерскойда Рушад мескен Хайбасның тавышы бөтенләй ишетелмәс булганчы бер үзе басып торды. Тәнкыйтьчеләр аның бу уйларын белсә, ни әйтерләр иде икән? Тиле кешенең җырын акларга маташучы акыллы тиле димәсләрме? Ихтимал. Тик акыллы кешеләр мәгънәсез җырны күкләргә күтәреп халык алдында мактасалар, аны ничек дип атарга? Өстәвенә, шуннан ләззәт табалар дип кылансалар? Сәнгатьтә шундый хәлләр булды бит, тагын булмас дисеңме? Бу бит аерым патологиянең серенә төшенергә

теләү генә түгел, бу аңлы яки аңсыз рәвештә дошман җырын җырлау дигән сүз!

Кызыл шәфәкъ әкрен генә сүнә. Идел өстендә — тынлык, тынычлык. Су бик күп, ләкин бозлар актарылмый инде, ташу беткән. Иртәгә көн матур, кояшлы булыр. Юк, яңгыр яусын, җил уласын иде, бөтен дөнья үкерсен иде. Рушадның рухы шуны сорый. Яңа нәрсә, тын болыннар өстендә кызарып кояш чыккан төсле, бер идиллия эчендә тумый. Рушад язылып бетмәгән картинасына үтә бер канәгатьсезлек белән карый. Эңгер-меңгердә ул хәтта ямьсез булып күренә. Рушад аңа көн яктысында да аз карамады. Көн яктысында күп нәрсә үзгәрә. Ләкин кешеләргә хәзер нәкъ шул кирәкме? Аларның җаны шуны телиме? Хәят күгендә болытлар куера бит. Элекке дуслар тагын безнең чик буен бозганнар, салкын карга чик сакчыларыбызның кайнар каны тамган. Бүген аларның кабере өстенә шәфәкъ кызыл канатын җәйгәндер...

Рушад кырык бишенче елны хәтерли. Япон самурайларын тар-мар итеп Кытай җиренә алар бар нәрсәдән кадерле азатлык алып бардылар. Ул бүген дә меңләгән кытай халкының шат йөзен күрә, «Шанго!» дигән күңелле тавышларын ишетә кебек. Тик бу күңелдә генә инде, чынлыкта хәзер анда автоматлар, пулеметлар күбрәк тырылдый. Кырык бишенче елда әле тумаган да хунбейвиннар безнең солдатларга мылтык төзи, күп газаплар кичергән Кытайга азатлык алып барган солдатларның балаларын беренче номерлы дошман диләр. Бу — башка сыймый, логикага каршы килә, моны ничек дип атарга да белмисең.

Әлбәттә, кулына корал тотып безнең туфракка аяк баскан теләсә кем бездән рәхим көтмәсен, ләкин бу мыек та чыкмаган малайларны кем күрәләтә үлемгә җибәргән? Кем алар кулына корал тоттырган? Бөек Кытай халкы шуны тиз аңлармы, әллә тагын меңнәрчә кешеләрнең каны җиргә агармы? Сәнгать менә шул борчулы сорауларга да җавап бирергә тиеш.

Ярый, бу зур сәнгать алдында торган изге бурыч булсын ди. Ә Рушад Вәлишин кебек тормыш нигезеннән егылып төшкән бер кешедән кем нәрсә сорарга тиеш? Яшь һәм көчле чагында ул гитлерчыларга каршы да, япон самурайларына каршы да илне яклап сугышты, аннары озак еллар буе, заводта эшләп, Ватанны ныгытуга үзенең өлешен кертте. Тормыш вахтасы бетмәгән булса да, нишлисең, сафтан чыкты. Шуңа инде буйсыныргамы? Бүген бит аның кайнар йөрәге тибә, сыңар кулы булса да бар. Һәм мең тапкыр уйланган уйлар, тыгызланып, яңадан аның башында айкалалар.

Даманский батыры Әнвәр Зәйнетдиновның рәсемен, газетадан кисеп алып, мольберты янына кнопка белән кадаклап куйган иде. Батыр татар солдаты. Төрле милләттән андый батырлар күп булган. Аларга ничек кенә карама, бер-ике сүз белән асылларын билгелисе килә: замана балалары! Рәсем чаралары белән ничек аларның илгә соңгы сулышкача турылыклы булуларын, изге ышанычларын һәм батырлыкларын бирергә?

Террасада Шәрифәнең ялгыз җыры күптән тынган иде. Ниһаять, ул ире янына керде.

— Абау, Рушад, нигә караңгыда утырасың?

— Караңгымыни?

Шәрифә электр утын кабызды, мастерской эче ялт итеп китте.

— Син чыннан да... Нигә болай үзеңне газаплыйсың? Бүген булмаган икән, иртәгә, берсекөнгә ясарсың. Куучы юк бит.

— Куучы... Утыр әле, Шәрифә. Мин беләм, аның өчен бер дә үпкәләмим: син минем буяуларыма бала шаяруы төслерәк итеп карыйсың. Әйе, әйе. Соңгы вакытта карашыңда бераз үзгәреш сизсәм дә, гомумән алганда, арттырмыйм шикелле. Ихтимал, синдә хаклык бардыр, мин бу турыда уйлыйм. Тик теләсә нинди очракта да... сәнгать белән шаярыр-

га ярамый. Нәрсәгә булса сылтарга да мөмкин түгел. Кешенең рухи халәте, табигый буларак, һәр картинада эстетик ләззәт эзли, әгәр чын чәчәк урынына ялган чәчәк тоттырсалар, бик рәнҗи... Син нигәдер эндәшмисең, мин бик томанлы сөйлимме, күңелемдәгене әйтеп бирә алмыйммы? Авыррак уйлыйм шул. Шулай да син мине кызганма, миннән... көлмә дә. Син үзеңне сәнгатьтән ерак торган беркатлы кеше итеп күрсәтергә тырышсаң да, асылда син бит андый кеше түгелсең. Һәр кешенең эстетик тойгылары бар. Син минем беренче караучым һәм беренче тәнкыйтьчем. Син минем башкалар күрми торган кимчелекләремне дә күрәсең. Хатын-кызның тойгылары тирән... аннары, син мине чын күңелдән яратасың. Керфекләреңне түбән төшермә, кызарма да, андый вак нәрсәләр өчен генә әйтмим. Моңарчы безнең сәнгать турында уртага салып сөйләшкәнебез юк иде, ә сөйләшергә кирәк...

Шәрифәнең төсе үзгәрде, коңгырт күзләрен киң ачып иренә карады. Күрәсең, иренең никадәр ихлас булуын белергә тели иде.

— Рушад, боларны чын күңелдән әйтәсеңме? Мин синең каршыңда ничек шундый зур ышаныч казандым? Әллә алданаммы?

— Юк, алданмыйсың, сине алдарга теләүче дә юк. Мин синең тормышымда гына түгел, әгәр шулай әйтергә яраса, иҗатымда да дус булуыңны теләр идем. Дөрес, минем иҗатым әллә ни булмас, ләкин мин кемгәдер таянырга тиешмен. Яшермим, сиңа ышанычым бик зур. Тик хатыным булганга түгел, чын дус булганга сорыйм.

Шәрифә кинәт иренең күкрәгенә капланды һәм баладай тынып калды. Ул Рушадның йөрәк тибешен тыңлады. Бер дә болай тыңлаганы юк иде, кара, чабыштан кайткан ат йөрәге төсле кага бит. Күрәсең, барысын чын күңелдән әйтә, рияланмый. Шәрифә үзен кинәт үсеп киткән, чистарган, пакьланган, рухи магурайган кебек хис итте. Беренче гашыйктай Рушад аңа чиксез якын булып китте. Күптән, күптән аларның мондый рәхәт минутларны кичергәннәре юк иде. Ул, күзләрен йомган булса да, иренең картиналарын ап-ачык күрде. Билгеле, күз ачып йомганчы могҗиза булмады, матурлык тойгысы да үсеп китмәде, бу картиналар аның алдында сәнгать энҗесенә әйләнмәде, әмма хәзер алар әүвәлге кебек җанга азык бирми торган салкын буяулар да түгел иде.

Рушад Шәрифәнең озак эндәшмәвен үзенчә юрады.

— Моңарчы мин шактый кыен хәлләргә калсам да, ниндидер яшерен максат белән синең алдыңда ялагайланмадым. Ялагайлану, минемчә, чын хисләрне мәсхәрәли, үзеңне дә түбәнәйтә. Кирәк тапмыйсың икән, күңелеңә хыянәт итмә, алдашма, мине җәлләмә...— Аның авыру дип җәлләмә диясе килде, шулай да әйтмәде, чөнки бу бөтенләй урынсыз иде.— Уф, тәмам буталып беттем. Әле хәзер генә шагыйрьләрнең нидән чәчләре иртә агара икәнен аңладым бугай.

— Миңа калса,— диде Шәрифә көлеп,— син әкрен-әкрен шагыйрьләр урамына кучәргә ашкынасың. Кабул итәләрме соң алар сине?

— Шәрифә!

— Ярый, бетте, бетте, артык бөртек тә мактамыйм. Ә тәнкыйтьләү хокукын син үзең миңа бирдең. Моннан соң түз генә, убырлы карчык шикелле, күзеңне ачырмыйм,— дип, Шәрифә чәчрәп көлеп җибәрде.— Син үзең дә сизмәстән шайтаннарны шешәдән чыгарып та аларны янадан шешә авызына кире кертә алмаган дәрвиш хәленә калдың.

— Бик күпләр үз хатыннарын шайтанга тиңләгәннәр, мин андый түгел,— диде Рушад көлеп.— Минемчә, андый ирләр беркайчан да үз хатыннарын сөймәгәннәр.

— Җитте,— диде Шәрифә иренең агара башлаган чәченнән сыйпап һәм урыныннан торды.— Сөйләшә торгач, шундый хәлгә килеп җиттек, я картаймыш көнебездә бер-беребезгә гыйшык җырлары әйтешә башларбыз, я ут ягып кычкырышырга тотынырбыз, бигайбә.

Идел уртасыннан бөтен утлары белән балкып пароход үтеп бара иде. Хәерле юл!

## 7

Рушад бу араларда ничектер үтә мавыгып эшләде. Бу эшне фәлән вакытка бетерәм дип биргән вәгъдәсе дә, бүтән максаты да юк иде, бетерсә ни дә, бетермәсә ни? Әмма дөрләп янып, дөньясын онытып эшли бирде. Ярый әле — Шәрифә бар иде, ул каруланмыйча Рушадны вакытында ашатты, вакытында Идел ярына һава ваннасы алырга, коеныргa җибәрде. Кичләрен, гадәт буларак, Рушад эшләми иде, я әкрен генә су буендагы урманда йөрделәр, я ачык террасада утырдылар. Черки булмаганга, Идел буенда сөйләшеп утыру бер рәхәт. Көндез колакны тондыра торган моторлы көймә тавышлары да ничектер юашланган, я бөтенләй тынган, ә күктәге ачык кызыл буяулар сине әллә нинди тирән уйларга сала, син сөйләшеп утырсаң да хыялың үз җаена йөзә бирә. Рухың гүя баеганнан-байый бара, күңелең татлы ләззәт җыя.

Шәрифә әллә шуны сизәме, әллә кичке кабатланмас буяулар турында сөйләшеп утыру Рушадның күңеленә аеруча якын икәнен беләме, сүзне күбрәк шул турыда алып бара. Сүз сүзне чыгара, диләр. Әгәр ялгыз уйлансаң, хыяллансаң, барысы да ничектер бер генә юнәлештә ага, каршылык тоймыйсың, икәү сөйләшкәндә исә, бигрәк тә Шәрифә кебек бөтен нәрсәне үзенчәрәк аңлаучы кеше белән гәпләшкәндә, каршы уйлар туа, син үзең дә сизмәстән бер секунд эчендә аңа җавап биреп өлгерергә, үз карашыңны ныграк исбатларга, ачыкларга тырышасың, ә кайчагында бөтенләй искә-акылга килмәгән фикерләр ялтырап китә һәм син гүя ачылмаган серләрне ачасың.

Рушад Шәрифә белән тулысынча килешкән очракларда да юри аңа каршы килә төшеп сөйли. Болай иткәндә сүз ихтыярсыз куера.

— Кара нинди бай төсләр, нинди олылык һәм шигърият,— ди Шәрифә, катлау-катлау кызыл болытларга карап.— Мин боларга игътибар итми идем, син өйрәттең.

— Кешене өйрәтергә булса, безнең бил бугаң, ди иде безнең бабай. Тик әйтерсең художникка Идел буе матурлыгы гына кирәк,— дип көлемсерәде Рушад.— Художникның бүгенге таләпләре...

— Аларың, Рушад, кайчан булса художниклар белән очрашканда сөйләрсең. Мин аларны аңламыйм да.

— Аңламасаң, тоясың. Тойгылар миңа иң асыл җәүһәр булып күренә.

— Кыландырмыйча, боргаландырмыйча гына әйт инде, Рушад.

— Анысы читенрәк шул, Шәрифә. Кыландырсаң, күп беләсең кебек...

— Абау, Рушад, хатының алдында алдашып утырырга оят түгелме? Ә күктәге буяулар сүнә. Минемчә, художниклар күк төсләренең бөтенесен бергә бирсеннәр иде.

— Бөек художниклар биргәннәр.

— Ул чагында хәзергеләре нишли инде? Кабатлыйлар гынамы?

— Юк, төсләр артында хәзерге заман кешесенең теләкләре ята: ул нәрсәнедер раслый, нәрсәнедер кире кага.

— Бурычлары бик тар икән.

— Ничек тар? Сүз бит идеяләрнең асылы турында бара. Ә оттенoклары чамасыз күп. Заманына, көненә карап алар тагын да төрләнә. Әгәр без нәрсәнедер яклый, нәрсәнедер кире кага дибез икән, ул нәрсәне хәзерге электрон машиналар да санап бетерә алмас иде.

— Җитте, Рушад, җитте,— диде Шәрифә, бармаклары белән чигә тамырларын кысып.— Боларга минем башым җитми, шундый уйларга чумучылар булса, аларны да кызганам.

Рушад көлеп җибәрде. «Беренче караучы һәм тәнкыйтьче» ачыктан-ачык алдаша иде. Элек Шәрифә сәнгать турында сүз чыкса, әллә ни уйлап та тормый, тисә тиенгә, тимәсә ботакка дигәндәй, теләнә нәрсә туры килсә, шуны әйтеп сала иде. Үчекләвен дә яшерми иде. Ире сәнгать юлына басып, бу эшкә җитди каравын әйткәч, «иң каты тәнкыйтьче» булырга вәгъдә бирсә дә, үзе сәнгать турында бик сакланып сөйләде. Рушад аның ярым-йорты сүзләрен дә бик игътибар белән тыңлады, күп вакыт Шәрифә белән эчтән килеште, синеке дөрес, дип әйткән чаклары да булды, яртылаш эшләнгән эшен кыю рәвештә читкә куйды, я яңабаштан кереште. Шәрифә моны күреп бик уңайсызланды, кызарды, мин ни беләм, мина карап башлаган эшеңне, зинһар, бүлмә, дип әйтте. Рушад аны бер кулы белән кочып:

— Үзеңне үзең яманлама, миннән мактау сүзләре әйттермә,— диде.— Без бер тапкыр килешкән идек бит. Бик беләсең килсә, соңгы тапкыр әйтим: әгәр мөмкин булса, синең йөрәгеңне үземә күчертеп куйдырыр идем. Аңладыңмы?

— Хәзер бит йөрәкне күчерәләр! — Шәрифәнең күзләре кара күктәге йолдыз кебек ялтырап китте.

— Әйе, ләкин аның өчен береңнең алдан үлүе кирәк. Ә без бергә яшик әле.

Иртән сәгать бишләрдә үк торып, Рушад тагын эшкә тотына. Шәрифәнең дә күзеннән йокысы кача. Ана Рушад тагын башлаган эшен бүлеп бөтәнен алгандыр күк тоела. Аныңча, бу коточкыч хәл. Күпме вакыты әрәм булды. Анысы шулай, ләкин әгәр дә яңасы элеккесеннән яхшырак булса? Күрәсең, сәнгать әсәре шулай мең газаплар белән туа торгандыр инде. Ана комачауларга гына кирәкми.

Бу сәгатьләрдә Шәрифә үзе дә Рушад янына керми, балаларны да әтиләре янына җибәрми. Дөрес, җәй көне балаларның буяуларга әллә ни исе китми, алар Идел буен артыграк күрәләр. Ә Шәрифә үзе ялда булса да, әллә ни ял итми, хатын-кызга дачада да өй эше табылып кына тора. Быел ул курортка барудан катгый рәвештә баш тартты, Рушад үгетләп-үгетләп караса да, булдыра алмады, ә балаларга, бигрәк тә кечеләренә, әниләренең өйдә булуы рәхәт. Үзләре пионер лагерена өченче сменага гына баралар.

Хәзер Рушад Даманский батырына багышланган картина яза иде. Аның белән ул байтак газапланды. Ул Әнвәр Зәйнетдиновны күреп белми иде. Фоторәсемне кабатлау — шулай ук художник эше түгел. Ул яшь совет солдатының художество образын тудырырга булды, ә Әнвәр бары тик прообраз гына булып калды. Шулай да, художник фантазиясе булуга да карамастан, бер яхшы теләк белән генә моңа ирешә алмыйсың. Бәхеткә каршы, Рушад үзе Ватан сугышы вакытында бронетранспортерда механик булып хезмәт иткән иде. Хәзер техника да, тактика да үзгә булуга карамастан, Рушад таныш стихиясенә чумгандай булды. Әнвәр дә бит бронетранспортерда хезмәт иткән!

Картина туудан ерак иде әле, хәзергә аның гомуми сызыклары гына бар, детальләре хыялда булса да, киндергә төшмәгән. Рушадка барысын да күңел күзе белән күрергә туры килә. Подразделение инде сугышчан боерык алган, берничә минуттан бронетранспортерлар кузгалып китәргә тиеш. Яшь совет кешесенең беркайчан да сугышта булганы юк, җитмәсә, ул кытай халкына дус рухта тәрбияләнгән. Нишләр, яшь буын шул катлаулы хәлдә аптырап калмасмы? Сугышта аптырау, илгә, халкына ышанычының югалту бары тик һәлакәткә генә илтүе мөмкин. Яшь совет кешесенең йөзендә шул катлаулы кичерешләр дә, аның аталары, өлкән абыйлары байрагына турылыклы булуы да — барысы да, барысы да чагылырга тиеш. Рәсемдә сүз юк, күз карашы, яктылык һәм күләгәләр, үлчәп салынган буяулар барысын да хәл итәргә, художникның уй-тойгыларын, илгә мәхәббәтен, дошманга

көйдергеч нәфрәтен күрсәтергә тиеш. Бәлки, әдәбиятта, музыкада бу эш җиңелрәктер, бәлки, аларның үз кыенлыклары бардыр. Әйе, сәнгатьнең һәр төре ифрат катлаулы, һәр төре үзенә генә хас читен мәсьәләләрне хәл итә. Әҗәткә бер нәрсә дә алып булмый.

Заводта квартал яки ел ахырында нинди киеренкелек тууы Рушадка бик яхшы билгеле. Хәзер дә ул нәкъ шул чактагы кебек эшләде. Картина күзгә күренә торган төс ала барса да, киеренкелек кимемәде. Рушад шактый ябыкты, әмма күзләрендәге ялкын көчлерәк ургылды, гүя атаканың хәлиткеч минуты якынлаша иде. Шунысы бераз гаҗәбрәк, иҗат кешесенең батырлыгын да, кыюлыгын да күрүче юк, гүя ул картинасын бик тыныч яза, гүя әле бер, әле икенче буявын буйый гына.

— Рушад, әгәр гел шулай яна торган булсаң, мин, ярдәм сорап, врачларга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булырмын,— диде Шәрифә, сабыр савытлары тәмам тулгач. Ул үзенең ялын яхшылап күрмәде дә. Хәзер эшкә чыкканга Рушадны да күзәтә алмый иде.

— Зинһар, алай итә күрмә. Мин синең таләпләреңә үзем буйсынырмын. Кара, бетеп килә бит инде. Тагын бераз гына эшлисе калды.

Рушад калтырана иде, аның «бераз гына» дигәне бер дә бераз гына түгел, моны инде Шәрифә яхшы төшенеп килә иде. Сәнгать әйберенә нокта кую — иң авыр эш. Әгәр шундый чакта йөрәк кызгану хисенә бирелеп, үз дигәнең генә алга сөрсә, файда китерү урынына картинаны да, ирен үзен дә харап итүе бар. Рушад гүя акылга җиңеләеп киткән, бары картинасын гына белә. Аңа хәзер врач та, дару да, больница да кирәкми, аңа бары тик дуслык кына ярдәм итсә итәр.

— Их, минем хәсрәтем,— диде Шәрифә иренә һәм кулыннан килгәнне барысын эшләде. Ашларның тәмлесен генә хәзерләде, вакытында ял да иттерергә тырышты, һавага да алып чыкты. Рушадның башына ял бирү өчен сәнгатьтән ерак нәрсәләр турында сөйләде, көлде, көлдерде.

Хатын-кыз йөрәге чиксез яратучан һәм чиксез кайгыртучан. Заводта Шәрифә парторг янына керде һәм:

— Мин тагын сезнең янга килдем әле, тагын хәсрәтемне сөйләргә тиешмен,— диде һәм Рушадның ничек эштә януларын сөйләде.— Тик мин зарланырга да, Рушадны үгетләргә чакырырга да килмәдем. Чөнки бу файдасыз.

— Аңлыйм. Теге вакытта сез авыруга бер юаныч кына булсын дигән идегез. Хәзер ничек соң, сул кулы белән чынлап эшлиме?

— Ул эшкә һәрвакыт җитди итеп карый. Мин, әлбәттә, аның картиналарына бәя бирә алмыйм, үзегез бер кереп чыксагыз, күрер идегез.

— Хәтергә төшерүегез өчен рәхмәт, Шәрифә ханым. Без көндәлек эшкә күмеләбез дә кайчак мөһим нәрсәләрне дә онытып җибәрәбез. Иртәгә үк барып чыгарга тырышырмын.

— Рәхмәт. Тик бу көннәрдә Рушадны эшеннән бүлдермәскә идегез. Бетмәгән эшен ул сезгә барыбер күрсәтмәс. Эше беткәч, үзем сезгә килеп әйтермен.

— Яхшы, алайса, шулай килештек.

Парткомга кереп сөйләшүе турында Шәрифә иренә бер сүз дә әйтмәде. Килгән-киткән кардәшләрне дә, дусларын да Рушад янына кертмәде, төрлесенә төрлечә хәйләләде, тизрәк Идел буена алып чыкты. Көннәр хәзергә ару тора, урманда яки көймәдә йөрүләре бер рәхәт. Кич Рушад үзе кунаклар янына чыга, кайчак күңелле итеп, теләп сөйләшә, кайчак йөзе бик сүрән була. Шәрифә сорамаса да моның сәбәпләрен белә: я Рушадның эше алга киткән, я ул, берни эшли алмыйча, сәгатьләр буе газапланган. Икәү генә калгач, түземи, сорап куя.

— Күп тә калмаган, тик йөрәгемне ахыргача ачып бирә алмыйм, Шәрифә. Һаман күңелем канәгатьләнми,— ди Рушад.

— Ә син шул җимешләрне дә капкала, аннары Иделгә ешрак кара. Кайчагында Идел кеше әйтә алмаганны әйтеп бирә бит. Ярына чыгып утырсаң бигрәк тә. Күрәсең, янына утырганны, серләшергә килгәнне сизә.

Ахрысы, Шәрифә чынын әйткән, Идел ярына чыгып серләшә торгач Рушад эзләгәнен тапты һәм шуннан соң озак та үтмәде, соңгы ноктане куйды. Ә вакыт төрле кеше күзлегеннән озын да, кыска да күренә. Шәрифәгә әлмисак үтте кебек. Заводта парторг аны берничә тапкыр очратып:

— Мин һаман көтәм бит, Шәрифә ханым. Бу вәгъдәсен онытты дип уйламагыз,— диде елмаеп.

— Мин дә сөйләшүебезне онытмадым. Рушад кына һаман эшен очлый алмый, тәмам ябыгып бетте, иртәдән кичкә кадәр мастерскоенда хәтта кеше белән дә сөйләшми башлады.

— Өзлегә күрмәсен.

— Үзем дә шуннан куркам.

Ниһаять, Шәрифә, бер көнне ирен көләч йөз белән күргәч, яшерен шатлык тоеп:

— Рушад, әллә тәмамладыңмы? — дип сорады.

— Шулай бугай. Әйдә күрсәтәм.

Алар пыяла мастерскойга чыктылар. Картина рамкага куелып, стенага эленгән иде. Шәрифәгә ул күптән таныш һәм шул ук вакытта өр-яңа булып тоелды. Әлбәттә, Рушадның шулкадәр озак вакыт нәрсә белән газаплануын абайламады, монысы хәзер мөһим дә түгел иде. Картина тулысы белән аның каршында. Ул Әнвәр Зәйнетдинов турында кат-кат укыган иде. Аның үлемгә каршы барганын белә. Ләкин картина яшәү рухы, җиңү рухы белән тулы, ул Ватанның бар нәрсәдән олы, изге булуын раслый. Ватан намына бу яшь совет солдаты утка да күзен йоммыйча керәчәк...

Шәрифә тиз генә артына борылды. Рушад, кулларын салындырып, стенага сөялгән. Ул бик арыган кебек булса да, йөзе илһамлы, күзләре яна, иреннәрендә әз генә канәгать елмаюга охшаган бер нәрсә сизелә иде.

— Рушад,— дип, Шәрифә иренең күкрәгенә капланды. Ул күңелендә ташыган тойгыларны аңлатырлык сүз тапмады. Хәер, бу минутта ул кирәк тә түгел иде, Рушад болай да барысын аңлады.

Берничә көннән соң Шәрифәгә ияреп, хәл белергә дигән булып, парторг килде.

— Мин авыру янына киләм дисәм,— диде ул бик җылы күрешкәннән соң,— сине бөтенләй яшәргән хәлдә күрәм. Тьфү-Тьфү, Рушад, күзем генә тимәсен. Әзрәк эшләштергәлисең дәме? Мастерскоеңны да караган юк бит әле.

— Килмәгәч, ничек карыйсың. Завод эше булса карар идең, пенсионер хәлен завод ишек алдында хатынынннан сорасаң да ярый.

— Тәнкыйть? Без инде аңысына күнеккән, дус кеше!

Алар өчәүләп якты террасага керделәр. Бу юлы инде башка картиналар да эленгән. Парторг завод хәлләрен чагылдырган картиналарны карады, кайберләрен таныды, соклануын белдереп телен шартлатты.

— Үзләре күргәннәре бармы? — диде, завод алдынгыларының рәсемнәренә карап.

— Юк, чакырганым юк, үзләре килми.

Парторг арадагы иң зур картина алдына килеп туктады. Ул Даманский батырларына багышланган «Ватан шуннан башлана» дигән картина иде.

— Менә Рушад Һилалович соңгы вакытларда нәрсә белән утырган икән! Шәрифә ханым да әйтмәде.— Парторг шелтә белән аңа карады.

Аннан тагын картинага борылды. Якынрак килеп тә, арткарак чигенеп тә карады.— Кайчандыр мин Ерак Көнчыгышта чик буенда хезмәт иттем. Ул чакта чик буе башка иде. Ә хәзер... Рушад Һилалович, бу — яшьләргә лаеклы бүләгегез булыр.

— Үземдә дә шундый уй бар иде. Көз армиягә китүче яшьләребезгә бүләк итәрмен дигән идем. Шуңа ашыктым да.

— Шәп идея. Тик аңарчы культура сараеның зәңгәр залында күргәзмәңне оештырыйк, Рушад Һилалович. Күрсеннәр, уйласыннар! Мин бу күргәзмәнең төп темасын «Коммунист батырлыгы» дип билгеләр идем.

Рушад башын селекте.

— Әллә тетеп салырлар дип куркасыңмы? Дөрес, кайберәүләр партия, коммунист, Ватан дигән сүзләрдән куркалар, дөресрәге, аларны безнең аңнан алып ташларга маташалар. Сәнгать көрәш мәйданы, Рушад Һилалович, ә сез партиянең турылыклы солдаты.

Рушад хатынына карап алды.

— Ничек, Шәрифә?

— Мин парторг тәкъдиме белән килешер идем.

Кинәт әллә кайдан, җир астыннан чыккан кебек, кыргый җырмы, мөңгерәүме ишетелде. Парторг гаҗәпләнеп тәрәзәдән карады.

— Бу — Хайбас. Күрше авылда шундый бер тиле егет бар,— диде Шәрифә.

Рушад гүя берни ишетми, ул актарылып торган Иделгә караган. Кай арада җил чыккан да, күк йөзе кара кучкыл болытлар белән каплана башлаган. Икенче якта әле һаман кояш көлә. Җил көчәйгән саен аның җиңелмәс нуры арта бара төсле.

## Зәки Нури

# ЛИРИКА ҺӘМ ЮМОР

### Яхшы сүзне яклап

Җиребезгә якты кояш нуры
Килгән кебек ерак-еракта́н,
Яхшы сүз дә җан җылыта ала,
Чыкса әгәр кайнар йөрәктән.

Металларның ныгы, затлылары
Җир куенына тирән күмелгән.
Яхшы сүз дә шулай нык сүз була,
Чыкса әгәр якты күңелдән.

Күргәнем бар кояш яктысын мин
Янып торган зәңгәр күзләрдә.
Яхшы сүзне кирәк якты күздән,
Саф йөрәктән кирәк эзләргә.

### Юлларда йөргән чакта

«Сукмаклар юлга чыгара,
Юллар халыкка илтә.
Елгага кушылган ермак
Диңгезгә барып җитә».

Бу сүзне мин күп ишеттем —
Күп җирдә, төрле якта.
Исемә кат-кат төшердем
Юлларда йөргән чакта.

Яуда мин шуны кабатлап
Күп тапкыр кердем утка.
Фашистка төбәп атканда,
Шуны да кордым тупка.

Булды чак — тубы, бомбасы,
Безгә төбәлде бар да.
Булды чак — кышын йокладык
Күмелеп тирән карга.



Җиңәргә ләкин үлемне
Җитте көч, җитте түзем.
Йөрәкләр канат иттеләр
Изге бердәмлек сүзен:

«Кушылды безнең
сукмаклар,
Чакырды Ватан юлга.
Ермаклар елга булдылар,
Диңгезгә җитәр елга!»

...Һөҗүмдә һаман илебез,
Авыр йөк безнең иңдә.
«Юллар халыкка илтә!» дип,
Шул сафта атлыйм мин дә.

Сукмакларны кушып, юллар
Юнәлә төрле якка.
Маягым иткән җырым бар
Юлларда йөргән чакта:

«Яшәсен җирдә уртак юл,
Юл ача күңел күзен!»
Бу — минем кыйблам
яктысы,
Илемне сөю сүзем.

## Йолдызлы кыз

Йолдызларга юллар ерак, диләр,
Мин йолдызга әле менмәдем.
Эзләмәдем сине йолдыздан мин,
Син андадыр диеп белмәдем.

Күз нурымны күккә төбәмәм мин,
Үз нурыңны җирдә эзләрмен.
Күкрәгеңдә алтын йолдыз балкый,
Явын алып минем күзләрнең.

Күзләреңнән синең очкын ява,
Хәтерләтеп якты көн йөзен.
Син генә бит минем йолдызлы төн,
Син генә бит минем көндезем.

## Эзләрмен бары сине...

Юлларны мин күп таптадым,
Узылды тары-киңе.
Атладым синең артыңнан.
Эзләдем бары сине.

Сине юлга озатканда,
Ак күлмәк кигән идем.
Гомергә сине югалтмам,
— Югалмам! — дигән идең.

Син кышын киттең фронтка,
Аерды безне сугыш...
Яратам хәзер буранны —
Ул синең изге сулыш.

Шул буранда сине эзләп
Һөҗүмгә керәм кебек.
Нинди юлдан атласам да,
Эзеңне күрәм кебек.

Нәләтләр яусын сугышка!
Ник безне аерды ул?
Икебезгә бер пар булган
Канатны каерды ул...

Исәрмен җитез җил булып,
Су булып агармын мин.
Күңелдә гел сине эзләп,
Гел сине табармын мин.

## Җир яме

Ана сөте белән эчтек
яктылыкны без.
Бер кояштан алдык бөтен
яхшылыкны без.
Бары тик үзебез өчен
алмадык ләкин,
Җир-күктән яшереп запаска
салмадык ләкин.
Алдык — караңгыга каршы
көрәшер өчен,
Алдык — җир гизеп, дусларга
өләшер өчен.
Юлчыларга маяк булып
күрен, яктылык,
Балкыт син безнең бәйрәмнәр
түрен, яктылык.
Күкләрдә безнең яктыр син
мәһабәт булып,
Йөрәккә һәм күзләргә кер
мәхәббәт булып.
Син безнең намус илчесе,
без юкта — юк син.
Яу купса әгәр — яшен бул,
дошманга сук син.
Ерактагы якыннарга
елмаеп яктыр,
Солдатлар белән постта син —
постыңда сак тор!
Без сине кояштан алдык,
син — яме җирнең.
Без түккән каннар сафлыгы,
без түккән тирнең!
...Җиңелер, һаман чигенер
караңгы төннәр.
Чөнки без — яктылык дусы...
менә без кемнәр!

## Булмый

Тәтенсез булмый утлар,
Якты — җылысыз булмый.
Көпшәсез булмый туплар,
Кылыч — кынысыз булмый.

Көннәрсез булмый айлар,
Авыл урамсыз булмый.

Явымсыз булмый җәйләр,
Кышлар буранссыз булмый.

Баш бәреп булмый ташка,
Суга сын ясап булмый.
Юк... Булмый синнән башка,
Бу җирдә яшәп булмый.

## Памир язы

Кошлар хәлен җирдә белеп булмый,
Күккә менеп үзең очмасаң.
Дүшәнбегә биш сәгатьтә җиттек! —
Тизлеге дә тизлек, ичмасам!

Рәхәт монда күрү бакчаларның
Апрельдә үк чәчәк атканын;
Җылы сүзнең таҗик йөрәгендә
Алтын хәзинәсе ятканын.

Сокланасың Памир куәтенә,
Биеклеген аның күрәсең.
Нигезенә Нурек ГЭСының син
Бер таш булып гүя керәсең.

Ак түбәтәй кигән ак түбәләр
Әйтерсең: «Мен, айдә!» дип әйтә.
Батырлыкка шулай өндәп тору
Менмәсәң дә көчне күбәйтә.

Җыр да монда таудай көчле — аны
Җәйләүләрдә чабан көйләсә.
Заставада исә — кырыс тынлык,
Чик сакчысы катгый сөйләшә.

Ә цехларга керсәң күңел эри,
Кызлар йөзе шундый сөйкемле,
Бер матуры ефәк җепләр белән
Йөрәгеңне урар шикелле.

Тракторлар мамык кырларында
Сырлый язның тәүге хатларын...
Мин күңелгә сурәт итеп сызам
Дусларымның туган якларын.

...Дүшәнбегә биш сәгатьтә җиттек,
Тизлеге дә тизлек, ичмасам!
Дуслар хәлен читтән белеп булмый,
Очып барып үзең кочмасаң.

## Кирәк һәм мөмкин

Җайдак атсыз була алмый,
Мылтык сунарда кирәк.
Суда йөзә белер өчен
Суга чумарга кирәк.

Әйбер һәм намус сатулар
Бары базарда мөмкин...
Бары дөрес уйлап кына
Дөрес язарга мөмкин!

## Тауларга менгәч

Таулар, таулар... Тауда ак кар ята,
Күз чагыла озак карасаң.
Кояш уйный таулар түбәсендә,
Тарлавыкта — әле кара таң.

Таң балкышы тиздән җиргә төшәр —
Үз юлыннан кыю бара таң...
Түбән җирне яхшы күрер өчен
Биеклеген җирнең яратам.

## Туйда

Булгандыр көнгә ун тапкыр
Күрми калмаган чаклар,
Булгандыр хәтта төшләрдә
Күрә алмаган чаклар.

Булгандыр «сөямсең?» диеп
Көн саен сорашулар,
Булгандыр шаркылдап көлү,
Булгандыр елашулар.

Булгандыр көн дә хат язып,
Көн саен хатлар көтү,
Мәңге ташлашмабыз, диеп,
Булгандыр антлар итү.

Син аем, син кояшым! дип
Булгандыр тиңләшүләр,
Ят күләгә күренсә дә,
Булгандыр көнләшүләр.

Мин күп көтәм, ә син аз! дип
Булгандыр санашулар,
Булгандыр пышылдап сөйләү,
Кычкырып талашулар.

Булгандыр тәүге үбүдән
Башның әйләнгән чагы...
Авыр чак ул — чәчнең чәчкә
Бергә бәйләнгән чагы!

Без туйда бит — күтәрик бер
Шуларны искә алып:
Яманын аста калдырып,
Яхшысын өскә салып.

## Урманда

Килеп чыктым шундый урынга:
Сагыз исе бәрә борынга.
Күзләр чагыла кояш нурыннан,
Колак чыңлый кошлар җырыннан.
Рәхәт монда тавыш аулавы,
Серле монда усак шаулавы.
Күккә ашкан нарат-ракета
Күңелне — киң, уйны шат итә.

Тар сукмаклар уза ешлыкка —
Күләгәгә китә, ышыкка.
Үлән куе... чалкан ятмыйм мин,—
Син булмагач, монда ятим мин.
Шомыртларга, ахры, чык кунган
Иртә белән. Алар шушыннан
Торып хәзер бөтен җир шарын
Аңкыталар төсле тоела.
Әллә каян сизеп җим барын,
Бал кортлары шунда җыела.
Җир җиләге — эссе җәй яме,
Күзләремә баккан кызыл күз
Әйтә кебек: мин бит бәйдәмен,
Кулларыңны миңа үзең суз!
Мин теләмим җиләк җыярга...
Сыем итеп кемгә куярга?
Җирне сыйпыйм кинәт чүгәләп:
«Китәм инде, сау бул, күбәләк!»
Кыңгырау чәчәк чыңлап кала күк,
Чикерткәләр аваз сала күк:
Онытма, дус, букет өзәргә,
Йөрәгеңнең гыйшкын бизәргә.
Кил безгә син таңнар атканда,
Күңелдәге таңың белән кил,
Бездә рәхәт парлап атларга...
Кыскасы, син аның белән кил.

## Кинаяле бүләк

Күрше өенә күрше
Муенчак тотып керә,—
Ачуын көчкә яшереп,
Кайгысын йотып керә:

— Чучкагызга бүләк алдык
Кызганмый акчабызны.
Чөнки бүген сөреп чыккан
Яшелчә бакчабызны...

## Чамалы аршин

Бер абзарга карап ярыктан,
Көлә икән Чучка Сарыктан:
«Чүп-чар капмый, сазда аунамый,
Тормыш ямен дөрес аңламый».

Беләм, Чучка шулай диячәк
Һәм якыннан күреп, һәм читтән...
Арала син, зинһар, арала
Безне, тормыш, шундый тәнкыйтьтән.

## Җыелыштан соң

Бригадир кыса балта остасын:
— Тәнкыйть сүзеннән килде косасым.
Шуның өченме теге чакта син
Алдың бүрәнә, чәлдең тактасын.
Шуның өченме прогул ясадың,
Шабашник булып йөрдең язларын.
Шуның өченме бүләк бирдердең?..
Ай-һай, күрше, тиз азып өлгердең.
Шуның өченме өстемә күпләп
Пычрак аттың син мине тәнкыйтьләп?
Ант иткән идең: дустым, әшнәм, дип,
Мин сиңа каршы бер сүз дәшмәм, дип.
Кинәнер идем тәнкыйть сүзеңә,
Үзара әйтсәң бары үземә.
Кеше алдында мине кызартып
Телләнү нигә? Андый сүз артык...
Инде нәтиҗә шул дип чутла син:
Иртәгә миңа эшкә чыкма син! —
...Шулай бетерде әйтер сүзен ул,
Кыйнады шулай үзен-үзе ул.

## Телефон турында телефоннан сөйләшү

Станцадан кисәтәләр: — Дүрт айга
Түләмисез ник телефон хакын? — дип.
Хуҗа әйтә: — Хатын гына тәкелди,
Һәм түләргә тиеш аны хатын! — дип.—
«Тәкелдәү»не нинди сүз ул дисезме?
Ну, сөйләшә... көне буе лыгырдый.
Берәр сүзне ишетмичә калганда,
Телефонны тирги: «Чукрак убыр!» ди...
Ну, кыскасы, шуннан артык бернәрсә
Әйтә алмыйм бу мәсьәлә хакында.
Тагын бер кат шалтыратып үзегез
Бу дәгъваны белдерегез хатынга.

## Кирәксез очрашу

Аркасында әвен хәтле биштәр,
Әкрен атлый — арган-талган ул.
Бер танышы юлда очрата да
Сизеп ала: хәтта салган ул.

— Бәй, кайдан син? Чирли дип ишеттем,
Профессорлар лечить итә дип...
— Ауга бүген соңгы тапкыр бардым,
Больничныем чөнки бетә бит.

## Хәйләле хат

«Бик тазарам... Кайтыр көннәремә
Ишекләрне өйдә киңәйт, хатын.
Эштән миңа акча җибәрсеннәр,
Тизрәк барып шуны син әйт, хатын!»

Беләсезме ялда бу иптәшнең
Нәрсә теләп, нәрсә юраганын? —
Туган йортын куандыра белеп,
Ашарына акча сораган ул.

## Илледәгеләр җыры

Артта калды тәүге гыйшкым —
Уттай янып сөюем.
Шуның өчен булыр алда
Бөтен яну-көюем.

Артта калды бик күп газап,
Ут кичкән кырыс еллар.
Алга атлар өчен шуннан
Сызылсын дөрес юллар.

Артта калсын хаталарым,
Булдылар алар, аңлыйм.
Алдагы юлга аның мин
Бер бөртеген дә алмыйм.

Артта калды илле елым,
Алда — алтынчы дистәм.
Аерма, язмыш, җырлардан,
Аерма кайнар хистән.

Артта калды илле яшем —
Яшьлегемнең картлыгы.
Картлык яшьлегемә керәм...
Кирәк түгел артыгы!

## Шәйхи Маннур

# КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕННӘН

## Төн уртасы

Төн уртасы,
Җиде төн уртасы.
Җирне урый татлы төшләрнең
Зәңгәр путасы...
Күкләр тулы күзләр ноктасы,
Кемнәр карый аннан?..
Кызык микәнни соң
Кешеләрнең
Сәрхуш дөньясы?..

Җир күзләре күккә кадакланган:
Бу төн анда —
Киек каз юлы.
Диңгез кичәр кошлар агымыннан
Ишетелә сыман
Яз җыры,
Наз җыры...
Ә миңа ул төнге сагыш кына.
Зарлы тавыш кына
Урый төсле бөтен җир өстен.
Чөнки мин исерек!
Мин бу төн
Ялгыз башым эчеп исердем.
Юк, азудан түгел,
Юл язудан түгел,
Сагышыннан шул бер исемнең
Бер ялгызым эчеп исердем.
Исерүләр юандырмый,
Беләм! —
Томан гына каплый күз алдын.
Исерттең дә язгы назың белән,
Әйт,
Нигә син,
Кая югалдың?

Диңгез сөйли миңа үз серләрен
Төннәрен дә
Тынмас җырында:

Бу ярларда күпме сөюләрнең
Балкып туган көне турында,
Бу ярларда күпме сөюләрнең
Батып үлгән төне турында.

Безнеке дә
Шулай үлдемени?..
Мин дәмени
Сүнгән исемнең
Сагышыннан
Шашкан байгыш сыман
Бер ялгызым
Эчеп исердем?..

1969

## Гаепле мин

Гаеплиләр мине усаллыкта,
Каты сүздә,
Инсаф җитмәүдә,
Баш бирмәүче
Кырыс булганлыкта,
Бүтәннәрне хөрмәт итмәүдә,
Тагын әллә нидә, әллә нидә...

Гаепле мин:
Күптер ялгышым да,
Бирмәстәйгә бирмим кулны да,
Бу тормыштан узып барышымда
Сапмастайга сапмыйм юлны да.

Гаепле мин:
Түзмим,
Кызамын да
Кыекларга туры бәреләм,
Шул бәрелгән сүздән кайчагында
Кан саркадыр бәгырьләреннән!

Гаепле мин бик күп бәлаләрдә:
Елмая да белмим яманга,
Хөрмәтем юк шома бәндәләргә,
Нәфрәт утым ярсый ялганга!

Гаепләрем минем хәттин ашкан,
Иң хәтәре — «сабырсыз»лыкта,
Тик гаепли алмас хәтта дошман:
Явызлыкта,
Намуссызлыкта!

Тик гаепли алмас хәтта бере —
Сафсызларга ярaклашуда;
Юл өстенә чыккан чакта бүре
Юлдашымны ташлап качуда.

1970

## Дәшмисең...

Җир тартымын җиңеп,
Һавасызлык чүлен гизеп;
Радиация чыбылдыгын ачып,
Җилдән җиңел калу
Авырлыгын татып;
Тагын күпме каршылыклар кичеп,
Күпме корбан биреп
Менә торгач,
Айга менде Кеше,
Беренче эз салып атлады.
Һәм таң калды:
Җирдән күргән ише
Матурлыкның
Берсен тапмады!

Үле ташлар,
Утсыз кратерлар,
Сулары юк «Яңгыр диңгезе»...
Тик шулармы сөю уяттылар?..—
Алдадың ич, Ай дус, син безне!

Көтә идем
Мин яшертен генә —
Җан иясе
Синдә булуын.
Космонавтның
Куык битлегенә
Ичмаса, бер черки кунуын!
Ичмаса, тик мескен бер үлән
Тибрәнүен кичке җил белән!
Син, моңсу Ай,
Тузан-таштан икән...
Ул ташлардан нинди файда бар...
Мин табасым килә сине күктән:
Әй, Кеше!
Син тагын кайда бар?

Әй, Кеше!
Син — галәм падишасы,
Син кайларда тагын яшисең?
Табышасы килә,
Танышасы!
Мин кычкырам,
Ә син — дәшмисең...

Әллә чынлап
Җирдә берүземме?
Чынлап та мин
Алла колымы?
Марсияннар,
Сез дә үлдегезме?..
Легендалар — юк сүз булдымы?..

Үлем чаршауларын үтә-сүтә
Керә Кеше Галактикага.
«Илаһи сер»
Бармы-юкмы күктә?
Барын белү кирәк бит аңа!
Әй, Кеше!
Син — галәм падишасы,
Син кайларда тагын яшисең?
Табышасы килә,
Танышасы!
Мин кычкырам,
Ник син дәшмисең?

1969

## Егет җыры

Биш атламны бер атлаган сыман
Мин атлыгып үргә менәмен.
Маңгаемны ак энҗеләр сырган,
«Дөп-дөп» килеп тибә йөрәгем:
    Типсен йөрәк, ә мин ашыгам —
    Барып җитәр өчен ашкынам.

Наратлыктан искән җиләс җилләр
Күкрәкләргә килеп урала.
— Ашыкма син, туктап ял ит,— диләр,—
Әллә нәрсә булмас ул ара.
    Юк, ашыгам шул, мин ашыгам,
    Сез исмәгез миңа каршыдан.

Тау буенда каен җиләкләре
Күз кысалар:
— Туктап кит,— диләр,—
Күрмисеңме ахак тәлгәшләрне?
— Иелеп бер авыз ит! — диләр.
    Юк шул, юк шул, вакыт табалмыйм,
    Туктап сезне өзеп кабалмыйм.

Агачларда кошлар сайрый моңлы,
— Туктап безгә колак сал,— диләр.—
Йөрәклардән туккән дәртле җырны
Таш булмасаң, отып кал! — диләр.
    Таш түгел дә... Күңел ашыга,
    Серле сукмак мине чакыра.

Серле сукмак, тау өстенә менеп,
Югаладыр урман эчендә...
«Урман кызы» көтә шунда,
Үзе кебек
Зифа буйлы каен төбендә.
    Мин ашыгам аның янына —
    Сагынып көткән сөйгән ярыма.

Иреннәре аның җиләк булыр,
Иркәләве — йомшак җил булыр.
Миңа гына әйткән сөю сүзе
Кошлар җыры белән тиң булыр.
Шул җыр өчен аңа очамын,
Ул көтә бит җәеп кочагын!

1961

## Хаклымы күңел?

Бик ашыгыч китеп бара идем,
Туктатты бер апа урамда:
Рәхмәт әйтте,
Кулны кысты минем,
Аңлый алмый алҗып торганда.

— Һич онытмам сезнең яхшылыкны.
Зур бәладән мине йолдыгыз.
Берәү бер күрмәсен ул шомлыкны!
Үзегез дә имин булыгыз...

Шаярта дип уйлыйм,
Көлгән булам:
Гаебем юк яхшылыкта! — дим.—
Яхшылыклы бүтән берәү булган,
Рәхмәтегез миңа — юкка! — дим.

— Түгел, энем.
Яхшылыкның йөзе
Саф чишмәдәй ачык күренә.
Явызлыкның гына майлы сүзе
Ефәк корты булып төренә...

Ышандыралмадым мин апаны,
Китеп бардым гафу үтенеп:
Мин дип белеп яхшы бер башканы,
Ялгышуы өчен үкенеп.

Ә шулай да,
Һичбер көтмәгәндә
Рәхәт булып китте күңелгә.
Әйтерсең
Мин үзем эшләгәнмен
Әйбәт бер эш!
Белмим, тик кемгә?..

## Табармы?

Хәтәрдән дә хәтәр
Корал көчен
Эзли кеше,
Эзли ашкынып.
Потенциядәге дошман өчен
Әзерли ул үлем ташкынын.

Серләр сере төрләренә табан
Кerә бара титан акылы.
Мылтыкны ул
Миллион елда тапкан,
«Атом-төш»не — ун ел аркылы...

Акыл белән аллага тиң кеше
Табар микән тәкать үзендә?
Тәкәнмәсме аның сабыр көче
Иң җаваплы
Авыр мизгелдә
Кагылмаска
Актык бер төймәгә?..

Ана кочагыдай шушы җирне
Ай шикелле үле итмәскә,
Үзе тапкан үлем көче белән
Үз башына үзе җитмәскә
Акыл табармы ул?..

## Әшулай да...

Ышанасым килә кешеләргә,
Гәрчә бик еш алдасалар да,
Гәрчә күпләр
Минем ишеләргә
Күктән генә карасалар да.

«Дивана ул!
Бик тиз инана ул!
«Утыртуы» аны бик ансат!» —
Дип көлсә дә миннән замандашлар,
Йөри алмыйм эчтә кер саклап.

Тик эрнимен.
Түбәнлеккә эрним,
Явызларга,
Гаделсезләргә.
Үзен саклап,
Вөждан таптап әйткән
Җан кыючы ялган сүзләргә.
Әшулай да,
Ышанасым килә кешеләргә —
— Әйбәтләре дөнья тулы! — дип.
Син тормышта авыр яшәгәндә,
Ярдәмчең дә —
Кеше кулы бит.
Кеше кулы бит...

1964

●

Уйный диңгез,
Уйный минем белән,
Бер күтәрә,
Ун кат батыра.

Батырса да,
  Холкын яхшы беләм:
Өйрәтә ул батмый калырга.
Тагын менәм дулкын сыртларына,
Дүрт кул белән
  Ялына ябышам.
Киләм төсле мәйдан уртасына
Сабан туендагы чабыштан.
Йота-йота тозлы суын аның,
Чапаланам,
  Карыйм артыма.
Ә ул,
Чайпап зәңгәр канатларын,
«Еракларга йөз!» дип чакыра.

●

Күп бирәм мин әйбәт киңәшләрне,
Әгәр берәү килеп сораса.
Шаккатырам хәтта иптәшләрне:
«Акыллы син, дускай, ичмаса!» —
Дип үтереп мактый алар мине...
Әй сөенәм!
Авыз — бер колач!
Тик үземә кирәк чакта инде...
Килеп чыга баштан чи умач!
Үзеңә юк әйбәт акылыңны
Бирү җиңел бүтән кешегә:
Ирешәсең,
  Түкми «бакырыңны»,
  «Яхшы кеше!» дигән исемгә...

1967

●

Йомшак кына карлар явып узган
Иртә кышның
  Көмеш кичендә
Икәү генә атлап ап-ак юлдан
Йөргән чаклар
  Һаман исемдә.
Урам тулы якты утлар иде...
Мәңге үлмәс — шул минутлар инде...

●

Күзгә болай күренмәсә дә ул,
Сизәм:
Йөри якында гына.
Әллә каян кинәт суза да кул,
Уйламаган чагыңда гына
Кысып-кысып ала йөрәктән,
Тез астыңа суга бертәттән.
Куркытмакчы була:
Уйла, имеш, уйла
Аның хакында гына,
Янәсе ул — якында гына!
Юк, курыкмыйм әле,
Яшим әле,
Бирешәсем килми мин аңа!
  Җиң сызганып,
Янып
  Эшлим әле,
Сүзләрем бар әле дөньяга.

Әхсән Баянов

# УТ ҺӘМ СУ

РОМАН[1]



Жәйге көн якты, матур.

Фәезнең дә күңеле чалт аяз. Аңа үзенең кырылмас кәефе, караңгыланмас чырае, эшлекле кыяфәте белән Лазарев ярдәм итә.

Төзелештә күңел төшенкелегенә урын юк.

Фәез җитәкләгән идарә соңгы айларда бермәбер зурайды — чынлыкта бу идарә үзе бер трест инде. Меңнән артык кешегә җитте. Заказлар күбесенчә шул промбаза объектлары төзүгә кайтып кала. Соңгы көннәрдә торак йортлар да салына башлады, чөнки иң төп база — торыр җир, ул — төзелешнең килер көне. Ә калганы була да була инде аның. Завод һәм яңа шәһәр мәйданнарында күз күреме җитмәс җирләр айкап ташланган. Тегенди-мондый машина белән керсәң, урап чыга алмассың — төзелә генә башлаган шәһәрдә урам исемнәре юк, юл күрсәтүче милиционер да юк — адашуыңны көт тә тор.

Фәез үз идарәсенә шул тирәдән дә заказлар алыначагына шикләнми — ул кадәр цехларны аның шушы хәтле зур идарәсеннән башка эшләп чыга алмаслар, әлбәттә.

Иртәнге караңгыдан кичке караңгыга чаклы Фәез — халык, дәүләт кешесе, һәм бу аның өчен иң хәерлесе. Көнелдәге бүтән уйлар урынын да шул ала, шул тутыра — шуның аркасында күңел бөтен һәм тыныч диярлек. Әгәр шулай әйтергә яраса.

Яраса... Чөнки сирәк-мирәк булса да, кем дигәндә ун гына тапкыр ул Каманы исенә төшерә, булачак очрашуларның меңвариантлы планын төзи. Мең арасыннан берсен кабул итте: былтыргы кебек бергәләп, сәяхәткә чыгарга. Шунда кызыклы гына башланган иде, бәлки шунда аңлашу да җиңелрәк булыр. Камага иптәшкә Гета кулайдыр. Калган яклары аның белән сөйләшкәч ачыкланыр. Шул уй белән Фәез Гетага телефоннан шалтыраткан иде, тегесе аны үзе яшәгән тулай торакка чакырды.

Кичке сәгать сигезләр тирәсе. Ишек төбендә беләкләренә кызыл тасма бәйләгән егетләр Фәезне кем икәнен дә сорамыйча уздырып җибәрделәр — беләләр, димәк... Ә эчтә барлык коридорлар (кызыл почмакны әйткән дә юк инде) шыгрым тулы — «шейк» дигән сәер ритм

[1] Ахыры. Башы 9, 10, 11 саннарда.

Фәезне дә бөтереп алып керде. Кешеләрне аралый-аралый Гета бүлмәсенә көчкә барып житте. Фәезне күрүгә, өч-дүрт кыз үзләренчә нигәдер чыркылдашып көлделәр дә ә дигәнче юкка да чыктылар.

— Хәерле кич, Гета.

— Хәерле кич, Фәез. Әйдә, утыр.

Телгә килгән беренче исәнләшү сүзләреннән соң, Фәезнең карашы өстәлдәге дәфтәрләргә төште.

— Синекеме болар?

— Әйе.

— Укырга ярыймы?

— Пожалуйста, тик анда берни дә юк.

Гета артык киемнәрен гардеробка урнаштырган арада, Фәез дәфтәрләрне актарып утырды. Һәр җөмлә, һәр фикер алдында диярлек даталар язылган, аларына игътибар итми генә укыды. «...Комсомол туган көнне флаглар күтәреп чыктык. Агачлар утырттык. «Беларусь» тракторына төялгән акацияләр, каеннар...

Тулай торакларда бәйрәм: бөтенсоюз өмәсенә хәзерләнәбез. Егетләр ишек-тәрәзәләргә пыяла куя, бүтән җиһазларны ремонтлыйлар, ишек алларын чистарталар. Кызлар тәрәзә юа... Җырлыйлар...

Чаллы урта мәктәбен бетергәч, сигез ел да сигез көн Братскида эшләп кайттым. Тәрбия эшенең нәрсә икәнен башлап шунда белдем — ул кешеләрне бәхетле итү дигән сүз икән. Җиңел түгел. Ләкин бөтен җәмгыять шуның өчен тырышкач, куркырга да урын юк бугай. Шунысы шәп түгел, монда кайбер тәрбиячеләр үзләрен танцы оештыручы дип кенә күз алдына китерәләр. Башта аларның үзләрен өйрәтергә кирәк булды. Үзебезнең участоктагы биш комендант белән бүтән шәһәрләргә бардык. Тольяттида берничә тапкыр булдык. Семинарларда булдык, тулай торакларын карадык. Кайткач, үзебез дә шундый семинарлар үткәреп, алган тәҗрибәне куллана башладык.

Тулай торакларда үзешчән сәнгать түгәрәкләре оештырдык, культура, хокук законнары университетлары, кино-лекторийлар...

Уналтынчы торакта беренче комсомол туе! Бәхетлеләр! Мин — тәрбияче, аларның бәхетләрен оештырам, ә үзем... Ходаем!

Алтынчы торакта — КВН.

Производство алдынгылары белән очрашу.

Син туган ягыңны, туган телеңне беләсеңме? — Викторина.

Һәр торакка — телевизор, уку залы, кызыл почмак...

Экскурсияләр — Түбән Кама, Алабуга, Шишкин музее.

Мәхәббәт хакында сөйләштек.— Диспут. Кызык, егетләр кызларны гаепли: тәмәке тартасыз, эш сөймисез, тәртипле түгелсез, диләр. Ә кызлар — егетләрне: аракы эчәсез, хулиганлык белән мактанасыз, диләр...

Авырлык — гаиләле кешеләр тулай торакта яши. Гаиләсезләр квартирларда — алар белән бергә. Җайсыз.

Яшьләр үзләре берниндн кыенлык сизми бугай. Ат кебек эшлиләр, күңелләре шулхәтле күтәренке, зарлану дигәнне белү юк, урын тар дип тә борчылмыйлар. Ай, көнләшәм дә инде шулардан! Карап торсаң, балалыктан да чыгып җитмәгән яшьләр, тал чыбыгы кебек сыек кызлар... Ә тормышта — геройлар! Нишләп мин дә түзүче түгел икән?

Көн саен тәрәзәдән карап калам: кыр казлары кебек тезелеп, төзелешкә китәләр, көләләр, шаяралар, яннарыннан барган егетләрне котырталар. Аларның күңелләре минекеннән мең мәртәбә көчлерәк, чистарак, мең мәртәбә сафрак. Ә мин — тәрбияче! Уйласаң исләрен китәрлек, уйламаска тырышам. Ходаем!

Стена газеталары чыгару — 52, 24, 41 тораклар.

Валитов белән әңгәмә (51). УМС слесаре. Эчү белән мавыга. Иптәшләре белеп торсын.

Шигырь кичәсе.

Лекция — Коммунизм төзү һәм яңа кеше тәрбияләү.
Лекция — Гинекологик авырулар.
Өч көн инде канализация җимерек.
Бытсоветлар сайлау.
Ах, шул кадәр төзүче буласым килә. Мин аларны тәрбиялим дип, ялгыш уйлап йөргәнмен. Мине бит алар үзләре тәрбияли!»

...Фәез дәфтәрләрне актарып чыкканчы, үзенең сары чәчләре белән җилфердәп, каршыга Гета килеп утырды. Фәез аның белән күпме вакытлар дус булып, бер нәрсә диярлек белмәсә, хәзер берничә минут эчендә Гетаның кем икәнен аңлады да куйды. Менә бит ул ни дигән сүз кешенең күңел серен белү!

Кич буе танцевать иттеләр, шунда ук сүз дә куештылар: киләсе атнада — былтыргыча сәяхәт ясарга. Гета Борисны да чакыру ягында икән.

— Син аны һаман да яратасыңмыни әле? — диде Фәез гаҗәпләнеп.

— Кызганам... Бар инде син аның янына, ярыймы? Авырый диләр аны...

Атна чамасы икеләнеп йөргәннән соң Фәез Борисның эшләгән җиренә шалтыраткан иде, һаман авырый, диделәр. Барырга кирәк — хәл белү булыр... Ничек, ни белән авырый икән? Күчтәнәчкә дип, бер шешә коньяк эләктерде. «Артык хәлсез булса, күрсәтмәскә мөмкин».

Соң иде инде — машина чакыртып тормады, җәяү генә китте. Урамнарның пычрак булуы гына бераз көйсез иде. Июнь — яңгырлы ай.

Беренче гаҗәп хәл: почта ящигы авызына язу кыстырганнар иде. Алып караса, нәрсә язылган диген! Фәез үз күзләренә ышанмыйча кабат-кабат укыса да, язу барыбер үзгәрмәде, шул ук: «В этой квартире продается совесть со всеми неудобствами. Оплата по соглашению». Кызлар кулы... Фәез әллә нинди авыр кичерешләр белән язуны бөтәрләп кесәсенә тыкты да звонокка басты.

Борис берүзе һәм шактый йончыган кыяфәттә иде.

— Авырып киттеңмени? — диде Фәез ишек ачылгач та. Тавышында элекке үпкәләшү ачуланышуның әсәре дә юк кебек. Һәм Борис та моны шундук сизде, ахры:

— Менә шулай инде,— дип елмайды да иңнәрен җыерып куйды.

Ярты ел чамасы арада берсен-берсе күралмаслык дәрәҗәгә килгән, очрашыр вакытларда да күрмәгәнгә салышып уза торган кешеләрнең хәзер икәүдән-икәү бер өстәл янында утыруы бераз сәер һәм гаҗәп, билгеле. Алар икесе дә моны сизә, әмма икесенең дә йөзендә ачу галәмәте юк — моның сәбәбе элеккеге якынлыктыр инде. Үчләшү, ачуланышудан икесенә дә файда юклыгын хәзер һәркайсы аңлый, ә килешеп, бер сүздә йөргән булсалар, ихтимал, нәрсәгә булса да ирешкән булырлар иде. Бозылышу бигрәк тә Бориска зыянлы булды, чөнки аның ачуы зуррак иде, шул хис, речьләргә әверелеп, халык алдына барып чыкты. Һәм, кем әйткәндәй, үз тирәнлеге үз битенә кайтып төште. Шуңа күрә, интегебрәк булса да, егетләр бер-берсенә карап елмаештылар, бераз сызлаулырак булса да, бу елмаю борынгыдан, борынгы җәнлекләрдән күчә килгән теш ырҗайтуга һич тә ошамаган иде инде. Сызлау дигәне бәлки әле хәерлегәдер — үкенү билгеседер...

— Менә шушылай яшәп ятабыз инде без,— диде Борис, ниһаять, сүз башлап.

— Нәрсә булды соң сиңа?

— Гриппттан азды.

— Кай төштә азуы?

— Башка сукты. Спазма, диләр.

— Спазма! Мин сиңа тагы күчтәнәч китергән булам.

Борис чын күңелдән шатланып рәхмәт әйтте һәм;

— Врачлар аны, коньякны, йөз граммга чаклы теләсә нинди чирдән дәва, дип әйтәләр әйтүен.— дигән булды.

— Алайса чыгарыйк без аны.— Фәез урындыкка куйган сумкасын ачып аннан бер шешә алды.— Молдаван коньягы.

— Әйбәт, мин яратам аны.

— Бүтән төрлесе юк.

— Минем өчен иң беренче урында ФРГ коньягы, икенче урында әрмәннеке, өченче урында менә шушы. Калганнарына исем китми.

— Булса баш тартмыйсың?

— Билгеле инде.

Йөрәкләрдәге боз шул кырык градустан эреп акты дияргә мөмкиндер. Икенче рюмканы тоткач, инде тавышларындагы тыйлыгу, кысанлык хисләре, хәмер парына әйләнеп, күтәрелеп киткәндәй тоелды, һәм алар иркенләп сөйләшә башладылар — әй дә җылы, якты лабаса. «Карасана, без икебез дә явыз кешеләр түгел икән, бик тиз гафу итә алабыз икән, беребезнең якты карашы җитә дә куя. Шунысы гына кыен: шундый күзләр белән кем башлап карый ала... Ә бу караш, бер уйласаң, чигенү, көчсезлек, икенче карасаң — зур җанлылык».

Бу юлы инициатива Фәездән булды бугай, ләкин ул үзен җиңелгән итеп тоймый — киресенчә, ниндидер югалган нәрсәсен яңадан тапкан һәм тагын да байый төшкәндәйрәк хис итә.

Фәез Борисның монда туганнары юклыгын, баласы белән хатыныңың кайтып киткәнен яхшы белә. Ләкин янына дуслары килмәве гаҗәп тоелды. Бу хакта сорагач, Борисның чырае тагын караңгыланып китте:

— Дуслар юк бит минем, брат.

— Гета? Теге кибетче кыз...

— Ә... Үзең беләсең — үпкәләделәр. Мин просто дус, ә алар күбрәкне өмет итәләр. Кибетче кыз дигәнең бөтенләй ирен үк ташламакчы. Нигә кирәк инде аның иреннән аерылуы? Кирәкми дигән идем — бизде. Менә шулай, брат.

«Ниндидер ир тора инде шәп хатын белән, тугры хатын белән торам дип».— Шуны уйлап, Фәез бүтән сүз әйтте:

— Алардан башка да танышларың бар иде бугай.

— Алары белән ул хәтле якынлык юк. Аркасыннан сыйпарга ирек биргән һәр хатын-кыз үз була башласа, күпкәрәк китәр иде бит.

— Ә менә шулай булып чыга: бер заман бер дустың да калмый.

— Әйе.— Борис башын иде һәм чәкештермичә генә коньякны эчеп җибәрде.— Мин ялгыз кеше.

Бу сүзләрне ул шундый кызганыч бер кыяфәт белән әйтте, әмма кызганыч булса да, аңа ярдәм итү мөмкин түгел — кешегә мондый хәлдә ярдәм итеп булмый шул.

— Нәтиҗә ясарга кирәк инде, Боря, әле син бөтенесен дә югалтып бетермәгәнсең.

— Дуслардан мин артык күпне таләп итәм бугай. Алар һич тә хыянәт итми торган, миннән туймый торган булсын. Ә хыянәт итми торган дус булмый. Шуңа күрә мин аларны табарга да тырышмыйм.

— Менә мин сиңа хыянәт итмәдем.

— Иттең...

— Мин? Сиңа хыянәт иттем? Ничек?

— Ярый инде, Фәез, калсын, отышлы тема түгел бу. Тагын берәрне салсак, хәерлерәк булыр.

— Сиңа ярамый бит, баш...

— Чәнчелсен лә!..

Мондый хәлдә аның белән бәхәсләшеп араны тагын бозмагаем дип, Фәез дә тынды һәм, тагын берәр рюмка эчкәч, үзенең төп йомышын әйтергә ашыкты.

— Хәтереңдәме: без узган җәй Кама буена сәяхәткә барган идек?

— Хәтеремдә.
— Шул сәяхәтне тагын кабатлап булмас микән?
— Дөньяда бернәрсә дә ике тапкыр кабатланмый.
— Ну, икенче төрлерәк...
— Кызларның берсе кияүгә чыкты. Кама исән... Гета исән. Ул сине һаман ярата...
— Ә... Камага әйттеңме соң?
— Аңа Гета әйтергә булды. Мин сиңа килдем. Син риза, ә миңа Кама нишләр.
— Минемчә, барырга тиеш. Бүтән кеше белән буталмый бит, өмете бетмәгән, димәк.
— Уһу, әллә ниләр беләсең син.
Хәтсез вакыт тын утыргач, Фәез Лазаревка Борис хакында яңа тәкъдим белән кермәкче булуын әйткән иде, иптәше кул гына селтәде.
— Ник? — диде Фәез моңа каршы,— югыйсә, дәрәҗәсе төшерелгән офицер кебек йөрисең бит. Штраф срогы үткәндер инде.
— Чакырткан иде, сөйләштек.
— Соң?
— Хатыныңны алып кайтып, адәмчә яши башла, дигән шарт куйды. Мине яңадан чын кеше итеп тәрбияләмәкче,— Макаренко!..
Борисның мыскыллап әйткән сүзләрен Фәез җөпләмәде:
— Ул яхшы ният белән сөйләшкән... Мин аңа ышанам.
— Миңа аның яхшы ниятеннән ни файда, ул миңа яманлык эшләгәч. Чиргә сабыштым менә — шул булды файдасы.
— Әгәр чыннан да хатыныңны алып килгән булсаң, малаең да булса, менә болай ялгыз интекмәгән булыр идең. Бәлки чирләмәгән дә булыр идең, һич югы — грипп азмас иде.
— Әйтүе кыен.
— Кыен булса да — мөмкин. Шулай эшләп кара, юри генә. Чынлап, бәхетле булачаксың, валлаһи дип әйтәм.
— Эшләп карадым инде.
— Соң?
— Килми хатын.
— Ничек?
— Килми, менә шул — вәссәлам.
Шуннан соң Борис ничек итеп Тольяттига баруын сөйләп бирде.
Очрашуның башы — бәхетсез гаиләләр белә торган хәлләрнең мең дә беренче вариантыдыр.
...Борис Тольяттига килеп житеп, кайчандыр үзенеке булган ишекне шакый. Күңеленә шундый рәхәт,— күздән яшьләр килерлек итеп йөрәкне әллә нинди таныш ләззәт кытыклый. Монда Борис чынлап бәхетле яшәгән икән — җанын борчырлык хәлләрне хәтерләми. Ордер алып, хатыны янына — аның эшләгән җиренә канатланып баруы, аныһының сөенеп урыныннан сикереп торуы, өр-яңа өйгә беренче аяк басулары, җиһазсыз өйдә беренче үбешүләре һәм шампанское эчүләре, аннары җиһазлар күчерү, яңаларын сатып алу, сатып алынган һәр әйбергә нәреп кайткан яңа бәхетләр һәм, ниһаять, иң зурысы — малай... Аннары бәби туе, аннары, детсадка барган беренче көн... аннары... аларны санап бетерерлекмени! Гомумән, бәхетне санап була микән?! Бәхет бар ул,— менә шул. Ул һава кебек, эчкән су кебек — бар, һәм шунысы хәерсез — эчкән суга күнеккән кебек аңа да күнегәсең икән. Аның юклыгын бары тик сусаганда эчәргә бер йотым калмагач кына сизәсең. Борисның хәзер чынлап та бер йотым суы да калмады бит инде. Сәбәбе — әлеге дә баягы — гаиләсеннән аерылганда шуны сизмәве булды... Бигрәк кызыклы тәкъдим кебек тоелган иде шул: чит илгә китеп эшләп кайтырга дип аңардан рәсми рәвештә үтенделәр; димәк, үзе өчен генә түгел, ил өчен кирәкле эш булган ул,— югыйсә, алай житди сөйләшмәсләр иде.

Шартлары нинди дигән әле — мондагы эш хакы да саклана, тегендәгесе дә зур... Гомумән, дөнья күрү, чит ил белән танышу — үзе бер вәсвәсә, үзе бер байлык. Шуннан ничек баш тартасың инде?! Авырлыклар да булыр, диделәр, билгеле, тик аның белән генә егет кешене куркыта алмыйсың. Хатыны да ризалашкач, Борис бернидән шикләнмичә, баласын үбеп, хатыны белән чын күңелдән кочаклашып, юлга чыкты. Авырлыклар дигәненә дә, ялгызлыкка да түзде, әмма бүтән бер газап килеп чыгачагын ул көтмәгән дә, уйламаган да икән... Матди яктан ныгыса да, икенче бер байлыгы — гаилә якынлыгыннан мәхрүм булып кайткан иде ул. Дөресен генә әйткәндә, бик артык иркенәергә шартлар булмаса да, вакыт-вакыт хатын урынына ярардай затлар очратмады түгел. Шуннан инде нәтиҗә чыгару да кыен түгел иде: әгәр шундый җайсыз шартларда да читкә сугылырга мөмкин икән, хатыны бөтен уңайлыкларны килгән шартларда гыйффәт саклап торгандыр дип, ничек кистереп әйтергә мөмкин? Юк, алай өзеп әйтүе кыен. Ә менә җайлы шартлардан файдалангандыр дип фараз кылырга бик мөмкин иде. Чынлыкта бу явыз шиккә буйсынмау — Достоевский аңлаган мәгънәдәге идиотлык булыр иде. Борис андый ук ахмак түгел. Дүрт ел буе 20—25 яшьлек яшь хатынның тик тормаганына ул башын кисмәгә бирер. Аның күңелендә менә шундый шик туды һәм бәхете дә юкка чыкты. Шунысы кызганыч, мондый хәл булырын Борис алдан күрә дә, фараз итә дә алмаган. Адәм баласы нигә шулай якындагысын гына күрә икән, шул кадәр дә күрә карау була икән! Нәкъ шундый ук шик, мөгаен, хатынның үзендә дә тугандыр. Дөрес, алар бер-берсенә бу хакта әйтмәделәр, алай гына да түгел, яңадан кавышуга сөенделәр дә хәтта. Ләкин бу инде теге чактагы тыныч сөенечләр, эчкерсез яратулар түгел иде, ә ышану турында сүз дә юк инде. Шулай итеп, кавышкач, алар үзләренең элекке нөсхәләрен танымадылар. Соңыннан аерылуга, җимерелүгә, хәзерге ялгызлыкка китергән сәбәпләрнең берсе — һичшиксез шушы югалту иде. Иң зур байлык шулай җуелды. Әйе, Борис гаепле, хатынының сафлыгына ышана алмады ул, әлеге дә баягы, күңел зурлыгы җитмәде... Ә хәзер...

Югалтуның зурлыгы, ишек төбенә килеп җиткәч һәм звонокка басарга куркып калгач, бөтен авырлыгы, чынлыгы белән аңлашылды. О, беренче сафлык, беренче бәхет! Ник без сине саклый белмибез?! Әллә нинди вәсвәсәләргә бирелеп, нинди зур нәрсәдән коры калабыз! Дөньяда белергә тырышу дигән нәрсә бар. Читләрнең нинди икәнен белергә, яшәү ләззәтен күбрәк тоеп карарга тырышу аркасында күпме шатлыгыбызны югалтабыз икән без!

Ул шатлыкларның инде яңадан кайтмаслыгына тәмам ышанган хәлдә, һич югында, хәзерге фаҗигале хәлдән котылу өчен, тагы да дөресрәге — җәмәгатьчелек кушуын тыңлап, менә Борис үзенең элекке нык-лыгы һәм тынычлыгына алып керергә тиешле ишек алдында басып тора. Ләкин ул ачылырмы?

Звонок...

Юк, ишек ачылмады. Күрше ишекләрнең берсеннән бер әби башын сузып, хатынының эштә икәнен, ә баласының мәктәпкә китүен (икенче сменага йөри икән) әйтте. Мәктәп?! Кай арада мәктәпкә йөрерлек булды соң әле ул? Читтә йөреп, баласының үскәнен дә сизми калган, имеш. Ул үзен һаман егет кешегә исәпли, һаман яшьлек гадәтләре һәм иркенлекләре белән яши. Тфү, шул иркенлек хәзер җанны кыса.

Борис ишек төбендә йөренде, мәктәп тирәләренә барып карады, тик хатынының кайда эшләгәнен белә алмады — баягы әбидән сорарга да оныткан икән. Бердәнбер чара — көтәргә кирәк. Эч пошудан, үтеп барышлый ресторанга кереп утырмакчы иде — уңайсызланды, ике-өч сәгатьтән соң буласы җитди сөйләшүгә андый җиңел кыяфәттә килеп керү, оятсызлыктан бигрәк, әшәке тилелек булыр иде. Түзде Борис,

һәм ишек кичке сәгать жиделәрдә генә ачылды. Хатыны да, баласы да өйдә иде.

— Исәнме, Люся.

Хатыны ишекне ачты да — кер дә дими, кит тә дими — шаккаткандай тик тора. Борис исә анардан да ныграк югалып калды. Менә икеөч минуттан соң ишеткән сүзе:

— Сезмени әле бу...

Бу сүзләрдән һәм аларның әйтелеш-яңгырашыннан бөтенесен аңларга һәм кире борылып китәргә генә кирәк иде дә, бүтәнрәк сүзләр ишетү өмете белән, Борис үзсүзлелек күрсәтергә, бәхете өчен соңгы бәрелешкә керергә тиеш тапты һәм китмәде.

— Өйгә чакырмыйсыңмыни?

— Өйгә? Рәхим итегез!

Хатын тавышында тагын бер тапкыр: «Ник? Кирәкме икән?» дигән сораулар ишетелсә дә, Борис аларны да аңына кертмәскә тырышты һәм сүзне туры мәгънәсендә аңлап, залга узды. Шул арада хатын, ирнең үзен генә калдырып, кухняга кереп китте. Суынса да суына ала икән кеше — формаль әдәп сакларлык та хөрмәте калмаган. Ярый, түзәргә туры килә, кан төкерсәң дә, сиздермәскә кирәк.

Таныш коридорда янадан чыгып утны үзе кабызды да, өс-башын салып, аякларына башмак элде. Башмак — аныкы. Башмак түзгәнчы, мәхәббәт тузды. Кызык килеп чыкты бит бу, ә! Башмактан элда туза торган мәхәббәт нинди мәхәббәт икән? Гомумән булды микән?

Юк, бөтенесе аңлашылса да, Борис үзен гаепле санамый. Бөтен сәбәп — беренче аерылышу... Шул чакта аерылышмаска кирәк булган — ничек итсән дә бергә китәргә яки, алай мөмкин булмаса, берсенә дә китмәскә кирәк булган. Хәзер менә гыйбрәт... Гыйбрәтне бүтәннәргә дә житкерәсе иде, югыйсә, аның хатасын тагын кемнәр генә кабатламас дисең! Алай дисәң, аның белән чит илгә күпме кеше барып, берсенең дә гаиләсе жимерелмәде. Нишләп әле Борис кына алама булып чыкты соң? Ник?

— Әти, кайтуың белән,— диде малае, йокы бүлмәсеннән чыгып һәм олыларча кул сузды.

Бу очрашу, бу минутларның чыннан да булганына Борис хәзер ышанып та бетә алмый инде — аларны аңлау, хәтерләү шул чаклы кыен — ниндидер буталчык төш кебек, салмыш баш белән сөйләшенгән сүзләр кебек кенә. Ләкин бу хәл булды. Әнә шулай салкын гына итеп малае аңа кул сузды. Шулай да әтисе шатланды:

— О, Вова, син өйдәмени! — дип элеккечә гади һәм ягымлы итеп эндәшсә дә, Вовасы аны кочаклап алмады, сүзсез генә басып тик торды.

— Я, ничек бара синең укулар?

— Әйбәт.

— Өчлеләрең күпме?

— Бар.

— Икеләләр?

— Алары юк.

— Бишлеләр дә бармы?

— Алары да бар.

Һәм шуның белән сүз дә бетте. Бәлки тора-бара тагын телләре ачылыр иде, ләкин әнисе, дәресләрең эшләнеп бетмәгән дип, аны йокы бүлмәсенә кертеп утыртты һәм үзе тагын кухня ягына чыкты: Борис аны шактый көтсә дә, хатыны һаман чыкмагач, ахырда үзе аның янына керергә мәжбүр булды.

— Бик үк яхшы каршыламыйсыз бит әле,— диде ул, ачусыз гына үпкәләп.

— Оркестр кирәк идеме? Кочакка ташланырга тиеш идекме?

— Ник, алай да мөмкин иде.

— Башыңны юләрлеккә салма! — Хатын кәстрүл капкачын ачкач, борынга искиткеч тәмле ис бөркелде.

Борис бу иснең нинди кадерле нәрсә икәнен гүя ки әле беренче тапкыр гына тойды. Ах, нинди ерак калган шушы җылылык, шушы тормыш! Ничаклы үкенгәнен белсә иде, аның хатыны да, әлбәттә, болай сөйләшмәс һәм киселгәнне янадан ялгарга тырышыр иде. Хәзер галимнәр табигатьтә регенерация күренешләрен тагын да күбрәк күрә һәм файдалана башладылар. Ә җан киселсә, аны ялгар һәм яңартыр әмәл табылмас микәнни? Әйе, хатын да үзен бөтенләй гаепсез дип уйлый һәм бөтенесен Бориска кайтарадыр, мөгаен. Ләкин бәхәстән файда чыкмаслыгы да көн кебек ачык икәнен күреп торган хәлдә, бер генә юл кала — ник кайтканын туп-туры әйтергә кирәк. Һәм Борис шулай эшләде дә.

— Мин сезне алырга кайттым, Люся.

Җавап юк, тәкать калмагач, Борис тагын кабатларга мәҗбүр булды:

— Безгә тормышны өр-яңадан башларга кирәк, начарлыкларны онытыйк.

— Яман кеше белән әйбәт тормыш кору — юк сүз ул.

— Ә менә безгә үзебезне дә яхшыртырга кирәк. Шунсыз ярамый, дөнья үзе шулай куша. Искечә яшәү мөмкин түгел.

— Син бит, киресенчә, модерн кыяфәтле тормыш белән яшисең — мода...

— Мин аңладым, Люся, тормышның нигезләре модага буйсынмый. Мин моны аңладым.

— Соң булса да уң булсын диденме?

— Безнең мода дигәнебез, модерн дигәнебез, киресенчә — искелек булып чыкты. Безгә хәзер яңарырга, гади һәм мәгънәле тормыш белән яшәргә кирәк. Сәламәтлек һәм ныклык — менә нинди яңалык кирәк безгә.

— Сина кем өйрәтте бу акыллы сүзләрне?

— Сүзләр? Сүз түгел — тормышның үзе бу, Люся. Без шул тормышка яраклы булып чыкмадык, үзебез гаепле.

— Акыл шулай эш узгач килә инде ул.

— Эш узгач?

Борисның соравын Люся җавапсыз калдырды.

— Минемчә, әле соң түгел.

— Ә минемчә, соң. — Люсяның бу сүзләреннән бая күрешкәндәге үртәлү һәм салкынлык сирпелде.

Шулай да Борис сөйләвендә дәвам итте:

— Без аерылышып бер ялгыштык. Мин беренче аерым яшәүне әйтәм, чит илгә синсез китүне. Хәзергесе аның — бары гик нәтиҗә генә. Ә икенче кабат ялгышсак, инде тормышыбызны бөтенләй рәтли алмавыбыз ихтимал. Анысы инде төзәлми торган хата булачак. Җитдирәк уйлавыңны сорар идем мин синнән, Люся.

— Инде соң...

Борис шунда гына хәлне төшенде һәм бүтән сорарга җөрьәт итмәде... Ишетәсе килмәде...

«Димәк, Люся, димәк...»

Мондый авыр фикерне Борис уена китерергә куркып, урыныннан торды да залга чыкты һәм сөялеп тын калды.

Башында бернинди фикер юк, күңелдә тик өметсезлек: булмады, булмады, тормыш барып чыкмады.

Звонок шалтыраттылар. Люся чыгып кем беләндер хәтсез вакыт сөйләшеп торды. Борис ничек кенә ишетмәскә тырышса да, ир кеше тавышы, каһәр төшкән калын бер гавыш оятсыз рәвештә түргә уза торды.

«Ах, каһәр суккыры бу тавыш! Син анда ишек төбендә, каракларча... Минем бәхетемне, киләчәгемне алып китәргә килгәнсең. Сәдака

сорап кергән хәерче шикелле. Мин синең көнгә үк калырга тиеш түгел. Дөрес, мин үзем дә кемнәндер әҗәткә шактый күп акча сораган кеше төслерәк хәлдә калдым. Ләкин мәхәббәт әҗәткә бирелми, ә үземә бирелгәнен мин тотып бетердем — чамадан тыш тиз туздырдым. Хәзер инде яңа хәзинәгә ирешергә кирәк. Ничек? Ничек? Акчаны эшләп табарга мөмкин. Ә мәхәббәтне? Чын якынлыкны? Ничек табарга аны, каян?»

Люся яңадан кергәндә, аның йөзе бозылган, битләре кызарган иде — күңелендә ачумы, каушаумы — әйтүе кыен. Икеләнүме, аптыраумы — белүе читен. Аның хәзер, гомумән, сөйләшерлек көче дә юк бугай. Хатынның болай да аптырап, югалып калганын Борисның беркайчан да күргәне юк иде әле. Хәтта Чаллыдан кайтып киткәндә дә...

Люсяның күңелендә нинди кичерешләр икәнен беләсе иде дә — сорап булмый. Беренчедән — әдәпсезлек, икенчедән — бәйләнчеклек булыр иде. Бәйләнеп үз дәрәҗәсен төшерә алмый ир кеше, алай итәргә тиеш түгел — үзеңә ихтирамны беркайчан да җуярга ярамый, үз дәрәҗәңне үзең таптау — шулай ук иң соңгы хурлык.

Борис малае янына чыкты һәм аны кочаклап үпте дә:

— Җәйге каникулда минем яныма килерсең,— диде, чак кына балаларча елап җибәрмәде.

— Әни белән,— диде малай, олыларча тыныч кына.

— Хуш, Вова, ачуланма миңа.

— Ярый.

Әтисенә нинди зур вәгъдә бирүен бала үзе, әлбәттә, аңламый торгандыр. Борис кухня ягына бүтән карамады. Шул килеш аерылдылар.

Бу инде соңгы аерылышу иде.

Чаллыга кайткач, үзенең тагын бер зур хата ясаганын аңлады Борис. Бәлки, Люся, үзе ике ут арасында тоеп, ничек хәл итәргә, кем белән калырга белми аптырап торган булгандыр, һәм ана нәкъ менә шул чагында киңәш белән ярдәм итәргә кирәк булгандыр? Нәкъ шул вакытта... Ә Борис, үзенең ирлек дәрәҗәсенә хилафлык китермәс өчен, хатынының яңа мәхәббәте хакында сүз кушмады. Кем белә, бәлки, ялган горурлык булгандыр бу?

Хатаны төзәтим дисәң, хәзер кире Тольяттига кайтырга (әлек соң дигән иде, хәзер соң түгелдер дип ничек башка китерәсең инде?!), һич югында, хат язарга кирәктер. Кирәк, әлбәттә. Шулай эшләргә кирәк. Ләкин хәл шул «кирәк» көенчә калды — бару түгел, ул ана хат та язмады. Нишләтәсең, кул бармый, үтерәсеңмени аны. Ә хәзер Люся иргә чыккандыр инде... Абау, мондый да хурлык, мондый да адәм көлкесе — Борис үзе генә белә, ләкин моннан ни җиңеллек? Борис үзенең нинди хәлдә калганын үзе бик яхшы белә бит!

Белә һәм беркемгә дә сөйли алмый. Фәезгә дә авыз ачмас иде, ләкин күңеле генә түгел, тәне дә бик йончыган чак — түзмәде. Ярый әле, Фәез акылсыз кеше түгел, бүтәннәргә таратып йөрмәс.

— Мондый хәлдә һич киңәш биреп булмый, Боря, фаҗига инде бу — шунысы хак,— диде Фәез, үз кайгысы төсле авыр кичереп.— Берни эшләр хәл юк. Түземлек кирәк, сабырлык. Болай бикләнеп ятудан синә чынлап та файда юк. Йөреп кайтыйк бергәләп.

Борис моның белән үзе дә бик теләп килеште.

Ә җомга көн кич, постройком көймәсе белән, дүртәүләп ике көнлек сәяхәткә чыгып киттеләр.

Ким дигәндә егерме чакрым узылгандыр. Көймә көйле булганда, бәйрәм инде ул — мотор бер көй белән гөрли генә. Гета белән Кама урта утыргычка икәүләп утырганнар, ә Фәез — Борис янында, арттa.

Каманың алар белән барырга риза булуыннан ниндидер яхшы нәтиҗә чыга бугай чыгуын да, ләкин Фәез әле үз бәхетенә һаман ышанмый. Каманың елмаеп куюына, су чәчрәгәч битләрен сыйпап, чын күңелдән

көлүенә дә ышанып житми — чынлап та шушы кыз Кама микәнни һәм Фәез аның белән бер көймәдә барамы? Күпме айлар беркемгә дә диярлек сөйләмичә, сөйләргә куркып йөргән хыялы бүген аның белән бер көймәдә бара. Могҗиза — аның янында гына... Кулын сузса, кул житә. Ләкин кул белән кагылу мөмкин түгел. Кагылсаң, очып китмәсме, юкка чыкмасмы? Кызлар дигәнең, хыял дигәнең үзләрен куя белә!

Барышлый телгә алырлык хәл очрамады дисәк, дөрес үк булмас. Фәез инде берничә көн буе кесәсендә йөргән, безгә таныш кәтүкне кулында уйната икән. Шуңа Гета игътибар итте:

— Нәрсә ул, Фәез?

— Бумы? — Фәез уңайсыз елмаеп Бориска карады, тегесе кызарып башын читкә боргач, калайны кызга сузды.— Бу — фиксатор.

Кызлар нәтиҗәне тиз ясадылар:

— Искитәрлек нәрсә түгел икән.

— Тарихи деталь, Борис белән безнең араны бозган нәрсә... Борис аны горком секретарена биргән иде. Әкренләп түбән төшә-төшә, идарә партбюросына килеп җиткән. Галина Алексеевна үземә кайтарып бирде. Миңа да кирәк түгел, мә, Боря.

Дустының ачусыз елмаюын күреп, Борис фиксаторны алды. Бераз тотып карап торды да суга атты. Чылт иткән тавыш кына ишетелеп калды. Шуннан соң юл буе диярлек сөйләшмәделәр.

Әмма, былтыр бергә булган тирәгә килеп туктагач, бөтенесе бик тиз һәм җиңел эшләнде. Фәез шатланып көймәне корыгарак өстерәп чыгарды, башта Гетага, аннары Камага кул биреп (Кама бернинди куркусыз, икеләнүсез үзенең аккош канатлары кебек кулын сузды — бар икән дөньяда хикмәт!), аларга төшәргә ярдәм итте, соңыннан бергәләп палатка һәм вак-төяк әйберне ярга төшерделәр, палатка кордылар — аннан эченә коры печән кертеп җәйделәр, уйнап-көлеп су керделәр һәм аннан соңрак аш пешерделәр. Дөресрәге, болар эш түгел, әйтеп аңлата алмаслык ләззәтле шатлык кичерү генә иде. Транзистор кәкре-бөкре көйләр һәм ритмнар чыгара башлагач, Фәез башта Гета белән танцевать итте, аннары хәтта Каманы чакырырлык көч тапты. Кама исә, ялындыру дигәнне кинәт оныткандай, каршыга үзе үк килде. Чирәм җирдә танец ритмына иярү бик җайлы булмаса да, ул канатлы кош шикелле җилпенә — әллә иркенлеккә чыгудан, табигать кочагындагы рәхәтлектән, әллә... әйтү дә кыен... әллә... әллә инде ул да Фәез кебек үк мәхәббәттән канатланганмы?!

Былтыр да шушы ук кыз иде бит, әмма болай ук гүзәл түгел кебек иде. Шушы ук күзләр белән караган иде бит кыз ул чакта да, ләкин Фәез бернәрсә дә күрмәгән булган икән... Күзсез булгандыр, мөгаен. Юк, ул чакта да карады, ул чакта да күрде, тик нәрсәдер күңел теләгәнчә үк түгел, нәрсәдер житми кебек иде. Мөгаен, Каманың үз итеп каравы житмәгәндер. Гаҗәп, ай-һай гаҗәп тә инде — бер кешене Фәез ике төсле итеп күргән — элекке күрүе һәм хәзергесе — җир белән күк аермасы. Сәер дә инде бу адәм баласы. Кыз мәхәббәт сирпеп карагач, әйтерсең аның төсе үк үзгәрде!..

Әйе, Каманың күзләрендә, йөзендә, бөтен кыяфәтендә хәзер читсенүнең инде әсәре дә юк. Гөмбә җыйган чакта (кызлар үзләренә мәшәкать таптылар), Фәез аны житәкләмәкче булгач, рөхсәт итмәде итүен, әмма төнлә палаткада йоклаганда, күбрәк Фәез ягына карап ятты... Ә йоклап киткәч, әлеге дә баягы, аккош канаты төсле кулын Фәезнең башына куйды, чәчләренә кагылды, хәтта сөйде, сыйпады да бугай. Бер мәл шундый үрнәккә егет үзе дә иярмәкче иде дә — урлашырга вөҗданы житмәде. «Булса булсын чын ярату, булмаса, бүтән кешегә тиешлесенә мин мохтаҗ түгел — кызлар күңеле төшмәслек үк рәтсез егет түгел мин».

Фәез шул уй белән Бориска таба (Гета белән алар да бөтенләй чит кеше кебек — икесе ике якта йоклый!) борылып ягты һәм рәхәт йокыга талды.

Иртәнге сәгать өчләрдә Борис белән тагы балыкка киттеләр. Ә сәгать уннарда корбан балык һәм кызылканатлар тулы кечкенә тимер кәрзин тоткан хәлдә палатка янына килгәндә, кызлар аларны көтәләр иде инде.

Үзләрен генә калдырганга, бераз үпкәләп тә куйдылар куюын, әмма бик үк чын күңелдән түгел инде монысы. Үзләре дә, якын-тирәдә генә булса да, җиләк җыя торганнар.

— Балык тотканнан ким түгел ул җиләк җыю. Каен җиләгенә хәтле бар,— диде Гета.— Сез юкка гына балык тотабыз дип йөрисез.

— Уханы җиләктән пешереп булса, барып йөрмәгән булыр идек,— диде Фәез. Борисның да, Гетаның да чырайлары караңгы иде. Теге юлы аларның кәефләре шәп, ә Фәезнеке алама иде. Дөнья — куласа шул, куласа.

Бер уйласаң, болары — ваклыклар гына... Гомумән, көн әйбәт. Тик менә кичке якта...

Кояш баерга шактый вакыт бар иде әле. Көн һаман кызу. Ничәнче кабат икәнен хәзер хәтерләве кыен — Фәез тагын бер тапкыр су кереп килергә чакырды. Кызлар исә, тагы җиләккә барабыз, диделәр.

Фәез: — Алайса, сез өчәүләп йөри торыгыз, ә мин сезне эзләп табармын,— диде дә берүзе яр буена төшеп китте.

Тиз дисәң дә, бер сәгатьләп вакыт узгандыр. Фәез үзенә таныш кыядан суга сикереп, туйганчы йөзеп, тагын яр буена менеп килгәндә, урман ягыннан сәер тавыш ишетелде:

— Фә-е-ез! Фә-е-е-ез!

Тавыш елауга охшаш. Шаярталар дип уйлады ул. Ләкин тиз-тиз киенде дә йөгерә-атлап иптәшләре янына китте.

— Фә-е-е-ез!

Фәез җавап бирергә мәҗбүр булды. Ә аңа каршы баягысыннан да хәвефлерәк аваз килде:

— Тизрәк кил! Тизрәк!

Фәез бөтен көченә йөгерергә тотынды. Озак та үтмәде, каршысына тыны-көне беткән Гета килеп чыкты.

— Нәрсә булды, Гета?
— Тизрәк, Кама һуштан язды.
— Нишләп?
— Елан чакты бугай... Борис шулай диде.

Бүтән сөйләшеп торырлык вакыт юк иде — икесе дә палатка янына йөгерделәр. Анда исә менә нәрсә булган икән. Җиләк эзләп йөргән чакта, Кама, үлән арасында елан күреп, ни өчендер аны тотмакчы булган һәм... кычкырып җибәргән. Борис белән Гета килгәндә, ул инде җирдә ята, сулкылдап-сулкылдап елый. Борисның «Ни булды?» дип соравына каршы, аягын күрсәтә. Ак тәндә карачкылланып торган тап... Борис канлы җәрәхәтнең нәрсә икәнен шундук аңлый һәм, кызны тиз генә палатка янына күтәреп китерә дә, җәймәне ертып, шуның белән Каманың аягын — җәрәхәттән өстәрәк — кысып бәйләп куя, тиз генә иреннәре белән ярадагы агуны суыра. Гета исә Каманың баш астына кечкенә мендәр белән бүтән әйберләр китерә. Менә шуннан соң алар янына Фәез килеп житте, ләкин берара нишләргә белмичә аптырап калды, чалкан яткан Каманың каралган аягына текәлеп тик торды. Үзе дә сизмәстән, Бористан:

— Суырдыңмыни? — дип, мәгънәсезрәк итеп сорап куйды.

Тегесе «әһе» дип баш каккач, тагы сорады:

— Беттеме икән?

— Әйтә алмыйм.

Шулай дигәч, Фәез дә кызның аягына иелде һәм агуны суырып карады. Күпмедер кан... Ихтимал, аңа агу да катнашкандыр. Шуңа игътибар итте тагы — нинди генә әшәке әйбердән дә чирканмаган Борис, молодец, курыкмаган. Болай булгач, кызны коткарып булачак. Ләкин озакларга барыбер ярамый.

— Әйдәгез көймәгә,— диде ул Каманы күтәреп,— сез калган әйберләрне алыгыз.

Борисның нигәдер күзләре тагын да сүрелгән, хәлсезләнгән кебек. Шулай да ул җәһәт кенә торып, палатканы сүтәргә кереште. Гета, урын-җир әйберләрен күтәреп, Фәез артыннан иярде. Фәез берничә урында абынып, егыла язганга, Гета:

— Сак бул, Фәез, алла хакы өчен, сак бул,— диде.

Яр буена җиттеләр — Гета шушындагы әйберләрне көймә эченә әйбәтләп җәйгәч, Фәез кызны шунда яткырды.

— Беразга үзе генә торсын,— диде ул Гетага,— курыкма, берни булмас.

Икәүләп тиз генә мотор белән бензин багын алып килделәр дә Бориска палатканы төрергә булыштылар һәм моторны көймәгә беркеттеләр. Фәез һаман Бориска карый — аның күзләрендә терелек кимегән төсле. Нәрсә булды икән? Бәлки, гади шикләнү генәдер бу? Берни юктыр, берни булмас. Әмма шик торган саен йөрәкне ныграк кимерә бара.

Менә Борис көймәне суга төшерергә дә булышмый, ул хакта уйламый да диярсең. Фәез чылбырны чишеп, аны көймә борынына куйды.

— Әйдә, Боря, утыр.

Тегесе көчкә-көчкә утыргач, аңа булышып, соңыннан көймәне суга, тирәнгәрәк этте дә шунда үзе дә сикереп менде. Гета ишкәкләрне алып ишә башлады.

Борис мотор кабызырга керешкәндә, Фәезнең эченә чак кына җылы кергәндәй тоелса да, иптәшенең бауны рәтләп тарта алмавын — моторның шактый озак киреләнүен күргәч, күңелендәге шом тагы да куера төште. «Шулай да бик үк рәтле түгел моның хәле!» — дип уйлап өлгергәнче, мотор кабынып, көймә урыныннан кузгалды да, алар юлга чыктылар.

Хәерле сәгатьтә!

Гадәтенчә, Фәез үзен шактый сабыр тотты — борчылмаска тырышты һәм борчылса да, иптәшләренә сиздермәде. Гета ара-тирә аңа һәм Бориска сагаеп карый. Борисның хәлсезләнүен күреп, куркулы карашын Фәездән алмый, киңәш сорый. Ә Фәез «зыян юк, үтәр», дип кенә куйса да, үзенен дә күңелендә сызлану артканын тоя.

Күпмедер баргач, Борис хәлсезләнеп аңа башын куйды да көймәне туктатты. Моның мәгънәсен аңлау кыен түгел иде: димәк, аны яткырырга кирәк. Монысы читен эш түгел — яткырырлар, ләкин Фәезнең көймә йөрткәне юк, койрыкчысыз нишләрләр алар — шунысы мәсьәлә. Моторны тизлеккә күчергәч, көймә кинәт ыргылып читкә борылды да бер түгәрәк буенча бөтерелергә тотынды. Белмәгәннән түгел, сизгерлек җитмәгәннән... Рульне икенче якка боргач, шунда ук тигезләнде. Әллә ни катлаулы нәрсә түгел икән болай — юнәлешне кул үзеннән-үзе таба белде һәм алып та китте.

Гета үз көенә уйланып бара-бара да тагы Кама өстенә иелә, аның башын тота, кулын капшый. Исән генә кайтып җитсәк, анда инде аны саклап калырлар, әлбәттә. Тик юл әле ерак — күп булса, биш чакрым җир киләндә. Инде кояш та баеп бара. Җитмәсә, мотор — сигез генә ат көчле, агымга каршы бик тиз бара алмый — алда яңадан унбиш-егерме чакрым ара бар. «Тизрәк, тизрәк...» дип ашыктырырга тырыша Фәез көймәне, ләкин аңа карап тегесе тизләми. Киресенчә, хәлдән тайгандай,

йөткерә-йөткерә бара. Сүнеп тә йөдәтә башлады. Көч-хәл белән кабызып, тагын бераз баргач, йөткермичә генә лып итеп сүнде дә куйды. Фәез нәкъ шушы хәлне куркып көткән иде — менә хәзер кайт инде. Алай тарт, болай тарт — өн дә юк, тын да юк. Ахырда Гетага сүз кушты:

— Ишкәк белән бара торыйк булмаса, кирегә агыза бит.

Гета, мескен, үзенең нечкә беләкләре, кечкенә куллары белән тагын ишкәкләргә тотына, ишкән була, бераз алга да киткән кебек була, ләкин нишлисең, ташбака тизлеге хәтле дә түгел инде бу. Мотор кабынмаса, бетте баш. Юк, ул кабынырга тиеш, шунсыз ярамый. Һәм Фәез җепне тарта да ычкындыра — мотор тыз-быз килеп тик тора — гөрләргә нияте дә сизелми юньсезнең. Сүтеп, төзәтеп карар идең, караңгы төште...

Шулай, кабынмавы рас. Ләкин өметсезлеккә бирелүен ул барыбер Гетага сиздермәс. Кыз ишкәкләре белән алга иелә, артка тайпыла,— ишкәк дигәннәре аксыл сызыклар төсле булып күз алдында ялтырап тора. Алалы-колалы шул сызыклар арасыннан әллә нинди мәгънәсез күренешләр елкылдап узган төсле тоела. Тора-бара алар ниндидер эчтәлек һәм форма да ала башлый — хәлләр һәм уйлар сурәте булып төсмерләнә бугай...

Менә ничек килеп чыкты бит, ә? Кама дип күпме хыялланды, күпме эзләде, тапкач, Фәез үзенең теләкләрен, кичерешләрен аңлата-җиткерә алмый интекте, вакыт һәм җай тапмыйча газапланды. Ә шуларның бөтенесе артта калгач, күңелләр бер-берсен аңлый һәм ияләнә башлады дигәндә, менә синә мә — хыялы аның кулында, янында, көймәдә генә — ләкин җансыз, хәрәкәтсез. Әйтерсең могҗизага кеше кулы кагылдымы, ул юкка чыга, һәлак була. Фәезнең уйлаганда да сак кына уйларга тырышкан максаты белән, мәхәббәте белән әнә шулай килеп чыкты шул. Ул менә монда хәрәкәтсез ята, бөтен торышы белән әйтә гүя: «Әкият юк дөньяда, син аны табам димә, эзләмә. Әкият һәм чынбарлык — ут белән су кебек — аларны кушам, берләштерәм димә син. Кешенең тормышы — мәңгелек чынбарлык, мәңгелек кырыс законнар белән көнкүрешкә бәйләнгән, җиргә кадакланган. Син үзең дә җиргә сыенган, аякларың булмаса, бөтен җаның, тәнең белән җиргә ябышкан — очсаң да барыбер син шуңа кайтып егылырга, хәлең яхшы чакта да җир дигән, туфрак дигән шул чынлыкка басып йөрергә тиеш. Әкият юк, ә ансыз никадәр күңелсез, караңгы бу дөнья!»

Көймәдә — дүрт кеше.

Тирә-якта су, караңгы дәрья, күк чиксезлеге. Караңгы дөнья эчендә мескен көймә чайкала. Ах, никадәр кечкенә ул көймә шушы чиксез киңлекләр уртасында — бер нокта кебек, бөтенләй юк та кебек.

Көймәдә — дүрт кеше.

Икесенең инде аң дигән яктылыгы сүнеп тә өлгергән. Караңгылык кочагында соңгы очкыннар гына яшеренеп яна. Анысы да озак янармы, юкмы — кем белсен. Әллә ул очкыннарны ялмап кую шушы чиксез су өчен, шушы караңгы дәрья өчен кыен эш дисеңме?!

Көймәдә — дүрт кеше.

Икесенең генә куллары хәрәкәттә. Ике кеше бергә утырганнар да һаман ишәләр дә ишәләр, үзләрендәге һәм иптәшләрендәге кечкенә яктылыкны саклап калыр өчен, аны гомум тормыш дигән яктылыкка кайтарып җиткерү, яңадан кушу өчен соңгы хәлләрен сарыф итәләр.

Көймәдә Кама ята, һәм аның янында ук Борис ята...

Әйе, теге вакытларда дустының үзеннән ничек көнләшүен аңлап җиткермәгән Фәез, хәзер су өстендә йомычка шикелле чайкала башлагач, хәтерендә булган бөтен нәрсәне энәсеннән җебенә хәтле дигәндәй тикшереп-барлап чыккач, көнләшүнең нинди авыр һәм кимсеткеч нәрсә икәнен бөтен гарьлеге, эчтәлеге белән тойды. Әйе, аңлап була, бик нык аңлап була... Нигә дисән, Фәез үзе дә көнләшә белә икән бит!

Хәтерләүләрдән бу көнгә кайтарган һәр минут аңа бер сорауны кабатлый:

Ник Борис урынында хәзер Фәез түгел, ник ул үзенең сүнеп барган хыялы белән бергә түгел? Ни булса да, ник бер язмыш түгел аларда? Ул бит Борис кебек кеше түгел: җирдә беркемнән дә рөхсәт сорап тормыйча, үз законнары һәм ысуллары белән яши торган матурлык — аның өчен яшәү мәгънәсе, тормыш яме. Фәезгә шунсыз дөнья юк, ул шундый кеше — экиятсез яши алмаячак. Икенең берсе — я Каманы саклап калырга, я бергә менә шушы кара бушлыкта сүнеп юкка чыгарга.

Ләкин һәлакәткә беркайчан да соң түгел. Аңа ашыгырга ярамый — кайтып җитәргә кирәк. Әнә алардан ике-өч йөз метр гына арада пароход йөзеп бара. Хәзер алар кычкырачаклар һәм аларны килеп коткарачаклар.

— Әһ-һә-һә-һо! Аһ-һа-һо-һо!

Юк, пароходтагылар аларны күрә дә, ишетә дә алмадылар. Ярдәм сорап кычкырган тавышлар кайтаваз булып килеп хушлаштылар да янадан еракка китеп олактылар.

Бер генә юл кала: йөзәргә — ишәргә кирәк, ишәргә.

Каршы яктан килеп, ярты чакрымга сузылган үзйөрешле баржа узды. Аңа кычкырудан файда юк — барыбер кире борылмаячак, кыймәтле йөк түгел, диярләр, ә монда нинди кадерле җаннар харап булачагын белмәсләр. Борылсалар да, ярдәмнәре тимәс — баржаның тизлеге көймәнекеннән әллә ни артык түгел. Уза бирсеннәр.

Ә менә икенче пароход килер булса, анысын инде ычкындыру ярамас. Шуңа күрә пароход йөри торган җыпкыга, маяклар белән билгеләнгән юнәлешкә керергә кирәк. Тик монда дулкын тагы да куәтлерәк иде, болай да юк чамасындагы тизлек бөтенләй бетте диярлек. Бер маяктан икенчесенә җиткәнче таң да ата язды. Хәзер инде вакыт дигән нәрсә гомумән мәгънәсен җуйды бугай. Кояш баткач, күпме киленгәнен Фәез чамалый алмый хәзер.

Гетаның да егетләр кочарга гына яраклы куллары табигатькә каршы, бушлыкка каршы озак көрәшә алмады. Ишкәк белән суны каера алмый башлагач, Фәез аңа ял бирергә мәҗбүр булды.

— Пароход-фәлән күренмиме, син шуны күзәтә бар.

— Ярый, Фәез, карармын. Карармын, Фәез.

Кама һаман хәрәкәтсез — тып-тыныч... Су өстенә, якты кинлеккә төшкән ай юлын да күммичә һәм җимермичә, салмак җил исә. Ялган тынлык... Су агышы көймәне һаман артка этә, бәргәли-бәргәли туктатырга һәм бөтенләе белән үз иркенә алырга тырыша. Ә бер бирелсәң, нәрсә буласын чамалау кыен түгел.

Фәез, Камадан күзләрен алган арада, Гетага карый. Гета да көймә очында, алга табарак текәлеп, тын калган. Ләкин бу кыяфәт һич тә тынлыкны аңлатмый, киресенчә, әгәр ул хәзер сурәт булса, рәсем астына «Җил» дип язып куярга кирәк булыр иде. Төнге сихерле балкышта, бигрәк тә яннан караганда, гаҗәп тә матур икән бу кыз. Чәчләренең, флаг төсле җилфердәгән чәчләренең аклыгы төнлә дә күренә кебек. Әллә чынлап шулай, әллә Фәез аларны көндезге төсендә күз алдына китерә, ничек дисәң дә, шунысы хак: ак флаг... Моңарчы тиешле максатын һәм бәхетен таба алмаган искиткеч гүзәл кыз, ак флаг күтәреп, парламентер рәвешле, хәзер үзенең язмышы белән сөйләшергә бара. Килешергә бара! Бәхет белән килешергә!

— Фәез, пароход!..

Чыннан да, артта утлар балкып күренде. Әгәр килсә, читләтеп уза алмас, күрми калмас. Фәез хәзер ул узачак төшне чамалый. Пароход туп-туры көймә өстенә килә. Әгәр бәрелсә? Төнге караңгыда күрмәсә? Рулевой тыныч кына, оеп кына бара торгандыр. Шушы кара төндә

каршысында ниндидер йомычка чаклы гына көймә бара дип каян башына килсен аның?

Фәез ишүеннән туктады, һәм алар икәүләп кычкырырга тотындылар — ачыргаланып кычкырдылар. Әгәр исерек кенә булмасалар, ишетергә тиешләр:

— Аh-hы-ho-ho! Ярдәм, Ярдәм!

Бәхетләренә каршы, аларга җавап биргән калын һәм көчле тавыш рупор аркылы дөньяны яңгыратты:

— За бортом — лодка! Идём на спасение. Право руля, право, тихий ход. Стоп...

Күпмедер вакыт үткәч, мескен көймәне пароход койрыгына менгереп утырткannнар, ә аның бәхетсез хуҗаларын тыныч бер каютага кертеп тә яткырганнар иде инде.

— Ничек уйлыйсың, Фәез, коткарып булыр микән?

— Болай булгач, булыр инде, Гета, булыр.

* * *

Чаллыга кайткан көнне Фәез үзен галәмнән урап кайткан кебегрәк хис итте. Төпсез караңгылык, тынлык — шул ук галәмдер инде ул. Ә хәзер менә, шөкер, бөтенесе үтте — дөнья якты һәм көләч. Хәтта больницада да шул ук яктылык.

Каманы Бористан бер кат өскәрәк урнаштырганнар иде. Фәез үзе дә сизмәстән туп-туры өченче катка менеп китте. Ачык ишектән кереп, кыз янына ашыкты.

— Я, ничек хәлләр? — Фәез үзенә чак кына елмаебрак караган ямансурак күзләргә текәлеп, мәхәббәт тулы караш белән балкыды.

— Әйбәт.— Кыз, егетнең бу карашыннан уңайсызлангандай, күзләрен йомды.

Егет аның чәчләрен сыйпады — тегесе сүз әйтмәгәч, ризасызлык белдермәгәч, шатлыгы эченә сыймыйча, иң якын кешеңә генә әйтә торган турылык белән:

— Сине югалтам дип, кот та калмады бит, Кама! — диде.

Кама тагын иркә караш ташлады да күзләрен йомды.

— Югалсам, бүтәннәр табылыр иде,— дип күзләрен ачты. Тагын нидер әйтмәкче иде, аның сүзен Фәез бүлдерде:

— Кама дөньяда берәү генә бит ул.

Фәез хәзер тәти сүз генә сөйләвен, ә чынлыкта, куркыныч вакытта, аны яклый алмаганлыгын сизә һәм үкенүгә якын бер кичерештән интегә. Дөрес, әгәр кыз аның сүзен тыңлап бергә су керергә төшкән булса, бәхетсезлеккә тарымаган булыр иде. Тик халыкта: күрәчәгең булса, күрәләтә утка керерсең, диләр. Икәүдән-икәү генә калудан, мәхәббәттән куркып, әнә нәрсәгә юлыкты кыз... Бер карасаң, үзе гаепле. Ләкин язмыштан узмыш юк — шулай килеп чыккан инде, үзе теләп түгел, нишләсен. Ә менә Фәез аңа ярдәм итә алмады... Бәлки, егет аны калдырып ук китмәскә, бер адым аерылмыйча, гел аның белән йөрергә тиеш булгандыр? Монысы — бәхәсле, билгеле. Шулай да, шулай да... Кыз тәненә күчкән агуны ул суырып чыгармады, бу эшне Борис эшләде. Кама гомерен ул саклап калды, үзен харап итә язып батырлык эшләде. Кама, Кама дип хыялланып Фәез йөрде, куркыныч хәл килгәч исә, хыялсызнисез генә Борис күтәрелде. Ә моның белән ул үзенең яшәү рәвешен, тагын да курыкмыйча әйткәндә, тормыш принцибын раслады түгелме соң? Бәлки, шулайдыр! Әкият — буш сүз, тормышта аның кирәге юк, дөньяда эш бар, тән бар, кан бар, ә калганы — ялган матурлык, үзүзеңне алдау, дин, ходайның бер төре генә, бүтән бернәрсә дә түгел. Син үзеңне алла дип игълан итсәң дә, син барыбер хайваннарга хас

булган биш инстинкт колы: ашыйсың, нәсел тудырасың, йоклыйсың, тәнеңне чиста тотарга тырышасың (каурыйларың, йоннарыңны паразитлардан саклыйсың), үзең кебек җан ияләре белән аралашасың. Без шундый яшәүдән өстенрәк булырга тырышабыз. Дөньяны танып белүнең аерым формалары булган сәнгать һәм фәнне яшәү максаты итеп, идеал итеп куябыз да, янәсе, үзебезнең кеше икәнлегебезне, табигать өчен хөкемдар икәнлегебезне раслыйбыз. Ләкин бу да — матур ялган гына. Фән үзе ачты хәзер: танып белүгә омтылыш хайваннарга да хас... Кешеләр, үзләрен мещанлыктан арындыру, изгерәк булу өчен, башкалар файдасына яшәү, хезмәт итү кебек бик матур принцип уйлап чыгардык дип исәплиләр. Ләкин бу исәп тә алар уйлап чыгарган нәрсә түгел. Кошлар белән яшәп кара, үз күзең белән күреп ышан: күп кенә кошлар — «иргә чыкмаган түтәйдәй» — бүтән кошларга «бәби» тәрбияләргә булышалар... Үзеңне үзең юатма, синең дә төп мәнфәгатьләрең шулар: ризык табу һәм йоту, җай килгәндә, шаярып яки сугышып (тиргәшеп) алу, ләззәт хакына хәрәкәтләнү, парлашу... Әмма юк, юк! Борисның бу батырлыгы бөтенләй башка нәрсә хакында сөйли. Акылы белән Борис мещан булса да, аның күңелендә, канында чын, саф кеше сыйфатлары да бар әле. Бер тәндә ике кеше яши...

Сүзсез утыру күпчелек очракта теләсә нинди әңгәмәдән дә мәгънәлерәк. Камага карап, шактый вакыт шулай уйланып утырды Фәез. Караган саен үзендә әллә нинди, әйтеп аңлата алмаслык якынлык, соклану хисе артканын тойды. Юк, бу — теләсә нинди җан иясендә була торган якынлык түгел, юк, оятсыз скептиклар гадилеге түгел, юк, юк, мең мәртәбә юк, гади парлашу инстинкты түгел, бу — югарырак омтылыш, бу — мәхәббәт, бу — поэзия, музыка, тагын әллә ниләр... Бәлки, әкияттер, ләкин биш инстинктның берсе түгел. Кама гади бер кыз гына булса, аның матурлыгы төс-биткә генә кайта торган булса, аның тиңнәрен аз күргәнмени Фәез! Ник аларның берсенә дә тукталмаган, ник берсенә генә дә шушылай соклана алмаган? Юк, гади кыз гына түгел син, Кама, син — хәзергә әйтеп булмый торган җанлы романтик мәгънә...

Яткан җирдән Кама керфекләре белән шул искиткеч тирән мәгънәне сирпеп, күзләре, бөтен торышы белән елмаеп куйды. Сирпелгән шул зәңгәр шатлыкның бер генә җебен дә әрәм итмәскә тырышып, Фәез сихерләнгәндәй тын торды.

— Шул суны стаканга салып бирче,— диде кыз карашыннан да иркәрәк тавыш белән.

«Су...»

Туры мәгънәсендә генә аңласаң, искитәрлек нәрсә юк кебек. Борис өчен монда бер генә мәгънә, ә Фәез өчен — диңгез! Шул сүзнең әйтелгәннән чагыштыргысыз тирән мәгънәсен тойган Фәез үзе дә сизмәстән торып басты да, кыздан күзләрен ала алмыйча, кузгала алмыйча йөдәде. Кыз, әлбәттә, моны сизеп, тагын баягы елмаюы белән елмайды һәм тагын да иркәләнә төшеп, мендәргә сыенды. Мендәргә түгел, чынлыкта бу сыенуның үзенә икәнен егет ләззәт тулы йөрәге, бөтен йөрәге белән тойды. Шул ләззәтне һәм өстәлдәге үзе китергән виноград суын кызга салып бирде.

— Рәхмәт.

Бу рәхмәттә дә бернинди кыланчыклык юк — ул да бары тик эшләнгән яхшылык өчен тиешле бүләк, мәхәббәткә мәхәббәт белән түлиләр. Аның бәясен бүтән нәрсә белән түләп булмый. Фәез яратмаса, айлар буе хыялланып аны эзләмәсә, шашмаса, хыялыйга сабышмаса, бәлки, менә шушы хәтле дә якты итеп елмая һәм карый алыр идемени аңа бу сөекле зат?!

— Ә нигә бер сүз дә сөйләмисең син миңа? — ди кыз эндәшми тормас өчен генә.

— Ни сөйлим соң? Тизрәк терел, бөтен сүзем шул сиңа. Иртәгә мин килгәнче терелгән бул.
— Иртәгә тагы киләсеңмени?
— Килмимме?
— Үзеңә кара. Барыбер сөйләшмисең...
— Мин сиңа карап аңлыйм барысын да.
— Мин дә...— дип, кыз кулын сузды.
Тагын күпмедер шулай бер-берсенә карашып тын утыргач, Фәез үз файдасына шаяртмакчы булды:
— Кара елан белән дус булырга ярамый дип әйткән идем бит мин сиңа.
— Мин аны тузбаш дип торам. Җилкәсендә соры тап булгач.
— Нәкъ зәһәр еланныкы шулай!
— Белгән булсам, якын бармаган булыр идем.
— Ничек алай? Син аның янына үзең бардыңмыни?
— Сиңа бүләк итмәкче идем. Кәлтә кулда иде инде. Анысы да ычкынды...
Фәез сикереп үк торды:
— Кама, син акылдан язгансың! Бу ни дигән сүз?
— Синең кыюлыкка каршы мин дә кыюлык белән җавап бирмәкче идем. Булмады, гафу ит.
— Эх, Кама, акылсыз!
Үзе дә сизмәстән, Фәез, кызны кочаклап, яңакларыннан үбәргә кереште. Кама исә ачуланмый, көлә генә:
— Җитәр, Фәез, булды! Фәез дим!..
Бу инде ничә еллар буе ашкынып көткән аңлашуның үзе иде.
Ким дигәндә ярты сәгатьлек тыныч очрашу шул рәвешле тәгәлләнде. Ахырда егет кызның хәлсез, йомшак кулын аеруча бер кичереш һәм рәхәтлек белән кысып хушлашты да өске катка, Борис янына менеп китте. Шул вакыт кинәт, барлык сөенечләрне җиңеп, башына сәер уй керде: «Әгәр Фәез үзе чакырып, аларны сәяхәткә алып чыкмаган булса, елан аның өенә килмәс иде бит. Әйе, очраклы хәл, очраклы бәла — ләкин ул очраклы булмаган, озак вакытлар инде йөрәктә йөргән һәм зурая, көчәя барачак мәхәббәт белән бәйле!»
Үзен ничек кенә акларга тырышса да, ул барыбер бераз гаепле бугай. Уйлый-уйлый фикерләр дә бутала: мәхәббәт һәм агу, лирика һәм тимер, Кама һәм автоград...
Ул үзен баһадир егет итеп, кулында гигант автомобильләр тотачак гигант итеп, кызны гүзәл Кама итеп күрә. Юк, бу хыял гына түгел, бу чыннан да шулай, ләкин егетнең ялгышуы аркасында Кама һәлак булса? Юк, алай булырга тиеш түгел! Мәхәббәт агуга әйләнмәскә тиеш. Баһадир егет һәм Кама... Аларның кавышуы Демон белән Тамара үбешүе кебек һәлакәтле булмаска, ә дөньяга тагын да күбрәк яктылык өстәгән электр лампалары төсле балкырлык мәхәббәтнең башлануын бөтен җир һәм күкләргә хәбәр итәргә тиеш!
Әлбәттә, Борис андый мәхәббәткә ышанмас һәм аны тагын бушка шапырыну дип атар. Хәер, аңа бу хакта әйтеп торуның хаҗәте дә юк лабаса!
Тик Фәез бу юлы юкка курыккан икән: Борисның хәле бәхәсләшерлек түгел, кәефе шактый түшенке күренә иде. Фәезне күргәч тә әллә ни шатланмады кебек.
— Исәнме, Боря! Хәлең ничек? — диде Фәез, карават янына килеп.
— Хәлләр ярыйсы, Фәез,— диде тегесе, тавышы белән «егет кеше зарланмас» дигәнне аңлатыбрак.— Утыр.
Фәез урындык алып утыргач, дустының башын тотып караса (ул моны Камага карата эшли алмаган иде бит, Борисның температурасы шактый югары кебек тоелды.

— Әллә салкын да тигәнме?
— Башта калган иде бит, һаман шул бугай.
— Һушыңны шуның аркасында җуймагансыңдыр бит? — Болай сорап, Фәез дустын рәнҗетте һәм, шуны сизеп, сүзен төзәтергә ашыкты:— Синнән соң мин дә суырган идем, агу калмасын дип. Чынлап та калмаган икән. Молодец.
Борисның йөзендәге үртәлү галәмәте кими төште.
— Әле... калган булса да... синең ирендә җәрәхәт булмаса, зыяны тимәскә мөмкин. Минем ирендә кечкенә генә яра бар иде.
— Ә син... агуны үзеңә күчергәнсең...
— Шулай булып чыга. Врачлар да шулай диде.
— Иреңендә шундый җәрәхәт барын белгән килеш...
— Ә нәрсә эшләргә? Бүтән җай юк иде бит. Гетага кушыйммыни?
Менә сиңа Борис! Үзен нинди кечкенә кеше итеп күрсәтергә ярата торган Борис чынлыкта чын кеше, герой да була ала икән! Бер факт моңарчы булган барлык хәлләр һәм вакыйгаларны кире какты да куйды. Менә нинди дә була беләсең икән син, дустым Боря!
Бу сүзләрне Фәез, бәлки, кычкырып та әйткән булыр иде, ләкин вакыт җитмәде. Хис һәм уйны бүлдереп, ишек артында әллә нинди шак-шок иткән тавышлар ишетелде һәм, күп тә үтмичә, ишек шакыдылар.
— Әйе.
Фәез шул сүзне әйтүгә, ишек ачылды да аннан... Иа ходай, Пичугин килеп керде! Култык таяклары белән! Фәез — телсез, шаккатып тик тора. Борис күзләрен үк йомган. Мескенең! Бүтән чарасы калмагач, шулай гына кача ала, әйтерсең, үз өстенә килгән бәладән шулай гына котыла ала!
Иптәшләренең югалып калуына мәзәксенгән Пичугин, дөп-дөп атлап, ишекне япты да әле Бориска, әле Фәезгә карап шактый торгач кына исәнләште.
— Исәнме, Коля,— диде Фәез икесе өчен дә,— уз әйдә.
— Узарга килдем...— диде Пичугин янаган сыман бер тавыш белән.
Баягыча дөп-дөп атлап, караватка якынлашуга, Борис:
— Якын килмә! — дип кычкырып ук җибәрде. Торып утырып, стенага терәлде.
— Пичугин, җүләрләнмә! — дип кычкырды Фәез дә.
Боларның каушавыннанмы, әллә бүтән сәбәптәнме, Пичугин баягыдан да ныграк гаҗәпләнгән төс белән әле Фәезгә, әле Бориска карый торгач, ниһаять, телгә килде:
— Ә ник? Миңа килмәскә идемени?
— Бәлки, шулай дөресрәк буласы булгандыр,— диде Фәез.
Пичугин үз колагына үзе ышанмады:
— Фәез, син сөйлисеңме соң бу сүзләрне? Кайчаннан башлап?
— Вакыты түгел, Борис авырый. Хәле начар.
— Шуңа күрә килдем дә бит инде.
— Ник?
— Хәл белергә.
— Хәл белергә?
— Менә инде. Моның нәрсәсе гаҗәп?
Фәез иркен сулап куйды һәм Бориска карап елмаерга тырышты:
— Боря, күрәсеңме син бу кешене?
— Күрәм.— Шулай дигәч, Борис тагын ятты.
— Кайчан кайттың?
— Кичә генә.
— Әй, утыр син, Коля. Кара без тиләләрне, урын да бирә белмибез,— дип, Фәез урындык китерде.— Мин теге вакытта сизми калганмын, озатырга өлгермәдем, кич барсам, инде сине очты диделәр. Ну, ничек анда, ошадымы Мәскәү врачлары?

— Ошамыйча.
— Нәрсә диләр?
— Монда арка миенә зыяны тимәгәнме дип шикләнгәннәр иде. Тимәгән диделәр.

Кайчандыр сау-сәламәт булган кеше, култык таякларына карап, бүген шулай дип шатлана — кызганыч та бит, нишлисең.

— Әйбәт,— диде Фәез аның кәефен төшермәс өчен,— бөтенләй тереләсең инде, алайса.
— Бөтенләй үк булмаса да... Таякларны ташларсың, диләр.
— Әйбәт.

Борис һаман сүзгә катнашмыйча ята бирде. Ул Пичугинның үзе янына ни өчен, нинди ният белән килүен аңлый алмыйча аптырый иде, күрәсең. Болай кыяфәте тыныч кебек булса да, Фәезнең дә әле фикере бик үк ачык түгел. Монда килүе Борисны гафу итүеме? Гафу итсә, димәк, ул Борис хаклы дигән нәтиҗәгә килгән. Аннары үзеннән-үзе аңлашыла инде: Фәез хаксыз була... Димәк, Пичугин аны гаепле дип саный. Менә бит ничек килеп чыкты. Бүлмәнең өч почмагында өч кеше утыра. Берсе белән килешсәң, икенчесен рәнҗетергә, берсе белән дуслашсаң, икенчесе белән дошманлашырга кирәк булып чыга. Хәлнең шундый хәерсез икәнен алар, мөгаен, өчесе дә сизә, өчесе дә нәрсәдер әйтергә тели, тик әйтә алмыйлар.

Борисның да, Коляның да физик көчсез чагы, аларның җанын борчу вөҗданга хилафлык китерер. Шулай булгач, бүрәнәнең юан башын Фәез үзе күтәрергә тиеш. Ләкин ничек итеп? Ихтимал, бу хакта сүз кузгатмаскадыр? Иң дөресе, бәлки, шулдыр? Алайса, һәркемнең күңелендә бөркөнге төслерәк бетон тау кала... Ә бетон, сәгать эчендә салкынаеп, ташка әйләнә. Нишләргә? Гомумирәк мәгънәләрдән башлап карарга кирәктер — бер тотынып нәрсә чыкмасмы?

— Карале, Коля, сине Мәскәүгә озатканда, мин өйдә юк идем. Син үпкәләмәдеңме?
— Юк.— Пичугин култык таягын сыйпарга кереште.

Сүз тагын бүтән якка китмәкче. Ничегрәк аны кирәк мәгънәгә якынлаштырырга соң?

— Безнең менә ничек бит... хәлләр...— диде Фәез, сүзенең мәгънәсен оештыра алмыйча,— шулайрак килеп чыкты... беребез теләгәннән дә түгел, әлбәттә. Төрле хәлләрнең бергә туры килүе диләрме, язмыш диләрме? Татарча язмыштан узмыш юк диләр. Шулайрак инде монда. Мин, мәсәлән, Коля, синең егылып төшүеңне һич тә теләмәдем. Ышанасыңмы шуңа?
— Ышанам.

Икесе дә Бориска карадылар — димәк, ул да үз сүзен әйтергә тиеш.

— Ә син, Боря? — Монысы да Фәез соравы, ләкин аны Коля әйтте һәм тагын култык таягына тотынды. Бу — аның Борис өчен кыенлык кичерүе иде бугай.

Үзеннән бигрәк, Коляны җайсыз хәлдә калдыра торган шикләрдән коткарыр өчен Фәез үзе дә сизмәстән шактый кискен тавышка күчте:

— Синнән сорыйбыз, Боря, ышанасыңмы шуңа?
— Билгеле, ышанам,— диде Борис сүренке генә.

Бу сүренкелекне бик үк ышанып житмәү, бары тик әдәп йөзеннән генә әйтү дип уйларга мөмкин иде. Әмма тегеләй дә болай дип юрарга өйрәнмәгән Коля, Борисның бу сүзен ишеткәч, җиңел сулап куйды. Тик бераздан тагын шөбһәләнгән кыяфәттә маңгаен сыпыргалады:

— Соң... Алайса, ник җыелышта икенче төрле әйттең?
— Ашыкма, Коля, алай каты куйма. Башта бер төрле уйлап, соңыннан кешенең фикере ачыкланырга, үзгәрергә мөмкин. Шулай бит, Боря?

Хикмәт, Борис тагын торып утырды. Фәез аны яткырырга тырышып, «бүтән вакытны сөйләшербез, бүгенгә җитәр», дип караса да — тыңламады, ятмады:

— Әйтсәм әйтим инде, алайса. Мин синең, Фәез, гаепсез икәнлекне башта ук белдем.

— Шулай булгач, сүз дә бетте, рәхмәт, ят, җитте. Без бит җитди нәрсәләргә күчтек болай.

— Мин курыкмыйм...

— Әлбәттә, куркырлык нәрсә бар монда? — Фәезнең сүзне туктатырга теләве тавышыннан ук сизелеп тора иде.

— Мин ялгыштым — синең гаепсез икәнне белгән хәлдә, яла икәнен белгән хәлдә...

— Әшәке җан!..

— Коля!..

— Сугып үтерәм мин аны хәзер, сволочьны. Нәрсә ди бит?

— Ул дөрес әйтә.

— Дөрес әйтә шул — мин аны алай ук түгелдер дип, теге вакытта ялгыш каты бәрелдем дип, гафу үтенергә киләм тагы, ашыга-ашыга киләм. Нинди кара ният белән йөргән бит, бүре!..

Алай-болай култык таягы белән кизәнә күрмәсен дип, Фәез тиз генә ике арага кереп, аягүрә баскан Коляны кочаклады:

— Ярсыма, ялгышма, ашыкма!..

— Яхшы ният белән, хәл белергә дип киләм бит мин аның янына. Тфү!..

— Ярый, булды, бетте. Борис та үзенең ялгышуын әйтмәкче иде, турысын әйтмәкче иде. Син аңа комачау иттең. Шулай бит, Боря? Шулаймы?

Борисның бит нервылары калтыранып тора. Шулкадәр кызганыч, шулкадәр күңеле тулган, шулкадәр ярсыган иде ул бу вакытта. Коля кебек тузына гына белми. «Ах, бер дулап алса хәзер!»

Борис орышмады, ләкин, үҗәтләнеп, әйтәсе килгәннең бөтенләй киресен әйтте:

— Юк, алай түгел! — диде. Шуннан соң караватына ятты да күзләрен одеял белән каплады. Чынбарлыктан тагын күз йомып котылырга тырышу инде бу. Ләкин нишлисең?! Коля бит эшне тагын бозды. Кылмагән булса, акыллырак эшләгән булыр иде. Тимер белән эш иткәндә гаҗәп оста куллар кеше кичерешләренә кагылганда коточкыч тупас булып чыкты шул. Аның үзенә моны әйтеп булмый, ни дисәң дә, ул үзе дә әле савыгып, кайгысыннан арынып җитмәгән, нервылар авыртуыннан котылмаган. Әгәр җаны һәм тәне сау булса, бәлки, ул да бу хәтле рәхимсез булмас иде. Хәзер менә гаделлек өчен көрәшәм дип гаделсезлек эшли.

Ничек кенә итсә дә, Фәез Бориска ачулана алмый һәм хәзер күңеленнән Коляны тирги. Ник алай иткәнен үзе дә аңламый әле.

— Әйдә, Коля, китеп торыйк, яхшы түгел,— диде ул.

Пичугин ишектән чыгып барганда, Фәез Борис янына килеп иелде дә:

— Ачуланма, Боря, ул кызурак канлы. Аңлагач, гафу үтенер әле,— дип пышылдады.

Борис, иреннәре калтыравын җиңеп, көчкә генә:

— Бик кирәк,— дия алды.

— Ну бит...

— Бернәрсә дә кирәкми миңа аннан.

— Син аны гафу итсәң, ул да итәр.

— Гафу итүе дә кирәкми, мин үземне гафу итә алырга тиеш. Аныкына исем китми.

Сызланып әйтелгән шул сүзләр, хикмәт, Фәезнең күңелен күтәреп

җибәрде. «Димәк, егет үз хәлен аңлады, димәк, аңарда хәзер икенче кеше уянган!»

Шуңа күрә Фәез, иптәшен тынычландырырга тырышып:

— Үзенне-үзең гафу итә аласың инде син хәзер...— диде.

— Һы...— Борисның бу ымлыгын да шулай ук үзен тиргәү галәмәте дип кенә аңларга мөмкин иде.

— Кеше ялгышмый тормый.

— Ялгышу белән ялгышуның аермасы бар шул, Фәез. Ә болай... Ярый, булды инде.

— Мин сиңа ачуланмыйм, Борис.

— Аннан ни файда?

— Ярый, алайса, соңыннан сөйләшербез. Давай, тиз генә терел. Хуш хәзергә,— дустының башын сыйпап әйтелгән кайгырту иде бу.

— Хуш,— диде Борис, сүренке тавыш белән...

* * *

Өченче көн дигәндә Кама больницадан чыкты. Борис янына Фәез белән алар бергә килә башладылар. Кыз элеккечә сау-сәламәт, якты чырайлы һәм шул яктылыгы белән Фәез тормышын гына түгел, бөтен дөньяны тагы да матуррак итеп бизи кебек. Тик менә Борис кына үзәкне өзә. Тәки фартсыз егет булып чыкты бит. Бер килмәсә, килми шул ул, үтерәсеңмени аны. Кама терелгәч тә, ул — коткарган кеше — әле өч-дүрт көн ятты, ә елан чаккан кеше тизрәк терелде. Туры килүен күр син аның — нәкъ менә шул көнне иренендә ярасы булган. Табигый инде — ярасы булгач, агу да үз эшен эшләгән...

Борис, мөгаен, үзе дә сизә торгандыр. Югыйсә, больницадан чыгасы көнне Фәез аңа:

— Я, ничек, савыктыңмы инде? — дип сорагач, Борис сәер генә итеп җавап бирде:

— Бетеп бетмәде, ахрысы... Нәрсәдер калды шунда, җанны бертуктаусыз сызлатып тора. Канда бераз агу бар бугай.

Андый ихтималлык юк югын, әмма кайчакларда нигезсез сүзгә дә ышанасы килә. Борисның күзләренә артык текәлмичә караганда да, кайдадыр тирәндә, тәннең кай төшендәдер бик әрнеп авырткан, янып торган шеш күренә төсле.

Пичугинга эшне ныклап төшендергәч, анысы үзенең тупаслыгын аңлады һәм, Фәез сүзен тыңлап, Бористан гафу да үтенде.

— Мин сиңа ачуланмыйм, Коля, борчылма,— дип кенә куйды Борис һәм шуның белән сүз дә бетте.

Кичләрен, дәресрәге — төннәрен, Фәез, Кама белән бергәләп, Борис өенә килгәли торган булдылар.

— Син юкка хафаланасың, бөтенесе рәтләнде, Боря, мин сиңа ачуланмыйм, Коля да гафу итте бит.

— Сез итү беләнмени, монда үзем бар бит әле,— диде шул сүзгә каршы Борис, чак кына елмаерга тырышып. Һәм шуның аркасында тагын да кызганычрак кыяфәткә керде.

Фәез, иптәшенә берничек тә ярдәм итә алмавын аермачык күреп, тугарылды да калды һәм көенүдән башка инде бүтән чара да тапмады.

Лазарев белән сөйләшеп карамакчы иде,— юк, җае чыкмый. Хәзер, автоград төзелеше башлангач, Лазарев яшен ялтыравына әверелде — күзгә күренеп өлгерми, юкка да чыга.

Кадрлар бүлегенә барсаң, һаман да чират — инженерлар, прораблар, ташчылар, бетончылар,— һөнәрлеләр, һөнәрсезләр. Картлар әйткәндәй, Җәмәлҗан явы кебек агылалар. Яңадан-яңа идарәләр оеша, аларга яңадан-яңа җитәкчеләр куела. Идарәләргә җитәкчелек итәр өчен

тәҗрибәле инженерларны көндез чыра яндырып эзләгән чак. Тик менә Борис читтә... Берни эшләтер хәл юк...

Беркөнне киногa чакыра кергәч, Борис анда барудан баш тартты. Кызлар белән дә сирәк күренә, үзенең элекке активлыгын югалтты кешең. Мәхәббәт тәмен дә җуйгач, ана тагын нәрсә кала икән инде?

Китешли, ишеккә килеп җиткәч, Кама сорый куйды:

— Мин сезне безнең төзелештән китә икән дип ишеттем, Боря. Дөресме шул?

— Төзелештән түгел, шәһәрдән,— диде Борис таныш, ясалма елмаюы белән.— Шунысын гына ялгыш әйткәннәр.

«Нигә?» соравының уңышсыз икәнен Фәез шунда ук төшенде, ләкин артык көтелмәгән яңалык булганга күрә, шуннан яхшырак сүз тапмады.

— Беләсең ич инде, Фәез.

— Кая җыенасың соң?

— Мәскәү ягына... Лебедев эш табарга вәгъдә иткән иде.

— Киткән чактамы?

— Әйе.

Фәез, аптырагач, бармаклары белән чигә чәчләрен тарагандай итеп торды да Каманы култыклап ишекне ачты:

— Ашыгырга ярамый, Боря.

— Гариза бирдем инде.

— Лазарев белән сөйләштеңме? — Фәез ишекне яңадан япты.

— Нәрсә хакында?

— Киңәшү мәгънәсендә.

— Нәрсәсен сөйләшәсең инде — бөтенесе ачык.

— Барыбер сөйләшергә кирәк. Бәлки, ул сине җибәрмәс.

— Уникe көннән соң мин азат.

— Нинди азатлык бит...

Күпме үгетләсә дә, файдасы булмады. Ахырдан, сүзне икенчегә борыр өчен генә, Борис Кама белән Фәезнең икесен дә бергә кочаклагандай итте:

— Бик шәп пар булырсыз, ахрысы.

Кыз сүзсез генә «әһе» дигәндәйрәк ымлык чыгарып елмайды, Фәез исә горур төстәрәк әйтә куйды:

— Мин генә таптым бит Каманы.

— Бу — Камилә, Кама түгел.

— Кама.

— Каманы син тапмадың, ә менә мин табачакмын.

Мактануга охшашрак бу сүзләр Фәезгә бик авыр ишетелде. Менә бит, син аңа ярдәм итәргә тырышып ут йотасың, ә ул нәрсә уйлап ята!

— Ярый, тыныч йокы, Боря...

* * *

Нихәтле рәнҗесә дә, Фәез әйткән сүзеннән баш тартмады. Каядыр узып барышлый аның идарәсенә тукталган Лазаревка беренче сүзе шул булды:

— Анатолий Самойлович, Борис бездән китә икән бит.

— Кайсы Борис?

— Филинов.

— Ә... Ну?

— Ни өчен киткәне сезгә билгелеме?

— Билгеле диярлек. Шуннан?

— Ул хәзерге эшеннән канәгать түгел.

Управляющий, китәргә җыенып, Фәезнең аркасыннан какты:

— Бөтен гаеп тә шунда шул: ул бер эштән дә канәгать түгел. Аның бердәнбер теләге — идарә башлыгы булу.

— Хәзер кешеләр нәкъ кирәк чак лабаса, сезнең өчен авыр эшмени бу?

— Бик кыйбатка төшә. Без үз теләгебезгә ирешми калабыз, аны тәки тәрбияли алмаганбыз дигән сүз була. Аның эшкә, коллективка, гомумән, дөньяга карашы һаман шул, элеккечә. Безнең дөнья кешесе түгел, чит дөньядан һаман кайтып житмәгән әле ул. Ә аны кайтарырга кирәк.

Лазарев шулай дип ишеккә якынлашты, ә аңа ияреп килгән Фәез үзсүзләләнә бирде:

— Бәлки, начальник итеп куйсагыз, төзәлер.

— Ә житәкчелек иткән меңнәрчә кеше күңеленә ул үз җанындагы чирне йоктырса?

— Ничек?

— Менә шулай. Йоктырса?

— Йоктырмас, бәлки?

— Бәлки... Ә миңа тәгаен кирәк. Бармы шундый гарантия? — Фәез эндәшми торган арада управляющий тагын да кискенрәк тавыш белән өстәде:— Юк андый гарантия... Димәк, мин аны кызганып, бүтән кешеләрне харап иттерә алмыйм. Хакым юк. Беттеме?

— Шулай да... үзе белән сөйләшеп карасагыз, шәп булыр иде.

— Ул минем фикерне белә инде.

— Тагын бер тапкыр. Соңгы тырышлык... Бәлки, файдасы тияр.

Ахырда Лазарев синнән котылып булмас дигән сыманрак бер хәрәкәт белән өстәл янына яңадан килеп утырды да, елмаеп:

— Ярый, син бик үтенеп сорагач, сөйләшермен,— диде.— Ләкин берәр рәт чыгар дип уйламыйм. Аңа моннан китү, бәлки, чынлап та хәерлерәктер. Югыйсә, аны бөтен кеше белә, бөтен кеше кырын карый. Кыендыр кешегә. Ә хәзер әйт: унжиденче комплексның сиңа тапшырыласын беләсеңме?

— Беләм.

— Ничек алай «беләм»?

— Ә нәрсә әйтим соң?

— Рәхмәт әйт, автоградта сиңа шундый зур объект, беренче дәрәҗәле зур объект бирәләр, ышаналар сиңа!

— Рәхмәт, Анатолий Самойлович.

— Менә бүгеннән үк ничек эшлисез, ничек башлыйсыз — хәл итегез. Графиклар төзеп тикшерегез, киңәшегез һәм безгә хәбәр итегез. Булдымы?

— Тырышырбыз, Анатолий Самойлович.

* * *

«Кама түгел, ул — Камилә, Камилә — Кама түгел». Шул сүзләр колакта көннәр буе чыңлап торды. Чыңлау гына түгел, уйларны, хисләрне каушатты. Көннәргә яктылык сибә торган бәхет, куәтле җилдә оясыннан купкан лампочка кебек, беркетелгән баганага бәрелердәй булып чайкала, талпына, тиберчеңә төсле. Кинәт шулай бәрелер дә челпәрәмә килер кебек. Бүген булмаса, иртәгә... Фәез көтә, үзе күрергә теләмәгән шул коточкыч көнне көтә. Ник? Моны ул үзе әйтә алмый әле.

Ләкин шунысын яхшы белә: Камилә һәм Кама, кыз һәм елга икесе бер йөрәктә бер төшенчә, бер үк гүзәллекнең ике төрле рәвеше булып яшиләр. Дөньяны чыңлаткан күпме җырлар, поэмалар, симфонияләр Каманы мактыйлар икән, алар Фәез мәхәббәтен дә зурлыйлар дигән сүз. Тик шул изге мәхәббәткә, Фәез ачкан матурлыкка хәзер Борис дәгъва кыла: «Сездән булмады, булмаячак та. Хәзер мин үзем сезнең

белән көрәшкә керешәм. Күцелем төшкән бер кызны да каратмый калмаган кебек, бу юлы да жиңәрмен. Бу юлы миңа Кама үзе караячак, мине Кама үзе яратачак! Син жиде метр биеклектән суга ташланган кебек, мин дә аның кочагына ташланачакмын!» — ди.

Бу сүзләрне Борис чак кына элегрәк әйткән булса, Фәез аңа ышанмас иде. Ә хәзер ышана. Нигә дисәң, Борис бүтән кешегә әверелеп бара шикелле. Аңардан әллә нинди кинәт борылышлар көтәргә мөмкин хәзер. Бигрәк тә шунысы кыен: дөньяга ул Фәез күзләре белән карый башлады, ахрысы:

— Кама мине яратачак! — диде бит...

Бу сүзләр, жылы, яшенле июль төнендә кырлардан кырларга, болыннардан болыннарга, урманнардан урманнарга таралып, яфраклардан яфракларга бәрелде, ярлардан ярларга, соры һәм яшел тауларга бәрелә-бәрелә шаулады. Фәез моны сизде, ишетте. Ләкин шушы кара төндә машинасына утырып, Борисның Кама белән кавышуга таба чапканын, юлларны юл дип, чокырларны чокыр дип белмәслек дәрәжәдә ярсыган көндәшенең караңгы ярлар, таулар, куаклар, урманнар буйлап атлыгуын гына күрмәде һәм башына да китерә алмады.

Юл юешлеген, машинасының тая-тая, кайбер жайсызрак, биегрәк чокырларда тау түбән оча язуларын Фәез түгел, Борис үзе дә тоймады. Аның башында бер генә уй: ул бүген Кама белән очрашырга, Кама белән кавышырга бара!

Кичен ресторанда утырганда ул моны бөтен кешеләргә ишеттерерлек итеп әйтте. Дөрес, кешеләрнең аңа ышанасылары килмәде, кешеләр моны бары тик исерек күңел тилерүе дип кенә аңладылар һәм ялгыштылар. Беренчедән, Борис алай тилерү дәрәжәсендә исерек түгел, икенчедән, ул чынлап сөйләшә иде. Хикмәт шунда — аның чынлап сөйләшүенә беркем ышанмый иде...

Менә хәзер Борис үзенең машинасында жилдертеп бара...

Фәез гашыйк булган кызга әйтерсең Борис та гашыйк һәм ул алданрак уңышка ирешергә сүз бирә. Житмәсә, теләген яшерми дә — Фәезнең үзенә генә түгел — үзе узган жирләрдә кешеләр күбрәк жыелган һәр төштә, һәр почмакта — нишләргә ниятләнүен кычкырып әйтә. Качып-посып түгел, ауга чыккан арыслан кебек ачыктан-ачык эшли! Ачыктан-ачык! Менә хәзер урманнарга, яланнарга кычкыра ул:

— Кама, ишетәсеңме, мин синең яныңа барам! Чык каршыма, каршыла, Кама, ник күрмисең мине? — ди.

Ә Кама чынлап та аннан кача, караңгылык белән, юк, карангылык белән генә түгел, жил, яңгыр, давыл белән томалана, шулар артына кача. Урманнар, таулар артына сыенуы гына житмәгән, машинага бәрелгән жилгә кушылып үчекләп көлә.

Әмма Кама юкка гына кача, Борис аңа барыбер барып житәчәк һәм...

Тукта, машина тау башына менүгә, Кама күренде түгелме? Караңгыда аеруы читен, әлбәттә. Ләкин әнә яшен ялтыраганда еракта, юк, еракта түгел, күп дисәң ярты чакрым арада Кама ялтырап китте. Әлбәттә шул, шул — Кама! Һәм машинаны туп-туры Камага таба куйды. Барлык газы һәм жегәрлеге белән үкерә-үкерә күпме вакыт баргандыр, әйтү кыен...

Сәгатенә йөз кырык чакрым тизлек белән чапкан машинаның ярты чакрым жирне күпме вакытта узганын, ничек кинәт кенә тукталуын һәм секунд эчендә диярлек түбән очуын исәпләү бик үк читен эш тә булмас иде, тик хәзер инде моның кирәге калмады. Шундый тизлек белән чапкан машинаның тын таулар биеклегеннән Кама кочагына ташлануы... күзгә дә чалынырлык түгел иде. Бу хәлдә вакыт дигән бөек кодрәт инде көчен жуйган иде шикелле...

Шул хәбәр икенче көнне шәһәргә һәм якын-тирәгә яшен тизлеге белән килеп житте, һәм аны ишетүгә, Фәез машинасы да, кичәге машина очкан тизлек белән диярлек, чабарга кереште.

Машина бер урында сулга борылды: чөнки юл шул тарафка, түбәнгәрәк төшә. Ә бер машина борылмаган, юеш җирне яра-яра, туп-туры киткән. Моның нинди юл икәнен бик тиз тойды Фәез...

Озакламый юл су читенә терәлеп, алар комлы тигезлек буйлап киттеләр. Үзәнлек барган саен тарая икән. Әгәр юл дөрес сайланмаган булса, алар суга терәлеп торган ярдан ары бара алмаячаклар. Шулай да тукталмадылар һәм шул тар урындарак кешеләр җыелып торганын күрделәр. «Шушында!» — Фәез тәненең эсселе-суыклы булып чымырдаганын сизде. Җиде метр биеклектән сикергәндә су шулай чымырдап тәнгә сырыша... Ләкин анысы — гаҗәеп ләззәтле бер чымырдау. Ә монысы... Борис та шундый ук биеклектән сикергәнме?.. Ай, бу сикерүләр!

Килеп тә җиттеләр.

Хәзер инде Фәез беркемне дә күрми, аны да күрмиләрдер, мөгаен. Югыйсә, кем дә булса сүз кушар иде бит. Хәзер инде барысы да сүзсез аңлашыла. Әнә ком өстендә машина... Суга өч метр ара калган.

Ком өстендәге машина ватылып-җимерелеп ята. Ярый әле, аның эчендә Борис юк икән! О! Фәезнең ничек шатланганын белсәгез!

Машина Камага өч метр калгач барып җитә алмаган.

Өч метр ара...

Фәез менә шул араны узарга — исән килеш узарга тиеш.

Өч метр ара...

* * *

Бу чатнамыш, шагыйрь әйткәндәй, Фәезнең йөрәге аша узды һәм аны да кискәләп үтте. Моңарчы мондый ук авыртуга, сызлануга очраганы булмагандыр аның, һәрхәлдә, хәтерләми ул. Борчылулар, кайгырулар булгандыр, ләкин бу хәтле үк булмагандыр. Таулы ярдан ташланган машина кебек, төзелештән Борис үзе дә имгәнеп киткәндер төсле.

Фәез эшләгән идарәдә ике участок начальнигы берьюлы имгәнде. Пичугин һәм Борис. Берсенең — тәне, икенчесенең — җаны... Икесе дә үзләре гаепле. Тик Фәез үз җитәкчелегендәге ике кешенең бер үк хәлгә таруында нindidер бәйләнеш эзләп интегә, нәрсәнедер күрми калдым бугай дип борчыла. Ничек? Нишләргә тиеш иде ул? Тагын нәрсә эшли ала иде?

Билгеле бер инстинкт кушуы буенча очраша килгән кыз-бызларын исәпләмәсәң, (әйе шул, аларны житди киңәшчеләр, иптәшләр санына ничек кертәсең!) Бориска иң якын торган кеше Фәез иде бит. Бүтәннәр күрә алмаганны беренче чиратта ул күрергә тиеш булгандыр. Ләкин нәрсә? Ничек?

Шәһәргә кайтып та җителгән икән. Хәтта идарәгә үк җителгән. Әмма Фәез, ник икәнен үзе дә төшенмәстән, икенче идарәгә узып китте. Күңеле сызлаган чакта Каманы күрәсе килде, ахрысы, шулай үзенең хәлен җиңеләйтмәкче булды.

Фәез машинасын тәрәзәдән үк танып, ул тукталганчы ук инде Кама ишек төбенә чыгып баскан да аны көтә иде. Машина туктагач та йөгереп килде. Фәез кабинадан чыгып аңа күтәрелеп караса, кызның күзләрендә курку, каушау билгеләре иде. Фәез дә машинага сөялеп — әйтерсең ул гаепле — тын калды. Шофер исә, комачаулыйм дип уйлады бугай, эше булмаса да, идарәгә кереп китте.

— Син ишеттеңмени, Кама?

— Ишеттем...

Фәезнең болай күнелсезләнүен Кама беренче тапкыр күрә. Хәтта больницага килгәндә дә болай түгел иде. Шуңа күрә кыз аны юатырга тиеш тапты:

— Сиңа монда кайгырыр нәрсә юк, минемчә. Борисның күнелендә сиңа карата бернинди рәнжү булырга тиеш түгел.

— Анысы шулай, әлбәттә.— Фәез ачык кабина ишегенә тотынды.

— Син аны җибәрмәскә күпме тырыштың...— Каманың тавышында шул кадәр ышаныч һәм тынычлык! — Бүтән ни эшли аласың инде?

— Бәлки, эшли алган да булыр идем...

— Ничек?

— Миннән дә якын киңәшчесе юк иде бит аның.

— Күрсәтте ул сиңа якынлыкны.

— Барыбер...

— Ярый, Фәез, тынычлан, кайгырма.

— Мин нәрсәнедер күрми калдым бугай, Кама. Кешелеклелек, игътибар дигән нәрсә җитмәде бугай. Менә мин уйлап торам әле, аның урынында син булсаң?.. Шулай да булуы мөмкин бит...

— Түгел, түгел! Мин ышанам сиңа, Фәез! Ышанам!

— Рәхмәт, Кама.

Кама — Фәезнең вөҗданы. Ул шулай дип торганда, чынлап та кайгырмаска кирәктер. Шулай да ямансу аерылыштылар.

Әйе, Фәезнең вөҗданы тыныч булырга тиеш — Кама хаклы!

Ләкин Фәез сизә: бу язмышка бүтән кешеләрнең дә катнашы бар, әйтик, Лебедевның. Борисны намусын пычратырга этәргән кеше шул түгелме? Ә Лазаревның? Әйтик, Пичугинның?..

Борисны идарә начальнигы итеп алучы, аннары баш инженерлыктан участок начальнигы дәрәҗәсенә төшерүче — Лазарев. Сәбәп һәм гаеп — егетнең үзендә, билгеле. Ләкин, ләкин... Күз алдында рәхимсез, ләкин табигый үсеш өчен бәрелеш, көрәш фаҗигасе төсмерләнә.

— Бзз-у, бзз-у-у...

Ишетелер-ишетелмәс кенә безелдәп, җайдак дигән нечкә билле бер чебен зур гына корт тирәсендә бөтерелә. Тегесе, моның ниятен белмәгәч, шикләнми дә, курыкмый да. Ә нечкә билле франт күз ачып йомарлык вакыт эчендә аны чагып та ала һәм... әлеге корт параличланган арада, аның корсак куышлыгына йомырка сала. Нияте изге — киләчәк буын хакында кайгырта! Аңына килгән корт, корсагында йомырка калганын әллә сизми, әллә авыртудан кагылырга куркып, тими. Ә көне җиткәч, йомырка, яралгыга әверелеп, зур кортның тәнендәге тереклекне суырып туклана башлый. Башта корт нәкъ әүвәлгечә яшәп ята: җепләрен суза, пәрәвез кора, ашый-эчә... берни белми, сизми — аның язмышы инде хәл ителгән. Көн үткән саен гәүдәсе, хәрәкәтләре сүрәнләнә Алдагы гомере нәкъ яралгы кортка кирәк кадәр генә калган. Ихтимал бала җайдакка әйләнеп, корт чыгып киткәч, ул терелә дә алыр иде. Әмма корт, аның тәненнән чыгар алдыннан — стратегик максатларда — аңа үтергеч агу җибәрә — чөнки, шулай эшләмәсә, үзенең корбан булуы ихтимал.

Мондый хәлләрнең табигатьтә еш очравын яхшы белә Фәез. Тик шунысын гына ачык әйтә алмый: ник менә тәгаен шушы вакытта күз алдына килде әле бу хәл? Тфү, шайтан...

Ләкин, теләсәң-теләмәсәң дә, фантазия эшли, син аны туктата алмыйсың инде. Фикер — туачак көн кебек, аның өчен бернинди киртәләр юк.

Бу заманда тормышны өч великан күтәреп тора: Табигать, Кеше, Машина.

Кеше урталыкта: ул бар нәрсәне дә күреп, бар нәрсәне дә ишетеп тора.

Әнә теге чебен һаман да тик кенә тормый — безелди. Безелдәве гүелдәүгә, мотор гөрләвенә әверелә... Гигант бөжән, металлдан ясалган баһадир бөҗән, табигатьнең үзе төсле мәңгелек гүзәллеккә гашыйк була, аның тирәсендә бөтерелә һәм... тиешле урында кортын калдыра...

Юк, юк, бу — тик куркыныч бер фикер генә, бу — киләчәк түгел, һич тә түгел. Ләкин, шундый куркыныч күләгә кыяфәтендә генә булса да, шундый уй дөньяга килә ала икән, аңа каршы хәзер үк инде баш күтәрергә дә кирәк. Кем эшли ала, шул эшләсен моны. Әйтик — Фәез.

Соңгы көннәрдә аның күңелендә сәер сурәтләр хәрәкәтләнә, аларны туктатырга кирәк. Ничек? Кем белән киңәшергә?

Әлбәттә, Лазарев белән.

Ләкин Лазарев төзелеш эшләренә муеннан чумган. Ул хакта аның белән сөйләшергә җай юк. Заданиеләр, йомышларның күбесе хәзер язмача, ә телдән булганда, башка кешеләр аша килә. Управляющийның үзен исә ай күрде, кояш алды. Күренгәндә дә, мөһим мәсьәләләр хакында гына сөйләшә дә, шәхси йомышлар үзеннән-үзе читтә кала. Алар хакында сүз башлау үзе үк уңайсыз. Ләкин Фәез җай табарга сүз бирде һәм болай эшләде: кичке эшләрдән үзе дә, управляющие да бушагач, управляющийның өенә китте.

Звонокка басты.

Ишек ачылды.

Лазарев үзе.

— Исәнмесез, Анатолий Самойлович.

— Исән. Уз.

Фәезгә шул гына кирәк тә бит инде — кыстатып торыр өчен килмәде — ишектән тиз генә өйгә кереп, әйткәнне дә көтмәстән, туфлиләрен салды.

— Әйдә, уз.

Шулай итеп, хуҗа аны залга чакырды. Хәзер инде әләктең, хәзер инде бөтен нәрсәне берьюлы ачыклаячак Фәез. Башта бер кызык ясап карау зыян итмәс, чөнки Лазаревның кәеф ярыйсы күренә. Хәзер менә нәкъ вакыты — хуҗа чак кына елмаеп карады да Фәез каршындагы креслога чумды:

— Берәр йомыш бармы?

— Сез мине сәгать сигезгә чакырган идегез,— диде Фәез, былтыргы чакыру турында уйлап.

— Чакырган идем?.. Сигезгә? — диде Лазарев, гаҗәпләнеп.

— Әйе. Тик үзегез тугызсыз кайтып җитмәдегез.

— Менә кызык... Ә! Чакырган идем бугай шул. Әйе, чакырган идем — оныткаңмын, валлаһи, оныткаңмын. Мең-мең гафулар үтенәм. Тәки оныткаңмын. Ник чакырганым да истән чыккан, менә бит, ә, баш!..

— Шундый вакыт бит, Анатолий Самойлович,— дип «ярдәмгә» килде Фәез.

— Менә ничек килеп чыга ул — мин шәхси очрашуларны көн расписанисенә кертмим. Язып куймагач, онытыла. Просто плансыз эшләр рәтенә кергәнсең, иптәш, ачуланма.

Әлеге сүзләрдән соң Фәез Лазаревка теге вакытта хәтере калуының никадәр мәгънәсез икәнен аңлап рәхәтләнеп көлде.

Ничек үпкәлисең инде шундый кешегә! Ә күпме шик туган иде! Аңларга кирәк шул, барлык шикләр аңлап бетермәү аркасында туа.

Иң яхшысы шул — Фәез хәзер чакырылган кунак хокукында утыра. Монысы инде бөтенләй бүтән хәл.

Тик менә ничек итеп сүзне башларга икән?

Борис бик яңа җәрәхәт шул, авыртып, сызлап тора, мөмкин кадәр кагылмау акыллырак булыр. Ерактанрак, әйтик, Лебедевтан башласа?

Анысын тагын кем белгән — бәлки Лазаревның чуанына кагылу булыр бу...

Әмма сүз җае үзеннән-үзе килеп чыкты. Рәсми вәкилләр очрашуы түгел, тикшереләсе сүзне өстәлгә салып, кискәләп карауның кирәге юк. Мондый чакта вакыт һәм сүз сөреше әңгәмәне үзе алып бара. Фәез дә шуларга иярергә кирәк тапты.

Башта хуҗа Фәез идарәсендәге эшләр хакында сорашты. Җайсыз яклардан берсе шул икән — проект заданиеләренең килеп җитмәвеннән зарландылар. Фәез үзенә тапшырылган комплекста эшне башлаган, бөтен дөнья айкап ташланган — нулевой цикл... Җирнең астын өскә китергән — шуларны әйтте.

— Дөнья беткәндә, җирнең бер каты юкка чыга, ди...

— Ә бездә дөнья шулай төзелә,— диде Лазарев,— без, илаһи көчне айкап чыгарып, шуны кешеләргә тапшырырга җыенабыз.

«Илаһи көч» диде, искиткеч куәтле яңа машина димәде. Лазаревтан мондый пафослы сүзләр сирәк ычкына. Димәк, ул хәзер үз идеясе белән шул дәрәҗәдә әсәрләнгән ки, кайбер очракларда хәтта хыялый Фәездән дә арттырып җибәрә.

Фәез һаман үзен кызыксындырган нәрсәне тикшереп азаплана:

— Илаһи көч дигәнебез дию булып чыкса? Үзебезгә теш ыржайта башласа?

— Безгә аңардан өстен булырга кирәк, әлбәттә, властьны ычкындырсаң, уңай җеннең тискәре җенгә әйләнүе бик ихтимал. Синең белән без шуның өчен куелганбыз да бит инде.

— Дегет кебек, кислоталы су кебек, бүтән шундый агулы сыекчаларның табигать дөньясына барып җитүе ихтимал,— диде Фәез, Лазарев сигарет пачкасын ачкан арада.

— Әйе. Проектчыларга без моны көн-төн тукып торабыз.

— Чынлапмы?

— Әйе!

— Алайса, без сезнен белән фикердәшләр икән.— Фәез, сөенүен яшермичә, рәхәтләнеп бер елмайды.

— Бергә эшләгәч, шулай булырга тиеш. Фикердәшләр булмагач, әнә кайберәүләр белән аерылырга да туры килде.

— Лебедевны әйтәсезме?

— Әйе.

Чыкты бит җай — менә сораш инде, Фәез дус. Тик форсатны ычкындырма, акыллырак итеп сора.

Акыллысын көтеп торсаң, җеп очы ычкынмагае дип, Фәез турыдан китте:

— Лебедев — минем өчен кызыклы бер табышмак ул...

Управляющий тәмәке кабызды.

Фәез, ашыгырга ярамаганны чамалап:

— Шакировта булган киңәшмә минем хәтердә әле,— диде.— Секретарь, үзегез хәл итегез, дигәч, Лебедев чыннан да үзе хәл итте бугай.

— Бүтәнчә эшли дә алмый иде ул.

— Ә сезнең киткәнне көтсә? Ул алай куймады, үзе китте.

Управляющий:

— Да...— дип кенә куйгач, тагын тынлык урнашты.

Ләкин Фәез утырдашын инде әсәрләндереп өлгерүен, хәзер сернең чишеләчәген сиздә һәм ялгышмады. Лазарев креслосы-нисе белән читкәрәк борылды, үзе чыгарган зәңгәр төтен аша каядыр еракка, узган хәлләргә күз ташлады һәм анда күргәннәрен Фәезгә әйтергә керешге:

— Ә бит булды шундый вакыт, әллә бөтен нәрсәдән — ГЭСыннан, автоградыннан кул селтимме икән, дигән сорау үземне дә ярыйсы ук

озак борчыды. Иртәгә торам да Мәскәүгә гариза җибәрәм, дип хәл кылган минутларны да хәтерлим. Ләкин андый фикерләрдән бик тиз айныдым. Җитди булмас иде алай.

— Дөрес әйтәсез, Анатолий Самойлович.

— Син үзең уйлап кара. Башлап кемгә тапшырдылар бу төзелешне? Миңамы, әллә Лебедевкамы?

— Сезгә, билгеле.

— Шулай шул. Рас миңа ышаныч күрсәтеп, шундый зур эш тапшырганнар икән, мин инде үзем дөрес дип исәпләгәнчә ахыргача эшләргә, тырышырга тиеш — үзем ышанганча! Үзем дөрес дип тапканча! Әгәр инде ялгышсам, җимерелеп төшсәм, рәхим итсеннәр — мине бүтән кеше белән алыштырсыннар. Ләкин, шөкер, ул чакта да, хәзер дә андый хәл сизгәнем юк. Кемдер, бүтәнчә эшләргә теләп, мине иманымнан яздырып, үз иманын миңа тагарга тели икән, юк инде, мин мондый чакта аңа юл куялмыйм. Тапшырсыннар үзенә һәм карасын үзенчә. Сәләтлерәк икәнен күрсәтеп карасын.

— Ә Лебедевта андый сәләт юкмы?

— Әгәр мин аның үземнән яхшырак икәнен тойсам, карар идем әле. Юк бит, миннән сәләтлерәк түгел ул. Хикмәт тә шунда. Ул бик кызыклы, акыллы кебек күренгән сүзләр сөйләр, матур итеп сөйләр. Ләкин сүз бер нәрсә, эш — икенче. Монда эш эшләргә кирәк. Сүз әйтелә дә бетә, ә эш кала — цехлар, заводлар булып, йортлар, шәһәрләр булып кала. Шайтан алгыры, монда бик оста ораторлар да муенын сындырыр һәм икенче тыгылмас мондый җиргә. Минем эштә бары тик дәрәҗә генә күргән карьеристлар бик кызыгалар миңа. Ләкин алар да тиле түгел, мине кысрыклап чыгарырга һәм минем машинага, минем креслога утырырга бик ашыкмыйлар. Тел белән эшләп кенә эшләргә мөмкин җирне карыйлар. Шулай бит?

— Бардыр инде.

— Бернинди «дыр»сыз. Менә син үзеңә кара, егет. Утыз да тулмаган молокосос бит син.

— Әйе... Филиновның үземнән өстенрәк икәнен дә сизә идем... Шуңа күрә...

— Дөрес түгел,— диде Лазарев, тавышын күтәрә төшеп. Син мине тыңла. Кемнәрдер күзлегеннән караганда, томшыгында сарысы да бетмәгән кош баласы нинди идарә белән җитәкчелек итә? Сиңа кызыгучылар юк дисеңме?

Фәез башын түбән иде һәм, «белмим шул» дигәндәй, иңнәрен җыерды.

— Бар. Бар гына түгел, күп алар. Ләкин буш куыклар синең урынга омтыла алмый, әлеге дә баягы — монда күзгә күренеп торган эш кирәк. Менә шуңа күрә тыкшынмый ул мондый җайсыз җиргә. Менә шуңа күрә синең кресло өчен конкуренция юк.

— Юк дип тә булмыйдыр инде, Анатолий Самойлович.

— Бүтән җирдәге хәтле үк түгел.

— Сез Лебедев хакында әйтмәкче идегез...— дигәч, Фәез уңайсызлык хис итте һәм тагын креслосына йомылды.

— Мин аның үзенә дә әйттем, син бик үк аккош түгел, төсең дә шактый кара, борының да шактый кәкре, тырнакларың да шактый очлы булып күренә, дидем, чак кына бүтәнчәрәк атала торган кош бугай син, дидем.

— Катырак әйтелмәдеме икән?

— Син нәрсә, миңа каршы чыкканда, ул чынлап та гел изге ният белән генә эш иткән дисеңме? Әлеге дә баягы, аның төп максаты — мине алыштыру иде бит, үзен акыллырак күрсәтү... Менә шуңа күрә дә каты тордым мин аңа. Ул үзе китәргә мәҗбүр булды. Шакировтан чыккач, бер атна көтте көтүен.

— Нәрсәләр уйлады икән?
— Анысы хәзер безнең өчен сер инде. Ул аны гомере буе беркемгә дә ачмаячак.
— Бер атна үткәч... шуннан ничегрәк?
— Мине Мәскәүгә чакырганнар иде. Шуны ишеткәч бу да керде. Сезнең урынга мин барып кайтыйм әле, ди. Үзең беләсең, монда эшләр яман да катлаулы чак иде — җибәрдем үзен Мәскәүгә. Ә ул, елан аягын кискән нәрсә, үзенә эш юллап киткән икән. Кайтып керүгә, назначениесен өстәлгә ташлады. Өстән каравын әйт син анын — утырмый да! «Ни әйтсән дә, иптәш Лазарев, мин синнән көчлерәк, син китә алмадың, ә мин менә китәм!..» — ди. Хәзер Мәскәүдә, минем белән җитәкчелек итә.
— Романыгыз яңадан башлана икән, болай булгач.
Уйлана калдылар. Фәез хәзер Лазаревның ниләр кичерергә тиешлеген чамалый. Ә тегесе бераз борчылганрак кыяфәттә утыра һәм үз вөҗданын тынычландырыр өчен, күрәсең, уйлаганын кычкырып әйтә:
— Юк, мин аны төзелештә калдыра алмадым, чөнки үземнән начаррак эшләячәген сизә идем. Киләчәкне спекулянт кулына тапшыру зыянлы булыр иде.
— Мин сезне аңлыйм,— дип сүз кыстырды Фәез.
— Ярар өчен генә әйтмисеңме?
— Гуманизм — сүз түгел, хәрәкәт. Үзеңнең матур хисләрең белән мактану, адым саен трибунадан кычкыру — алдашу дигән сүз. Чын хис тыйнак була.
Фәез, бу сүзләрне әйткәндә, никтер кызарып куйды.
— Дөрес, син бит менә мактанмыйсың, син хәтта оялчан. Ә чынлыкта...— Фәез үзен кая куярга белми аптырап торганда, Лазарев фикерен очлады:— Чынлыкта заман синеке бит...
— Анатолий Самойлович, сез ялгышасыз! — Катырак әйтелгәнгә Самойлович сагая калды:
— Ничек ялгышам?
— Шулай инде.
— Ничек шулай?
Фәез, кичерешләргә бирелмичә генә, сүзләренең ялгыш икәнен белгән хәлдә, соныннан бернинди шик калмасын өчен, үзенең гаепләрен юри куертып, ник алай уйлавын аңлатырга тырышты.
— Минем вөҗданда — ике кеше. Берсен физик яктан имгәттем, икенчесенең җанын... һәм... Гомумән, үземне гаепле саныйм. Болай, эш белән мавыгып, оныткан кебек тә тоеласың. Ә искә төшсә, сискәнеп китәсең, йөрәк авырта... Чын җитәкче мондый ялгышларга юл куярга тиеш түгел. Җитәкченең төп төзү материалы кирпеч, бетон гына түгел, ә кеше йөрәге, кеше язмышы. Мин, үзем дә сизмичә, көнләшергә мәҗбүр итеп, Бориснын җанын җәрәхәтләп торганмын. Җитәкче өчен бер кеше бик күп ул,— артык дәрәҗәдә күп. Ә миңа нихәтле кеше ышанып тапшырылган! Моңарчы биш йөз иде — ярты мең! Ә алар көннән-көн арта, күбәя бара — хәзер меңнән артты кеше! Юк, болай ярамый. Начальник үзенең беркемне дә имгәтмәслеген белеп торырга тиеш.
Фәез, кайнарланып, ярыйсы ук озын речь сөйләп ташлаган икән. Тамашачылар булса, моны сәнгатьле уку дип кабул итәр һәм, мөгаен, кул чабарлар иде.
Фәез күзләрендә ялтыраган чын яктылыктан Лазаревның да чырае яктыра барды һәм тегенди-мондый гына түгел, уйчан яктылык, мәгънәле яктылык иде бу. Мәгънәле тынычлык аның сүзләренә дә көчте. Лазарев, барлык ишеткәннәреннән үзенчә нәтиҗә чыгарып:
— Сездә тагын да күбрәк кешеләр коллективы белән җитәкчелек итәрлек сәләт бар,— диде һәм креслосыннан торып өстәлнең бу ягына — Фәез ягына чыкты.

Кинәт шулай «сез»гә күчүен кара син аның.

— Кешеләр өчен сан төшенчәсе юк, бары тик сыйфат төшенчәсе бар,— диде Фәез.

— Сез хаклы.

— Ә Филинов?

— Анда синең гаеп юк. Барысы өчен дә ул үзе гаепле. Чөнки ул без урнаштыра торган яңа тәртипләргә яраксыз кеше, иҗади сәләтле булуына карамастан, бөтен нәрсәне үз файдасына борырга тырышучы карьерист булып чыкты. Андый кеше коллективта ничек яши алсын?

— Бәлки, без аңа ныграк ярдәм итәргә тиеш булганбыздыр?

— Син аңа ярдәм иттең дә. Югыйсә, ул бу эшкә бара алмаган булыр иде. Машина белән бергә, үзенең яраксыз фәлсәфәсен ярдан тәгәрәтте бит ул. Шулай, син аны имгәтмәдең, ә терелттең...

— Сабак... Гыйбрәтле сабак. Безнең өчен дә.

— Яхшы кеше син, брат, тагын да зуррак эшләргә әзерлән.

— Нинди эшкә?

— Төзергә.

Фәез кайчандыр Бориска әйткән сүзләрен: «Төзергә, төзергә, төзергә — минә кешенең тормыш билгеләп куйган төп бурычы», диюен хәтерләп, елмаеп куйды.

— Эһе, төзергә.

— Тагын да зуррак колач белән. Кайчан булса да син мине алыштырачаксың... Мин шуңа ирешәчәкмен дә...

— Юк, юк, сез...

— Заман — синеке, дустым. Шуңа күрә фартлы кеше син.— Шулай дип, Лазарев егетнең иңенә кулын салды.

Фәез моны «аудиенция тәмам» дигән мәгънәдә аңлап, ишек төбенә килде һәм управляющийга иптәшләрчә күз кысты:

— Тыныч йокы.

Фәез аның өеннән күңеле ничектер бушанып, иркенәеп чыкты, гәүдәсе җиңеләеп калды. Тиз һәм җиңел адымнар белән үз өенә кайтып китте.

«Димәк ки, Кама хаклы, хаклы Кама!» Лазарев та, Кама да аңа ышандылар, ул бернәрсәне дә яшермәде. Ышандылар! Моннан да зуррак мактау буламы! Юктыр.

Вөҗдан теләсә кемне газапламый, яхшырак кешеләрне сайлый шул...

Иртән кояш башка көннәрдәгедән балкыбрак чыкты бугай. Югыйсә, менә бу яфраклар нигә тагын да сафрак булып яшелләнгән, ә һаваның зәңгәрлеге нигә тагын да ачыклана төшкән һәм чистарган?! Дөнья күбрәк аңлашыла төшкәнгә шулайдыр ул.

Фәез эшкә барышлый юри баш идарә бинасы яныннан узды һәм Лазарев кабинетына игътибар итте. Управляющий кичәге салмаклыгын тагын онытkан, гадәти тавышы белән үзенең яраткан сүзләрен телефоннан кычкыра иде:

— Колагыңа киертеп куй, иптәш, тупас кыланырга синең йоклагачкына хакың бар. Анда да берүзең йоклаганда.

Итагать турында кычкырган бу тавышта аңлашылып бетми торган ниндидер парадокс бар барын, ләкин нишлисең — ходай биргән тавыш. Лазаревның атаклы бу тавышы фәлсәфи фикерләр әйткәндә генә салмак ага башлый.

Бигрәк тә шунысы хәерле: төзелешнең беренче аккордлары — чиксез-чамасыз дөбердәү, гүелдәүләр, кычкырулар, җырлар, бәхәсләр, талаш, килешүләр — көннәр, айлар һәм еллар белән исәпләнә торган бөек симфония шуннан башлана. Бу аккордларда моңаюга, кайгыруга охшашлы бер генә аваз да юк — иртән кояш чыккан вакыттагы бу шатлык көннәр буена сузыла. Шулай башланган гомуми күтәренкелек

күңел төшенкелегенә бирелергә урын калдырмый. Бу — Каманың бердәм агышы. Анда дәрья — тамчылар була алмый. Кама... менә бу урында ул үзенең мәңгелек юлын чак кына үзгәртәчәк. Бу җирдә Фәез җитәкли торган идарә елганың яңа тарихын иҗат итә. Тарихның башы гидростанция дип атала.

Электросварщиклар кулыннан бүген ташып чыга торган утлар озакламый шушыннан шаулап агачак сулар сафлыгы булып әверелер... Каманың болай да якты сулары тагын да чистарып, бәллүр шикелле балкып һәм зәңгәрләнеп агар. Кама шушы төштә үзенең икенче төрле агышын — үзенең ут, яктылык рәвешендәге икенче төрле тормышын башлап җибәрер. Судан алынган, судан ургылган утлар... Ут һәм су — тоташ агым, бердәм хәрәкәт!

Аларны кушкан кодрәтнең башы, мөгаен, могҗиза күрә белүче кешеләрдәдер. Бу агым — күңел яктылыгы дип агала торгандыр. Һәм ул... ага, шаулап ага, чиксез һәм тыелгысыз булып ургыла...

Фәез дә йөрәгендә шундый тыелгысыз агым тоя, бәлки ул уттан ук яралгандыр әле. Борынгы философлар дөнья уттан яралган дип юкка гына уйламаганнар бит. Ә кайберләре судан яралган дип фараз иткәннәр. Дөрестер дә: ут белән су — дөньяның башы...

Һәм алар кавышырга тиеш!

Берәүләр яна, икенчеләр яңа ярала...

Мәңгелек агыш — кая барма, кая карама — үзгәреш.

Кайбер нәрсәләрдән һәм кайбер кешеләрдән бары тик истәлекләр генә калыр, кемнәрдер якты истәлекләргә әверелер. Ә кайберәүләр... Алар хакында сөйләп торуның да кирәге юктыр. Ә менә Рабига әби һәм аның кебекләр күңелләргә шулай ук яктылык булып өстәлер.

Фәез, инде безгә мәгълүм эшләре белән авылга барып, үзе төзеткән каралтыларны колхозга тантаналы төстә тапшыргач, былтыргы матур очрашуларны хәтерләп, әбинең үтенечен тыңлап (кыш көне: «өй исәнме икән, карап кайт әле», дигән иде бит), шул урамга килсә, ни күзе белән күрсен — өйгә яңадан тормыш кергән. Тәрәзәләргә кадакланган такталар алып ташланган. Анда гөлләр чәчкә атып утыра.

Өйнең яңа хуҗалары белән танышыйм, дип ихатага ашыгып керсә, тагын бер могҗиза: Рабига әби үзе басып тора. Кулында борынгыдан калган агач тас. Шуны тавыклар алдына куйды да Фәезгә күтәрелеп карады.

— Исәнме, Рабига әби!

— Ә! Син икәнсең әле, үз улым икән, танымый торам.

— Әби, син берәү генәме, әллә икәүме? — дип, Фәез күрешергә кул сузды.

— Ничек инде мин икәү булыйм, ди, балакаем, язмаганны,— дип, әби ике куллап исәнләште.

— Сине бит без шәһәргә урнаштырган идек, менә дигән итеп тора башлаган идең. Син шунда идең ләбаса.

— Юк, улым, калагыз үзегезгә булсын. Мин кайттым инде шушында.

— Нинди әйбәт тормышны ташлап, монда утынсыз-нисез газап чигәргә... Бик ялгыш эшләгәнсең, әби, ялгыш. Авырып китсәң, кем карар?.. Ә тегендә киленең, оныгың, врачлар, җылы өй...

— Оҗмах булса да кирәкми, балам. Үзегезгә булсын.

— Ах, әби, әби!

— Тора алмыйм, тыным кысыла. Үләм дип торам. Атна-ун көн рәттән елагач, түзә алмадылар. Рәшитем китереп ташлады.

— Бер ялгызың ничек гомер итәсең инде?

— Ялгыз түгел, менә чебиләрем бар... Чеп-чеп-чеп-чеп-чеп!

Якында гына йөргән чебиләре чыркылдаша-чыркылдаша килеп тә життеләр.

Шулар белән сөйләшеп калды әби...

Кешеләрнең тормышын яңартабыз һәм яктыртабыз, дип йөрибез. Ләкин бөтен кешеләрнекен дә түгел шул. Без төзегән тормышны яратмыйча, бу әби кире кайтып китте менә. Без төзегән тормыш һәм. кагыйдәләр белән килешер өчен Борис китте... Кемнәрдер китә... Кемнәрдер кала. Калучылар күбрәк. Әйе шул, чагыштыргысыз күп. Әби китсә, аның килене, оныгы калды. Алар өчен шәһәр — туган жир. Күптән түгел генә кыланчык һәм ялган егет булып буталып йөргән Рәшит тәмам акылга утырды. Бервакыт кич урам буйлап беләкләренә кызыл тасма бәйләгән егетләр һәм кызлар узып китте. Шуларның берсе Рәшит иде.

Беркөнне, эшкә барышлый очрап, Фәезне Гета да таң калдырды — кыз зәп-зәңгәр бушлат һәм чалбардан иде. Шул кадәр үзгәргән! Һәм тышкы кыяфәте генәме икән?

— Ничек син мондый кием киден, Гета? — дип сорады Фәез аңардан.

— Штукатурчы мин хәзер. Түзә алмадым.

— Молодец, Гета, яңа һөнәрең белән!..

Күңелләме? Күңелле. Ә андыйлар азмыни?

Йөзләр генә түгел — меңнәр алар. Бәлки, меңнәр генә дә түгелдер әле.

Шулай, Фәез бушка йөрми, һич тә вакыт әрәм итми — аның тырышлыгы күпчелеккә кирәк. Яшәүдә мәгънә бар, димәк, һәм ул яшәргә тиеш. Ничек яшәргә?

Төзергә.

Төзергә.

Төзергә!

Икмәк үстерү белән өйләр төзү — кешенең иң борынгы, иң бөек бурычы һәм мәгънәсе.

Фәез шулай яши дә. Күңелендә, уйларында — сүнми торган ут агымы. Ләкин аңа нәрсәдер житми бугай әле. Нәрсә икән?

Ут үзе генә булганда, күпчелек очракта — сафландыргыч кодрәт булу белән бергә, барлык начар яралгыларны юкка чыгаручы, дөньяны чистартучы көч булу белән бергә, һәлакәт тә ул... Чиста дөнья кысыр булып калмасын өчен, ут белән су кавышырга тиеш.

Егет белән кыз кавышкан кебек.

Ә Фәез? Кама?

Беркөнне кичке якта Фәез, эшләре артык күбәйгәнлектән, өйгә кайтырга соңлаган иде, аның янына зәңгәр блузасын аркасына салган Кәрам килде дә шундый ук зәңгәр карашы белән елмаеп әйтә куйды:

— Син, егет, тәкәбберләнеп киттең әле бу арада. Анда сине кызлар юксына, ә син...

— Нинди кызлар?

— Нинди булсын, Кама.

— Кама?

— Бүтән кем тагы?! Менә инде!..

Фәез дустының кулларын кысты да каты итеп селкә башлады:

— Син каян беләсең аның мине юксынганын?

— Үзе әйтте. Бар, ул анда сине көтә...— Фәезнең ышанмаска тырышканын сизде Кәрам,— үзе әйтте...

Кайчандыр Каманың кайда икәнен әйтмичә яшереп йөргән кешенең, хәзер килеп, очрашырга бар дип үгетләве — шулай ук яңалык. Семья тормышы рәтләнеп, бөтен уңайлыклары килгән квартирда үз малайлары һәм хатыны белән бергә чын мәгънәсендә матур итеп яшәгәнгә күрә генә, шуңа ирешергә Фәез ярдәм иткән өчен генә түгел бу, әлбәттә.

Камага күз ташлау һәм өметләнүнең үзе өчен буш хыял икәненә ышанганнан киләдер бу. Борис сикереп күрсәтте — Кәрам да шуны ук кабатларга тиеш түгел бит...

Хаклымы, түгелме, Фәез шулай дип уйланды һәм Кама эшләгән идарәгә китте. Кәрам әйтмәсә дә, шулай эшләгән булыр иде, билгеле.

Фәез эчкә кереп өлгергәнче, кыз беркөнгечә үзе каршы чыкты. Күзләренең, бөтен торышының мәхәббәт белән балкуыннан аның нинди уйлар һәм хисләр кичерүен тоюы, дөресрәге, күрүе кыен түгел. Моның өчен күзсез генә түгел, моңсыз да булырга кирәк.

Бориска охшамас өчен, Фәез кызны машинага чакырмады. Еарграк барасылары килгәнгә, тын ярлар буйлап җәяү генә киттеләр.

Кичке киңлекләр — мәхәббәтнең үзе шикелле чиксез һәм серле иде.

Егет һәм кыз, җитәкләшеп, шул чиксезлек буйлап атлыйлар.

— Мин синсез яши алмыйм!

— Ә мин — синсез!

Егет һәм кыз, икәү.

Нәрсә хакында сөйләшәләр икән?

Мәңгелек темагадыр — бүтәнчә ничек булсын?!

Яфрак белән җил сөйләшәме, әллә егет белән кызмы? Әллә яр белән сумы? Кичләр һәм төннәр буе. Яфрак белән җил, яр белән дулкын кавышкан кебек, шәфкатьле тыныч төндә, дөньяның иң ягымлы, йомшак мизгелендә — иреннәр кавышты... Шул чакта кинәт бу чиксез чал дөньяда өр-яңа йолдызлар кабынып киткәндәй тоелды. Юк, юк, тоелды гына түгел, чынлап кабынды өр-яңа утлар, өр-яңа сөенечләр балкып китте! Гидростанция дип исемләнгән өр-яна корылмалар өстендә гөлт итеп кабынган утлар — лампалармы, әллә күктәге җем-җем йолдызлармы алар? Кайдан алар — киләчәктәнме, әллә әкиятләр иленнәнме? Өйдән өйләргә кереп, бөтен каланы әйләнгән, ә аннары авылларга һәм бүтән калаларга китеп, бәхетләр матурлыгына тоташкан сөенечле яктылык иреннәр кавышуыннан башланамы? Шуннандыр — бүтәнчә ничек булсын?!

Ул яктылык, икенче төрле әйткәндә, мәхәббәт дип атала.

*Беренче китап бетте.*

Чаллы — Казан.

1969—1971

## Фәнис Яруллин

### Ат сайладым...

Бирәү кашка ат бирде,
Үзең җаен тап, диде.
Чыбыркы ал да кулыңа
Иярлә дә чап, диде.
Тоягы җирләргә тисә,
Тетерәр җирләр, диде.
Чапкан чагында ялларын
Таратыр җилләр, диде.
Менеп атлансаң өстенә,
Кош кебек очар, диде.
Тик шуны бел, егылдыңмы —
Ташлар да качар, диде.

Бирәү миңа ат бирде,
Үзең җаен тап, диде,
Йөккә җиксәң, бер ягыннан
Син үзең дә тарт, диде.
Яллары җилдә уйнамый —
Ялларын кискән, диде.
Тоягы йомшак ярата,
Җир сөреп үскән, диде.
Турылыклы туры ат бу,
Чыбыркы көтмәс, диде.
Егылганда ялгызыңны
Һич ташлап китмәс, диде.
...Туры атны алмадым мин,
Атландым кашкасына.
Бер бәреп китәр, ахры, ул
Читләрнең капкасына.

### Көткәндә

Бүген аның туган көнә,
Күкләр зәңгәр, офыклар ал.
Ә табында тезелешеп
Саф-саф булып тора бокал.
Шешәдәге шәрапларга
Нурлар кунып уйнап китә.
Урындыклар зарыгышып
Кунак көтә, кунак көтә...
Машиналар үткән чакта
Чынаяклар чыңлап кала.
Ә уртада зур графин
Һәр тавышка колак сала.
Минут үтә, сәгать үтә,
Күкне болыт каплый башлый.
Кунак көтеп бәлеш көя,
Кунак көтеп ашлар ташый.
Урамнардан күз алмыйча
Тәрәзәдән гөлләр карый.
Ишектәге салкын тотка
Җылы куллар көтеп ярый.
Буп-буш өйдә ялгыз хуҗа,
Бер минуты — бер ел аңа!
Күзләр бокаллардай тулы,
Мөлдерәшеп яшьләр тама.

## Харрас Әюпов

### Атлар

Бөек Ватан сугышыннан кайтмый
калган авылдашларым истәлегенә.

Томырылып һаман атлар чаба,
Чаба атлар болын буйлатып,
Килгән шәпкә күкрәгемә баса,
Басып уза, җанны елатып.

...Дагаларда алсу нурлар уйный,
Бәкәлләргә коела таң чыгы,
Минем бу җан кайсыгызны эзли,
Кайтмый калган илгә кайсыгыз?

Ялгыз колын кемне эзләп чаба,
Кемгә кешни еллар аркылы? —
Кыңгыраулар, әй, бу кыңгыраулар,
Таңга кадәр йөри чакырып.

Болыннарны иңләп атлар чаба,
Ялкайларын җилләр җилгәрли,
Алсу таңда илгә җилләр кайта,
Эх, гомерләр җилгә иярми шул,
Кеше гомере җилгә иярми...

Минем бу җан кайсыгызны эзли,
Кайтмый калган илгә кайсыгыз? —
Башны иеп, каршыгызга киләм,
Бер минутка бары кайтыгыз!

...Тупырдашып атлар чабып уза,
Җанга суга гүя чаң чыңы,
Дагаларда алсу нурлар уйный,
Керфекләргә куна таң чыгы...

### Таныш шәүлә

Хыялымда таныш шәүлә йөри,
Бер тукая, тагын бөгелә,
Ак яулыгы арыш диңгезендә
Йөзгән җилкән булып күренә.

Хәтер офыгында аҗаган кук
Чагылып китә җитез урагы,
Туры килгәч, шул кечкенә урак
Ниләр генә җирдә урмады!

Арышын да, бодаен да урды,
Иелеп-бөгелеп урды тарысын.
Илдән ирләр китте,
Шул ук урак
Көлтә-көлтә урды кайгысын...

Көлтә-көлтә урды — зарланмады,
Уйламады үзе турында,
Ашыкты ул кайгы бөртеге дә
Калмасын, дип, килер буынга.

Еллар аша таныш шәүлә килә,
Бер турая, тагын бөгелә,
Аркасыннан чәченә кушып үргән
Тәңкә чыңы җиргә түгелә.

Тезелешеп чүмәләләр кала,
Кала шунда яну-ярсуы,
Һәм үзенә тере һәйкәл булып,
Торып баса арыш басуы.

●

Бу туфракка күпме җылы сеңгән,
Елгаларда күпме җыр аккан,
Никадәрле гөлләр сулып кипкән,
Җир өстенә күпме ел яткан!

Бер тамчы да үзгәрмәгән хәят,
Эй, җиһанның изге баласы!
Сиңа кадәр күпме шулай булган
Һәм күпмегә шулай барасы...

Ләкин җирдән эзсез китәбез, дип,
Дулама, җан, әрнеп елама,
Елгаларда әле чит җыр түгел,
Ят җыр түгел, безнең җыр ага.

Мең елдан соң, бәлки, тагын берәү
Без тукталган шушы урында
Башкаларга сөйләр бу туфракка
Бездән сеңгән җылы турында...

## Җил

Авылыма сары көз сузыла,
Тәрәзәгә сугып уза җил,
Каеннарның чәчен сибеп ташлый,
Хәтеремә кереп туза җил.

Бар көченә дулый-дулый да ул,
Киереп ача хәтер капкасын,
Әйдә, йөрәк, чыгыйк әле шуннан,
Юлыбызны җырлар капласын.

Чыксын тагын безнең белән бергә
Шул кыюсыз авыл малае,
Йөгереп чыккан шәпкә сагышларның
Бәреп ярсын әле маңгаен!..

Ә агачлар менә бүгенгедәй
Сары таңкә сипсен юлына,
Һәм әнкәсе лампа яктысында
Чүпрәк сумка тексен улына.

Кабатласын тагын бөтен класс:
— Я... яфраклар, к...көз, а...авыл...
Эх, йөгер син, хыял, малай чакка,
Тынмас шунсыз җанда бу давыл!

...Авылыма сары көз сузыла,
Капкаларны каерып уза җил,
Юлларыма алтын таңкә сибә,
Хәтеремә кереп туза җил...

## Туй килә

Бер җыр йөри авыл урамында,
Югары очтан гөрләп туй килә,
Күкрәк киереп, моңын түгә баян,
Чыңлап тора урам, ду килә.

Кияү егет кәләшенә карый,
Саклык белән алган биленнән.
Якты йөзе айдай балкып килә —
Уңар, ахры, авыл киленнән.

Бер моң йөри авыл урамында,
Капка саен килә тукталып,
Кинәт кенә тәтен булсынмыни —
Янсынмыни йөрәк ут кабып!

Ярты авыл кыз төшерә бүген,
Ярты авыл — кияү бу туйда,
Ярты авыл үз кәләшен кочып,
Җырга күмелеп килә бу туйда...

Хыял, хыял!
Туй килгәндә генә
Очынмасаң сиңа ни булган?!
Капка саен картлар басып тора,
Күзләренә әллә яшь тулган?

...Сузылып-сузылып моңын түгә баян,
Чыңлап тора урам, ду килә,
Илдән китеп башын салганнарның
Хыялында калган туй килә...

## Туган якта

*Авылдаш егетләргә*

Монда гөлләр — бары безнең өчен,
Безгә бары — җилләр иссәләр,
Безнең көйне сузып шаулый урман,
Безнең өчен ага чишмәләр.

Кошлар әле безнең хакта сайрый,
Сукмакларда ята эзебез,
Әйтерсең лә барыбыз бергә монда,
Таралмаган, читтә түгел без.

Таралмаган энә йолдызлар да,
Безнең өчен калка ай һаман,
Йокыбызны алган сылуларның
Тәрәзәсен чиртер җай калган...

Ә сылулар...
Бары алар гына...
Аерылган бездән юллары,
Тәрәздә тик — чиккән пәрдәләре,
Күңелләрдә — чиккән җырлары...

Юк, сайрамый кошлар безнең өчен,
Сукмакларда беткән эзебез,
Учакларның көлен җил тараткан,
Таралганбыз икән инде без.

Башкаларның юлын яктыртырга
Кичләр җиткәч, монда ай чыга,
Бүтән кызлар бүтән йөрәкләргә
Истәлеккә яңа җыр чигә...

●

Бер үк җырның ике яртысы без,
Бер тургайның ике канаты,
Пар аккошлар шуны әйтеп узды,
Шул хәбәрне җилләр таратты.

Иреннәрдә янган ул сөюне
Йөрәкләргә салдык икебез,
Шул хис белән ялкыннарда яндык,
Яңгырларда калдык икебез.

Сүрелү белмәс кайнар йөрәкләләр
Һәм җирдәге сөю хакына
Ай нурыннан һәйкәл куяр идем
Без очрашкан юллар чатына...

## Роберт Батулла

# КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК

хикәя



Кыш бик матур башланган иде. Салмак кына кар ява иде. Көн якты, көнелләр аяз иде.

Ләкин кичә кич кемдер көнгә күз тидерде.

Буран котыра... Урамнарда кот юк...

«Тышта никадәр салкын булса, өйдә шул кадәр рәхәтрәк!» дип уйлады Гөлфия һәм тизрәк атлый башлады.

Кесәсендә ачкычы булса да, ул һәрвакыт кнопкага баса. Ишекне балалар яки ире ачса, аңа көнеллерәк була. Балалар өйдә юк — каникул... Авылда әбиләрендә кунакта. Ишекне Бәхтияр үзе ачачак!

Эчтә электр кыңгыравы шалтыраганга җавап итеп:

— Хту там, абыстай эспит! — дигән тавыш ишетелде.

— Шаярма әле, Бәхтияр, суык бит! — дип кычкырды Гөлфия.

— Хту там, мама дома нету...

— Ач инде, Бәхти! Миһербанлы кеше этен дә алай озак тотмас!

Ишек ачылды.

— Тизрәк кер! Салкын ияртәсең! — диде Бәхтияр.

Гөлфия пальтосын салып, аякларына йомшак башмаклар элдерде дә кухняга йөгерде.

— Кабаланма! — диде Бәхтияр.— Син кушканнарның барын да эшләп куйдым инде. Ит салмак кына кайный, чәйне сөлгегә төреп, мендәр белән томаладым. Ипи юка гына телем-телем итеп киселгән... Үземә каерып кистем. Культурный булу бер хәл, ашыйсы килү икенче хәл! Юка телемнәрне чит илдән килгән кунакларга куярбыз. Янәсе, без дә нәзакәтле була беләбез...

— Тел бистәсе!..

— Һу-һу, тел бистәсенең эше күп! Ә син аңа аш пешерергә кушасың!.. Иртәгә концерт!

— Бүлмәгә кер дә ятла! Аш пешкәч, чакырырмын...

Бәхтияр мыдыр-мыдыр килеп шигырь ятлый. Гөлфия, токмач кайнап чыкканны көтеп, кухняда утыра. Тышта буран котырганнан-котыра бара. Өйдә ниндидер басынкы бер тынлык хөкем сөрә. Буран улавы бу тынлыкны тагын да көчәйтә төшә. Әллә ничек ямансу булып китте Гөлфиягә. Ул, кулларын тезләренә куйган килеш, әллә кая бушлыкка карап да монаеп калган.

«Ай аллам, кемнәр генә бу буранда юлга чыкты икән?.. Кемнәр генә адашып йөри микән?.. Юлда калганнарны ярдәменнән ташлама, ди торган иде мондый чакларда әбекәй»,— дип уйлый Гөлфия.

Токмачы ташып, шулпасы кайнар плитәдә чыжылдый башлагач, сискәнеп китте ул.

Бераздан инде алар токмач ашап утыралар иде. Гөлфия күзләрен Бәхтиярдән алмый. Бәхтияр үзе ашый, үзе күңеленнән генә шигырь кабатлый. Аның эчтән тәкрарлаганын Гөлфия белә, шуңа күрә юк-бар сораулар белән Бәхтиярне аптыратмый.

— Чәйгә күчеп карыйк! — диде Бәхтияр, ашап туйгач.— М-м, хуш исләр аңкый чәйнектән!

— Һи, кәмит! Шушы да булдымы хуш исле чәй!.. Син кайнаткан чәй тәмле буламы соң! — диде Гөлфия, ачулангандай итеп.

Ул бәләкәй чәйнекне алып кухняга китте.

— Мин сиңа ничә тапкыр әйттем инде,— диде Бәхтияр,— шундый мөһим эшне миңа тапшырма, дидем!

Кыңгырау шалтырады.

— Зөләйхадыр!.. Кешене салкында озак көттермә, бар ач! — дип кычкырды Гөлфия.

Бәхтияр ишек ачарга йөгерде.

— Гөлфия, синең янга! — дип кычкырды Бәхтияр.

Ул үз бүлмәсенә кереп китте. Гөлфия кунакны каршы алырга чыкты. Ләкин ишек янында туныннан кар кагып маташучы хатынны танымады.

— Исәнме, Гуленка! — дип, таныш булмаган хатын кочакларын җәйде. Гөлфия юеш тунга борыны белән төртелгәнен сизми дә калды. Юеш мехтан кыйммәтле хушбуй һәм шәраб исе бөркелә иде. Бу исләрдән Гөлфиянең тыны капланды.

— Гаҗәп чибәрләнгәнсең син, Гуля!

Хатын, Гөлфияне ычкындырып, чишенә башлады. Әйтерсең лә ул биредә үз кеше!

— Үтегез! — диде Гөлфия.

Кунак бүлмәсенә уздылар. Җентекләп карый торгач, Гөлфиягә бу хатын таныш кебек тоела башлады. Ләкин үтерсәң дә ул аның исемен дә, ни дәрәҗәдә таныш икәнен дә хәтерләми.

Утырдылар. Сүзсез калдылар. Күрше бүлмәдән Бәхтиярнең шигырь ятлаганы ишетелә. Хатын бүлмәне карап-тикшереп чыкты да:

— Гуля, син мине оныткансың, ахрысы... Без синең белән бер бүлмәдә яшәгән идек... Хәтерлисеңме, ашханә янындагы йортта... Кырык икенче бүлмәдә... Төзелеш башланган көннәр генә иде әле...

— Зөлфия?! Зөлфия шул! — диде Гөлфия, шатланып.

— Боже, әле генә таныды! Неужели мин шулай нык үзгәргәнмен!

— Юк, юк, хәзер гел үзең инде! Хәтер диген, йөзең онытылган... Бәхтияр, Бәхтияр, карале, кем килгән безгә кунакка!

Хатын гаҗәпләнеп кычкырып җибәрде.

— Сез өйләнештегезмени?.. Бәхтюшка-батюшка синең иреңме?

Бүлмәдән Бәхтияр чыкты.

— Бу — Зөлфия, хәтерлисеңме, син әле болай дип җырлый идең: «Аһ, Гөлфия, ваһ, Зөлфия, миңа булмас микәнни соң бу кызларның берсе дә!»

— Ә мин сине «Бәхтюшка-батюшка» дип үрти идем!

Бәхтияр елмаеп кунак хатын янына килде.

— Исәнме, Бәхтюш! — диде хатын.

Күрештеләр.

— Гөлфия! — диде Бәхтияр, шатланып.— Тиз генә өстәл әзерлә! Бу күрешүне юарга кирәк!

Артык нәрсәләрне алып, хуҗалар өстәл әзерләде. Бәхтияр чәркәләргә шәраб салып чыкты.

— Гөлфия белән Зөлфия исәнлегенә! — дип, Бәхтияр берне каплап та куйды. Гөлфия дә иреннәрен чәркәгә тидереп алган булды да кире куйды. Зөлфия генә чәркәгә кагылып та карамады.

— Син һаман шәраб эчәргә өйрәнмәдеңмени әле? — диде Гөлфия.
Зөлфия елмайгандай итте, ләкин аның чыраенда шатлык күренмәде. Ул сәеррәк итеп әйтеп салды:
— Мин сухой вино эчмим... Миңа катырак, зәһәррәк булсын иде...
Гөлфия белән Бәхтиярнең күзләре очраштылар. Гөлфия тиз генә торып баскан иде, Бәхтияр аны күз карашы белән урынына утыртты да:
— Мин хәзер... Сез сөйләшә торыгыз...— дип киенми-нитми генә чыгып китте.
— Алла хакы өчен кичер, Зөлфия, безнең өйдә аракы сирәк була... Бәхти аракы эчми... Мин инде...
Кунак хатын сумкасыннан бер кап сигарет чыгарды.
— Гафу ит, мин кабызыйм әле...
Гөлфия көл савыты китереп куйды. Хатын тирән итеп суырды да төтеннең бер тамчысын да читкә җибәрмичә, тирән итеп эчкә алды. Төтенне эчкә алганда гыжылдау тавышы ишетелгән сыман булып китте. «Өзлексез аракы эчеп, тәмәке тартучы хатыннарның күбесендә шундый сызгыру була...»
— Гаҗәпләнмә, Гуля... Тартам инде...
Заман шул: хатыннарның тәмәке тарту, аракы эчүләре гадәти хәл булып бара. Ләкин кем ничек тарта бит! Берәүләр башка хатыннар тартканны күреп модадан калмаска тырыша, икенчеләре тәмәке тартуны культурага саный. Өченчеләре чын-чынлап, ирләрчә, тәмен белеп тарталар. «Зөлфия чынлап тартадыр!» — дип уйлады Гөлфия.
— Я, сөйлә әле, ничек яшәп ятасыз?.. Ярыйсы урнашкансыз... Теге чакта ничек яши идек? Ә? Мичкәгә тутырган балык кебек идек бит!.. Пианино?! Кем уйный?
— Мин дә... балалар да — маташтырабыз шунда!
— Бер бармак беләнме?
— Юк, балалар музыка мәктәбендә укыйлар...
— Эшлисеңме?
— Шул мәктәптә укытам... Дүрт ел кирпеч салдым, йортлар җиткердем... Диплом яклар вакыт җиткәч, тәзүчелекне ташларга туры килде.
— Ирең лектормы бәрәр?.. Бик каты кычкыра?
— Юк, ул һаман шунда!
— Шофер?
— Шулай дисәң дә ярый, бер ел инде «Батыр»да инженер-механик...
— Кайда?.. Ах, боже мой, мин онытканмын да...
— Иртәгә концерты... Культура сараенда шигырь укучылар конкурсының йомгаклау концерты була...
— Кара син аны! Артист тамыни?
— Син үзең ничек соң?.. Киттең дә олактың, дигәндәй, хәбәр дә бирмәдең!
Хатын тәмәкесен сүндерде. Ул көл буялган бармакларына карап торды да кинәт шат-көр тавыш белән әйтте:
— Яхшы яшим! Теге чакта китеп дөрес эшләдем мин... Сез шүрләп калдыгыз! Дөнья күрер идегез!
— Без монда да күрдек инде, Зөлфия...
Гөлфия Зөлфиянең уң күз кабагы тартышканын сизеп алды. Зөлфия аны күрсәтмәскә тырышып, чәнчә бармагы белән күзен сөрткән була. Бу хәрәкәтләрне ул бик нәфис, аристократларча нәзакәтле итеп эшләргә тырыша, янәсе, керфегенә тузан кунган!
Бәхтияр кайтты. Кайтты да бер шешә «Столичный»ны өстәлгә куйды.
— Хәзер, хәзер, туташлар...— дия-дия, хуҗа зуррак стаканнарга аракы салып чыкты.
Кунак хатын иң беренче булып стаканны бушатты... Берни капмады. Тагын стаканын Бәхтияргә сузды.
— Бахтюш, сал әле...

Бәхтияр салды. Кунак хатын тагын чөнкәйтте.

— Сез мине гафу итегез инде... Магаданда эшләгәндә гел спирт кенә эчә идек... Аракы сагынылган...

— Тарсынма, тарсынма! — диде Гөлфия.

Зөлфия тагын тәмәке кабызды. Тагын тирән итеп суырды да эчкә алды. Нindидер канәгатьсезлек билгесе чыкты аның чыраена.

— Курортка барышым... Кырымга... Самолет Казанга төшәргә тиеш иде, Казан кабул итмәде... Менә сезнең Чаллыга килеп утырырга туры килде... Без килеп кунаклаган гына идек, буран башланды... Очышны кичектерделәр... Шунда мин сине эзләп табарга булдым... Көчкә таптым... Кешеләрегез гаять тупаслар. Сезнең урамны беркем күрсәтми...

— Шулайдыр, бу бит яңа урам... Мәрҗани урамын белүче юктыр да әле...— диде Гөлфия.

— Килеп яхшы иткәнсең, аэропортта кеше шыгрымдыр... Сөйләшеп утырырбыз...— диде Бәхтияр.

— Ашап эч, Зөлфия, ашап эч! — дип кыстый Гөлфия.

Кунак бераз дәшми утырды да көлемсерәп кенә:

— Онытып та бетергәнмен ул исемне...— диде.— «Зөлфия» минем исем кебек түгел... «Зинаида», «Зина»га күнегеп беттем инде...

«Гаҗәп,— дип уйлады Гөлфия,— ни өчен исемен үзгәртте икән? «Зина» татарча бик начар мәгънәле сүз бит...»

Зөлфия аклангандай әйтеп куйды:

— Барыбер түгелмени?.. Зина ни дә, Зөлфия ни... Кеше булырга кирәк!

Ул чәнчә бармагы белән күзен сөртеп алды. Ләкин аның кул хәрәкәтләре төгәл түгел иде инде, ул керфек сөртәм дип, керфегенә буяган сөрмәсен бозып куйды.

— Шулай...— диде ул, бераз утыргач.— Кем уйлаган... Бәхтияр инженер-артист булыр дип... Ха-ха...

— Кирза итек киеп йөрүче авыл малае — өченче класслы шофер... эрудированный инженер, да еще громогласный Маяковский! Ха-ха!

— Син ялдамыни? — диде Гөлфия, сүзне икенчегә борырга тырышып.

— Шул чама... Мин күптән ялда инде... Кияүгә чыкканнан бирле ялда... Володяны ялга җибәрмәделәр... Чик буенда тыныч түгел диган булып...

Сөйләшү арасына буран тавышы килеп керде.

— Котыра гына! — диде кунак.— Кайчан китәрмен икән... Эч поша сездә... күңелсез... Бәхтюш, әйт әле, теге чакта син китәргә әзерләнеп беткән идең бит, нигә калдың?.. Курыктың?.. Курыктың? Әйе?

— Син үзеңне романтика белән аклама инде, Зөлфия! Сиңа кыенлык романтикасы кирәк булмаган... Әгәр дә син чын романтика эзләгән булсаң, Чаллыда калыр идең. Син бит кая барасыңны белми киттең...

Зина шаркылдап көлә башлады. Аның көлүе кызыктан түгел иде, ясалма һәм көчәнеп көлү иде.

— Да-а, үзгәрткәннәр сине... Әллә тагы партиягә дә кердеңме?

— Кердем! — диде Бәхтияр.

Ул моны шундый тәвәккәл итеп әйтте, кунак кинәт хахылдавыннан туктап, житдиләнеп калды.

— Тагын сал әле! — диде кунак.— Мин бөтен СССРны йөреп чыктым... Кайларда гына йөргмәде мине язмыш! Тольятти, Кемерево, Магадан! Күрде инде Зина апагызның башлары... Хет роман яз... Син, Бәхти, романнар язмыйсыңмы? Мин сиңа материал бирә алам... Аннан соң хәрби очучыга тормышка чыктым... Гөлфия, җаным, уйна әле... теге без яратканны... «Тимер чана карлар яра...»ны. Син рояльдә уйна, мин җырлыйм...— дип, Гөлфияне ирексезләп пианино янына алып килде.

Зөлфия урындык аркасына тотынып җырлый башлады.

Тимер чана карлар яра,
Бу йөрәгем ник яна шул...
Бу йөрәгем ник яна...

Ул кинәт шып туктады. Гөлфияне иңнәреннән чытырдатып тотты.

— Утыр! — диде Бәхтияр.

Бәхтиярнең куәтле тавышын ишеткән кунак кинәт йомшап, тахтага утырды. Утырмады — ауды! Аның уң күз кабагы бик каты тартыша башлады. Бармак белән дә туктата алмаслык итеп дерелди, калтырый. Зина ике кулы белән битен каплап, үкереп еларга тотынды.

Гөлфия түзмәде, күңеле тулып, кухняга чыгып китте.

— Син нәрсә тагы? — диде Бәхтияр.— Син дә балавыз сыгарга чамалап торасыңмы?

— Кызганыч бит... Чибәр иде... шаян иде... «Такташның Алсуы» дип йөртә торган идек...

— Димәк, Алсу булмаган инде! Алсу булса, матурлыгын да, шаянлыгын да, исемен дә җуймас иде!

...Кунакны озатырга Бәхтияр дә, Гөлфия дә төште. Өчесенә дә кыен, никадәр генә сөйләшергә тырышып карасалар да, әңгәмә башланып җитмичә өзелә иде. Саубуллашу алдыннан Зөлфия Гөлфияне читкә алып китеп, болай диде:

— Гөлфиякәй, мин кичә әллә ниләр сөйләнмәдемме?

— Юк! — диде Гөлфия.— Алай зыянлы булмады. Нигә алай сорыйсың?

— Болай гына... Син, Гөлфия, гафу ит инде, ярыймы?.. Бернинди ирем дә юк минем, Кырымга да барышым түгел...

— Кая барасың? — диде Гөлфия хафаланып.

— Белмим... Син Бәхтияргә әйтмә! Кая да булса барып төртелермен әле...

— Нишләп аны өйдә чагында ук әйтмәдең! — диде Гөлфия ачынып.— Мин юлыңа күмәч, пәрәмәчләр тыккан булыр идем...

— Юк, юк, кирәкми...

Тик кенә торганда Гөлфиянең күңеле тулды.

— Ничек инде, Зөлфия, болай кая барасың?..— Ул кесәсеннән бөгәрләнгән берлек акчалар чыгарып Зөлфия кесәсенә салды.— Ал, ал, Зөлфия... Эшкә урнашканчы булса да ярап торыр...

— Кирәкми, кирәкми! — диде Зөлфия, ләкин акчаларны кире Гөлфиягә бирмәде.

— Хуш, Гөлфия, бәхетле калыгыз! — диде дә ул самолетка таба китеп барды.

Бәхтияр бераз читтәрәк, Гөлфия тимер рәшәткә янында баскан килеш, Зөлфия самолетка кереп югалганчы карап тордылар. Зөлфия артына әйләнеп карамады. Озын баскыч буйлап менгән чакта әйләнеп, кул болгамакчы булган иде, ахрысы, арттан килүче пассажирлар, тоткарламагыз дигәндәй, аны этә-төртә самолетка алып кереп киттеләр.

Самолет кузгалганчы Гөлфия белән Бәхтияр басып тордылар.

Бәхтияр Гөлфия янына килеп:

— Әйдә, карчык, кайтыйк! — диде.

Гөлфия ирен култыклап алды.

Ул үзенен гаять бәхетле икәнен сизде.

«Гаҗәп! — дип уйлады Гөлфия.— Мин моңарчы бу турыда башыма китергәнем булмады. Кешенең бәхетсез язмышын күргәч кенә үзеңнең аңа караганда бәхетлерәк икәнеңне тоясыңмы икәнни? Бу бит бер карагында гаделсезлек, миһербансызлык! Кеше фаҗигасен күреп, үзеңнең көр, матур тормышыңа карап сөенү — гаделлек була ала микән?»

Шул ук мизгелдә аның күңеленә икенче уй да килеп китте. «Бәхетле булу өчен, күрәсең, ил биргән хокуклар гына җитми. Алардан файдалана да белергә кирәктер шул...»

▪▪▪▪▪▪▪▪▪▪▪▪



## Рашат Низамиев

•

*Мин язның беренче көнендә туганмын. Бу минем беренче шигырьләрем — беренче язым... Тормышны яратам. Дөньяны шигырьләр аша күрәсем, аңлыйсым килә.*

*Туган җирем — Саба районы, Олы Мишә авылы.*

*Миңа 21 яшь. Казан дәүләт университетында укыйм.*

### Һаман калды

Исемеңне язган идем
Комлы ярга,—
Инде күптән юылгандыр
Дулкыннарда.

Исемеңне язган идем
Ап-ак карга,—
Инде күптән күмелгәндер
Бураннарда.

Исемеңне уйган идем
Кыя ташка,—
Укый алмас аны кем дә
Миннән башка.

Юлларымда
Нинә тапкыр давыл купты!
Дулкын миңа сукса сукты,
Буран мине екса екты,—
Тик йөрәктә синең исемең һаман калды.
Юылмады,
Күмелмәде,
Җуелмады.

### Чит җирдә

Яңгыр суы туфрак юа,
Чыклы үлән тамчы коя.
Чит туфрак бу, чит үләннәр —
Кире кайтмый шул үлгәннәр...

Окоптагы табан эзе —
Әйтелмәгән соңгы сүзе.

Йөрәктәге кайнар уттан
Ядрә эреп юкка чыккан.

Көтә микән хат кыз бала?
Ә кабердә йолдыз яна.
Язлар аңа туган җирдән
Кызыл гөлләр алып килгән.

## Сабый чакның бер иртәсе

Сабый чакның кышкы иртәсе,
Күңелдән юк шуның китәсе,—
Йоклап яткан җирдән тәнемә
Юрган аша җылы бәрелә.

Юрганымны ачам уянып:
Өйнең эче балкый нурланып.
Мондый чакта буламы йоклап,
Бер тәмле ис тора кытыклап,—

Әнкәй мичтән ипи алган ич,
Ак җәймәгә тезеп салган ич!
Яңа пешкән икмәк исеннән
Гөлләремә кадәр исергән.

## Салават Рәхмәтуллин



*Туган елым — 1942.*

*Туган җирем — Башкортстан, Авыргазы районы, Солтанморат авылы.*

*Урта мәктәп, Стәрлетамактагы 6 нчы төзелеш-монтаж участогында балта остасы, педагогия институты; Төрембәт урта мәктәбендә директор ярдәмчесе; армия, Петровский балалар йортында директор ярдәмчесе, туган авылда рус теле һәм әдәбияты укытучысы...*

*Төрле җирләр, төрле кешеләр күрдем. Тормышның ачысын-төчесен шактый татыдым.*

*Битараф булып кына яши алмыйм. Иртәгәсе көнне бүгенгедән дә матуррак итәргә теләүчеләрнең образы мине уйландыра...*

*Иң беренче тапкыр, 1963 елда, шигырем «Агидел» журналында басылды. Шуннан бирле «Кызыл таң», «Ленинчы» газеталарында, «Яшь көчләр» альманахында катнашып киләм.*

●

Бер мизгелгә дөнья тынып калган:
Изрәп йоклый җирдә халыклар,
Томаннарга төренеп таулар йоклый,
Изрәп йоклый суда балыклар.

Зәңгәр пәрдә корып, галәм йоклый,
Ай да йоклый болыт-юрганда...
Дөнья шулай шау-шуыннан арынып,
Бер мизгелгә тынып торганда,

Төннәр буе җирдә яшьлек йөри,
Төннәр буе йөри — туктамый;
Төннәр буе постта солдат тора,
Төннәр буе шагыйрь йокламый,—
Чөнки җирдә дошман йокламый.

●

Йолдызларга сине тиңләдем дә
Ник күтәрдем икән күкләргә.
Син биексең хәзер,
Син янасың
Нурларыңны сибеп күпләргә.

Син биексен, син йолдызсың хәзер,
Елмаясың галәм эченнән...
Яна-яна югалырсың сыман
Ычкындырсам тарту көчемнән.

●

Кайгылар баш идертә ул,
Башыңны имә, егет.
Кайгыларның карасыннан
Караеп көймә, егет.

Кизәнсәң таулар егардай
Кулыңда көч бар чакта,
Йөрәгеңдә — дусыңа җыр,
Дошманга үч бар чакта,
Башкаеңны имә, егет,
Кыядай биек күтәр.
Кыяга болыт уралган,
Җил иссә, болыт үтәр.

Җил иссә, һава сафланыр,
Күмелер дөнья нурга...
Моңайган кәккүк моңайсын,
Ник безгә моңаерга.

Башлар имик, янмыйк-көймик,
Корыч дип уйласыннар.
Әйдә, тирәкләрдә үксеп
Кәккүкләр еласыннар,

## Сүзем бар...

Бер сүзем бар,
Ул сүз бер кемгә дә
Ишеттерә торган сүз түгел.
Һәм ул сүзем минем йөрәкләрне
Өшеттерә торган сүз түгел.
Йөрәк түрләремдә сакласам да,
Ул әйтелми торган сүз түгел.

Мин әйтермен аны, тик ашыкма,
Сабыр итче бераз, түз, күңел!

Бер сүзем бар,
Гади бер сүзем бар...
Ул саклана йөрәк түрендә...
Мин әйтермен аны,
Йолдыз булып
Яңа алсаң күңелем түрендә!

## Сагышлы җыр

Бөтен дөнья түп-түгәрәк,
Күңелләр генә китек.
Ике күңел — ике китек —
Нихәлләр генә итик...

Еллар аша йөгерәм-йөгерәм...
Һич сиңа булмый җитеп.
Кайталсаң, кайт яшьлегеңә
Гомер йомгагың сүтеп,
Язмышлар аша үтеп —
Яшьлегем тора көтеп.

Бөтен дөнья түп-түгәрәк,
Күңелләр генә китек...
Шул китек күңелләр белән
Кемнәрне хәсрәткә салыйк,
Кемне бәхетсез итик...

Бөтен дөнья түп-түгәрәк...
Күңелләр генә китек.
Ике күңел — ике китек —
Эх!
Булмый түгәрәк итеп,
Кемнәрне гаеп итик...

## Чатлар

Күңел иләс-миләс чаклар,
Йөрәк ашкынган чаклар.
Хушыгыз, гамьсез вакытлар,
Алдымда — чатлар, чатлар...
Уңармынмы, туңармынмы? —
Чатларда — төрле яклар...
Язган язулары кайда,
Кайда акыллы картлар?..
Абынсам, кемнәр кул сузар,
Ялгышсам, кемнәр яклар...
Дусларым аз түгел микән,
Күп түгел микән ятлар...
Язмыш кулда да... тезгенен
Тота белмәгән чаклар...
Алдымда — чатлар!
Аяклар
Кайсы якларга атлар...

## Таулардагы яңгыр

Этюд

Көтмәгәндә, ябырылып,
Тауга болыт килде.
Кыяларны сискәндереп,
Күкне яшен телде!

Юаш җил исте тау буйлап,
Гөлләр башын иде.
Тәүге тамчы, ташка төшеп,
Чәлпәрәмә килде.

Күк күкрәде...
Кыяларда
Ут ялтырып торды;

Яңгырда, көлмәкчән кыздай,
Тау калтырап торды.

Утлы ирене белән болыт
Тауның битен үпте.
Җилләр белән үтте болыт,
Еракларга китте.

Кояш чыкты...
Тау битеннән
Ал нурлар бөркелде.
Соңгы тамчы, ташка төшеп,
Көлде... көлде... көлде.



## Әнәс Ибәтуллин

*1952 елда Татарстанның Сарман районы Яхшыкаран авылында урманчы гаиләсендә туганмын. Сигезьеллыкны тәмамлаunion сон, Лубян урман техникумына укырга кердем һәм быел аны тәмамлыйм.*

*Район газетасы битләрендә шигырьләрем чыккалый.*

### Саумы, апрель!

Саумы, апрель,
Саумы, бала чагым,
Тау битеннән киң суларга табан
Гөрләп-уйнап аккан шаян чагым!

Саумы, апрель,
Саумы, бөдрә талым,
Бөреләргә җирне күмгән ягым,
Яз кызының зәңгәр күзләрендә
Синең матурлыкны күргән чагым!

Саумы, апрель!
Саумы, көткән язым,—
Оясына кошлар кайткан чагым.
Яшәү мәхәббәте киң сулардай
Йөрәкләрдә ташып аккан чагым!

## Ак каеннар

Ак каеннар ак була,
Акларында тап була,
Кашлар — болыт, күздә—яшь—
Үпкәләдең чак кына...

Болыты инде үткән,
Тамчылар күздән кипкән,
Каен табы күңелдә —
Янгыр юалыр микән?

## Яшәү турында

Яшәү көче яшел яздыр!
Үлгән яфраклар астыннан
Җиргә шыткан кар чәчәген
Кулга алып үбәр идем...

Яшәү хисе нинди гаҗәп!
Яшәвем бөрегә биреп,
Үзем, көзге яфрак кебек,
Үкенмичә сүнәр идем...

## Көзге этюд

Авыр сулап әкрен генә
Шаулады урман.
Куркып-каушап җил йөгерде
Яфраклы юлдан.

Ә монда усак малае
«Балавыз» сыга.
Урман шомлы булып калган,
Куркадыр шуңа.

Яшь ана кебек кызара
Оялчан миләш.
Яфрак бите уттай яна,—
Нәкъ унсигез яшь..

Күлмәкләрне алыштырды
Каен кызлары,
Хәйләкәр дә, бик шаян да
Икән үзләре:

Өр-яңамны күрмәсен дип
Ятлар, башкалар,
Карт наратлар артларына
Качып басканнар.

Рәмзи Максудов

# ШӘЙМОРЗА КЕШЕЛӘРЕ[1]

## Хөсәен Идрисов



И-йөгереп тә карыйсың син, Хөсәен дус. Артыңнан чаптар атлар белән дә куып житәрлек түгел!

Мәгъсүм дусты Хөсәен янына килеп житте дә никтер башыннан кепкасын салды. Кепкасын кулында озаклап әвәләде, йомарлап бетерде, шуннан соң мамык сырма өстеннән эсседә дә, суыкта да, аязда да, яңгырда да киеп йөри торган кожаныының кесәсенә салып куйды.

Беркавым сөйләшми генә бардылар. Аннары Мәгъсүм игеннәр турында сүз кузгатты. Янәсе, механизатор халкына жиңел булмас. Кыш суык килде, кар рәтләп яумады. Аннары Мәгъсүм, тора-торыштан, ата казың күкәй саламы дигәндәй, эшкә бик тә аккуратный чыгуын сөйләп китте. Башта кар тотарга щит-мазар ясап йөргән, имеш, инде килеп, агрегатларга симәнә бодае ташый икән. Бригадир аны ничәмә-ничә мәртәбә мактап телгә алган. Бүтәннәргә үрнәк итеп уйган. Куярсың да, абзыкаем. Мәгъсүм тал чыбыгы кисәргә үзе барды, читәнне үзе үрде, барысыннан күбрәк эшләде. «Чаптар ат белән дә куып житә алмастай дусты» Хөсәеннең кинәт идарәгә таба борылуын күргә, Мәгъсүм ашыга-кабалана, сәбәпсезгә-нигә каударлана ук башлады. Кожан кесәсеннән таушалып беткән, козыреклары яньчелгән фуражкасын тартып чыгарды, ике кулы белән фуражканың ике ягыннан тартып тотып, яньчелгән, ямьшәйгәнен яза, өзеп чыгарырдай итеп турайта башлады. Башта сөйләгәннәренә кушып-нитеп тормастан:

— Гәзит чыгарырга барасыңмыни? Парткомгамыни? — диде.

— Гәзит чыгарырга барам. Парткомга,— диде Идрисов.

— Хөсәен дус, син инде чамалап кылан. Ил-көн алдында адәм мәсхәрәсе итмә, яме.— Мәгъсүм башын түбән иде.— Идарә карары дөрес. Анысына һич кенә дә сүзем юк. Бригадир урынбасарлыгыннан алулары да дөрес. Анысына да сүзем юк. Гаеп үземдә, абзыкаем. Иллә дә мәгәр, шунысы да дөрес, әгәренки түзәлмәсәм, баскан жиремдә чәчрәп үлим, андый хәлнең бүтән буласы юк. Үтенеп сорыйм: гәзиткә чыгара күрмә.

[1] Башы 10 санда.

— Ярар, редколлегиядә киңәшербез,— диде Идрисов.— Гаеп итмә, сөйләшеп торырга вакытым юк.

Партком да инде аны коллегалары: Рәисә Сәмирханова белән Мәсгудә Арсланова көтә иде.

— Әллә соңга калдыммы? Гафу итә күрегез,— диде Хөсәен. Ләкин сәгатенә карагач, нәкъ вакытында килеп җиткәнен аңлады. Тик гафу үтенгәне өчен үкенмәде. Зыян юк, иптәшләре тәртипкә өйрәнә торсыннар.

— Юк, Хөсәен абый, соңга калмадыгыз. Без бүген үзебез иртә килдек. Гел безгә генә гафу үтенеп торырга димәгәндер бит?!

— Әгәр сез һәрвакыт шулай иртә килә торган булсагыз, мин сезнең алда көн саен гафу үтенергә риза,— дип, йомшак кына итеп шаяртып алды редактор.

Әкренләп эшкә тотындылар. Баш мәкаләне гадәт буенча колхозның партком секретаре язарга тиеш. Ә менә газетның төп мәкаләсен кем язар? Беренче бригада бригадиры Равил Мөхитов язса әйбәт булыр иде. Ул бригада бик тырышып эшләде, ашламаны кырга көздән үк чыгарып куйды. Күп итеп кар тотты. Язгы чәчүгә дә иң беренче алар әзер булды.

Бер уйласаң, баш мәкалә язу — баш агроном эше. Гадәттә, язгы чәчү алдыннан булган киңәшләрне ул бирә, язгы ярышның йомгакларын ул хәбәр итә. Кече агроном Шәүкәт Галиәкберовның язгы чәчүгә симәнә әзерләү турындагы мәкаләсе әйбәт булып куяр иде.

Ә бит Идрисовның япа-ялгызы гына газет чыгарган заманнары да бар иде. Үтә дә төссез, үтә дә күңелсез булып чыга иде газет. Шуңа күрә ул өч айга бер генә чыга торган иде шул. Ә хәзер ай башында да, ай уртасында да кешеләр яңа газет укырга гадәтләнеп киттеләр.

Бервакыт стена газетында трактор бригадалары хисапчысы Әнвәр Алиуллин «Кем күпме ягулык тота?» дигән мәкалә язып чыкты. Бригадаларда ягулыкны янга калдыру өчен көрәшмиләр икән — хисапчы әнә шуларны сөйләп биргән иде. Ник көрәшмиләр, ник ягулыкны әрәмшәрәм итәләр? Бактың исә бер тракторга күпме ягулык тотыла, бер машинага күпме май китә — болар шушы көнгә тикле исәпкә алынмый килгәнгән. Заправкачы машина башыннан белешмә-ведомость яза, чынында исә бар булган машиналарга, кемнең күпме тотканын исәпләп тормастан, уптым илайһем берьюлы язып куялар икән.

Шушы мәкаләдән соң колхоз идарәсе фактларны тикшерү өчен махсус комиссия төзеде. Ревизия йомгакларын идарәгә куеп тикшерделәр. Әнвәр Алиуллин мәкаләсе зур бер вакыйгага әйләнде. Хәзер инде тракторчылар белән шоферлар машинага ягулык салган чакта авызлары белән карга тотып тормыйлар. Алар керосин белән бензинны һәм машина маен кайчан һәм күпме алганнарын төп-төгәл беләләр. Заправкачының бишкөнлек исәп-хисап дәфтәренә кул куйганчы башта бик җентекләп үз язуларын карыйлар, анда күпме ягулык алганны граммына чаклы язып куелган шул инде.

Элек ягулыкны артык тоту, әрәм-шәрәм итү хакында өзлексез сөйләп торалар иде, хәзер күбрәк янга калдыру турында сүз кузгала. Карыйсың, я шофер, я тракторчы ягулыкның кадерен белеп, саклап тоткан өчен бүләк ала.

Газетның һәр санында диярлек Иршат Бәширов мәкалә язып чыга. Иршат — колхозның спорт активисты. Ул колхозда барган ярышларны да, район ярышларын да яза, тренерлык тәҗрибәсен уртаклаша.

Колхозчылар дүртенче бригада парторгы Камил Камалов язганнарны да яратып укыйлар. Авылдашларына сөйләр сүзе күп Камилнең. Урак өстендә ул комбайн йөртә, кышын колхоз котельныенда кочегар булып эшли. Аның көтү көткән, электрчы булып торган чаклары да булды. Мал-туар караучылар ярышын язамы, комсомол оешмасы яки үзенең бер иптәше хакында сөйлиме, аның язганы гел кызык булып

чыга, белә Камил эшне, ярата. Тагын шул ягы да бар: белгән белгәнен эшли, белмәгән бармагын тешли, диләр бит. Эш кешесен тыңлау үзе бер күңелле.

Кызлар редакторга бүгенге сан өчен дип җыелган хәбәрләрне берәмберәм күрсәтеп чыктылар. Гөлфирә Низаметдинова, Әнвәрша Азизов, Тимерша Хисаметдинов язуларын карадылар, кайсын кайда, нинди рәсемнәр белән урнаштырырга дип киңәштеләр. Урак өстендә аерым бригадаларда чыгып килә торган «Яшен», «Сугышчан бит»ләргә быел кемнәрне җаваплы итеп беркетү хакында да фикер алыштылар. Кыр станнарына Радия Алиева белән Зөлфирә Хәсәнованы, беренче бригадага Миңнурый Вәлитова белән Фәния Усманованы кую әйбәтрәк булыр дигән карарга килделәр. Житезлекләре дә бар, матур итеп укый да беләләр, аннан да битәр — кушкан эшне җиренә җиткереп, яратып эшлиләр.

Фикер алышу ахырына җитеп килә инде, кызлар Мәгъсүм турында никтер сүз кузгатмыйлар. Редактор Идрисов борчыла башлады. Бу ни дигән сүз? Әйтергә уңайсызланаларммы, әллә редакторга әйтмичә шыпырт кына яшереп калдырырга ниятлиләрме? Хөсәен, озын өстәл өстендә зур бер эскәтер хәтле булып сузылып яткан ак кәгазьгә, булачак стена газетына төбәлеп, күңеленнән әнә шул уйларны кичерә иде.

Мәсгудә ничектер уңайсызланып, тотлыгыбрак сүз башлады:

— Хөсәен абый, безнең тагын бер мәкалә бар бит әле.

— Кем турында? — дигән булды Идрисов, белмәмешкә салышып.

— Бригадир ярдәмчесеннән төшерелгән Мәгъсүм турында.

— Һм. Соң шуннан?

— Усал язылган...

— Язылса. Тәнкыйть мәкаләсеннән куркабызмыни?

— Куркуын курыкмыйбыз,— дип, Рәйсә дә сүзгә кушылды.— Болай да җәза бирелде бит инде. Әгәр без дә... егылганны дөмбәсли башласак... Бәлки, бу юлы бирми торырбыз, ә?

Идрисов мәгънәле итеп башын кашып торды, уйга калган булды, ә үзе күңеленнән кызлар белән килешкән иде инде.

— Анысы дөрес. Кешенең хәсрәтендә бию яхшы эш түгел,— диде Идрисов, бик йомшак кеше булып калмаска тырышып.— Ләкин бит безнең урыныбыз кала. Аны нәрсә белән тутырабыз соң?

Ул кадәресен кызлар уйлап җиткермәгәннәр икән, бер генә минутка аптырашта калдылар. Аларны бүлмәгә килеп кергән төзүчеләр бригадиры Хәмит Яфизов коткарды: барысы белән дә күрешеп, исәнләшеп чыкканнан соң, нинди йомыш белән килүен ашыкмый гына әйтеп бирде:

— Мин ни... мин сезгә Зыя абзый турында хәбәр язып китердем. Бик күптәннән эшли. Заманында мине балта тотарга өйрәтте. Картаймыш көнендә кирпечтән каралтылар салу, штукатур-маляр эшләрен дә өйрәнеп алды. Озакламый юбилеен үткәрмәкче булып торабыз. Бер җылы сүз әйтәсе иде бит. Яшьләргә гыйбрәт булыр иде, иллә мәгәр,— диде бригадир, эре-эре хәрефләр белән язып тутырылган дәфтәр битен кисәсеннән чыгарып өстәл өстенә салды.

Идрисов хәбәрне башта үзе укып чыкты. Аннары кызлардан укытты, кызлар баш кагып кына риза икәнлекләрен белдерделәр.

— Рәхмәт, Хәмит абзый, хәбәреңне урнаштырырбыз,— диде Идрисов. Бригадир бик күңеле булып, катлы-катлы рәхмәтләр әйтеп һәм олыларга ихтирамлы булу, яшьләрне шулар үрнәгендә тәрбияләү хакында тагын бер мәртәбә сөйләп чыгып киткәч, кызларга карап әйтте:

— Карагыз әле, чибәркәйләр, әгәр без газетыбызда «Безнең ветераннар» дигән бүлек ачсак, ә? — диде.

Кызлар икесе берәвыздан:

— Бик әйбәт булыр, Хөсәен абый, бик әйбәт! — диештеләр.— Балта

остасы Зыя картны рәсемгә төшерергә кирәк. Рәсеме белән бирербез. Менә безнең газетка тагын бер бүлек артты.

— Мәгъсүм урынына мәкалә дә табылды,— диде Хөсәен Идрисов һәм, нурланып киткән күзләрен күтәреп, кызларга карады.

## Җәүдәт Әхмәтҗанов

Җәүдәт Әхмәтҗановны алырга гадәттә аның берәр тыңлаучысы килә. Идарә урнашкан үзәк усадьбадан Космовский поселогына хәтле биш километр, аны унбиш-егерме минутта үтәләр. Ул арада пропагандист Әхмәтҗанов халыкның кәефе ничек, бригадада нинди яңалыклар булуын сораштырып өлгерә. Әңгәмә вакытында барысы кирәк булачак.

Аны алмага килгән Сабир Мансуров — бригадир — аз сүзле кеше. Гомумән, ул караңгы чырайлырак. Пропагандист Әхмәтҗановны бу хәл бераз аптыраштарак калдыра. Ник караңгы чырайлы бу Сабир? Шат күңелле булырга кирәк иде түгелме соң аңар? Бригада иген уңышын гектарыннан егерме центнердан да ким алганы юк. Егерме өчкә житкән еллары да бар. Терлек асрауда да бригада бирешми. Беренче урында ук булмаса да, икенчедән түбән төшкәне юк. Шулай булгач, ник соң авызга су кабып, караңгы чырай белән йөрергә?

Сабир аны алмага килгән чакта, ишек алдына кергәч:

— Киттек,— дип бер генә сүз әйтә.

Әгәр юлда бригадирны «уятып» җибәрергә мөмкин булса, ул телевизорда ни күргән, «Красная звезда» газетында ни укыган — кыска гына итеп шуларны әйтә. Сабир, күрәсең, ул газетны бик ярата. Фронттан кайтканнан бирле алдырып килә. Башта хәрби газетны юл капчыгына салып алып кайткан иде, ә менә хәзер почтальон ул газетны чирек гасыр буе аңа китереп тора.

Сабир аз гына хәйләкәррәк тә бугай. Әгәр телевизордан күргәне яки газеттан укыганы хакында берәр нәрсә сорарга теләсә, ул аны сорау итеп бирми, пропагандист белән ул хакта киңәшә, үзенең белемен генә түгел, пропагандистның да белемен тикшереп карый. Син нәрсәгә сәләтле, янәсе.

Кайвакыт Җәүдәт Әхмәтҗанов бригадирның холкы-фигыле хакында сүз кузгата:

— Сезне әйтәләр, бик коры табигатьле, диләр. Кешеләргә карата артыграк таләпчән түгелме сез? Әйтик, берәрсе ат сорап та биш кенә минутка соңга калса да, сез аңар ат бирмисез, имеш. Дөресме шул хәл?

— Мин нишләргә тиеш синеңчә? — ди бригадир сабыр гына.— Ат сораучының соңга калганын көтеп утырырга тиешмени? Соңарып килә икән, ат аңар әллә ни кирәк түгел. Үз вакыты да, бүтәннәр вакыты да жәл түгел аңа. Соң бит шул атны аңардан соң бүтәннәргә дә бирергә кирәк. Үзен дә, бүтәннәрне дә ихтирам итә белми торган кешегә нигә дип әле мин ләббәйкә дип торырга тиешле?

Кәефе яхшы чакта бригадир ат турындагы сораудан соң җанланып китә. Кешеләрне мактый, атларны мактый, көннең аяз булуын мактый. Тик боларны ул чәчрәп китеп, сүзләренә төелә-төелә сөйләми, әкрен генә, җай гына сөйләп бара. Сөенече бар икәнне, кәефе шәплекне аның нурланып киткән күзләреннән генә күрә пропагандист. Эштә тәртип булырга тиеш. Тәртип булмаса, рәт-чират юк инде ул, иптәшкәем. Кеше үзенә эшләсә, бәрәңге бакчасын казыса яки ишек алды себерсә, капка-коймa төзәтсә, эшне ул иртәрәк тә, соңрак та башлый ала — анысы аның үз эше. Ник дисәң, эшне бүген бетерәме ул, бер атнага сузамы,

аның хуҗалыгына моннардан әллә ни зыян килми. Ә менә кешеләр бергәләп, кулны-кулга тотынып, кырда яки фермаларда эшлиләр икән, юк инде, иптәшкәем, монда инде эленке-салынкы йөрергә ярамый. Син бүген эшлисе эшне эшләп бетермәдең, ди, аны бит синең өчен бүтән кеше эшләп бетерергә тиеш булып чыга. Әллә син ул кешенең өендә эше юк дип беләсеңме? Син эшләп бетермәгән эшне әллә ул мичтән чыккан бәлеш кебек көтеп кенә утыра дип беләсеңме? Ни өчен әле ул син кояшта сырт җылытканда синең өчен бил бөгәргә тиеш? Менә шуннан китә рәнҗү, китә канәгатьсезлек. Ә бит рәнҗү белән канәгатьсезлек бик тә хәтәр кәефне ала и шулай ук кул эшкә бармый башлый,— дип, Сабир абзый үз фикерен куәтләп җибәрә һәм пропагандистка кирәкле әллә никадәр факт сөйләп ташлый. Уйчан кеше бригадир, аның үз дөньясы үзе белән. Менә нигә ул тонык чырайлы, менә нигә ул аз сүзле икән...

Пропагандист Әхмәтҗановны алмага килгән кешенең икенчесе Зыя Камалов. Ул Сабир Мансуровның ярдәмчесе, иген үстерүгә җаваплы кеше. Холкы белән ул Сабир Мансуровның капма-каршысы. Бригадирыннан ул күп өлкәнрәк, ә менә таләпчәнлек, кырыслык аңарда тамчы бөртек тә юк. Бригаданың уңышларына, колхозның үсүенә ул сөенеп кенә калмый, сокланып бетә алмый. Аңардан берәр нәрсә таләп итә, таптыра башласалар, теш кысып үткәргән авыр яшьлеген искә ала.

Юлда барышлый Зыя Камалов көньяк шәһәрләре, Кавказ таулары, диңгез сулары турында, санаторийларда күргән-очраткан кешеләре турында сөйләп бара. Ул ел саен путевка сатып ала, авылыннан читтә, кайдадыр еракта берәр ай йөреп, җилләнеп кайта.

Космовский поселогы белән Кече Шәймөрзә арасына урнашкан кызыл почмакка килеп җиткәндә, пропагандист Әхмәтҗановның кәефе я бик күтәренке, я төшенке була. Шуңа карап ул кешеләрне я колхозның уңышларына шатланырга, шул уңышларны ил күләмендә барган зур төзелешләр, яңа карарлар белән бәйләргә, яки хезмәт дисциплинасы турында сүз кузгатып, намус, вөҗдан, ихласлык турында сүз куертып җибәрергә ярата. Сөйләр сүзен белеп, чын күңелдән сөйләгәнгә, көн үтсенгә йөрмәгәнгә аны колхозчылар ярата, бирелеп тыңлый, бу исә аның күңелен тагын да күтәреп җибәрә.

Әңгәмәгә иң беренче булып Шаһиҗан Җәббаров килә. Космовский мәктәбенең беренче укытучысы ул, егерме биш еллык партстажы булган коммунист. Пропагандистка сорау биргәнгә кадәр яки берәр хәлне сөйләп биргәнче ул узган яшьлеген искә төшерә. «Без укытучы булган заманнарда...» дип башлый торган бик тә яраткан сүзе бар. Кайвакыт Шаһиҗан укытучы шундый сораулар казып чыгара, күзең маңгаеңа менә. Пропагандист Җәүдәтнең ничәмә-ничә тапкыр, аның соравына җавап эзләп, мәктәп һәм авыл китапханәсен актарганы бар, ничәмә тапкыр ачуы килгәне бар. Әмма ачуланса да, сорауга җавап тапкач, күңеленнән канәгать тә булып куя. Карт укытучы, сизмәстән генә, аны гел укыта, гел белемен арттырырга мәҗбүр итеп килә. Димәк, ул сорауны юри бирми, аны батырып өчен бирми, аны күтәрергә, үстерергә теләп, изге ният белән бирә. Шаһиҗан әле колхозга булышып, төрле эшләрдә эшләштергәләп йөри, шулай да ул күбрәк вакытын, бигрәк тә кыш көннәрен өендә үткәрә. Педагогик журналлар да, политик журналлар да алдыра, радио тыңларга бик ярата. Менә шуннан аның тынгысыз күңелендә сораулар тезелә башлый. Бар, тиз генә җавап биреп кара син аларга!

Нургали Фәезов, картлар сүзе белән әйтсәк, Космовскийның башлыгы, вазифасы буенча ул поселок советы председателе, өлкәннәр җыелып беткәч, бераз соңрак килә. Күбесенчә ул пропагандистка дәресен алып барырга булыша. Бөек Ватан сугышы турындагы диафильмнар

күрсәтелгән чакта, сугыш истәлекләрен сөйли. Диафильмны бик иркенләп аңлатып бара.

Ә менә Заһидулла Әхмәдуллин башкалар сөйләгәнне бирелеп тыңлый. Яшь чагында аңа уку күп эләкмәгән. Гомере аның терлек-туар тирәсендә уза. Аның хакында авылдашлары: ул туганда да фермада туган, дип сөйлиләр. Баштарак елларны ат караган, хәзер җәйләрен симертергә куелган малларны көтә. Аның рәсеме колхозның Мактау тактасыннан төшми. Эшенә күрә ашы дигәндәй, айлыгы — өч йөз-өч йөз илле сум. Тормышы көйле агайның. Балаларыннан да уңды. Олысы армиядә хезмәт итеп кайтты да колхозда эшли, кечесе унынчыдан соң армиягә китте.

Политтүгәрәккә ул бик теләп йөри. Колхоз эшләре турында сүз кузгалса, машиналарны списать итүче комиссияне күзәтеп торыгыз, кирәклесен әрәм итә күрмәсеннәр, дип борчыла. Кайчагында бит эшкә ярарлык машинаны да списать итәргә тотыналар. Имеш, яңасы килгән, шәбрәге. Ә бит аларга заманында күпме акча сарыф ителгән. Ул хакта уйламый хәзерге яшьләр, шәбрәге булсын, яңарагы, тизрәк ура торганы. Бәлкем әле, аны каккалап-суккалап, төзәтеп тә куярга мөмкиндер, бәлкем әле, ул берәр эшкә ярап куяр, ашыкмаска кирәк, ашыгу шайтан фигыле...

Тыңлаучылар арасында төрле кеше бар. Беришесе — Исмәгыйл Сәйдәшев кебеге — сөйләгән бер сүзеңне язып барыр, шуның янына үз уйларын да теркәп куяр, беришесе язу алып баруны кирәксез эш дип санар, имтихан тотасы юк бит дип исәпләр. Әмма тыңлаучылар арасында шундый да әкрен, шундый да сабыр, пошмаслары бар... Хәер, аны исеме белән әйтсәк тә була. Тазалыгы ташып торган, өнсез булуы, дәшми-тынмый йөрүе ашып киткән Насихны менә ничек кузгатырга? Ничек итеп аның күңеленә ачкыч табарга? Диафильмнар барган чакта иң кызыклы урында туктатып, Насихтан сорап та карады Җәүдәт. Кайвакыт, башкалар ярдәме белән, Насихны кузгатып җибәреп тә була, диафильмны сөйләтеп тә була. Ләкин һәрбер дәрес диафильм күрсәтеп кенә үткәрелми бит. Кайбер материал аеруча игътибарлы булуны таләп итә.

Уку елы башында Җәүдәт бригадирга әйтеп куйды, әгәр мөмкин булса, дәрестән соң аны өенә Насих озата барсын иде. Шул сүздән соң Җәүдәт белән Насих кышкы аяз кичләрдә яки көзге эңгер-меңгердә байтак вакытлар бергә йөрделәр. Күп сүз сөйләштеләр. Пропагандист үзе турында сөйләде. Сугыштан соң физкультура укытуын, аннары институтка укырга керүен, инде менә мәктәптә тарих укытуын сөйләде. Мәктәптә эш аз түгел. Иртән сигезенче яртыдан көндезге икенче яртыга кадәр — дәресләр. Дүртенче яртыда тагын мәктәпкә киләсең — районнан алып кайткан яңа фильмнарны күздән кичерәсе бар. Кичен өлкән класслар белән эшлисе, консультация үткәрәсе. Дәрестән соң мәктәптәге эшне тавык чүпләсә дә бетәсе түгел. Шуның өстәвенә Җәүдәт Әхмәтҗанов — мәктәп парторгы бит әле.

Өенә кайтса — контроль эш яки яңа конспектлар әзерли — быел аның пединститутта дәүләт имтиханнары тапшырасы бар. Шул уңай белән аны политтүгәрәк алып барудан азат та итмәкче булганнар иде, үзе риза булмады. Насих белән әлерәк кенә уртак тел таба башлады бит ул. Соңгы дәресләргә инде ул әзерләнеп, конспектларын язып килде. Егет машиналар ярата, механизатор булырга ниятләнә. Әхмәтҗанов аның өмете бушка китмәсен дип тырыша: кирәкле китапларын табып алып килә, үзе белгән эшләрне сөйләп, киңәшләр бирә, гел сорашып, гел белешеп тора. Насих моңар шундый күнекте, Җәүдәтнең сораганына, хәл белешкәненә ул чын күңеленнән рәхмәтле, килгән саен бер яңалыгын хәбәр итәргә әзер. Түгәрәкнең азаккы дәресендә — имтихан-әңгәмә вакытында Насих барлык сорауларга да җавап бирде. Дөрес, бик

озаклап, һәр жөмләсен үзенчә әкрен һәм озак уйлап сөйләде, әмма материалны белүе күренеп тора иде.

Пропагандист Әхмәтжановның күңеле канат какты — әкрен һәм аз сүзле Насихны көне буе тыңларга әзер иде ул.

## Нуретдин Азизов

Һәр авылның үзенә генә хас, күп таралган фамилиясе була. Әгерже якларында Тукаевлар күп. Хәтта авылның яртысы Тукаев булганнары да бар. Бөек Тукай фамилиясен йөрткәнгә алар бик горурланалар, кызлары хәтта кияүгә чыккач та фамилияләрен үзгәртми саклый. Иске Шәйморзада иң күп таралган фамилия — Азизов. Биредә — укытучы Азизовлар, чөгендер үстерүче Азизовлар, механизатор Азизовлар бар.

Без Нуретдин Сөләйман улы Азизов хакында сөйләп бирергә телибез. Халык телендә йөргәнчә әйтсәк, «житмеш төрле һөнәр иясе» Азизов турында безнең сүзебез. Ул электрик та, ул слесарь да, комбайн йөртүче дә, тракторчы да. Ләкин аның иң төп сыйфаты нәрсә дип сорасагыз, Иске Шәйморзада әйтерләр, Нуретдин Азизов колхоздагы һәммә нәрсә өчен үзен жаваплы итеп тоя, диерләр. Авылдашлары аны берничә мәртәбә авыл Советы депутаты итеп сайладылар. Хәзер дә ул, депутат буларак, авылны яшелләндерү, төзек-пөхтә итеп тоту комиссиясендә эшли.

Яшәвен ул атасы йортында, «төп йортта» яши. Дөрес, ата йорты дигән төшенчә биредә нәсел башына ихтирам йөзеннән әйтелә, ник дигәндә, элеккеге, жиргә иңгән, балчык сыланган иске өй урынына алты почмаклап, ишек-тәрәзәләрен зур итеп салган өр-яңа йорт балкып утыра. Йорт янында жиләк-жимеш бакчасы шаулый. Көзен алсу әнисләр алмагач ботагыннан тәрәзәгә тикле сузылалар.

Нуретдиннан ерак түгел генә аның абыйсы Миргасим яши. Калган туганнарының кайсы Казанда, кайсы Йошкар-Олада. Туганнар хәл белешергә дип ел саен бер-берсенә кунакка жыела. Борынгыдан килә торган гадәт буенча кунакка барырга берничә ай элек әзерләнә башлыйлар. Кайсы туган нәрсә ярата, нәрсәгә хирыс — барысы исәпкә алына. Кеше арасында хур буласылары килми, артык кыйммәтле бүләк алып, туганыңны рәнжетергә дә ярамый. Кыйммәт тә булмасын, туганыңның күңеленә дә хуш килсен — әнә шундый бүләкне сайлап кара син.

Беренче булып Рәшит абыйларына жыелалар. Күпереп торган паштет, балга катырган бавырсак, каклаган каз шәһәр халкына бик тә урынлы булып китә. Башка төр бүләкләр аларны шаккаттырмый. Ә менә Газизә апаны йорт ризыгы белән таң калдыра алмыйсың. Ул үзе бик шәп кулинар, кафе мөдире. Азизовлар нәселеннән иң яше булган Суфиягә затлырак кием-салым алсаң да ярый, беренче көнне үк кунаклары янына киеп тә чыгарлык булсын.

Кунакка алдан ук әзерләнә башласалар да, барыр көн көтмәгәндә килә. Тимер табанлы яңа чанага жигелгән аргамак жилләр уйнатып капка төбенә килеп туктый. Вакыт әле иртә булса да, озатырга күршеколан жыела. И китә шуннан ашыгу-каударлану, бәхетле юл теләү дә йомыш кушулар! Никадәр онытмаска тырышсалар да, берәр күчтәнәч онытылып кала, ярты юлдан әйләнеп кайткан чаклар була. Ярый әле, колхоздан атның әйбәтен бирәләр, нәкъ поезд киткән минутка ат станцага китереп тә житкерә. Уфа — Казан поезды Азизовларны тәяп туганнары янына ерак юлга алып китә.

Поезд зәңгәр төтеннәрен болгый-болгый, рельсларны саный-саный, кырлар, урманнар буйлап чапкан чакта Казанның Патрис Лумумба

урамындагы бер йортта — Рәшит Азизовта ду килеп кунак каршыларга әзерләнәләр. Очрашу вакыты — Яңа ел алды. Телеграмма-мазар сукмый гына килеп төшәләр. Шуңа күрә очрашу һәрвакыт яңа һәм шатлыклы була.

Еллар туганнарның яшь аермасын бетерә бара. Азизовларның кайсы олы, кайсы кече икәнен тиз генә аера да алмассың. Шулай да күп еллардан килгән гадәт-йола буенча түр башына Миргасимны утырталар. Аның янында — Рәшит белән хатыны. Аннары башкалар тезелеп китә. Беренче очрашу, күрешү шау-шулары узганнан соң, сөенеч-шатлыклар, елга ярына кайткан язгы су кебек, үз ярларына кайтып утыргач, моңсу тынлык минутлары булып ала, менә шуннан соң игътибар Азизовларның иң кечесенә, «житмеш төрле һөнәр иясе» Нуретдинга юнәлтелә.

Нуретдин инде егет-җилән түгел, яшь кияү дә түгел, төп йортның семья башлыгы. Аның өендә дүрт малай үсеп килә, абыйларына ул әле һаман төпчек. Алар Нуретдинның кырык беренче елны читәнгә сөялеп, чебиле аякларында таптангалап, олылар елаганга аптырап, абыйларын сугышка озатып калуын хәтерлиләр. Ул чакта әле ул әнисенең нигә елавын, әтисенең нигә бөкрәеп килүен аңларлык хәлдә түгел иде.

Миргасим белән Рәшит очсыз-кырыйсыз фронт юлларында йөреп, илне афәттән саклаганда, чебиләгән аяклы Нуретдинны да үлемнән сакладылар бит. Ә менә ул, алар кебек, ил өчен ни эшләгән? Үз куллары белән колхозга нинди файда китергән? Алар гүя аңардан әнә шуны сорыйлар.

Кайберәүләрнең биографиясе, поезд расписаниесе кебек, гап-гади: туган, үскән, мәктәп бетергән, инженер булган. Нуретдинның алай гади дә, җиңел дә булмады. Абыйларыннан соң аңа өйдә хуҗалык карарга, колхоз эшенә йөрергә, биш класс белем белән торып калырга туры килде. Сигезенче классны ул егерме елдан соң, уллары белән бергә тәмамлады.

Әмма һөнәрне ул бик яшьли, унбиштән үк сайлап алды.

Сугыш Иске Шәйморзага Федоров дигән картны китереп ташлаган иде. Татарча белмәсә дә, техниканы бик хәтәр белә иде карт. Авылда ашлык сугу машинасының двигателен эшләтергә куйдылар. Нуретдин әнә шул карт янына урнашып алды. Ындырда, двигатель урнашкан бәләкәй бөркү өйдә көннәр буена утыра торган иде. Машинист саңгыраурак иде, аз сүзле иде. Машина аның берүзенә авырга туры килә. Көненә ике-өч мичкә су саласы, карыйсы да майлыйсы бар. Нуретдин аның карусыз ярдәмчесе булып китте.

Баштарак аны әнисе күлмәк-ыштанын мазутка буяп кайтканы өчен ачулана иде, тора-бара кул селтәде: машина җене кагылган малайны биздереп буламы соң машинадан!

Нуретдинга шул гына кирәк тә! Карт һава сулап керергә дип чыккан чакларда ул валның әйләнешен тизләтеп җибәрә. Ашлык сугу машинасында эшләгән хатыннар канәгать: барабан тизрәк әйләнгәнгә күрә, аңа салам уралырга өлгерми. Ә карт чатыр чабып будкага килеп керә дә барабанны тыя төшә.

— Барабанга салам уралса, аны чистарту әллә ни түгел, ә менә машина ватылса, безгә яңасын бирмәсләр бит, син шуны уйладыңмы, улым? — ди Федоров.

Язын Нуретдин плугарь булып йөрергә рөхсәт сорады. Алмадылар, үсәсең бар әле, диделәр. Шулай да ул, үзеннән озынрак буйлы яшьтәше белән сүз куешып, өч көн генә булса да трактор артыннан йөреп калды. Тракторчы Петр аны ул чакта хәтерендә дә калдырмагандыр.

Армиягә ул буй җиткән, киң җилкәле, тап-таза егет булып китте. Хәрби частьта аларны сафка тезеп, командир:

— Тракторчылар, ике адым алга! — дип команда бирде.

Нуретдин ике адым алга чыкты, әмма төннең төн буе йоклый алма-

ды. Ә кинәт белсәләр, аның тракторчы түгел икәнен аңласалар? Уздылар. Танк йөртүчеләр батальонына укырга алдылар. Нуретдин эләккән экипаж беренче айда ук күнегүләрдән иң яхшы бәя алды. Укуын тәмамлаганда ана һәм аның дусты, Саратов егете Виктор Кучинга сержант исеме бирделәр. Нуретдин армиядән «Отличный танкист», отделение командиры булып кайтты.



Кайтуга председательдән шоферлар курсына җибәрүен сорады. Кем иде әле председатель? Хәер, кем булса да барыбер түгелмени, колхозның хәле мөшкел иде, механизаторлар да, техниклар да юк диярлек иде. Председатель вәгъдә бирде дә онытты, исенә төшергәч, бәйләнмә әле, синнән башка да эш муеннан дип сукранырга тотынды.

Машинага ашлык төяүче булып китте. Арыган шофер йокымсырый башлаган чакларда рульне үз кулына алды. Машинаны бергә карап, бергә ремонтладылар. Көзен алты айлык комбайнчылар курсына укырга керде. Укудан кайтканда, колхозда инде башка председатель иде. Ул хәлләргә инде унбиш еллап вакыт узган. Әнә шуннан бирле ул чынчынлап механизатор булды. Башта ярдәмче иттеләр, аннары үзе комбайн алды. Башлап эшләгән комбайны СК-3 не инде хисаптан төшерделәр, тик әле ул эштән чыкмады. Нуретдин арыш-бодайны СК-4 маркалы яңа комбайнда ура, иске комбайнын борчак-мазар урганда файдалана.

Яңа комбайн, сәгать кебек, төгәл эшли, бик һәйбәтләп карап, герметизация дә үткәргәч, кырда бер генә бөртек тә калдырмый.

Рәшит абыйсы анардан:

— Я, энекәш, эшләр кай тирәдә синең? Ничәнче урынга чыктың? Нинди премия бирделәр быел? — дип сорады.

Ничәнче урынга чыктың? Нинди премия бирделәр? Нуретдин урынның ничәнчесе эләгер дип баш ватмады. Ул яңа комбайн алды. Аны тикшерәсе, аны эштә сыныйсы, шөрепләрен ныгытасы, гомумән, эшкә җайлыйсы бар иде. Андый чакта ашыгу үзе начар. Федоров карт әйткән иде бит, машина ватылса, яңасын алу кыен, дигән иде. Заводтан чыккан гына көе комбайнны дөбер-шатыр куа башласаң, күпмегә генә чыдар ул? Кумады Нуретдин, җай белән эшләтте һәм алтынчы урынны алды. Ләкин ул хакта абыеңа, сиңа күзләрен мөлдерәтеп карап торган иң өлкән абыеңа ничек әйтәсең? Башка елларны бит ул Рәшитнең иң алга чыгып барганын да, нинди бүләкләр алганын да белә.

— Нуретдин безнең быел яңа һөнәр алды, Тәтештә курслар бетереп, слесарь-монтажник булып чыкты,— дип Миргасим «төпчек»не йолып калырга ашыкты.— Хәзер ул яңа салынган фермаларга су китерү җайланмалары ясый.

Нуретдин үзе дә авызына су кабып калмады.

— Рәшит абый, менә сез яңа приемник алгансыз. Сез аны шундук акырта башлыйсызмы, әллә берәм-берәм барлык регуляторларын тикшереп чыгасызмы?

— Син кай яктан бөгәсең, энекәш? — диде Рәшит, көлемсерәп.

— Узган елны мин яңа комбайнымны тикшереп-сынап карадым, ә менә алдагы елларда билне буып, тагын бер ярышып карарга исәп.

Рәшит абыйларында кунак булганнан соң Газизә апаларына кереп чыктылар, Йошкар-Оладагы Сәрия апаларының да хәлен белеп, Яңа елга авылга кайтып төштеләр. Туганнар чыршы бәйрәмен һәркайсы үз өендә үткәрергә гадәтләнгән.

Шәймөрзалар бәйрәм итә беләләр. Өлкәннәр алты почмаклап салынган иркен йортларының ике ягын да тутырып үз өйләрендә мәш киләләр. Яшьләр Октябрьның 50 еллыгына житештерелгән культура сараена ашыга. Биюләр, җырлар, маскарад, викторина — шәһәрдәгечә. Культура сараенда бәйрәм оештыручыларның берсе — Азизова, Иске Шәймөрза мәктәбе укытучысы.

Күңел көр булгач, бәйрәм итүе дә күңелле. Соңгы биш елда гына да Шәйморзалар иген ашлыгын икеләтә артык үстереп, гектарыннан егерме икешәр центнер алдылар. Һәм бу югары уңыш Нуретдин Азизов кебек булдыклы, тырыш һәм намуслы механизаторлар исәбенә үстерелде.

## Әхмәтгәрәй Әбдриев

Әхмәтгәрәй Әбдриев, колхоз председателе, президиумда өстәл янына ук утырып, сөйләүчеләрне игътибар белән тыңлый. Вакыт-вакыт ул блокнотына бер-ике сүз язып куя, сорау билгеләре сызгалый, шулай да күбрәк вакытын тыңлап үткәрә. Бригадир сөйләвен ул кашларын җыергалап, бер сүзен дә ычкындырмаска теләп тыңлады. Зоотехник сөйләгәндә, елмая биреп, хәтта урындык аркасына кайшала төшеп утырды.

Вакыт-вакыт ул үз уйларына да бирелеп алгалады. Ни турында иде аның уе? Бәлкем, ул председатель булып сайлангандагы беренче көннәрен уйлагандыр, бәлкем, иртәгесе көнне күреп, кимчелекләргә борчыла белергә өйрәнгән авылдашларына шатланадыр...

1955 елның 5 февралендә партия райкомы үзенең сотрудникы Әхмәтгәрәй Шакирҗан улы Әбдриевне колхоз председательлегенә тәкъдим итәргә карар чыгарды. Шәйморзалар аны ике көннән колхоз башлыгы итеп сайлап та куйдылар. Моңарчы бүтәннәрне ничек сайлаган булсалар, Әбдриевне дә шулай сайладылар, әллә ни каршы килмичә, зур әметләр багламыйча сайладылар. Председательләр килделәр дә киттеләр, колхоз арттa кала бирде. Хезмәт көненә иң аз түләүдә Шәйморзалар үрнәк булып сөйләнде. Кемнәрдер читкә китте — Казанга, Ульяновскига барып урнашты, матур киемнәр киеп бәйрәмгә кайтты, яшүсмерләрнең күзен кызыктырып, кала тормышы белән ымсындырып китте. Калганнары үз бакчасында, үз абзарында казынды. Казан базарына да, Ульяновскига да ерак түгел, юлда очраган берәр машина сөтче кызларны көтүе белән төйи дә алып китә иде.

Әмма колхозны төзегән, авыр сугыш елларында аны үз җилкәләрендә күтәреп чыккан кешеләр өчен яңа председательнең кем булуы барыбер түгел иде. Сайланганның икенче көнендә Әбдриев идарәгә килгәч, агайлар аны тавыш-тынсыз, дәшми-нитми каршы алдылар. Председатель сәлам биреп, әчкә узды. Бусагадан анар тәмәке төтене белән бергә бригадирларның карлыккан тавышлары ияреп керде. Бу — өнәмәү билгесе иде. Күрәсең, алар председатель әле яңа гына йокысыннан торып, өеннән чыккан, дип уйлыйлар иде. Әбдриев ул көнне таң атканчы ук торды, ат караучыны уятып, кошовкага председатель атын үзе җикте һәм япа-ялгызы авылдан чыгып китте.

Ул елны кар күп яуды, күз күреме җирдә басу өсте ап-ак иде, шулай да Әбдриев еракта урылмый калган басуны күрде. Атын шунда куды. Таң җиле белән камыллар җиргә сыгыла, башаклардагы ашлыкның яртысы коелган иде инде. Чирләшкә орлыклар, суыктан башагынаябышкан бөртекләр генә торып калган. Язын коелган ашлыктан уҗым үсеп чыгар. Башка төр культурага дип билгеләнгән ул басуда әле шул зәгыйфь ашлыкны чүп үләне итеп утарлар. Әнә шундый басулар өчен партия линиясе буенча председательләр каты шелтә алалар да инде. МТСларда механизаторлар җитешми, машиналар җитешми, кешеләр урак тотып, чалгы тотып кырга чыгуны онытканнар...

Җилдә чайкалган сирәк камыллы кыр Әбдриевнең күз алдына ап-ак кары белән, орлыксыз башаклары белән мәңгегә торып калды. Идарәдә анар бригадирлар ябырылды, банкта кредит бирмәделәр. Ул барысын

үзе ерып чыгарга, барысын үз башы белән хәл итәргә тиеш иде. Мондый чакта иң элек үзең үрнәк күрсәт, иң элек алны-ялны белми үзең эшлә.

Әхмәтгәрәй беренче җәйне тырышкан кадәр беркайчан да тырышмагандыр. Комбайнчылар урырга өлгермәгән басуларны ул гектар ярымлап хуҗалык саен бүлеп бирде, үзенә дә шундый ук чорманы алып, төннәрен чалгы тотып кырга чыкты, көндез колхоз башлыгы булып артель мәшәкатьләре белән йөрде.

Кул астында эшләүчеләрнең сиңа ышанып караулары канатландыра, дәртеңне арттыра икән, Әбдриевнең колхозы елдан-ел ныгый, елдан-ел тернәкләнә барды. Өч елдан алар алдынгылар рәтенә чыктылар. Әхмәтгәрәй Әбдриев Татарстан Верховный Советына депутат булып сайланды, ә 1961 елны аны Татарстан коммунистлары XXII партсъездга делегат итеп сайладылар.

1967 елны колхозның акча кереме ике миллион сумга, бүленми торган фондлары өч миллион сумга җитә язды.

Авылдашларының бай яшәүләрен генә түгел, матур һәм ямьле итеп яшәүләрен дә кайгыртты председатель. Менә хәзер дә әле ул, партия җыелышында авылдашларының сүзләрен тыңлаган чакта, шул хакта уйлап утыра иде, сүз бирелгәч, уйларын колхозчыларга да әйтеп бирде.

Колхоз фермалары якын арада ике смена белән эшли башларга тиеш. Бу — аларның күптәнге хыялы. Идарәнең карарын җыелышка чыгып әйткәнгә тикле якын күршеләрен дә, ераграк күршеләрен дә карап кайттылар. Тәҗрибәгә тәҗрибәне кушып карадылар. Белгечләр белән киңәштеләр. Акча түләү тәртибе генә түгел, савымчыларның ничегрәк эшне бүләргә теләүләре дә мөһим бит. Мәсьәләнең монысын хәл ителгән дип тә санарга була инде. Председательне борчып торган мәсьәләләр аннан башка да җитәрлек. Әйтик, менә колхоз тиздән зурзур каралтылар төзеп бетерә. Фермалар, амбарлар, мастерскойлар бик нык итеп, иркен итеп салынды. Мәктәп ихатасында да эшләр бетеп килә. Урта мәктәп өчен ике катлы яңа бина өлгергәч, укучылар бер генә смена укый башлаячак. Бу шулай ук колхозчының вакытын күбәйтеп, кулын чишеп җибәрәчәк. Колхоз капитал төзелешкә елдан-ел күбрәк өлеш чыгарырга исәпли, ул чагында авылны төзекләндерү, колхозчыларга яңа йортлар житкезү мөмкинлеге арта төшәчәк бит. Йортларны нәрсәдән салуны гына түгел, ничек итеп салуны да уйларга кирәк. Культура йортының нигезен салганда Казаннан архитектор чакырдылар. Культура сарае! Авылда ул иң матур йорт, иң зур йорт һәм иң уртада торырдай йорт булырга тиеш. Архитектор өч йортны күчерергә киңәш итте — килештеләр. Авылны матур итеп күрәселәре килде.

Председатель проектлар институтына авылның генераль планын сызарга кушылганны хәбәр итте. Аны гөр килеп хупладылар. План белән генә эш бетми, төзелеш материалы күп кирәк булачак. Райүзәктәге кирпеч заводын зурайтмакчылар. Җиде-сигез миллион кирпеч сугарлык итәселәр. Биш йөз-алты йөз меңне бирми калмас аларга. Казан заводы ике йөз-өч йөз мең бирсә, Әлмәт ягыннан кыр ташы китерсәләр. Председатель инде исәпләп карады, андый материал ел саен сигезтугыз йорт салырга җитә. Колхозның хәзер үз балта осталары, үз ташчылары, үз штукатурчылары һәм буяучылары бар. Культура сараен үз төзүчеләре салды лабаса! Больница каралтыларын салганда авыл төзүчеләренең тәҗрибәсе арта төшәчәк.

Киләчәк көн турында председатель колхозчылар белән бергә хыяллана. Культура сараенда яп-якты булып утлар яна, ут яктысында колхоз авылы хуҗасының Алтын йолдызы чагылып-чагылып китә һәм шул утлар яктысында аның киләчәк көнне кайгырткан уйлары әкрен генә агыла, авылдашларының күңелен җилкендереп, шатландырып агыла.

Гөлсинә Мөхәммәдова

# ГУМАНИЗМ ҖЫРЧЫСЫ

Тормыштагы уңай башлангычны раслау, яңа чынбарлыкның матурлыгына һәм гүзәллегенә дан җырлау, коммунизм төзүче совет кешеләренең рухи байлыгын һәм әхлакый сафлыгын ачып бирү — совет язучылары алдында торган бурычларның иң аеруча мөһимнәре әнә шулар. Күренекле язучыбыз Габдрахман Әпсәләмов әсәрләрендә без нәкъ менә әлеге принципларның тормышка ашырылуын күрәбез.

Халыклар дуслыгы һәм гуманизм — социалистик реализм әдәбиятындагы үзәк темаларның берсе. Яңа кеше өчен көрәш һәм гуманизм идеясе Габдрахман Әпсәләмов иҗатының буеннан буена сузыла.

Безнең әдәбиятка ул хезмәт һәм героик эшләр поэзиясе, зур идеаллар белән янып яшәүче романтик геройлар алып килде. Тормыштагы яңалык үрентеләрен күрә белү, халыктагы иҗади көчләрнең колачын дөрес тасвирлау аның бөтен әсәрләренә хас.

Шуның белән бергә, заманның үзенчәлегенә, теге яки бу әсәрдә алынган мәсьәләләрнең характерына карап, Габдрахман Әпсәләмов иҗатындагы бу сыйфатлар үсә, үзгәрә һәм тирәнәя баралар. Мисалга язучының соңгырак елларда язылган ике романын алып карыйк. Аларның берсе — «Сүнмәс утлар», икенчесе — «Ак чәчәкләр» романы. «Сүнмәс утлар» романында язучы социализмнан коммунизм җәмгыятенә күчү чорына хас каршылык һәм конфликтларга мөрәҗәгать иткән иде. «Ак чәчәкләр»дә инде ул әлеге каршылыкларны тагын да үстереп, сәнгатьчә үткенәйтеп бирә. «Сүнмәс утлар»дагы Сөләйман карт характерына салынган гуманизм, актив, сугышчан, Горькийча гуманизм икенче романдагы Әбүзәр Таһиров образында тирәнәйтелә, көчәйтелә төшә. Әгәр беренче романдагы Хәсән Мортазин образы аша язучы башта үзен җәмгыятькә каршы куеп та, эшчеләр коллективына килеп эләккәннән соң индивидуализм хисләрен җиңеп чыга алган бер шәхесне сурәтләсә, «Ак чәчәкләр»дәге Яңгура образында искиткеч комсыз һәм бары үзен генә ярата торган вак җанлы кешене фаш итә. Мондый чагыштыруларны өзлексез дәвам иттерергә мөмкин.

«Ак чәчәкләр» медицина эшчеләре турындагы роман, ләкин идея яңгырашы ягыннан караганда, ул бу тема рамкалары белән генә чикләнми. Ул, барыннан да элек, гуманизм принципларының тантана итүе, җиңеп чыгуы хакында сөйли торган әсәр. Романның язылу тарихына тукталып, автор болай ди: «Теге яки бу әсәрне язу теләге кинәт кенә тумый, образлар берьюлы тулы канлы һәм тере булып күз алдына килеп басмый. Барысы да әкренләп, озаклап һәм, дөньяга килә торган һәрнәрсә шикелле, каты газап белән туалар. Сугышка кадәр мин авырмадым һәм авыруның нәрсә икәнен дә белми идем. Беренче тапкыр врачлар кулына фронтта, яралангач эләктем һәм шунда бу профессия кешеләренә беренче мәхәббәтем уянды. Ул мәхәббәт, күрәсең, шактый көчле булган, мин беренче романымда ук врач образын тудырырга омтылып карадым. Ул «Алтын йолдыз»дагы военврач Мөнирә образы иде...

«Газинур» романын язганда мин яңадан врач образын бирергә тырыштым — ул Катя Бушуева иде. Күрәсең, бу ике образ гына минем врач турындагы хыялымны канәгатьләндермәгән. 1955 елда авылдашым һәм якын дустым атаклы хирург Әхмәт абый Айдаров турында очерк язу нияте белән Әгерҗе тимер юл больницасына киттем... Әмма Әхмәт абый турында очерк яза алмадым. Ә Әгерҗедән кайткач, врачлар турында берәр зуррак нәрсә язу теләге көчәйде. Ләкин ул арада «Сүнмәс утлар» белән мавыгып киттем һәм ул «утлар» миңа бик кыйбатка төште... Чын-чынлап авырып больницага эләктем. Больницадан чыкканда, калын бер дәфтәр шундагы күзәтүләр белән тулган иде. Берничә елдан соң яңадан йөрәк чыгымлый башлады. Нәтиҗәдә яңадан больница койкасы һәм яңадан калын бер дәфтәр күзәтүләр. Һәм булачак геройлар күз алдына ачыграк, конкретрак булып килеп бастылар. Өченче тапкыр больницада ятканда, «Ак чәчәкләр» язылып беткән иде инде».

...Больницада Г. Әпсәләмов очраклы рәвештә атаклы медик, профессор Терегулов белән бер палатага эләгә. Медицина эшчеләре тормышыннан әдәби әсәр язарга җыенып йөргән әдип кулына кирәкле материал үзе килеп керә. Уртак тел таба, сөйләшә бел дә көндәлекләр алып барырга иренмә. Ул шулай эшли дә. Ләкин бу — «Ак чәчәкләр» романы бик җиңел язылган дигән сүз түгел әле. Г. Әпсәләмовның көндәлек дәфтәрләрендәге язмалары шул хәлендә генә романга кереп китә алмаган кебек, әсәрдәге Әбүзәр Таһиров та тормыштагы Әбүзәр Терегуловның гади күчермәсе түгел. Язучының иҗат лабораториясе аша узганда тормыш материалы бик нык үзгәрә, бөтенләй яңа эретмәгә әйләнә. Артык, очраклы нәрсәләр төшеп кала, икенчеләре үстерелә, күпертелә, куертыла. Г. Әпсәләмов бик дөрес яза: «...иҗат эшендә иң кыены, иң авыры прообраздан образга бару юлы. Бу юл бик катлаулы, бик сикәлтәле һәм шул хәтле үзгәрүчән, кайчакта прообразлардан бернәрсә дә калмый диярлек... Син героеңның прообразын тапкансың, ләкин ул әле образ түгел. Ул образ булсын өчен тагын шуныңише уннарча, йөзләрчә прообразларның сыйфатлары кирәк. Сиңа гүя образ иҗат итәр өчен бер мәрмәр кисәге тоттырганнар. Шушы мәрмәр кисәгеннән конкрет образның сурәтен тудырыр өчен таштагы бөтен артык кисәкләрне алып ташлау да җитә. Әмма образ тудырыр өчен мондый хезмәт кенә аз, образ тудырыр өчен тагын да зуррак хезмәт салырга кирәк, чөнки анда бөтенләй яңа сыйфатлар, яңа чалымнар килеп чыга». Романдагы Әбүзәр Таһиров образы әнә шулай зур көч сарыф итү, күп тир түгү нәтиҗәсендә туган.

Бер карасаң, геройның тормыш юлы тышкы вакыйгаларга әллә ни бай түгел кебек (башта пансионда, аннары гимназиядә һәм университетта уку еллары, авылда эшләү, тагын шәһәргә килеп, ординатурада уку һәм еллар буе Казан больницаларының берсендә хезмәт итү). Әмма эчке, рухи байлык күпме аңарда! Университет тәмамлауга терапия корифее, мәшһүр профессор Алексей Николаевич Казем-Бек үзе аны ординатурада калырга үгетләп карый. Әбүзәр авылга, үзен укыткан кешеләрне дәваларга җибәрүләрен сорый. Аның теләген канәгатьләндерергә мәҗбүр булалар.

Муллага дога кылган өчен дә сәдака бирергә гадәтләнгән авыл кешеләре башта төмам аптырап калалар: ничек инде бушка кеше дәваларга мөмкин?! Әбүзәр докторның хәтерендә шундый вакыйга сакланып калган. Шулай бервакыт аның янына, авыру баласын күтәреп, яшь кенә хатын килә. Доктор баланы карый, тиешле ярдәм күрсәтә. Хатын, баласын дәвалаган өчен, акча бирә, Әбүзәр алмый. Хатын үпкәли башлый. Аптырагач, Әбүзәр аңа, акча урынына, чәчәкләр китерегез, ди. Ямьле Дим буеннан китерелгән шул ак чәчәкләр аның бөтен гомере буена рухи сафлык һәм эчкерсезлек символы булып кала.

Әсәрнең көндәлек дәфтәрләре формасында язылуы авторга кирәк чакларда турыдан-туры хикәяләүгә катнашып китәргә мөмкинлек бирә: «Гомере гел больницаларда, аһ-зар, кан-яшь эчендә үткән карт врачның күңеле ахыр килеп катып беталдер, кичерешләре дә сүлпәнәядер, табигать күренешләре дә әсәрләндерми торгандыр дип уйлый идем мин үземнең беркатлылыгым белән. Бик ялгышканмын! Әбүзәр абзый шагыйрь кебек нечкә күңелле, рәссам шикелле табигать яратучан бер кеше булып чыкты»[1]. Әбүзәр абзыйның Кама буйларындагы табигать турында сөйләгән

---

[1] Г. Әпсәләмов. Сайланма әсәрләр. 2 том. Казан. 1968 ел. 178 бит. Алга таба барлык өземтәләр шушы басма буенча китерелә.

сүзләрен китереп, автор безне аның чыннан да художник йөрәкле кеше булуына ышандыра.

Табигатькә, кешеләргә булган зур мәхәббәт хисе аны картаюдан, рухи ярлылыктан саклый. Хисләре каткан кеше башкаларның күңел сафлыгына соклана алмас иде. Әбүзәр Таһиров, күп еллар узган булуга карамастан, ике гади рус хатынының совет сугышчыларын фашистлардан саклап калуларын оныта алмый. Авыруларның профессорга ышанычлары никадәр зур булуын Хәйдәр Зиннуров хисләре аша да белергә мөмкин: «Мин аны иң каты авыртынган, буылган минутларда да таный идем. Ихтимал, мин аны хыялымда гына күргән чакларым да булгандыр, чөнки ул миңа минем караватым янынннан тәнлә дә, көндез дә бер дә китми күк тоела иде» (200 бит). Профессорның ягымлы мөнәсәбәте авыруга иң кыен минутларда кара үлем шәүләсен куарга булыша. Авыруның койкасы янында булуы белән генә дә ул аның күңелендә яшәүгә өмет уята, хикмәт хәтта аның профессор булуында да түгел, ә ягымлы, игътибарлы кеше булуында. Галина Петровнаны уңышлы дәвалап чыга аласына профессор үзе дә ышанып бетми. Әмма авыру яткан палатадан ул ышанычлы, нык адымнар белән чыга. Чөнки аның һәр хәрәкәте, хәтта аяк атлауларына кадәр авыруларда ышаныч һәм өмет уятырга тиеш. Әбүзәр Таһиров образына бәя артист Любимов фикерләре аша аеруча калку итеп бирелә. «Әбүзәр Гәрәевич кебек кешеләр,— ди ул,— тормыштан бер эзсез генә югалмый, җирдә аларның җуелмас эзләре кала, алар җисмән бетсәләр дә, эшләгән эшләре, күрсәткән батырлыклары, рухи гүзәллекләре белән башкалар күңеленә күчәләр һәм алар белән бергә яшәүләрен дәвам иттерәләр» (513 бит).

Врачның авыруны терелтү өчен куйган тырышлыгын язучы тауны терәтеп торган каен образы белән чагыштыра. «Алан артында текә тау... Шул текә тауга озак карап торсаң, ул агып килә сыман тоела, әйтерсең шарлама кебек югарыдан ишелеп төшә... Тик аланның тауга барып терәлгән читендә берднәнбер киртә бар: бер төптән биш тармаклы каен үсеп чыккан. Менә шушы каен шуып килгән мәһабәт тауны терәп туктаткан кебек» (409 бит). Тау дигәне кешеләр өстенә ишелеп килә торган чир, ак каеннар — медицина эшчеләре.

«Ак чәчәкләр» романында авырулар галәме, врачлар хезмәте турында сөйләнә. Әмма авторны дәвалау процессы үзе түгел, бу мәсьәләнең әхлакый ягы кызыксындыра. Әйтик, ышаныч, идеяләр кешенең үз-үзен тотышында нинди роль уйный? Ни өчен тормыштагы бер үк шартларда кешеләр үзләрен төрлечә тоталар?..

Геройлар хикәяләүгә үз тормышларының шундый моментларында килеп керәләр ки, без аларның төп характер сыйфатларын да, шәхси язмышларын да кинәт күреп, аңлап алабыз. Асияны алыйк. Ул яшь кыз, аңа нибары унтугыз тулган. Менә шул яшь кыз, озак еллар больницадан больницага йөри торгач, өметсезлеккә бирелгән, ышанычын югалткан. Дөрес, аның әле кечкенә генә өмете калган, атаклы терапевт Таһировка күренәсе бар. Ул ни әйтер?..

Профессорга күренер алдыннан Асия янына йөргән егете Илдар килә. Кыз авыру икәнлеген яшереп йөргән була. Хәзер инде, сәламәтләнә алуына ышанычы беткәч, Асия аңа дөресен әйтә. Илдар үзе дә врач, комбинированный порок белән авырган кешене нәрсә көткәнен яхшы аңлый. Әйе, авыр, өметсез була кызның хәлләре.

Асия приемга килгәндә, Таһировның да кәефсез чагы була. (Дөнья мәшәкатьләре күпме, җитмәсә, һәртөрле Тютеевлар, Саматовлар канга тоз сала.) Ләкин бу аңа авыруга карата игътибарлы һәм ягымлы булырга комачауламый. Әбүзәр Таһиров башкалар хакына шәхси кайгыларын оныта торган юмарт табигатьле, киң күңелле кеше. Аның өчен иң мөһиме — авыру белән дөрес мөгамәләдә булу, аның ышанычын яулау. Шуннан соң гына ул бик уйланып диагноз куя, дәвалау юлларын билгели. Әбүзәр Таһиров кебек игътибарлы һәм сизгер җанлы врачка туры килмәсә, Асия бәлки савыга да алмас иде. Әбүзәр абзый гади врач кына түгел, кылган эшләре, инанулары буенча ул чын коммунист. Әгәр менә шушы саф күңелле, искиткеч зур йөрәкле, хезмәт сөючән кеше гомеренең соңгы елларында партиягә керә икән, бу бик табигый күренеш.

«Ак чәчәкләр» романы характерлар тудыру ягыннан Габдрахман Әпсәләмовның осталыгы тагын да камиллеше төшүе, образларның эчке дөньясына үтеп керү сәләте

тагын да ныгый баруы турында сөйли. Коммунизм җәмгыяте төзүче яңа кешенең җаны да гүзәл, кылган эшләре дә гүзәл, ди автор. Әбүзәр Таһиров — шундый кешеләрнең берсе.

Әмма совет кешеләрендәге матур якларны, уңай башлангычны тасвирларга омтылу тормыштагы кимчелекле, тискәре якларны күрми, дәшми калырга чакыру дигән сүз түгел. Кешеләр аңындагы шәхси милекчелек калдыклары безнең тормышта торган саен кечәя, тирәнәя барган алдынгы кешеләр белән каршылыкка керәләр. Ләкин искелек тарафдарларын фаш итү, кайберәүләр уйлаганча, җиңел эш түгел. Профессор Яңгура да чын йөзен озак вакытлар яшереп килә. Автор аның һәр адымын күзәтеп бара, бер генә хәрәкәтен дә күздән ычкындырмаска тырыша. Яңгураның асылын билгели торган төп сыйфатлар — эгоистлык, коры исәп. Яңгура кебек кешеләргә акыл, талант, үз-үзеңне тота белү җәмәгатьчелектә яхшы фикер тудыру өчен генә кирәк. Икейөзлелекләре, хәйләкәрлекләре аларга асыл табигатьләрен яшерергә булыша. Шуңа да җәмгыять өчен куркыныч кешеләр алар. Менә Яңгура эшли торган клиникага бары ашыгыч операция юлы белән генә коткарып калырга мөмкин булган бер авыру китерәләр. Консилиумга җыелган врачларга Яңгура бу хәбәрне җиткерә, ә үзе иптәшләре аның тәкъдимен кире каксалар иде дип көтә. Авыруның хәле бик начар, операциянең уңышлы чыгуына өмет чамалы. Яңгура мондый тәвәккәллек сорый торган эшләрдән читтәрәк калуны яхшы саный. Шунда профессор Таһиров аның карталарын бутап ташлый. Гомумән, дөньяда Әбүзәр Таһировлар яшәмәсә, Яңгура эшли торган клиникада Мансур булмаса, Яңгура янына беләгенә кызыл тасма бәйләгән кеше килеп чыкмаса, тагын байтак вакытлар аның кемлеген белми йөрерләр иде әле.

Яңгура — үз ягын гына кайгыртa торган кеше. Аның эче бозыклык, хәсетлек белән тулы. Дусларны да ул ифрат тар максатлардан чыгып сайлый. Кирәк чакта, файдасы тиярдәй күренгәндә, Саматовны үз канаты астына ала. Инде тегесе гаепләнеп, кеше арасында яман аты чыккач, Яңгура аны бар дип тә белми. Ярдәм кулы сузу турында әйткән дә юк инде, ул аны хәтта куып чыгара. Ә бит тышкы кыяфәтенә, тасма теләнә һәм үз-үзен тотышына карап, аны юньле кеше дип тә уйларга мөмкин. Аның Әбүзәр абзый клиникасында яки Таһировлар өендә ничаклы әдәпле булып кылануына игътибар итегез. Изге бер фәрештә дип белерсең. Хәтта Мансур турында гына уйланып утырган Гөлшәһидәдә дә ул уңай фикер уята.

Тора-бара Яңгураның тагын бер начар гадәте ачыла. Ул ифрат дәрәҗәдә даншөһрәт сөюче кеше булып чыга. Үзе өчен файдалы, аның дәрәҗәсен күтәрә торган эш булса, Яңгура аңа теләп алына, кыюлык һәм тәвәккәллек күрсәтә белә. Инде дәрәҗәсенә зыян килерлек булса, ул куркак һәм сүлпән бер кешегә әйләнә. Алай гына да түгел, алдашу юлына баса.

Яңгура эшли торган клиникага зур бер белгечне салалар. Хәле бик авыр, коткарсаң, ашыгыч операция ясау юлы белән генә коткарып калырга мөмкин. Ә операция ничек узар? Моны шулай ук алдан әйтеп булмый. Яңгура боларның һәммәсен аңлый. Ләкин консилиум барышында бу хакта дәшми кала. Җитмәсә, төрле сәбәпләр табып, операцияне һаман суза, кичектерә килә.

Үз мәнфәгатен генә кайгыртып яшәүче мондый типларның берсе белән без Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романында ук очрашкан идек. Ул — Хәсән Мортазин. Бу җәһәттән карaганда, Яңгура Мортазинның дәвамы һәм варисы булып тора. Сәнгатьчә эшләнеше ягыннан исә ул — Г. Әпсәләмов иҗатындагы иң уңышлы образларның берсе.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, ул үзенә кирәксез кешеләрне чүпкә дә санамый. Авыру хатын Дилбәр Сәлимова, операциягә керер алдыннан, ире һәм балалары белән очрашырга рөхсәт сорый. Яңгура рөхсәт бирми. Моңа хәтере калган Дилбәр операциядән баш тарта. Шул чагында инде Яңгура авыруны больницадан куып чыгаруга кадәр барып җитә. Мансур ярдәм кулы сузмаса, ихтимал, куган да булыр иде. Мансур тәвәккәл адымга бара — Дилбәр Сәлимовага операция ясарга риза була. Ахыры ни белән бетәрен дә, Яңгура белән конфликтка керәчәген дә уйлап тормый. Авыру операция өстәлендә үлә. Мансур гаебе белән түгел, билгеле. Шулай да ул бу хәлне гаять авыр кичерә. Юк, ул хезмәт урыным югала яисә авторитетым төшә дип тә кайгырмый. Ул авыру хатынның ышанычын аклый алмавына үкенә.

Романдагы төп конфликт тормышны, яшәү мәгънәсен ике төрле аңлый торган кешеләр арасында бара. Бер якта Әбүзәр һәм Мансур Таһировлар, Гөлшәһидә һәм Маһирә ханымнар, икенче якта — Яңгура һәм Саматовлар.

Яңгура күпмедер дәрәҗәдә А. Расихның «Ике буйдак» романындагы Заһид Сафичны хәтерләтә. Яңгура кебек үк, Заһид та иң элек үз мәнфәгате, шәхси карьера өчен яши торган кеше. Яңгура кебек үк, ул да үз хезмәтенең нәтиҗәсе, халыкка никадәр кирәк, файдалы булуы белән кызыксынып тормый. Аңа, барыннан да бигрәк, гадәтләнгән тыныч тормыш булсын. Галим буларак, Заһид фән белән тормыш арасында бәйләнешләр йомшаграк булган елларда формалаша. Бер заман фәнне практик тормышка якынайту мәсьәләсе көн тәртибенә куела, Заһид Сафич моңа хәзерлексез кеше булып чыга. Болай ул эрудицияле галим, студентлар аның лекцияләрен яратып тыңлыйлар. «Ак чәчәкләр» романындагы кебек үк, Заһид белән Рәхим арасындагы бәрелеш төрле әхлаклы, төрле карашлы галимнәрнең конфликты ул. Шуларның үзара көрәшен тасвирлау аша автор социалистик җәмгыятьнең алга таба үсешен күрсәтә. Рәхим алдында торган киртәләрне, кыенлыкларны сурәтләп, А. Расих тормышгагы яңалыкның ни рәвешле үзенә юл яруын раслый. Икеләнеп һәм шикләнеп, үз юлларының дөреслегенә ышанмый яшәүче Заһидлар, замана барышына иярә алмыйча, тормыштан төшеп калалар. Алар «Ике буйдак»тагы Рәхим, «Ак чәчәкләр»дәге Мансур кебек кыю һәм тәвәккәл яшьләргә юл бирергә мәҗбүрләр. Тик шунысы бар, Заһид тибындагы кешеләр кызганыч булса, Яңгура кебекләрә куркыныч та әле.

Мәхәббәт темасы Г. Әпсәләмовның бөтен әсәрләрендә диярлек күтәрелә, әмма «Ак чәчәкләр»дә аңа аеруча зур игътибар бирелгән. Язучы бер төрле мәхәббәтне яклый, икенчесен кире кага, шулар белән үзенең дөньяга мөнәсәбәтен билдерә, укучыны уйландыра, аңардан да шул мәсьәләләр турында фикер йөрттерә. Язучы укучыны мәхәббәтнең кадерен белергә өйрәтә, аның зур, матур хис икәнен, тормышка ямь һәм бәхет бирүен әйтә.

Гөлшәһидә Мансурны ярата. Аның Мансурга булган мәхәббәт хисләре шул хәтле көчле, күпме генә тырышып караса да, ул аны оныта да, ташлый да алмый. Мансур кайткан дигән хәбәрне ишетүе була, беркайчан да бармам дип ант иткәне булса да, ул тагын яшьлек хатирәләре белән бәйле истәлекле урыннарга килеп чыга. Казанканың текә ярлы урынына килеп басуга аның сулышы ешая, йөрәге сулкылдап тибәргә тотына, күзләре елтырый башлый. Күз ачып йомган бер мизгел вакыт эчендә күңеленнән моннан дүрт ел элек булган хәлләр үтеп китә...

Гөлшәһидәнең күңелендә киеренке көрәш бара, аек акыл: «Оныт аны, ул барыбер сиңа булмас», ди. Ләкин хисләре башкача сөйли һәм аның уйлары тагын Мансурга әйләнеп кайта. Билгесезлек аның кәефенә дә тәэсир итми калмый. Гөлшәһидәнең кәефе гел үзгәреп, алмашынып тора.

Шулай итеп, Гөлшәһидәне Мансур белән очраштырганга кадәр үк, язучы безне аның тирән итеп, зур итеп ярата белә торган кеше булуына ышандыра. Дөньяда мәхәббәт хисеннән дә көчлерәк хис юктыр, мөгаен. Гөлшәһидә Илмирадан көнләшми булдыра алмый, чөнки Мансурны аннан шул кыз тартып алды. Ләкин Гөлшәһидә Илмирага карата да күңелендә ачу сакламый. Беркатлы Фатихәттәйнең:

— Аерылышканнардыр әле, күңелем шулай сизә,— дип әйтеп ташлавы була, Гөлшәһидәнең күзенә яшь тыгыла. Кемдер бик тә, бик тә кызганыч булып тоела аңа. Тик кем: үземе, Әбүзәр абзый белән Мәдинә апамы, Мансурмы яки тагын берәрсеме? «Аерылышканнардыр әле»... Әй, бу Фатихәттәйнең теле! Ни дип әйтә инде ул бу сүзләрне? Гөлшәһидәне юатыр, өметләндерер өченме? Юк инде, Фатихәттәй аны андый вөҗдансыз кеше дип уйламасын...

Илмира үлгәннән соң да бер ел вакыт уза. Мансурның йөрәк ярасы һаман төзәлми. Игътибарлы, сак күңелле Гөлшәһидә моны сизми калмый. Үзе исән булмаса да, Илмира һаман Мансурның йөрәк түрендә икән әле. Гөлшәһидәнең Мансур белән бәйле кичерешләренә үтеп кереп, язучы кеше күңеленең иң нечкә тибрәлешләрен күрсәтә алган.

Гөлшәһидә дүрт ел буе гел Мансурны уйлап яши. Тик Мансур аңа карата һаман да битараф, салкын кала. Күпме түзәргә була бу хәлгә?!. Әнә шул көннәрдә Гөлшәһидә күзенә ифрат игътибарлы һәм тәкәллефле Яңгура чалына. Ул Яңгура белән мавыгып киткәндәй була. Шунда ук автор героиняның үткән тормышына экскурс ясый,

Акъяр, анда бер агрономга кияүгә чыгуы искә төшерелә. Моның белән автор, гүя ки, Яңгура белән мавыгу аның Мансурга булган хисләрен сүндерә алмаячак, дип әйтергә тели. Вакыйга барышы нәкъ шуны раслый, Яңгура, Гөлшәһидә һәм Мансур театрда очрашалар. Гөлшәһидә Мансурдагы үзгәрешләрне шундук абайлап ала. Төс-кыяфәте кәрәйгән. Чигәләрендәге ак чәчләре хәтта сирәгәйгән сыман. Бу аңлашыла да. Ул төньяктан кайтканнан бирле байтак гомер узды. Төзәлмәс яра, онытылмас кайгы булмый, диләр. Әлеге көтелмәгән очрашу тагын Гөлшәһидәнең күңел яраларын кузгатып җибәрә. Юк икән, онытып булмый икән, күңел түрендә һаман Мансур икән. Никадәр генә игътибарлы, эрудицияле һәм тапкыр сүзле булмасын, Яңгура Мансурны оныттыра алырлык кеше түгел икән шул.

Гөлшәһидә Акъярга китәр алдыннан, Әбүзәр абзыйсы телефон буенча аны үзләренә кунакка чакыра. Гөлшәһидә, мең рәхмәтләр әйтеп, баш тартып карасә да, Әбүзәр абый «үпкәлибез» дигәч, барырга була. Телефон трубкасын куеп, ул үз бүлмәсенә әйләнеп керә. Яңа үтүкләнгән җылы күлмәген өстенә кигәч, Гөлшәһидә көзге алдына килеп баса. Ябыккан, күзләре зурайган, йөзе дә суырылган. Умрау сөяге дә беленә башлаган. Киенеп юлга чыккач, тагын икеләнә башлый. Ник бара ул? Картларга хөрмәт йөзеннән генәме? Әйе, фәкать шулай гына! Башка берни дә, берни дә юк. Әмма Таһировларның таныш парадныена килеп керүе була, йөрәге тагын сулкылдап тибәргә тотына. Парадныйда аны кулларына шәмсез шәмдәлләр тоткан канатлы фәрештәләр каршы ала. Бүтән вакытларда да шул фәрештәләрнең кулларына яна торган шәм тоттырасы килә Гөлшәһидәнең, бүген ул теләге аеруча көчле була. Күрәсең, күңелнең кайсыдыр почмагында өмет уты сүнмәгән әле.

Әбүзәр абзыйлар йортында аны бик җылы каршылыйлар. Тик Гөлшәһидә генә үзен энә өстендә утыргандай сизә. Өйдә телефон шалтырый. Фатихәттәй кире әйләнеп керә дә:

— Сине,— ди Мансурга.

Аның коры тавышы Гөлшәһидәне Мансурга борылып карарга мәҗбүр итә. Ә Мансурның уңайсызланып китүеннән аны хатын-кыз чакыруын аңлап ала. Гөлшәһидә, бугазына килеп төелгән дулкынны сиздермәс өчен, пальма артынарак яшеренә. Казаннан ул Таһировларга башка килмәм, Мансур белән бүтән беркайчан да очрашмам, дип китә. Акъярга кайтып эшли башлауга, яңадан хисләре кайнарга тотына. Күпме тырышса да, оныта алмый ул Мансурны.

Гөлшәһидәне партия өлкә конференциясенә делегат итеп сайлыйлар, ул яңадан Казанга килә. Акъярда ничектер йомылыбрак торган сагынулары тагын уяна һәм Гөлшәһидә янә бер тапкыр Мансурны оныта алмавын, аңардан башка яши алмаячагын аңлый. Ул зарыгып Мансурны көтә. Аның Казанга килүенә берничә көн үтә, газеталарда аның рәсемнәре чыга, радиодан да аның турында сөйлиләр. Боларны Мансур бер ишетмәсә дә, бер ишетергә тиеш ләбаса. Димәк, Мансур аны көтми, димәк, Гөлшәһидә аңа бөтенләй кирәкми.

Совет кешесенең рухи дөньясы никадәр матур булуын күрсәтү нияте белән, язучы Гөлшәһидәнең эчке дөньясын бик җентекләп тасвирлый. Романның бу ягы ышандыра. Инде Гөлшәһидәнең җәмәгать эшлеклесе буларак башкарган хезмәтләрен автор күбрәк санап кына чыга. Бу, билгеле күләмдә, образны ярлыландыра, түбәнәйтә.

Тормыштагы иң яхшы кешеләрне күрсәтергә, совет кешеләренең әхлакый матурлыгын расларга омтылу теләге романда кулланылган типиклаштыру алымнарына да үз эзен салган. «Ак чәчәкләр» романы романтик характердагы әсәрләргә тартым. Бу, барыннан да бигрәк, профессор Таһиров һәм Гөлшәһидә образларына карый.

Гомумән алганда, Г. Әпсәләмовның иҗат почеркы «Сүнмәс утлар» романындагыча калган. Тик лирик агым көчәя төшкән. Геройларны тел ягыннан һәм психологик яктан характерлау осталыгы үскән. Аның элеккерәк әсәрләрендә икенче дәрәҗәдәге персонажлар еш кына күләгәдә калып килә торган иде. Бу романда андый персонажлар да тулы канлы һәм ышандырырлык булып чыкканнар. Мәдинә ханым, Асия, Фатихәттәй, Николай Максимович кебек образлар, болай вакыйгаларның үзәгендә тормасалар да, тормышчан итеп, яратып эшләнгәннәр.

«Сүнмәс утлар» һәм «Ак чәчәкләр» романнары образ иҗат итүдә авторның осталыгы тагын да үсә, камилләшә төшүен сөйли. Үзенең бу әсәрләрендә Г. Әпсәләмов,

вакыйгаларның тышкы калыбын сөйләүдән качып, игътибарын геройларның психологиясенә, эчке дөньяларын ачуга юнәлтә. Бу әсәрләрдә конфликтлар дөньяга каршы карый торган кешеләрнең үзара бәрелешеннән килеп чыга. «Алтын йолдыз» белән чагыштырганда, «Газинур» бер адым алга китү иде. Бу әсәрдә язучы гади авыл егетенең поэтик образын тудыра, аның батырлыкка килү юлын ышандырырлык итеп сурәтли алган иде. Биредә авторның игътибар үзәгендә бер герой, әсәрнең бөтен агышы Газинур образын ачуга буйсындырылган. «Сүнмәс утлар» романында инде ике төп герой. Романның төп конфликты шуларның үзара бәрелешеннән килеп чыга. Әсәрдәге сюжет-композиция, образлар системасы әлеге ике образны ачуга хезмәт итә. «Ак чәчәкләр»дә шулай ук ике төп герой: Әбүзәр Таһиров һәм Яңгура. Тик бу романнарның архитектоник төзелешендә аерма да бар. «Сүнмәс утлар»да бер генә төп линия, калган линияләрнең һәммәсе үзәк линиягә буйсындырылган. Ә «Ак чәчәкләр»дә исә Гөлшәһидәнең Мансурга булган мәхәббәте турындагы яки Гөлшәһидә белән Яңгура арасындагы мөнәсәбәтләргә багышланган бүлекләр, болай романдагы төп образларны ачарга булышсалар да, үзбаш, мөстәкыйль әһәмияткә дә ияләр.

Типик характер аны тудырган җирлекнең төп сыйфат һәм үзенчәлекләрен дә үзендә туплаган була. Сөләйман һәм Иштуган Уразматов, Гөлшәһидә һәм Әбүзәр Таһиров образларында язучы алдынгы, коммунистик моральнен кешенең табигатенә, аның үз-үзен тотышына никадәр көчле йогынты ясавын раслый. Үз әсәрләрендә ул әхлак ягыннан үрнәк булырлык кеше характерлары бирә. Шуның белән бергә, Хәсән Мортазин, Яңгура образлары аша кешеләр аңындагы шәхси милекчелек, индивидуализм чире калдыкларын тәнкыйть итте.

Габдрахман Әпсәләмов иҗаты коммунистик тәгълимат белән коралланган совет язучысы алдында чикләнмәгән мөмкинлекләр ачылуы турында сөйли.

## Әдип Маликов

# УТТА ЧЫНЫККАН ДУСЛЫК

1947 елның көзе иде. Казандагы Матбугат йортының борылмалы баскычларыннан, шау-гөр килеп, бер төркем яшьләр күтәрелә. Бик яшь дип тә булмый аларны. Берәүләре Иделдән Берлинга кадәр җиңү юлы үткән, икенчеләре сугышны Тын океанда тәмамлаган. Әле күбесе хәрби киемен дә салмаган, иңбашларында — погон эзе. Әле күңелдәге һәм тәндәге җәрәхәтләр дә җөйләнеп өлгермәгән...

Төркем уртасында, авыр гәүдәсен чайкалдырып, без дәреслекләр буенча белгән «тере язучы» Кави ага Нәҗми атлый. Ул, борылма саен диярлек туктап, йөрәгенә ял бирә-бирә, нинди дә мәзәк сөйләп ала. Егетләр фронт «парын» өстәп җибәрәләр. Арада иң озын буйлысы, дала егетенә охшаганы, җор сүзгә аеруча оста булып чыкты. Өлкән язучыбыз аны тыңлаганда, битендәге һәр шадрасын балкытып, елмаеп куя иде.

Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче яшь язучылар сугыштан соң беренче мәртәбә семинар-киңәшмәгә җыела иде.

Татар әдәби теленең үзенчәлеге, байлыгы — халык мирасы турында «Совет әдәбияты» журналы редакторы Кави Нәҗминең мавыктыргыч сүзен тыңладык. Аннан трибунада шигырьләр яңгырады. «Күтәрелештә» исемле яшьләр альманахының беренче сигнальный саны, зал буйлап, кулдан-кулга йөрде.

— Яшь шагыйрь Зәки Нуриига сүз бирелә,— дип белдерделәр.

Баскычтан күтәрелгәндә без игътибар иткән озын буйлы егет сузылып сәхнәгә чыкты. Шундый да чая, кыю булып күренгән егетебез халык алдында каушап калгандай булды, сәер генә елмаеп куйды. Кулында шырпы тартмасы зурлыгында гына блокнот...

Нинди шигырьләр укыгандыр ул, хәзер атап кына әйтүе кыен. Әмма ике юлы хәтердә калган:

> Мине бүген бомба шартлап түгел,
> Сандугачлар сайрап уятты...

Еллар узу белән битләре саргая төшкән «Күтәрелештә» альманахын кулыма алгач, мин бу юлларның кайсы шигырьдән икәнен белдем: «Тәрәзә янында» икән.

> Тәрәзәмне ниләп ачтым. Күрәм:
> Таныш урман, таныш күл, әнә.
> Нинди рәхәт, җәйнең җиле керә
> Блиндажга түгел, бүлмәмә.

Туган ягын сагынып кайткан сугышчының самими хисләре гади генә итеп шигырьгә салынган. Шаккатыргыч бизәкләр дә юк, шулай да тойгыларны берьюлы кузгатып җибәрә. Сәнгать дәреслеге бар.

Бомба шартлавы... һәм сандугач сайравы... Капма-каршы ике төшенчә. Ничәмә еллар утлы күкрәү эчендә йөргән совет солдаты сандугач сайравын үтә дә сизгер тоя. Чөнки ул туган ягының сандугачлы таңнарын уйлап йөргән, шуларны яклап сугышка кергән.

Тойгыларының чынлыгы, сугыш мәктәбе Зәки Нури шигырьләрен әнә шулай беренче көннәреннән үк халыкка якын һәм кирәкле итте.

1921 елның 24 декабрендә Татарстанның Чүпрәле районы Татар Төкесе авылында туып-үскән, Лубян урман техникумында укыган Зәки Нури Бөек Ватан сугышын Польша чигендә каршылый, фашист Германиясенең тәреле танкларына беренчеләрдән булып үлем яудыра. Блокнотында — беренче солдат шигырьләре:

**Мин бу яуда, бәлки, күп йөрермен,**
**Белмим, бәлки, пуля эләгер...**
**Ярам ун булса да,**
**тик үлемне**
**Кабул итмәс кебек йөрәгем.**

Чигенү газапларын да беренче булып татыган яшь шагыйрьнең тавышы торган саен кырыслана бара:

**Ачы булса, кайнар булса,**
**Кабергә һич кумелмәс үч.**
**Ярсып торса, ташып торса,**
**Уттан куркып чигенмәс көч! —**

ди ул, хак эшнең җиңәчәгенә ышанып.

Илбасарларга көнен дә, төнен дә тынгы бирмәскә, аларны тылдан торып кырырга — туган илнең әмере шундый. Илдә партизан отрядлары оеша. Зәки Нури Белоруссиянең легендар улы Константин Заслонов җитәкләгән партизаннар берләшмәсендә кала. Фашистларга каршы авыр һәм аяусыз көрәш көннәре башлана. Мылтыкка, хәнҗәргә ярдәмче булып шигырь килә:

**Котырса да берни түгел**
**Давыл һәм кар тузаны.**
**Җиңү — Маяк!**
**Шул сүз күңел**
**Канаты партизанның!**

Партизан булып үткәргән көннәр Зәки Нури иҗатының беренче чорында чын тормыш материалы булдылар. Партизан шигырьләрен автор «Дан юлы» исемле шигырь китабына (1947), хикәя-очеркларын «Үлгәннәр дә үч алды» (1962) исемле проза җыентыгына туплады. Җыентыкларда күккә очкан күперләр, офыкны иңләп күтәрелгән ут шәүләләре бар, әмма шул тышкы күренешләрдә кеше югалмый. Хикәя-очеркларда без коми егете Кырыс, белорус егете Скроба, татарның яшь шагыйре «бух-бух» Андрей, Нева ярларыннан курку белмәс Пашка белән очрашабыз. Кышкы озын кичләрдә, урман эчендәге землянкада грузин Петрашвили «Сулико»сын сузып җибәрә, Мариләнең «Левониха»сы, татарның «Ямьле Агыйдел»е яңгырый. Урал җырга тотынса, Чебоксар кушыла. Гүзәл күренеш булып Совет ватанының интернациональ дуслыгы яши. Шул олы дуслык тойгысы кешеләрне көчле итә, җиңүгә күтәрә, җырга илһам бирә.

Зәки Нури поэзиясенең төп лейтмотивы әнә шунда салына, партизан учаклары янында туган, сугыш утында чыныккан дуслык-туганлык җырларына шагыйрь гомер буе турылыклы булып кала.

Чик буендагы беренче мылтык тавышыннан башлап, җиңү көненә кадәр газаплы, данлы юл кичкән, фашист ерткычлардан бөтен көчен-сәләтен куеп, аяусыз үч алган партизан, разведчик, шагыйрь туган якларын сагынып, Татарстанга кайткач, кайда гына эшләмәсен — яшьләр газетасында редактор урынбасарымы, урман белгечеме, Татарстан китап нәшриятында яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдиреме —

шагыйрь күңелендә сугышта чыныккан дуслык хисен саклый, шул хис аны гел дулкынландырып, иҗатының мәгънәви зурлыгын билгеләп тора. 1951 елда Зәки Нури Сталинград ГЭСын төзүчеләр янына барып чыга һәм, озак та үтми, ул укучыларга «Тәп юнәлештә» исемле очерклар, «Диңгез ясалган якта» дигән шигырь китапларын бүләк итә. Соңга таба шагыйрь Түбән Камадагы химия гигантын төзүчеләргә шулай ук ике китабын багышлый: «Матурлар һәм батырлар» (очерклар), «Горур гүзәл» (шигырьләр).

«Горур гүзәл» җыентыгын автор «Кама турындагы симфониягә кечкенә бер кереш» дип атый. Ә «симфониянең үзен... төзүчеләр иҗат итә». Автор төзүчеләр белән йөрәген ачып, күзгә-күз карап сөйләшә, уйнап-көлеп кенә тәнкыйть сүзләре дә әйтә, өй түйлары өчен табын җырларын да онытмый. «Өй туе» дигән озын шигырьдә төрле милләт кешеләренең үзенчәлекле, тапкыр җырлары оста тотып алынган. Бу — шулай ук дуслык темасының яңа шартларда дәвам итүе. Гореф-гадәтләре төрле булса да, алар зур бер семья булып, яңа тормыш нигезен коралар. Җор күңелле лирик герой үзе дә уен-көлкедән, биюдән, җырдан читтә калмый.

Шагыйрь эзләре буйлап йөри торгач, без шомлы Белоруссия урманнарыннан Шишкин урманнары шаулаган Кама буйларына килеп чыгабыз. Биредә, әкияттәге сыман, гүзәл кала туа. Җырчы хыялында тиздән сафка басачак ГЭСның утлары балкып кабына.

**Биек итеп буа будык,**
**Кама зур эшкә җигелде.**
**Ул диңгез булып җәелде,**
**Ул утлар булып сибелде.**
**Чигенде җилләр, бураннар:**
**«Бирешмәсләр, чыдам болар...»**
**Шәһәрне гүя краннар**
**Җирдән тартып чыгардылар.**

Кешеләрне ныграк яраткан саен, аларны кимчелекләрдән ничек тә тизрәк арындырасы һәм тагын да әйбәтрәк итеп күрәсе килә. Зәки Нури шигырьләрендәге шаянтөртмә юлларны укучы көлә-көлә «мыегына чорный». «Чабу астыннан ут йөртүче» икейөзле аумакайларга, дуслыкны карьера ясау өчен бер баскыч дип санаучы «алыш-бирешче»ләргә карата шагыйрьдән мәрхәмәт тә, шәфкать тә көтмә. Чөнки ул, үлем күзенә туры караган солдат буларак, чын дуслыкның бәясен яхшы белә.

Зәки Нури иҗаты, тормышның үзе шикелле, күп тармаклы. Очерк, поэма, лирик шигырь, юмор-сатира һәм мәсәлләреннән тыш, без аның композиторлар көй язган популяр җырларын да, публицистик ялкын бәреп торган мәкаләләрен дә беләбез. Шагыйрьнең күңеле балалар өчен дә юмарт. Ул аларга сәхнә шигырьләре, хезмәткә, табигатькә өндәгән җырлар, ял мәзәкләре, табышмаклар бүләк итә. Автор, үзе бик кысылмыйча гына, балаларны мәктәпкә я походка озатып йөри, дөньяның ямен күбрәк күрсеннәр өчен аларны кулына күтәрә. Зәки Нури балалар дөньясын нечкә тоя, әйбәт белә.

Зәки Нури иҗаты күп тармаклы дидек. Күп тармаклы зур агач яшәү көчен каян ала соң? Туган җиргә тирән үтеп кергән дуслык тамырлары аша ала.

**Ялган хисләр калсын бер читтә,**
**Чын дуслыкны зурлап, җыр, яшә!**
**Чәчәкләр дә әнә букетта,**
**Берсен берсе белеп берләшә.**

Халыклар дуслыгына, бердәмлеккә чакыру мотивы шагыйрь иҗатында, байрак төсе булып, ялкынланып бара.

**Без танышлар түгел...**
**Ләкин җирдә**
**Таныш итәр безне берләшү.**
**Кушылып акса суның бетми көче,**
**Зур елгада кипми бер дә су.**

«Без танышлар түгел» дигән хат-поэманың үзәгенә шушы идея салынган. Казанда яшәүче Гөлсем үзе шикелле сугышта ирен җуйган немец хатынына хат аша йөрәгендәге зур хисләрен белдерә. Сугышның беренче көннәре, җан әрнеткеч минутлар берәм-берәм аның күз алдыннан үтәләр:

**Кубекләнә, кайный, ташый елга,—**
**Әйтерсең лә суны яр кыса.**
**Кара-каршы килеп ике дөнья**
**Шул кечкенә ярда тартыша.**

Чик буенда хезмәт итүче ире янына кунакка барган, карынында бала йөрткән яшь хатын сугышның беренче көнен чик сакчылары окобында каршылый. Аның окобы өстеннән, кояшны каплап, немец танкысы үтеп китә. Гөлсемнең күз алдында фашист солдатлары яралы пограничникны тереләй җиргә күмәләр, икенчесен яр читенә сөйрәп китерәләр... Кечкенә окопта, зур илен үлемнән аралап, пистолет күтәрә Гөлсем.

Боннда яшәүче немец хатыны шул чагында нәрсә белән шөгыльләнде икән? Бәлки ул ашыга-ашыга снарядка дары тутыргандыр? Яралы пограничникны тереләй җиргә күмеп куючы бәлки аның ире булгандыр?..

Әмма гел нәфрәт белән генә яшәп, яхшыга ирешеп булмый. Кешелекнең якты, тыныч киләчәге хакына үч һәм нәфрәт аша да атлап чыгарга мөмкин. Моны, Гөлсем шикелле, совет чынбарлыгында тәрбияләнгән җылы җанлы, гуманист хатын-кызлар эшли ала. Гөлсемнең дә, Боннда яшәүче немец хатынының да уллары үсә. Алар хат алышалар.

Гөлсем бу хатны улы Азаты — бердәнбере хакына, фестивальдә табышкан дуслык, киләчәк хакына яза. Байгышларча хискә бирелү яки коры үгет-нәсихәт кенә түгел бу. Тарихның онытылмаслык ачы тәҗрибәсе — хәтер дигән нәрсә бар. Хәтер ник кисәтә, Гөлсем хәтере кисәтә моны:

**Уттан тагын курмик дисәң газап,**
**Утка каршы корал ала бел!**

Хәтер бердәмлеккә чакыра:

**Бердәм булып аяк басса халык,**
**Тетрәтергә мөмкин җирне дә!**

Зәки Нуриның моннан унбиш ел элек иҗат иткән «Без танышлар түгел» поэмасы бүгенге көнгә бик аваздаш. Кайнар вакыйгалар фонында аның актуальлеге тагын да ачыграк күренә.

Шагыйрь «Мин яшим тынычлык илендә» исемле шигырендә үз ватанының зур миссиясе — дуслык, тынычлык миссиясе турында образлы итеп әйтә:

**Иделдә, тулып хуш исләргә,**
**Чәчәккә күмелсә бакчалар,**
**Беләбез, бу исне иснәргә**
**Дунайда тәрәзә ачалар.**

Зәки Нури иҗатындагы интернациональ дуслык темасы Ленин темасы белән бергә органик төстә үрелеп бара. Чөнки:

**Ленин сызган барчабызның офыгын**
**Уч төбендә кояш тоткан кул белән.**
**Җитеп була аңа бары көрәштә**
**һәм хезмәттә җиңеп узган юл белән.**

Шагыйрь, кешелек даһие йөргән эзләр буйлап, илебезнең күп кенә өлкәләрендә була, Себердәге Шушенское авылына, Польша шәһәрләренә барып чыга. «Озын сүзнең кыскасы» исемле җыентыкка кергән «Офык», «Җыр белән очрашу», «Шушь елгасы буенда», «Тауларга менү», «Диңгез күзе» кебек Совет ленинианасына лаеклы өлеш кертердәй шигырьләре — шул сәяхәт җимешләре.

Тынгысыз юлаучы Себердәге Шушь елгасы буеннан, «Россиянең үткән көне белән киләчәге... кушылган» урыннан киң Иделгә, Казандагы Ленин һәйкәле басып торган Ирек мәйданына кайнар сәлам алып кайта. Ильич гүя «обком йортыннан чыккан мәлгә бер минутка тынып калган»:

> **Килә цехлар, килә кырлар монда,**
> **Яшь химиклар килә Камадан.**
> **Отчет белән килә чорлар монда...**

Шагыйрь кайларга гына барып чыкмасын, аны зур бер тойгы — Ленин төзегән совет Татарстанына — туган җиргә булган мәхәббәт хисе озатып йөри:

> **Җирне кошлар ике якка бүлә:**
> **Берсе җылы, берсе салкын як.**
> **Ә уйлары нәкъ безнеке кебек:**
> **Тик туган як җирдә — алтын як.**
>
> **Маяк булып, Кояш, күтәрел син,**
> **Тарал юлда тизрәк, күк таман!**
> **...Тезелгәннәр кошлар**
> **...җылы якны**
> **Салкын якка теккән җеп сыман.**

«Вислада су кергәндә» дигән шигырендә бу хис аеруча конкрет төс ала:

> **Сез якыннар җанга, елга-күлләр,**
> **һәр кайда да рәхәт сез тәнгә.**
> **Әмма кочам Идел дулкыннарын,**
> **Нинди генә суда йөзсәм дә.**

Белоруссия урманнарындагы партизан учаклары инде күптән сүнгән. Ләкин ветераннар күңелендә аларның яктысы калган. Дошман өстенә һөҗүмгә барганда тәрҗемәче кирәк булмагандыр. Тынычлык теле болай да аңлашыла. Мәхәббәт һәм нәфрәтне йөрәк тәрҗемәчесез дә бик тиз тоя. Әмма шигырь, ни әйтсәң дә, музыка түгел. Ул икенче телгә тәрҗемә итүне сорый. Зәки Нури бергәләп разведкага йөргән партизан дуслары — курку белмәс Пашкалар, Талашлар белән бүген дә элемтәсен өзми. Ул аларның үзләре, балалары һәм туганнары белән шигъри тәрҗемәләре аша төрле телләрдә сөйләшә, гүя ил буйлап перекличка ясый. Аның үз шигырьләре социалистик илләрдә — немецчә, румынча, венгрчә, полякча да тәрҗемә итеп чыгарылды. Мәскәү нәшриятларында исә шагыйрьнең уңлап җыентыгы дөнья күрде.

Шулай итеп, шагыйрь партизан шигырьләрендә үк җырлый башлаган дуслык хисе, туганлык тойгысы аның үз иҗатын да дусларына илтеп җиткерде.

## Аяз Гыйләҗев

# АК НУР БЕЛӘН...

Театрның тамаша залы.

Халык шыгрым тулы. Биш йөз кеше, алты йөз... Мең кеше! Кемнәр генә очрамый алар арасында? Кемнәр генә җан азыгы эзләп театр ишеген какмый?!

Юмартлар да килә, саранннар да.

Эшчәннәр дә йөри, ялкаулар да.

Көләчләр дә монда, моңсулар да.

Җитәкчеләр дә, көмәч пешерүчеләр дә.

Нигә киләләр алар? Ни эзлиләр? Ни көтәләр? Тамашамы? Кәмитме? Матур киемнәрен киенеп, тазарынып, чистарынып, сафланып киләләр дә, сәхнә дип атала торган нәни генә мәйданчыкка күз текәп, тынып калалар.

Нәни дидем дә, сагаеп калдым. Нигә нәни булсын ди сәхнә?! Зур ич ул, гаҗәеп зур: шушы мәйданга тормыш бөтен барлыгы белән сыя лабаса! Кешеләр туалар да, үләләр дә анда. Яшиләр, сөяләр, җиңәләр һәм җиңеләләр. Хак юлны эзлиләр, табалар, шуның өчен һәлак булалар.

Шушы, гадәттә өч ягы төрле җиһазлар, декорацияләр белән капланган шанлы-шөһрәтле мәйдан аша кешелекнең бөтен тарихы, хәзергесе һәм киләчәге уза. Ярсып гаскәр башлыклары килеп керәләр, гайрәтле революционерларның көрәш юллары сызыла, гашыйклар һәм мәзәкчеләр, хакимнәр һәм эшчеләр көн күрәләр.

Залда катлаулы һәм каршылыклы тормыш вәкилләре утыра, сәхнәдә дә шулар тормышының чагылышы. Аталарының, бабаларының, үзләренең тормыш күренешләре. Әнә шул, күрер күзгә нәни генә, уйлап карасаң бөтен җир шарын сыйдыра ала торган мәйданда тормышның чагылышын карарга ил сукмагы өзелми, касса аллары, театр фойелары, чишенү бүлмәләре давыллы көндәге күл өсте сыман кайнап, дулкынланып тора.

Тамаша залы көндезләрен буп-буш...

Репетицияләр булмаса, театр тып-тын. Партердагы урыннар ак җәймә белән томаланган. Җыештыручылар да кычкырып сөйләшмиләр. Тынлыкның кадерен һәр кеше саклый. Биредә чын тынлыкның бәһасен беләләр!..

Тамаша залы кичләрен шыгрым тулы.


Тамаша залы кичләрен дә тып-тын кала.

Залда тыгызланып утырган мең кеше, бар дөньясын онытып, сихерләнеп, сәхнәгә йотыла. Уйлый, шатлана, кайгыра, елап җибәрә.

Нинди кодрәт тудыра бу тынлыкны? Нинди көч, сихер мең кешенең йөрәген ике-өч сәгать буе бердәй тибәргә мәҗбүр итә?! Юмартны да, саранны да, эшлекленеэшлексезне, яшьне-картны нәрсә берләштерә!

Режиссерның мәгънәле, оста хәрәкәтләргә корылган спектакле кызыксындырамы? Актерларның уены күңел кылларын шундый киеренкелектә тотамы? Сәхнә рәссамының җанга ятышлы декорацияләре халыкның игътибарын җәлеп итәме?

Катлаулы, бик катлаулы механизм театр! Ул байтак буыннардан тора, чылбырның бар өлешләре бер юнәлештә, бер тында, бер моңда хәрәкәт итәргә тиеш. Шул бер-



дәмлек, бергәлек булганда гына тамашачы сәхнә теленә ышана, аны чын тормышның чагылышы итеп кабул итә. Ә сәхнәдә чын тормышны йөрәккә үтеп керерлек образлар, буяулар, төсмерләр белән чагылдыру өчен режиссердан, актерлардан, рәссамнан һәм сәхнә эшчеләреннән күп нәрсә таләп ителә. Төрле зәвыктагы, төрле яшьтәге, төрле әзерлекле тамашачыны рухи канәгатьләндерү, аңа эстетик тәрбия бирү эше елдан-ел авырлаша, катлаулана бара.

Әлбәттә, спектакльгә рух өрүче, аның агымын билгеләүче, эш дәвамында очраган бусагаларны бер-бер артлы кичеп үтүче, әсәрнең идея-максат юнәлешен тирәнтен ачучы зат — режиссер.

Кәгазь битләрендә, атылмаган патроннар кебек, сибәлеп яткан сүзләргә тылсымлы илаһи хис бирүче кешеләр — артистлар, сәхнә осталары.

Тормышның бер почмагын бары үзенчә генә күрә белеп, шуны саран детальләр аша сәхнәдә гәүдәләндергән кеше — театр художнигы.

Бу өч төркемгә өш кына композиторлар килеп кушыла, спектакль музыка белән баетыла. Менә шушы көчләр берләшеп тамаша залының күңелен яулап алалар, сихерлиләр, тәрбиялиләр, үстерәләр. Һәр кич меңләгән кешене бергә җыеп, авызына каратып тоту өчен күп көч салына, күп тир түгелә, йөрәк мае сыза!

Шулай булганда гына тамашачылар да сәхнәдә бара торган вакыйгаларның катнашучыларына әйләнәләр, андагы геройлар белән бергә яшиләр, җиңеләләр, көрәшәләр, матурлыкны әшәкелектән, хаклыкны хыянәттән аерырга өйрәнәләр. Сәхнәнең тәэсир көче искиткеч зур, аны бернинди сан-исәпләр белән генә үлчәп бетерерлек түгел. Спектакль ике-өч сәгать кенә барса да, аның бәрәкәте, тәэсир көче атна-айларга бара, кайчагында гомер буе онытылмаслык истәлек булып кала.

Мактаулы, чагыштырусыз мактаулы хезмәт театрда иҗат итә алу!.. Режиссерлар, артистлар, театр рәссамнары бездә бөтен халыкның хөрмәтен яулап алып, күз өстендәге каш кебек яшиләр!..

Без монда эшнең нәтиҗәсен, аның ахырын, елганың тамагын күзәттек. Елганың чишмәсе каян чыга? Кайда башлана? Ничек туа?.. Театрның каян башлануы турында байтак акыллы фикерләр әйтелгән. Әмма ничек кенә фикер йөртеп карама, һәр спектакльнең чишмәсе борын төрткән урыны — ул язучы-драматургның күңеле, аның йөрәк тибеше. Язучы күңелендә сәхнә аша халыкка әйтәсе килгән яңа фикер туа. Ул шул фикерен үзе сайлаган образларга йөкли, үзен борчыган мәсьәләләрне, драма, комедия, трагедия формаларына төреп, театрга алып бара. Спектакль, һичшиксез, коллектив хезмәте булса да, әсәр иң әүвәл ялгыз кеше күңелендә туа. Шәхеснең кем булуы, аның талант дәрәҗәсе, язучының гражданлык сыйфатлары әсәрнең тирәнлеген, йөзен билгели.

Әйтик, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт иҗатларының асыл сыйфаты нәрсәдә? Ни

өчен, еллар үтә барган саен, без бу авторларны ныграк аңлыйбыз, ныграк ярата төшәбез?

Моның сере нәрсәдә соң?

Заманында шаулап барган күп пьесалар мәтәлеп төшеп калганда, аерым бер пьесалар мәңгелек дан яулап алалар. Ни өчен алай?

Кәрим Тинчурин да, Таҗи Гыйззәт тә үз чорының, үз халкының намуслы, саф күңелле, талантлы, эшкә бирелгән көрәшчеләре иделәр. Аларның иҗаты халык язмышына нигезләнеп чәчәк атты, алар язган һәр юл, алар әйткән һәр сүз артында халык язмышы торды. Халыкны сөю Тинчурин, Гыйззәтләрнең яшәү мәгънәсе иде. Алар бөтен барлыклары белән халыкка тугрылыклы булып калдылар. Талантларын чүп-чарга баш идермәделәр, көндәлек вак-төякләр стихиясенә бирелеп китмичә, бер көнлек проблемаларның колы булып ансат юл сайламыйча, авыр көрәш юлыннан—хаклык юлыннан бардылар. Шуңа да халык аларны үзенең чын уллары итеп таныды, мәңгегә үз күңеленә алды. «Күңелдән чыккан гына күңелгә керә» дигән сүзнең асыл мәгънәсен К. Тинчурин, Т. Гыйззәтләр мисалында без тагын бер кат ачык итеп күрдек.

Г. Камал, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Т. Гыйззәт хәзерге һәм киләчәк буын драматурглары өчен сүнмәс маяклар булып калдылар. Шушы изге җаннар күңелендә тибеп чыккан саф чишмәләр, бергә берләшеп, давыллы, көчле елгаларга әверелде. Ул елга дулкыннарын безнең бүгенге театрларыбыз Мәскәү, Ленинград, Уфа кебек күренекле шәһәр тамашачыларына да илтеп җиткерделәр.

Татар халкының рухи тормышын «Зәңгәр шәл», «Сүнмәс йолдызлар», «Җилкәнсезләр», «Ташкыннар», «Чаткылар» әсәрләреннән башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Шушы әсәрләр булмаса, безнең әдәбиятыбыз да, димәк, шуңа бәйле рәвештә без үзебез дә ярлыланган, фәкыйрьләнгән булыр идек. Һәм һич шикләнмичә әйтергә мөмкин, халкыбыз яшәгәндә «Галиябану», «Зәңгәр шәл», «Чаткылар», «Хуҗа Насретдин» пьесалары да сәхнәбездән төшмәс, безнең балаларга, оныкларыбызга юлдаш булып, күңелләрне рәхәтләндереп, яктылыкка, матурлыкка өндәп яши бирерләр.

Драматург сәнгатьтә үз урынын дөрес таба алса, шул урыннан торып юлын билгели белсә, шул юлга тугрылыклы булып кала алса, бу — аның бәхете.

Хәзер театрлар белән эзлекле һәм даими эшләп килүче драматурглар арасында гаять кызыклы авторлар бар. Шәриф Хөсәенов, Юныс Әминов, Хәй Вахит, Туфан Миңнуллин. Тукталып, уйлап карасаң, болар бер-берләренә һич охшамаган үзенчәлекле драматурглар. Аларның әсәрләре бер үк театрларда барып, бер үк режиссерлар тарафыннан куелып, бер үк актерлар тарафыннан башкарыла. Ә әсәрләре һәрберсенеке үзенчә, һәрберсенеке яңача. Әгәр исемнәр санаудан уза алмаган театр тәнкыйтьчеләре аларны бер бәйләмдә йөртәләр икән, бу — аларның хаталары. Театр тәнкыйтьчеләре сәнгать тирәсендә буталып йөрүчеләрне дә чын драматурглар белән күп очракта бергә бутап йөртәләр.

Театр өчен бик кадерле шушы кешеләр арасыннан бүген минем Юныс Әминов иҗатына тукталасым килә. Менә егерме ел инде Юныс Әминов театр сөючеләрнең мәхәббәтен казанып килә. Ул шушы егерме ел эчендә театр сәнгатен үстерүгә зур көч салды. Минзәлә, Әлмәт, Республика күчмә театрлары, Яшь тамашачылар театры, Бөгелмә театрларында дистәдән артык пьесасы куелды. Иң яхшы берничә әсәре Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уңыш белән уйналды.

Юныс Әминов игелекле язучы булып чыкты. Эшчән, тырыш драматург булып өлгерде. Аның үсүенә, үз юлын табуына республикабызның күренекле театрларыннан Минзәлә дәүләт театры һәм аның баш режиссеры Сабир ага Өметбаевның роле бик зур булды. «Язылмаган законнар» спектакле Юныс Әминовка киң юл ачты.

Юныс Әминовның драматург буларак үзенчәлеге нәрсәдә соң? Моңа кадәр бер генә театр тәнкыйтьчесенең дә моны эзлекле, нигезле итеп ачып бирә алганы юк. Сүз уңаеннан шуны да искәртеп китәсе килә, безнең тәнкыйтьче иптәшләргә язучыны бөтен бер шәхес итеп карау җитеп бетми. Алар, гадәттә, яңа язылган әсәрне аерып алалар да, бары тик шуның тирәсендә генә, бары тик шуның хакында гына фикер йөртергә тотыналар. Әйтерсең лә аның башка әсәрләре булмаган да, куелмаган да. Мондый өзекләндерү, язучыны шәхес буларак вак кисәкләргә турау күп

очракларда ялгыш нәтиҗәләр ясауга да китерә. Иҗат юлында, уңышлар белән беррәттән, уңышсызлыклар да булырга мөмкин, язучының һәр яңа адымы аның элгәреге адымнарының законлы дәвамы итеп каралырга тиеш. Әгәр шулай булса, без бүгенге көндә иң актив, иң төпле драматургларның берсе булган Юныс Әминовның иҗат үзенчәлеге нидән гыйбарәт дигән сорауны куеп та маташмас идек. Язучы бөтен бер шәхес, ул ни турында гына язмасын, нинди жанрда гына иҗат итмәсен, аның һәр сүзендә дөньяга карашы чагыла. Ул нәрсәнедер раслый, яклый, нәрсәнедер кире кага.

Драматургның егерме еллык иҗатына күз ташлаудан элек, аның үзара сөйләшеп утырганда әйткән бер сүзен хәтергә төшереп үтәсем килә. «Мене мине «Язылмаган законнар», «Тамырлар» пьесаларының авторы буларак кына таныйлар. Мин үземне «Умырзая чәчәкләре» авторы буларак та белүләрен бик теләр идем»,— диде ул.

Шушы сүзләрдә миңа Юнысның кеше, гражданин, көрәшче буларак бөтен йөзе, бөтен барлыгы ачылып китте. Бик, бик аңладым мин аның тел төбен!

Чыннан да, драматургның үз халкына әйтер сүзе бар, ул шул сүзе белән тынгысызланып, борчылып, кабынып, янып яши. Мәскәүдә Юныс Әминов белән бергә укып, янәшә бүлмәләрдә торган шагыйрь Шәүкәт Галиев болай дип сөйли иде: «Төнге икеләрдә-өчләрдә, тулай торак изрәп йоклаган чакта, кинәт күрше бүлмәдән Юнысның «Галиябану» көенә кычкырып җырлаганы ишетелә башлый».

Белмим, матур җырлыйдырмы, юкмыдыр Юныс, ишеткәнем юк. Әмма төн урталарында җырлап җибәрә икән, димәк, аның күңелендә нәрсәдер кайный, ташый... Бәлки, әнә шул «нәрсәдер» инде кәгазь битләренә төшкәндер. Бәлки, ул «Умырзая чәчәкләре»ндәге Максут сүзләредер... Бәлки, яңа язылып ята торган әсәрләрдәге яңа кешеләрдер...

Юныс Әминов — беренче пьесасы белән үк үз темасын, үз тавышын тапкан бәхетле язучы. Хәзерге заман татар драматургиясендә авыл темасын, анда бара торган катлаулы процессларны Юныс Әминов тирәнтен ачып бирә алды. «Язылмаган законнар», «Тамырлар», «Гөлҗәннәтнең җәннәте» һәм әлегә сәхнәгә куелмаган «Үлемнең үлеме» пьесалары бу уңайдан авторның театр аша халыкка әйткән зур сүзләре булды. Юныс тема эзләп әллә кайларга чапмый, аның пьесалары — беренче карашка үзе кебек тыйнак, гади пьесалар. Ләкин аларның һәрберсендә заман чагыла, халкыбызның зур, катлаулы язмышы тасвирлана.

Тарихи темага алынганда да Юныс үз-үзенә турылыклы булып кала, ипи-ипекәйне олылый, игенче-кырчының беек, буйсынмас, горур җаны турында җырлый.

«Умырзая чәчәкләре» пьесасы аның якташларына — Әгерҗе районының Салагыш авылында 1919 елның 14 мартында ак фетнәчеләр тарафыннан вәхшиләрчә үтерелгән Вәҗи Сәхәбиев, Хабибрахман Күкрәков истәлегенә багышланган.

Чын тарих. Чын кешеләр. Чын көрәшчеләр. Пьесада алар Максут яки башка исемнәр алсалар да, без Совет власте өчен үлә белгән ярлы татар крестьяннарын — Сәхәбиевларны, Күкрәковларны күз алдына китерәбез. Максут гади, ләкин олы җанлы, гадел, тормыш өчен үлә белүче кеше. Максут — Юнысның идеалы. Максут җир кешесе, халык вәкиле. Аның артында прототиплары, исән кешеләр торганга гына түгел, Күкрәков кебек якташлары булмаган очракта да Юныс бу пьесасын язар иде. Ул аны язарга мәҗбүр булыр иде. Драматургның тоткан юлы, яшәү максаты өчен кирәк бу пьеса. Бу пьеса аша ул калган барлык пьесаларына күпер салды. Октябрь көннәрен бүгенге көннәр белән тоташтырды. Әсәрдә тирән мәгънәле бер эпизод бар. Шушы эпизодта яңгыраган сүзләр өчен генә дә Юныс «Умырзая чәчәкләре» пьесасын язар иде.

Әсәр геройлары дошман тырнагына эләгеп, үлем көтеп торганда киләчәк турында сүз алып баралар:

«— Вакыт үтәр... Берзаман язарлар: 1970 ел.

— Җитмешенче елларда бу урында нәрсәләр булыр икән?

— Бик зур, бик күп бүлмәле йорт. Бүлмә саен шкафлар. Шкаф саен калын-калын китаплар, тышларына алтын белән язылган...

— ...Кеше арасына чыкканда, аягыбызда лаклы галошлар булыр...

— ...Эчке күлмәк кенә киндер булыр, ә тышкысы ситсы...

— ...ул заманның кызлары биргән вәгъдәләрендә торырлар. Яратканнарына гына

чыгарлар. Туй узгач: «Яратмыйм, кире кайтам»,— дип йөрмәс ул заман кызлары... Гаҗәеп тату яшьләр алар. Хатыннар да ирләрен әткә әйтмәс сүзләр белән тиргәмәс... Сандугачлар кебек тату, дус яшьләр.

— ...тормышы да икенче булыр. Игенне дә урак белән урмабыз...

— Эш башында Ленин торса, яңадан сугышы да булмас иде.

Киләчәк җитмешенче еллар турында сөйләшкәч, Сәмига: «Мондый чакта үлем турында сөйләргә кирәкми», дип куя».

Бу сүзләрдә Юныс Әминов ярылып ята. Үзенең барлык әсәрләрендә гаделлекне, әхлакый сафлыкны пропагандалаучы, бары тик матурлыкка гына өндәүче автор үзенең идеалларын әнә шул бөек көрәшчеләргә илтеп ялгый. Ул үзенең идеяләр сукмагын шуннан сала. «Умырзая чәчәкләре»ндә анык идеаллары яши. «Язылмаган законнар»дагы сыер савучы Фәридә дә, «Гөлчәчәк»тәге Гөлчәчәк тә, Максутлар, Сәмигалар хыялланган кешеләр. Алар — Күкрәковларның, Сәхәбиевларның турыдан-туры варислары.

Гадәттә, язучылар арасында уңай образларны язу кыенрак, кире образлар җиңелрәк табыла дигән сүзләр йөри. Кире образны гади штамплар буенча иҗат иткәндә, шулай да буладыр. Юныс Әминовка уңай һәм кире образларны бердәй осталык, тирәнлек белән иҗат итү хас. Җирне, дөньяны ярата белгән автор кирелəрне дә, уңайларны да кешелек сыйфатларыннан аермый. Бу уңайдан «Язылмаган законнар»га һәм «Тамырлар»га мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Шәйхенур — автор тарафыннан хөкем ителә торган кеше. Тасма телләргә ышанып, үзенең иманын саткан, әнкәсенә, сөекле хатынына хыянәт иткән Шәйхенурны, берәү булса, эттән алып әткә салыр иде. Әмма Юныс ул юлдан китми. Ул башта Шәйхенурны яраттырып өлгерә. Аны җанлы, кешелекле сыйфатлар белән бизәп бирә. Алдагы күренешләрдә Шәйхенур түбәннән түбәнгә тәгәри башлагач, тамашачы ихтыярсыздан аның язмышы өчен тирән борчыла башлый, пассив күзәтүчедән актив катнашучы булып китә.

«Тамырлар» комедиясендә Гапсаттар белән Хәернисадан ничек оста көлә Юныс! Әмма яратып, үз итеп көлә. Чын итеп көлә. Бу карт белән карчык та асылда кеше булып калганнар, үзләренең саранлыклары, карунлыклары белән безнең заман кешеләре арасында яраша алмыйча, төрле көлке ситуацияләргә дучар булалар.

Кешеләрне тирәнтен ярата белгән кеше генә алар хакында олы фикер әйтә ала, акны ак, караны кара дип раслаудан курыкмый.

Икәү генә сөйләшеп утырган чакларның берсендә Юныс ярым әрнеп, ярым борчылып: «Мин тешсез игәү хәлендә калуымнан куркам»,— дигән иде.

Үз халкының борчылулары, мәшәкатьләре, шатлыгы-кайгысы белән яши торган, үз урынын халыкның уртасында тапкан, аның телен, гореф-гадәтләрен бик яхшы белгән Юныс Әминовның бу сүзләрендә киләчәккә ачык күз белән каравы күренеп тора. Ул үзен бер генә минутка да гомуми сафтан читтә итеп күз алдына китерми, халыкның гаярь сугышчысы булып калырга омтыла. Шулай яши, шулай яшәрмен дип ышанып тора...

Минә мең кешелек тамаша залы тынып калган.

Шунысы тансык, кадерле тынлыкны тудыруда язучы-драматургның да хезмәте, роле зур. Драматурглар пьесаларын сәхнәдән төрлечә кабул итәләр.

Шәриф Хөсәенов спектакльләренә көн дә килеп йөри, һәрбер ноктасы, өтере өчен борчылып, янып-көеп бетә.

Туфан Миңнуллин, башын бераз арткарак ташлап, хәтәрләнеп, мыегын бөтера-бөтерә тамаша кыла.

Хәй Вахитның диңгез бәрмәсе кебек гөрләгән көлү тавышы мең кеше арасыннан аерылып тора.

Юныс Әминов песи кебек тын гына, мин икәнен сизмәсәләр ярар иде дигән кебек, мыштым гына карый...

Ләкин бу мыштым кешенең күкрәгендә сүнмәс ут бар: ул аның туган илен, туган халкын сөюдән килә. Шуңа күрә ул ут халык күңеленә ак нур булып төшә.

# ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ — ШАГЫЙРЬ ЯЗМЫШЫ

*Шагыйрь Сибгат Хәким белән*
*тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин әңгәмәсе*

**Тәнкыйтьче:** Сибгат ага, мин Сезне иҗат процессы, хәзерге поэзия һәм әдәби тәнкыйть турында фикер алышырга чакырам. Татар совет поэзиясендә кырык елдан артык эшләп килгән шагыйрьнең әлеге мәсьәләләргә карашы укучылар өчен дә кызыклы булыр дип уйлыйм.

Сезнең бөтен иҗатыгыз буенча сузылып килгән һәм кайта-кайта уйлана торган үзәк темаларыгыз бар. Ленин һәм илебез халыклары язмышы. Тукай, Җәлил, Вахитов, Ибраһим Йосфи — ягъни шушы халык улларының батырлыгын, үлемсезлеген җырлау. Бөек Ватан сугышы. Ниһаять, киң мәгънәсендә заман темасы. Минем ачыклыйсы килгән фикерем менә нинди: Сезнең иҗатта бүгенге чынбарлык үзәк урынны алып торса да, гадәттә, ул үткәннән һәм киләчәктән аерым булып, «саф килеш» яшәми. Аңа әледән-әле Бөек Ватан сугышы килеп кушыла. Әйтик, «Үрләр аша» поэмасы. Бу хәл сугыш михнәтләрен үз җилкәсендә тойганнан түгелме? Әгәр шулай булса, бу тема, бәлки, яшьлек хисе кебек, әсәргә сезнең ихтыярдан башка, үзе килеп керәдер? Әллә сугыш гражданлык һәм патриотлык тойгыларын үлчәү бизмәнеме? Кеше рухының олылыгын һәм бөеклеген чагылдыруның отышлы бер чарасымы?

**Шагыйрь:** Һәр шагыйрьнең яраткан үз темасы була. Минем иҗатта, Сез әйткәнчә, Ленин зур урын алды. Тукай, Вахитов, Җәлил, Ибраһим Йосфи турында язылган поэмаларым, шигырьләрем, җырларым бар. Ни өчен алар турында? Мин, шагыйрь буларак, поэзиядә беренче чиратта кеше эзләдем. Халык алдында намуслы, хакыйкатькә турылыклы булган кеше эзләдем дигәч, махсус шундый максат куеп эзләгән шикеллерәк тоела. Юк, алай түгел. Эзләнү, борчылу сүзләре миндә һәрвакыт бер тирәдә йөри. Заман, чор үзе тудырган борчулар. Җандагы тынгысызлык. Җан чагыштыра, үлчи, бизмәнгә салып карый, үткәннән һәм бүгенгедән эзли. Тукай турындагы беренче поэмаларым моннан утыз ел элек язылганнар. Күңел һаман әле Тукайга кайта.

**Өем тыныч, Аккош күле тыныч,**
**Тыныч түгел нигә бу җаным!**
**Чорны чорга якын куеп карыйм,**
**Вөҗданына аның — вөҗданым!**

**Өч гомерен аның яшәп җирдә**
**Чагыштырыр эшем бармы соң!**
**Җырны җырга якын куеп карыйм,**
**Намусына аның — намусым.**

Әйтергә теләгән фикеремне шушы юллар тизрәк аңлатыр кебек.

Тукай телгә алынгач, тагын бер нәрсәне әйтеп үтәсе килә. Тукай миндә идеаль образ булып калды. Аңа табынган кебек мин бер шагыйрьгә дә табынмадым. Башка шагыйрьләрне мин таланты өчен, әйбәт язганы өчен яраттым. Тукай мине халык рухына алып керде, үз җиремә, үз телемә бик нык бәйләде, аның бәйләп тота торган ниндидер көче бар... Тукайлар минем өчен бары тема гына түгел...

Ватан сугышы темасы... Әйтерсең мин үзем эзләп тапкан аны. Ватан сугышы үзе тартып кертте мине. Ил язмышы, халык язмышы. Башта язмыш. Темалар соңыннан туалар... Зур вакыйгалар күңелдә озак саклана. Кешеләрне мин сугышка кадәр дә азмы-күпме белә идем. Шулай да халыкны чын-чынлап сугышта таныдым. Читтән күзәтеп түгел, үзе белән бергә булып, арасында булып, авыр вакытта, иң кыен вакытта. Халыкның җаны, характеры бөтен матурлыгы, бөтен байлыгы белән киң итеп ачылган чакта... Минем бәхеткә, сугышның миңа баштагы — безнең өчен артык га-

заплы чорын гына түгел, аның биек ноктасын, халыкны җиңү менбәренә менгән чоннәрендә күрергә туры килде. Дуга сугышларын мин менбәр итеп күз алдыма китердем. Ник? Белгород тирәсендә ак таулар... Июль кояшы... Илнең куәтен күреп күтәрелгән күңел... Романтика. Әйбәт, җирлекле батырлыктан калыккан романтика, абстракт түгел. Мин сугышта разведчикларны күп очраттым, ихтыярларына, батырлыкларына сокландым, кайвакыт җәлләдем... Ләкин алар үзләренең шушы коточкыч авыр, кыен хезмәтләрен бернәрсәгә дә алыштырмыйлар. Аларга адым саен үлем белән басып торган шул тынгысыз разведка ошый... Романтика ул тирәндә, кеше күңелендә, олы вакыйгалар эчендә.

**Тәнкыйтьче:** Батырлыкны романтика тудырамы, әллә батырлык романтиканымы?..

**Шагыйрь:** Сугыш чоры ул минем яшьлек тә. Әдәбиятка яңа килгән йөзләгән яшьләр, аларны рухландыручы Җәлилләр, Кутуйлар... Заман рухы булып шулар әсәрләремә барысы бергә керә. Күңелдә һәрвакыт сүзгә күчеп җитмәгән тонык тойгылар яши. Әрәмәдән агып яткан инеш кебек. Төбендә таш, ком, үлән... Көн яктысы да шунда, хисләрең дә шунда... Заман, патриотизм, гражданлык хисләре... Мин аларны тоям, ләкин бары да кешеләрне сагынудан башлана кебек. Шигырь итеп карыйм, җыр итеп карыйм, поэма итеп... Язмаларга күчәм. Кешеләрне сагынудан хисләрнең дулавы ул. Кешеләр, кешеләр... Язучыга олы биография кирәк, гомеренең ахырына чаклы җитә торган тормыш биографиясе. Шуңа күрә мин хәзер шагыйрьне бер-ике җыентык белән түгел, үткән юлы белән үлчим...

**Тәнкыйтьче:** Бер тәнкыйтьче, ялгышмасам, Гази ага Кашшаф бугай, сезне, шагыйрь буларак, сугыш окопларында формалашты дигәнрәк фикер әйткән иде. Мин сезнең сугышка чаклы язган җыр һәм поэмаларыгызны кат-кат укыдым. Иң соңгы эпик әсәрләрегездә сез нәкъ менә «Пар ат»та табылган эстетик принципларны һәм алымнарны үстереп җибәрдегез. Бу мәсьәләгә карата шагыйрьнең үз фикере дә булуы мөмкин бит әле. Үзегез ничек уйлыйсыз?

**Шагыйрь:** Мин үземнең кайда, ничек формалашуымны белмим. Окоптамы, окопка кадәрме? Дөресрәге, формалаштым микән? Бу хакта беркайчан да уйламадым... 1943 елда Дугада, безнең дивизия политотделына Гали Хуҗи килеп чыгып, минем шагыйрь икәнлегемне әйтмәсә, бәлки, белмәгән дә булырлар иде. Фронтта: «Мин шагыйрь», дигән сүз уйдан чыкты. Күңелне зуррак башка нәрсәләр билгән, күрәсең. Шагыйрьлегеңне беренче планга куймасаң, язу җиңел, табигый хәлеңә кайтасың...

**Тәнкыйтьче:** «Дуга» поэмасына язган керешегездә шундый сүзләр бар: «...Уттан бер чыкканнан соң икенче тапкыр керәсе килми. Әсәргә алыну минем өчен утка яңадан керү белән бер...» Шулай да, күпчелек әсәрләрегез «яңадан утка» кергәннән соң, ягъни шул урыннарны икенче кат кургәч, язылды. «Үрләр аша» һәм «Дуга» поэмалары да, Җәлил һәм Германия турындагы шигъри бәйләмнәр дә сугыш эзләре буйлап яңадан бер үткәч туды. Минемчә, бу әсәрләрдә сугыш афәте 1941—45 елларда язылган шигырьләрегезгә караганда киңрәк һәм тирәнрәк ачыла. Хис тирәнлеге дә, киеренкелек тә башкача. Шигъри әсәр кичерешләр яңа, детальләр күз алдында чакта камилрәк була, дигән концепция белән бәхәскә кермиме бу күренеш?

**Шагыйрь:** Әйе. Кичерешләр яңа, детальләр күз алдында чакта язу җиңел, дигән фикер яши. Берәүләр өчен читен, берәүләр өчен читен түгел. Фатих Кәрим траншеяда, землянкада солдатлар ял иткән арада язган. Лирик шигырьләр, «Идел егете», «Үлем уены» кебек поэмалар, «Разведчик язмалары»... Шагыйренә карап, күрәсең. Кем ничек иҗат итә ала...

Минем үземә ара кирәк. Бераз көтә торган гадәтем бар. Бу әсәрнең характеры белән дә бәйләдер. Фатих Кәрим бер вакыйганы сюжет иткән. Мин сугышның үзе, заман-чор, кешеләр турында гомумиләштереп сөйләргә тырыштым. Моның өчен вакыйгаларга, бәлки, ерактанрак карау кирәктер. Күрү, күзәтү ноктасы. Икенче чордан торып бәя бирү. Фикерләү, уйлау, фәлсәфи синтезлар өчен күз алды ачыла, офыклар киңәя төшә кебек.

**Тәнкыйтьче:** Күпчелек әсәрләрегезнең, бигрәк тә поэмаларыгызның, нигезендә реаль тормыш, документальлек ята. Ул хакта сез үзегез дә яздыгыз. Бу алым, минемчә, өстәмә мәшәкать тудыра, вакыйга-күренешләр белән сак эш итүне сорый. Материал «каршылыгын» җиңү, аңа шигъри рух бөркү кыенлаша. Документальлекнең уңай, позитив ягы нәрсәдән гыйбарәт?

**Шагыйрь:** Иҗат мең төрле. Һәркемнең яраткан үз алымнары бар. Мин реаль тормышка таянам. Ләкин тормыш күренешләрен яки документаль материалны үз рухымнан чыгып сайлыйм. «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты»нда мин үз биографиямнең бер өлешен күрдем: 1921—22 еллардагы ачлык..., теш, бер кәтү атлар... Тәштә Ленинның крестьянга ат өләшүе өчен, мин тапкан материалда хыялга нигез булырга тиеш. Шул нигезне алдан күрмәсәм, мин аңа алынмыйм. Кыен ягы: материал каршылыгы... Хатта — документта — атлар гына түгел, башка мәсьәләләр дә кузгатыла (мәктәп һ. б.). Шигырь дә, поэма да җентекләүне яратмый... Миңа, крестьян малаена, ат кирәк. Минем хыялның шигъри җирлеге: җир — атлар — галәм — спутниклар... «Үрләр аша»дагы торбалар да миңа тотынып бару өчен кирәк булды... Документальлекнең куркыныч ягы шунда: синең факт, детальләргә, натурализмга кереп батуың бик мөмкин... Уңай ягы: анда тормышның, чорның нинди дер кул тимәгән зур кисәге. Кузгат, эченә кер, чорны алга бастыр, романтикасын ач. «Ленин фәрманы белән» поэмасындагы Казан полкын мин тарихи документлардан актарып чыгардым, аннан инде минем хыял уйнарга кереште, полк Төркстан комлыкларына кереп китте...

Һәр жанрның үз материалы бар. Үз күңелемә яткан нәрсәне мин төрле тәштән әзлим: тормыштан, документлардан... Әсәрнең ышандыру көче реаль җирлеге булуда, укучы җирлекне тойсын.

Җирлек, уртак хакыйкать, тормыш чынлыгы... Судта утырышчы, Казан шәһәр Советы депутаты һәм башка төрле җәмәгать эшләре мине иҗат эшемнән читкә алып китмәде. Халык арасына ныграк тартылган саен көндәлек тормышның каршылыклы процессын якыннан тоясың. Хисләрнең чынлыгы фәкать тормышта икәнлегенә эз генә дә шигем юк. Шагыйрьнең формалашуын мин шушылай аңлыйм...

**Тәнкыйтьче:** Иҗат юлыгызны «саф реалист» буларак башладыгыз да илленче һәм алтмышынчы еллар аралыгында романтизм белән кабынып киттегез. «Ибраһим Йосфи», «Сары капкалы йорт» шикелле балладаларыгызны, соңгы елларда язылган поэмаларыгызны күздә тотам. Шигъри күремегезнең болай үзгәрүе, дересрәге, үсүе нәрсә белән аңлатыла?

**Шагыйрь:** Алдарак романтика мәсьәләсенә мин бер тукталган идем инде. Тормыштагы героик эшләр нигезендә романтика ята. Реаль тормышка басып югарыга омтылган оптимистик романтика — хисләрнең канаты. Моның иң әйбәт үрнәкләре Такташта «Гасырлар һәм минутлар», «Киләчәккә хатлар»ның яшәүчәнлеген мин шул ике сыйфатның — реаль тормыш белән романтик хисләрнең кушылуында күрәм. Реалистик әдәбиятка революцион романтика! Киләчәктә аларның синтезы барлыкка килер дип уйлыйм.

**Тәнкыйтьче:** Поэзияне мәхәббәт лирикасы, пейзаж лирикасы, политик лирика кебек төрләргә бүлеп куярга яратучылар бар. Сезнең каршыга мондый бүленеш, проблема буларак, килеп басканмы юкмы?

**Шагыйрь:** Поэзияне мәхәббәт, пейзаж, политик лирика киштәләренә салып карадым. Дәрдмәнд, Фет шигырьләре искә төште. Туфанның табигать турындагы шигырьләреннән үз кичерешләрен, чор борчуларын аерып алырга тырыштым. Әйтерсең бер төер, оешкан, кристаллашкан, күз яше белән генә эретергә мөмкин... Шәхес — бер, шагыйрь — бер, йөрәк — бер...

**Тәнкыйтьче:** Соңгы елларда гражданлык поэзиясе турында күп сөйләнелә. Нәрсә ул? Кайберәүләр уйлаганча, тема гынамы? Әллә поэзиянең җаны, асылымы? Әйтик, мәхәббәткә багышланган шигырь гражданлык мотивына урын калдыра аламы?

**Шагыйрь:** Соңгы елларда гражданлык поэзиясе турында, чыннан да, сүз күп булды. Мәскәүдә хәтта бу темага язучыларның аерым пленумы да чакырылды. Ник шулай актуаль? Ник шулай торган саен, бигрәк тә көрәш кискенләшкән саен, гражданлык поэзиясе алгы сызыкка баса? Гражданлык поэзиясен мин ил язмышыннан, халык язмышыннан туган хисләрнең, көрәшче шагыйрьнең йөрәгә аша узган патриотик хисләрнең югары бер формасы итеп күз алдыма китерәм. Фатих Кәрим аны «Үч һәм моң» дип атаган. Шунысы кызык, шагыйрь моңа кайчакта үзенең һәлакәте аша килә. Гомум зур максат, идеал өчен үз тормышын, үзен корбан итеп килә... Фатих Кәрим, Муса Җәлил кебек шагыйрьләрнең гражданлык поэзиясенә күтәрелү юлы — көрәшчеләр юлы...

**Тәнкыйтьче:** Сез укытучыгызның исемен һәрвакыт горурланып әйтәсез. Ул — Тукай. Укучы белән остаз арасында мөнәсәбәт нинди булырга тиеш? Традициягә каршы чыгуны да аны дәвам иттерү диләр. Бу бит, чынында, тәнкыйтьчеләр һәм әдипләр еллар буе кылыч чәкәштерә килгән мәсьәлә, ягъни традиция белән яңачалык арасында мөнәсәбәт турында сүз йөртү дигән сүз.

**Шагыйрь:** Тукайдан башладым. «Пар ат»ны Тукай үзе җигеп бирде. Традицион! Бер дә үкенмим, сулышы киң. Сулыш бетүдән, сулыш тараюдан куркам. Традицион шигырь, крестьянның йөк аты шикелле, ышанычлы, күпме салсаң да тарта. Заман сынавын узган... Бер караганда, барысына да бер әзер калып сыман. Юк, Җәлил башка, иң яшь шагыйрьләрдән Зөлфәт башка, Мөдәррис Әгъләмов башка. Шигырьнең калыбы бер, тоны, ритмикасы, заман сулышының юлларга басымы башта... Хикмәт — талантта, талант кабатланмый. Ләкин мин эзләнү ягында, төрле формалар ягында...

**Тәнкыйтьче:** Сез яшьләргә вакытыгызны кызганмыйсыз. Р. Фәйзуллин, Р. Харисов, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин, Зөлфәт, Г. Рәхим, М. Әгъләмов кебек яшь каләмнәргә аеруча игътибар белән карыйсыз. Метафорага, ассоциатив фикергә, хәтта вакыты белән дилбегәләре бушаган стильгә өстенлек биргән бу яшьләрнең күбесе сезнең үз шигъри интонациягездән башкарак юл белән атлыйлар. Ләкин сез, беренче чиратта, нәкъ менә шул яшьләр турында язарга һәм сөйләргә яратасыз. Моны ничек аңларга? Яңа буын шагыйрьләре сезгә кайсы яклары белән охшый? Кемнәргә аеруча өмет баглыйсыз?

**Шагыйрь:** Беренче чиратта мине татар әдәбиятының киләчәге кызыксындыра. Мин аны иң алдынгы әдәбиятлар белән ярыша ала торган әдәбият итеп күрергә телим. Хәзер милли әдәбиятлар киң мәйданга чыктылар. Интеллектуаль яктан хәзерлекле яшьләр, эстетик карашлары нык булган, үзенчә фикер йөртүче яшьләр кирәк... Ләкин шуларның барысыннан тыш ул зур мәйданда ярышу өчен әле үз халкының тарихы да, традициясе дә, Тукайлары да кирәк булачак, мең еллык культураның олы рухы кирәк булачак.

Мин өмет баглаган кешеләр күп хәзер. Сәнгать фикер һәм хисләрнең бөтенләген ярата. Бала чакта миңа күрше хатыны кура җиләгенең түбен бирә торган иде. Кура җиләген учта шундый итеп сыккан, коры түбе генә калган була. Равил Фәйзуллин белән Ренат Харисов та материалның фәлсәфәсен шулай сыгып чыгаралар шикелле. Алымнары ачык, нык, ышанычлы.

Рөстәм Мингалимов «Минем дәүләтем»дә ачылды, фикер һәм образлылыкның синтезы дияр идем мин ул поэманы. Баштагы ике шагыйрь белән Мингалимов арасында бу яктан шактый уртак яклар бар...:

Рәдиф Гатауллин романтикасын беренче шигырьләрендәге конкрет җирлеккә бастырса, әйбәтрәк булыр кук тоела. Кайдадыр ул аерыла, югала. Бүгенге тормышның зур вакыйгаларына романтик ялкынын кушса (Такташча, «Киләчәккә хатлар»дагыча), Рәдиф зур юлга чыгар.

Гәрәй Рәхим үзенең гадилегендә матур. Гадилегендә я ул (самовар куеп улларын көткән ана) кинәт күтәрелә, я арбаның бер тәгәрмәче казылмага төшкән кебек, аксый, кайчакта шигырьне үтә примитивлаштырып та җибәрә. Гәрәйдә беренче сыйфат җиңәр, анда тормыш күп, халыкчан нигезе әйбәт...

Ике шагыйрь бик нык аерылып тора: Зөлфәт һәм Мөдәррис Әгъләмов... Болар шигырьгә Тукайча, усал ябышканнар. Горурлык хисе — халыктан килә, шигырьләре форма бәхәсенә урын калдырмый туа, хис, моң үзе шул шигырьне тиреннән формалаштырып алып чыга. Зөлфәттә зур социаль темаларны югары ноктасына җиткереп гомумиләштерү көчле. Кайвакыт бераз риторика сизелә. Әгъләмов сак. Болар, әлбәттә, минем субъектив фикерләрем, мин аларны бәрәүгә дә көчләп такмыйм...

**Тәнкыйтьче:** Шигъри жанрлар хәрәкәтендә кызыклы үзгәрешләр күзгә чалына. Мәсәлән, Ш. Мәхмүдов, Р. Харисов, Р. Фәйзуллиннар иҗатында традицион поэмадан да, шигъри циклдан да үзгә бәйләмнәр барлыкка килде. Р. Харисовның Фатих Кәрим истәлегенә багышланган шигъри көлтәсен искә төшерегез. Аның янына «Мулланур»ны өстәргә була. «Көрәшчеләр»ендә Р. Фәйзуллин да поэманың традицион таләпләре белән артык санашып тормый. Хәлбуки, эстетик яктан барысы да балигъ әсәрләр. Бу ни? Аңлы рәвештә традицион формадан баш тартумы? Яки традицион форманы яңа иҗтимагый һәм сәнгать таләпләреннән чыгып, бәйгегә чакырумы? Әллә яңа жанр

туып киләме? Сез форма камиллегенә, эчтәлек белән тышкы киемнең гармониясенә зур әһәмият итәсез. Поэма икән, аның шартлары килгән, җөйләре тәйнәлгән булсын. Баллада икән, ул «мин баллада» дип кычкырып торсын. Шуңа күрә әлеге эзләнүләр турында, дәресрәге, аларга мөнәсәбәтегез турында сезнең фикерне ишетү кызыклы булыр иде.

**Шагыйрь:** Жанрлар үзгәрә, яңа формалар барлыкка килә. Заман үзе тудыра дип уйлыйм. Хәзер классик формасындагы, баштан ахырына чаклы сюжетка, вакыйгага корылган поэмалар аз. Поэма эченә автор үзе, аның чор белән бәхәсе, уйланулары килеп керде. («За далью даль».) Минем үз поэмаларым да: «Мин чын поэма»,— дип кычкырып тормыйлар. «Үрләр аша» да, «Дуга» да шагыйрьнең лирик кичерешләренә totынып торалар. Равил Фәйзуллинның «Көрәшчеләр»е һәм Ренат Харисовның «Мулланур»ы лирик герой — авторның чор белән сөйләшүе формасында бирелгән, бер үк үзгәреш, бер үк процесс...

**Тәнкыйтьче:** Белүемчә, начар һәм урта кул шигырьләрнең күп язылуы сезне дә хәвефләндерә. Мондый җансыз тезмәләргә кемнәрдер мөһер суга, бастырып чыгара, бенгаль уты шикелле ялтыравык рецензияләр яза бит. Моның зарары без уйлаганнан күбрәк. Зәвыксызлык укучының шигырьдән күңелен биздерә. Бу хакта сез ни уйлыйсыз?

**Шагыйрь:** Начар шигырьне яхшы шигырь кысрыклап чыгарырга тиеш. Моның җаваплылыгы бигрәк тә танылган шагыйрьләр өстенә төшә. Алар йомшак әсәрләрен укучыга тәкъдим итәргә тиеш түгелләр. Йомшак шигырь архивта калса, яхшырак булыр. Әдәбият белгечләре аларны соңрак барыбер өйрәнерләр, бастырып чыгарырлар. Дәрәҗәле шагыйрьләрдән үрнәк алып, яшьләр дә язган бер рифмалы тезмәләрен типография хәрефе аша уздырырга тырышмаслар.

**Тәнкыйтьче:** Күрәсең, тәнкыйтьнең тешсезлеге дә йомшак әсәрләрнең басылып килүенә ярдәм итә торгандыр. Тәнкыйть дигән сүз телгә элләкәч, тагын бер нәрсәне ачыклап үтик. Күптәннән әдәби тәнкыйть көн таләпләреннән артта кала дигән фикер яшәп килә. Шул ук вакытта әдәбият белән тәнкыйть үсеше арасында ниндидер закончалык та яши. Олы талант иңнәре белән бер чорда талантлы тәнкыйтьчеләр дә үсеп чыга. Пушкин белән Лермонтовны Белинский күтәреп чыкты, укучыга җиткерде. Егерменче-утызынчы еллар чоры әдәбияты үзе белән мәйданга Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Галиләрен алып килде. Әдәбият үсешендә эз калдырган күренешләр, ачышлар тәнкыйтьченең фикерләвенә канат бирәләр, үстерәләр. Бәс, тәнкыйть артта кала дип сөйлибез икән, ул чагында үзеннән-үзе: «Ә әдәбият үзе ничек үсә? Тәнкыйтьне рухландырырлык, кыядан сикертерлек әсәрләр күп языламы?» — дигән сорау туа.

**Шагыйрь:** Мин тәнкыйтьтә, күп кимчелекләре булуга карамастан, һаман әле Гомәр Галине сагынам. Турылыгы, кыюлыгы, таләпчәнлеге өчен сагынам. Әдәбиятны урта кул шигырьләр басып китмәсен өчен, Гомәр Галиләр кирәк.

**Тәнкыйтьче:** Менә кайбер язучыларның тәнкыйтьне тар аңлаулары борчый. Тәнкыйтьче бүгенге көн әдәбияты белән генә яшәргә, исән-имин шагыйрьләр иҗатын гына өйрәнергә тиеш, дигән фикерне яклаучылар бар. Алар борынгы яки XIX йөз әдәбиятын, аннан соңгы чорларны өйрәнүче галимнәр эшенә кимсетебрәк карыйлар. Минемчә, киресенчә, культурабыз тарихын ныклабрак өйрәнергә һәм киңрәк мәйданда күрсәтә белергә тиешбез. Ахыр чиктә, Кандалый, Тукай, Дәрдмәнд, Такташ, Җәлилләр поэзиясен җентекләп өйрәнмичә, хәзерге шигърияtне дә бөтен тулылыгы белән тасмерләве, аңлавы кыен булачак.

**Шагыйрь:** Әдәбиятның үткәне... Тәнкыйть ярдәмендә мин аның зурлыгын тоярга телим. Бүгенге үткәнгә таяна. Әдәбият белеменең барлык тармаклары тигез үсәргә тиеш. Шул чагында гына ул әдәби хәрәкәткә нәтиҗәле йогынты ясый алачак.

Леонид Ильич Брежнев партиянең XXIV съездында ясаган докладында, әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр алдында торган бурычларга тукталып, болай дигән иде: «Шик юк ки, әгәр дә безнең әдәби тәнкыйть партия линиясен тагын да активрак үткәрсә, таләпчәнлекне такт белән, художество кыйммәтләрен иҗат итүчеләргә игътибарлы мөнәсәбәт белән бергә бәйләп, зуррак принципиальлек белән чыгыш ясаса, совет әдәбиятының һәм сәнгатенең уңышлары тагын да зуррак булыр, ә кимчелекләре тизрәк бетәрләр иде».

Бу сүзләр безнең тәнкыйтьчеләргә дә карый.

# ЯЗУЧЫ һӘМ КӨРӘШЧЕ

*Кави Нәҗминең тууына*
*70 ел тулу уңае белән*

Тормышта төрле кеше очрый. Беришесе белән озак еллар бергә яшисең. Әмма аерылып күп тә узмый, ул күңелдән эзсез югала. Икенчесен үзең искә төшерергә теләмисең. Өченчесе... ә менә өченчесе олы җанлы һәм киң күңелле булуы белән гомерлек юлдашыңа әверелә, төсе-бите, холкы-фигыле күз алдыңда тора, һәм син аны аерылганнан соң күпме еллар узгач та һаман тере итеп күз алдына китерәсең.

Кави ага Нәҗми әнә шундый кеше иде. Ул һәрвакыт ачык күңелле булды. Ул һәрвакыт танышларының кәефен күтәреп җибәрерлек үткен сүз, кызык бер мәзәк таба белә иде. Андый чакта аның шадралары да йөзенә ниндидер мөлаемлык, яшьләрчә шуклык өстәгендәй була. Бер-ике мәртәбә очрашып сөйләшүдән соң ук аның гаҗәп бай эрудицияле, искиткеч яхшы хәтерле булуына соклана башлыйсың. Күп еллар элек булып узган вакыйгаларны һәм аларда катнашкан кешеләрне, газета һәм журналларда чыккан күп төрле хәбәрләрне ул бөтен ваклыкларына кадәр исендә тота, алар турында йотылып тыңлардай итеп сөйли иде.

Яше артык зур булмаса да, гәүдәгә шактый тулыланган Кави ага (аны берничә ел йөрәк авыруы борчыды) язучыларның гомуми җыелышларына яки тантаналы утырышларга һаман бер үк киемнән йөри иде: күпне күргән китель белән галифе чалбар, аягында — кара хром итек.

Аның тышкы кыяфәтендә һәм киенүендә генә түгел, ә бөтен торышында гражданнар сугышы елларындагы Кызыл Армия комиссарларын хәтерләтә торган һәм бары тик хәрбиләргә генә хас чалымнар бар иде. Бу табигый дә. Чөнки аның бөтен гомере көрәш юлында узды: гражданнар сугышы елларында кызылармеец, соңрак Татар-башкорт хәрби мәктәбенең укытучысы һәм комиссары, «Кызылармеец» газетасының редакторы, Татарстан язучылары союзы идарәсенең иң беренче председателе. Кави Нәҗми язучылык хезмәтен бервакытта да иҗтимагый-политик эшләрдән аерып карамады. Ул Татарстан АССР Верховный Советы депутаты, Тынычлыкны яклаучыларның Татарстан комитеты председателе, КПССның өлкә комитеты пленумы члены иде. Үзенә тапшырылган җәмәгать эшләренең һәммәсен чын намус һәм бирелгәнлек белән үтәп килде.

Кави Нәҗминең беренче шигырьләре гражданнар сугышы елларында басыла башлый. Искене җимерү, изү-җәберләүгә каршы кискен протест, эшчеләр сыйныфыннан җырлау — аның беренче өйрәнчек шигырьләренә әнә шул сыйфатлар хас.

Көрәш мотивы шигырьләрдән аның проза әсәрләренә килеп керә. Профессор Г. Сәгъди «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» исемле китабында бик хаклы рәвештә болай яза: «Кызыл гаскәр сафында житешкән Кави, шагыйрь булу сыйфаты белән дә, беллетрист булу сыйфаты белән дә һәрнәрсәдән элек пролетариатның кызыл гаскәре; ул сәнгать дөньясында, иҗат мәйданында, бар нәрсәдән элек шул сыйныфның (пролетариатның) өстенлеген җырлаучы һәм социализм тормышы өчен сугыш алып баручы бер шагыйрь... Кавидә иҗат мотивы: сыйнфый көрәш, сугыш, җиңү».

Чыннан да, Кави Нәҗми бөтен иҗат эшчәнлеге дәверендә татар хезмәт ияләренең сыйнфый көрәш тарихы, аларның социалистик революциягә килү юлы һәм яңа тормыш төзүдәге батырлыгы белән кызыксынып яши. Аның күпчелек хикәяләрендә, «Яр буендагы учаклар», «Якты сукмак», «Кояшлы яңгыр» кебек повестьларында шул тема үзәккә куела. «Язгы җилләр» романы исә Кави Нәҗми талантының югары ноктасы иде. Кави Нәҗми «Язгы җилләр»дә татар халкының бөек революцион үзгәрешләр чорындагы тарихи юлын, татар эшчеләренең политик аңы уянуын һәм аларның рус пролетариаты белән бергә азатлык яулап алуын җанлы картиналарда тасвирлады. Сәнгатьчә яңгырашы һәм идея эчтәлеге белән интернациональ характердагы, образлары һәм сурәтләү чаралары белән гаять дәрәҗәдә милли булган бу роман инде менә ничә еллар дәвамында күп телләрдә (рус, украин, казакъ, эстон, чуваш, мари, әзәрбәйҗан, болгар, словак, чех, немец, уйгур һ. б.) яратып укыла. Чын сәнгать әсәре, шулай итеп, башка халыкларның да уртак культура байлыгы булып әверелде. «Правда» газетасы аны 1951 елның 30 март санында «бөтен тугандаш әдәбиятлар үсеше өчен дә тирән принципиаль әһәмияткә ия әсәр» дип бәяләде.

Әйе, Кави Нәҗми «Язгы җилләр» романы, күп санлы шигырь һәм поэмалары, хикәя һәм повестьлары белән танылган күренекле әдип иде. Әмма шул ук вакытта ул талантлы публицист та әле. Егерменче елларда иҗат иткән күп санлы мәкаләләрендә үк ул шул чор әдәбияты һәм культурасының актуаль проблемаларын күтәреп чыкты. Дөрес, аның төрле елларда язылган мәкаләләрендә бәхәсле моментлар да очрый. Нишлисең, үз чорының кешесе иде ул, һәм аның иҗатын да шул чордан аерып карау мөмкин түгел. Әмма ничек кенә булмасын, Кави Нәҗминең вакытлы матбугат битләрендә басылып чыккан мәкаләләрендә яңа әдәбият, совет әдәбияты өчен көрәш идеясе, халыклар һәм әдәбиятлар арасындагы дуслыкны ныгыту турындагы фикерләр, укучыларның сәнгатьчә зәвыкларын үстерүне кайгырту алгы планда тора. Аларда язучының эстетик карашлары һәм идеаллары да, шулай ук татар совет әдәбиятының төрле чордагы үсеш процессы шактый тулы чагылды.

...Зур һәм катлаулы, бай һәм кызыклы иҗат юлы үткән Кави Нәҗми татар совет әдәбияты тарихында якты эз калдырды. Без аны тууына 70 яшь тулган көндә чын коммунист, язучы һәм көрәшче буларак тирән хөрмәт белән искә алабыз.

Нур ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН

Кави Нәҗми

# АВТОБИОГРАФИЯДӘН ӨЗЕКЛӘР

Мин 1901 елда Горький өлкәсе Красный Остров авылында ярлы крестьян семьясында туганмын. Әтием, нужадан качып, бөтен семьясы белән бергә туган авылыбыздан чыгып киткән чакта миңа ике яшь тә тулмаган булган.

Бала чагым Идел буе, Кырым, Урал, Себер шәһәрләре буйлап һәм ул чагында әле бик аз кешеле Алтай далаларында каңгырып йөреп үтте. Кая гына барсак та, нужа артыбыздан калмады. Ниһаять, без Актүбә шәһәрендә урнашып калдык. Ләкин әти-әниләремә биредә дә тыныч кына озак гомер итәргә туры килмәде. Барлы-юклы хакка ялланып авыр эштә эшләү, ачлы-туклы яшәү аларның саламәтлеген тәмам какшатты. 1917 елның гыйнварында әтием гүр иясе булды, ә берничә атнадан соң әнисез дә калдым.

Ул елларда минем өчен бердәнбер якты урын Актүбә рус-татар мәктәбе булды. Анда мин рус классикларының һәм татар халык шагыйре Габдулла Тукайның әсәрләре белән таныштым. Шулар тәэсире белән 1913 елда үземнең «Көз» дигән беренче әсәремне яздым һәм Кольцовның «Урман» исемле шигырен тәрҗемә иттем. Аннан соңгы каләм сынавым үзебезнең мәктәптәге дин укытучысы турында «Җирән үгез» дигән кечкенә комедия язу булды. Ул реакцион байлар тарафыннан куелган хәлфә иде. Без, укучылар, минем пьесамны сәхнәгә куярга җыенгач, алар, спектакль алдыннан күзләренә ак-кара күренми мәктәпкә атлыгып кереп, театр уйнаучы без-яшьләрне кыйнадылар, ә тамашачыларны куып тараттылар. Аларның шул кыргый хөкеме минем әдәбиятка омтылуымны тагын да көчәйтте һәм мин явызлыкка, рухи торгынлыкка, иске дөньяның кара көчләренә каршы көрәштә туры сүзнең көчен һәм әһәмиятен аңлый башладым.

Шуннан соң озакламый тагын бер вакыйга миңа бик нык тәэсир итте. 1914 елның язында рус теле һәм әдәбияты укытучысы Федор Дмитриевич Николаев безне үзе белән бергә даладагы Илек дигән кечкенә инеш буйлап йөреп кайтырга чакырды. Җылы, аяз көн иде. Инде җир кипкән. Иртәнге җилдә әрем исе аңкый. Биек күктә тургайлар сайрый. Комлы кечкенә калкулыкларда, яңа казыган оялары алдында тәпиләре белән танауларын ышкып, йомраннар сызгыра.

Кысан өйләрдән иркен далага килеп чыккач, безнең, бер генә көнгә булса да тормыш ачысын онытып, уйныйсыбыз, шаярасыбыз килде. Федор Дмитриевич та иренмичә безнең уеннарга катнашты, ә инде барыбыз да шактый арыгач, безне ялгыз агач күләгәсе астына чакырды. Һәм ашыкмый гына рус язучыларының безгә укырга «рөхсәт ителми» торган әсәрләре турында сөйли башлады. Без патша хөкүмәте Чернышевскийны тоткын иткән һәм 1905 елда Горький да утырып чыккан Петропавловск крепостеның караңгы казематы турында шунда беренче тапкыр ишеттек.

Кырга чыгып йөреп кайтуыбыздан соң берничә атна үтүгә сугыш башланды. Шунда ук Актүбә гарнизонына яңа килгән солдатлар өстәлде. Капкаларда һәм йортларның ишекләрендә фронтка озатылганчы шул өйләргә урнашырга тиешле солдатлар санын күрсәткән цифрлар пәйда булды. Империалистик сугышка каршы фикерле кешеләр ерак җирләргә сөрелде. Яшь йөрәкләребездә рус язучыларының бөек әсәрләренә мәхәббәт уты кабызган сөекле укытучыбыз да шулар арасында иде.

Миңа әле бик озак азап чигеп, каңгырып йөрергә туры килде. Әти-әниләр исән чагында мин, җәйге айларда Актүбә байларында эшләп, кулымнан килгәнчә булыша торган идем. Мәктәпне тәмамлаганнан соң ел буе эшләргә мәҗбүр булдым. Ул чагында әдәби иҗат турында хыялланырга да мөмкин түгел иде.

Илебез тормышындагы бөек үзгәрешләрдән соң гына алдымда якты киңлек ачылды. Ярлы һәм эшче халык арасында яшәгәндә күргәннәрем, баштан кичергәннәрем минем өчен яхшы мәктәп булды: төрле милләт хезмәт ияләрен азат итү эшендә рус эшче сыйныфының һәм аның партиясенең тарихи ролен мин шул вакытта ук аңлаган идем инде. Шул нәрсә мине — үнсигез яшьлек егетне — коммунистлар сафына китерде. Чит ил интервентларына һәм аларның ялчыларына каршы көрәшкәндә Кызыл Армия сугышчысы булдым һәм минем совет газеталарында басылган беренче әсәрләрем шул көрәшкә багышланган иде.

Гражданнар сугышы елларында ара-тирә буш вакыт тапканда гына яза алдым. Тормыш безнең алга бик күп искиткеч һәм күңел дулкынландырырдай темалар китереп куйды, ләкин мин аларны укучыга тәэсир итәрдәй җанлы сүз белән гәүдәләндереп бирә белми идем. Нәкъ шул вакытта «РОСТ тәрәзәләре»ндә Маяковскийның алга өндәүче ялкынлы һәм формасы буенча да, эчтәлеге белән дә үзенчәлекле әсәрләре чыкты. Аңарчы берәүнең дә алай язганы юк иде әле. Ул шигырьләрне оныту мөмкин түгел иде.

Маяковский белән танышканчы, мин татар әдәбиятында яшәп килгән традицион шигырь техникасын үзләштерергә тырыша идем. Хәзер инде ул мине канәгатьләндерми башлады. Мин аңарчы булмаган яңа форма, үз формамны табарга омтылдым. Шул газаплы эзләнүләр чорында мине Мәскәүдәге хәрби-педагогик институтка укырга җибәрделәр.

Институтның тулай торагы зоопаркка каршы аерым йортта иде. Ничектер укулардан буш бер кичне безнең бүлмәдә Чернышевскийның «Нишләргә!» романын кычкы-

рып уку оештырдылар. Күршедә генә зоопаркта ач җанварлар зәһәрләнеп улый. Ләкин без ул тынгысыз күршеләргә игътибар итмәдек. Без үзебезнең дә ач булуыбызны сизмәдек (курсантларга бирелә торган бәрлы-юклы паегыбызның бер өлешен үз теләгебез белән Идел буендагы ачларга һәм үзебезнең шефлык иткән балалар йортына бирә идек). Алексеевский равелин зинданында язылган романны тыңлаганда, якты, югары моральле, ир йөрәкле көрәшчеләр күз алдыбызга килеп басты. Минем дә шундый ук көчле образлар иҗат итәсем килде һәм мин үземә әле бик күп укырга, күп уйларга кирәклеген аңладым.

Ләкин әдәбиятта «яңа чыккан» әсәрләрне йотлыгып укый торгач һәм төрле әдәби төркем (имажинистлар, «ничевоки»лар һ. б.) шагыйрьләренең чыгышларын тыңлагач, мин, аны-моны төшенми, сүзләрнең мәгънәсендә никдидер алышыну-переворот булган икән дигән карарга килдем һәм «иң яңа үрнәкләр» буенча буталчык, тозсыз сүзләр тезәргә тотындым. Бәхеткә каршы, бу суплык чире озакка сузылмады. Андый артык бизәкле сүз уйнатуларның берәүгә дә кирәге булмавына укучылар үзләре ышандырдылар... Дөрес юл табарга миңа Горький ярдәм итте.

Алексей Максимович хакында мин беренче тапкыр Тукайның Лев Толстой үлеменә багышланган мәкаләсен укыганнан соң белдем. Ул югалтуны бик авыр кичергән Тукай Горькийга, аның бәйсез, горур, яхшы сүзләренә тагын да көчлерәк омтыла.

...һәм менә 1928 елда Горький Казанга килде. Җәйге кояшлы көн иде. «Урицкий» теплоходы дебаркадерга килеп туктады. Идел яры тулы халыкның дулкынлануын сүз белән аңлатырлык түгел иде.

— Алексей Максимовичка сәлам! Безнең Горькийга ура! — сүзләре яңгырады.

Горький бездән тормыш турында, китаплар турында сорашты, тормышны тирәнтен өйрәнергә, туган илебезнең киңлекләре буйлап сәяхәт итәргә өндәде...

Бөек язучының вакытын һәм игътибарын алырга кыймыйча, байтак икеләнеп торганнан соң, мин шулай да аңа «Шобага» дигән хикәямнең тәрҗемәсен бирдем. Очсызкырыйсыз зур, мөһим эшләр белән мәшгуль Горький минем җитлекмәгән әсәремне укырга вакыт таба алырмы икән әле, дип уйлаган идем. Ләкин бик ялгышканмын! Казаннан китеп берничә көннән соң ук Алексей Максимович миңа хат җибәрде. «Сезнең бүләкне — «Шобага» хикәясенең кульязмасын алдым. Рөхсәт итсәгез, мин Сезгә гадирәк язарга киңәш итәр идем: чын матурлык һәм акыллылык һәрвакыт гадилектә...» — дип язган иде ул.

Мин гадирәк, димәк, яхшырак яза башладым. Миндәге зур үзгәрешне укучылар да абайладылар һәм хупладылар. Моны мин бигрәк тә татар язучыларының Дагыстан, Әзәрбәйҗан, Грузия, Украинага иҗади экскурсиясе вакытында сиздем (безнең ул сәяхәт Горький тәкъдиме буенча оештырылып, анда татар совет әдәбиятының Шәриф Камал, һади Такташ кебек күренекле осталары да катнашкан иде).

Идел буенда, Закавказье, Кырымда беренче колхозлар оештырылган һәм зур фабрика-заводларның нигезе салына башлаган еллар иде ул. Бөтен илдә күтәренке рух белән социалистик төзелеш барганы сизелә иде. Без яңа тормышның иске дөнья калдыклары белән аяусыз көрәш шартларында тууын күрдек. Татар язучыларының яңа китаплары шул вакытларның җанлы яңгырашы булды. Минем «Якты сукмак», «Кояшлы яңгыр» повестьларым да шулай ук тормышны социалистик нигездә яңадан кору темасына багышланганнар иде.

Сәяхәт кылып кайтышлый Алексей Максимович белән тагын, бу юлы Мәскәүдә очраштык. Ул безнең тугандаш совет республикалары буйлап йөрүебез турында сөйләгәннәрне игътибар белән тыңлап, язучылар, колхозчылар, эшчеләр белән очрашулар хакында җентекләп сораштырып утырды. Ә биш елдан соң совет язучыларының Беренче бөтенсоюз съездында без инде Горький белән күптәнге танышлар кебек очраштык.

Милли әдәбиятлар турындагы докладлардан соң, Горький төрле республикалардан килгән язучыларның байтагын үз дачасына чакырды. Без, ачык верандада озын өстәл тирәсенә утырышып, аның яхшы күңел белән сөйләгән тирән, акыллы сүзләрен, гомергә онытмый истә калдырырга тырышып, тыңладык. Ул шунда, рус укучыларын милли әдәбиятларның иң яхшы әсәрләре белән таныштырыр өчен, аерым журнал оештырырга тәкъдим итте. Без, барыбыз бердәм шатланып, Горькийның бу тәкъдименә

кушылдык, билгеле. Хәзер «Дружба народов» дигән айлык журналга әйләнгән әдәби альманах әнә шулай дөньяга килде.

Кичкырын, Мәскәү елгасы ярларыннан салкынча җил исә башлагач, без бүлмәләргә кердек. Алексей Толстой, Новиков-Прибой, Николай Тихонов, Всеволод Вишневский, Петр Павленколар һәм милли республикаларның күренекле язучылары катнашкан әңгәмә торган саен җанлана барды.

Әңгәмә бүленеп торган бер арада мин, Горький янына барып утырып, үземнең язарга уйлаган китабым турында сөйләдем (бик күп еллар эшләгәннән соң «Язгы җилләр» романы булып чыкты ул китап). Башта төзегән планым буенча, мин анда Казан фабрикантлары, сәүдәгәрләрнең образларын кертмәскә уйлаган идем. Горькийның мине шелтәләгән сыман башын чайкап әйткән сүзләре хәтеремдә саклана:

— Ничек инде Сез, кадерлем, шундый романда буржуйларны читтә калдырып үтәргә булдыгыз. Алай булганда, ул китапта сыйнфый көрәш булмаячак бит. Тормыш та башка иде бит...

Һәм ул шунда ук, сүз барышы уңаенда, үзе белгән Казан байларының кайберләренең портретын берничә сүз белән сурәтли барды.

Соңыннан, романымда тимерче Мостафаның фабрикант Вәлишин белән бәрелешү күренешләрен язган чагымда, Алексей Максимович миңа тормышны төрле ягыннан ачыграк, көчлерәк, тирәнрәк сурәтләргә кушып, янәшәмдә карап утыргандай тоелды.

Хәтта хәзер дә, яңа роман язган чакта да мин Горькийның 1928 елны Казанга килгәндә әйткән кайнар сүзләрен ишеткәндәй булам:

«Мин зур максатлы, көчле ихтыярлы кешеләргә баш иям. Элек минем хыялымда гына булган кешеләр хәзер яшиләр, эшлиләр, сөйләшәләр һәм бөек эш башкаралар. Сезнең ихтыярыгыз белән дөнья үзгәртелеп төзелә, сезнең ихтыярыгыз кешелек дөньясының үсүенә комачаулаган нәрсәләрне юк итәчәк».

Үземнең яңа романымда минем нәкъ әнә шул кешеләрне, Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә бөтен илне үзгәртеп яңадан төзегән көчле ихтыярлы, максатлы кешеләрне күрсәтәсем килә; хәзер алар, бердәм тыгыз сафларга тезелеп, шатлыклы, якты коммунизм биеклекләренә таба баралар.

«Язгы җилләр» романы өчен Дәүләт премиясе белән бүләкләнү минем тормышта бик зур вакыйга булды. Бу зур бүләкне мин совет кешеләренең халыклар арасында дуслык өчен, тынычлык өчен, коммунизмның җиңүе өчен героик көрәше турында яңа әсәрләр язып акларга тырышачакмын.

1955 ел, 3 май.

---

К. Нәҗминең бу мәкаләсе «Советские писатели. Автобиографии в двух томах» (том II. Москва, 1959. Составители Б. Я. Брайнина и Е. Ф. Никитина) дигән китапта рус телендә басылып чыкты. Мәкаләнең ахырында төзүчеләрнең түбәндәге искәрмәсе бар:

«Кави Нәҗми безгә сәйләп шикелле тезелгән матур вак хәрефләр белән тулы калын дәфтәр җибәргән һәм ул кулъязма «Автобиографиянең кайбер битләре» дип аталган иде. Биредә ул кыскартылып басылды.

Кави Нәҗми соңгы елларда халыкның Совет власте өчен героик көрәше турында яңа роман яза иде һәм аны Бөек Октябрь революциясенең кырык еллыгына тәгәлләргә ниятли иде.

Кави Нәҗми 1957 елның 24 мартында Казанда үлде».

Мәкалә китап тексты буенча С. Әдһәмова тәрҗемәсендә бирелә.

* * *

...Казакъ даласында 9 яшьлек көтүче булып йөргәндә мин әле шигырь яза белми идем. Ләкин казакъның гаҗәеп тирән моңлы үләңнәрен тыңлап, шулардан тәм таба торган идем. Казакъ килененең бала тирбәткәндәге бер җыры минем хәтердә әлегәчә сакланган. Менә аңардан бер өзек:

Әлди, әлди, ак бупәм,
Ак түсәккә жат, бупәм.
Жылама, бупәм, жылама —
Җилек чагып бирәен.
Ала эттең койрыгын
Җепкә тагып бирәен...
Әйналаен, чырагым,
Ханыма алып чабаен...
Туйга киткән әкәнде
Кайдан эздәп табаин...

Актүбә капиталистларыннан Сабит Алюковның хуторында су ташып, утын ярып, башка авыр эшләрен үтәп (ул вакытта миңа унберенче яшь иде) йөргәндә дә мин шигырь яза белми идем. Ләкин хутордагы переселенец хохол кызларының кичке хороводтагы җырлары минем йөрәккә тирән эз сыздылар. Шунлыктанмыдыр, 1912 елда Актүбә мәктәбендә укыганда (мин анда миссионерский школдан качып кердем. Казакъ балаларын чукындыру өчен салынган ул мәктәпкә мине Сабит Алюков көчләп биргән иде.) «Күз» исемле беренче «шигыремне» яздым. Ул вакытта Актүбә мәктәбендәге тел мөгаллиме Габдрахман Сәгъди һәм башкалар шул шигырьне, минем яшем белән чагыштырып, яхшы ук уңышлы дип таптылар. М. Гали дә, Хәйретдин Вәли дә ул вакытта кыршылган фәс киеп йөрүче, ертык киемле «нәни имажинистны» белмиләр иде (кыршылган фәсне мин Бакчасарайдан алып кайттым. Бакчасарайда без 1907 елда булдык. Ул елны минем әти Исмәгыйл Гаспринский мәктәбендә сторож-каравылчы булып торды). Шуннан соң...

Мин «Вакыт» газетасына берничә шигырь яздым. Басмадылар. Сәбәбен дә язмадылар.

Шуннан соң...

Әти дә үлде, әни дә үлде.

Шуннан соң...

17 ел да җитте. 18 ел да җитте. 18 елның язында Казанканың Бишбалта артындагы бер өлешенә туктаган баржалардан күн заводына каеры ташыдым. Көненә 25 тиен түләделәр (10 тиен — постоялый дворга, калганы — ашарга).

18 елның кышында «Эшче» газетасында берничә шигырем басылды. 19 елның башында Сембер педкурсларына алдылар. Августта партиягә язылдым. Ноябрьда (яшем 18 дә булуга карамыйча) Кызыл Армиягә теләп киттем. Фронтлар вакытында рәтләп язып та, бастырып та булмады. Фронтлар бетеп, Мәскәүгә эләккәч кенә, тагын бераз шигырь-хикәя белән шаяру мөмкинлеге туды. Әдәби эшемнең калган ягы күз алдыгызда — газета-журнал битләрендә үтте...

Матур әдәбиятка бирерлек вакыт рәтләп булганы юк. Күбесенчә якшәмбе көннәрен генә файдаланам. Шуңар күрә язмаларымда өзеклек, гасабилек, ашыгучанлык билгеләре бәрелеп торалар...

Соңгы вакытларда мин бераз «акылга да утыра» башладым. Укучыларымның теләкләре белән дә исәпләшәм. Ләкин укучыларымның да, тәнкыйтьчеләремнең дә койрыкларына гына тагыласым, естерәләсем килми. Анысын гафу итәсез, сез теләгәнчә эшләп булмас.

Укучыларның теләкләрен үтәү өчен (бәйләнешсез) әйберләрдән, кисәк-кисәклардан кул селкедем. Хәзер мин үземнең көчемне, буш вакытымның һәрбер кисәген бәйләнешле әсәр бирү, киң иңле киндерләргә гаҗәеп күп тармаклы тормышыбызның бөек моментларын, аеруча характерлы типларын, тирән мәгънәле вакыйгаларын шәүләләндерү юлына багышлыйм. Ел ярымнан бирле бер бөтен әсәр (роман) язу өстендә көчәнәм...

---

Бу өзекләр К. Наҗминең «Беренчесе дә, соңгысы да шушы булсын!» диган мәкаләсеннән алынды. Мәкалә тулы килеш «Безнең юл» журналының 1927 елгы 6—7 саннарында басылып чыккан иде.

# ӘДӘБИ КҮМӘКЛӘР

...Октябрь революциясе миллионнарның иҗат энергиясен ачып җибәрде һәм илебездәге барлык халыкларның әдәбиятлары үсешенә этәргеч көч бирде дип әйтәбез икән, бу хакыйкатьне теге яки бу әдипне бәяләү белән генә түгел, бәлки аларның иҗат оешмаларына да дөрес характеристика бирү ярдәмендә дәлилләргә кирәк. Октябрь революциясенә кадәр татар язучыларының үз әсәрләрен, иҗат проблемаларын тикшерерлек аз санлы коллективы да юк иде. Ул гына да түгел, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал кебек язучылар да беренче тапкыр совет чорында гына Казан шәһәрендә очраштылар. Ә бит менә шундый очрашулар, бергәләп иҗтимагый-әдәби эш алып бару өчен уңай шартларны беренче әдәби күмәкләр: «Завод» — 1923 ел (миңа да аны оештыручыларның берсе булырга туры килде), «Часовой» (Шамил Усманов тарафыннан 1923 елда оештырылды), «Октябрь» (1924 елның башында Казан шәһәре коммунистларының Үзәк клубы каршында оештырылды) тудырдылар; Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, М. Фәйзи, М. Җәлил, К. Нәҗми, Ф. Әсгат, А. Шамов, Г. Кутуй, Ш. Усманов, Г. Толымбайский, Г. Гали, Ә. Исхак һ. б. бу зур коллективның членнары иде. Коллектив предприятиеләрдә, уку йортларында, Татарстан районнарында әдәби түгәрәкләр белән җитәкчелек итте. Бу коллектив оештырган әдәби кичәләр, җыелышлар, диспутлар һәрвакыт күп санлы аудитория катнашында уздылар. Диспутларда һәм кичәләрдә еш кына Ф. Әмирхан, Г. Камал, К. Тинчурин, М. Гали һ. б. «Октябрь»гә кермәгән язучылар да катнаша иде. Коллектив «Иптәш» исемле әдәби стенгазета чыгарып килде, газета һәм журнал битләрендә күп әсәрләр бастырды, В. И. Ленин истәлегенә багышланган «Ленин» исемле зур җыентык, гражданнар сугышы геройлары турында «Кызыл Армия сафында татар-башкортлар» дигән җыентык чыгарды, буржуаз милләтчелек идеологиясенә, мещанлыкка каршы актив көрәш алып барды...

«Октябрь»нең совет әдәбиятына керткән уңышлы өлеше газеталарда һәм журналларда, аның әгъзаларының шул елларда чыгарган китапларында ачык чагыла. «Октябрь» коллективының төп, программ положениесе — укучыларны Коммунистлар партиясенә бирелгәнлек рухында, совет патриотизмы һәм халыклар дуслыгы рухында тәрбияләү — аның уставында һәм газеталарда басылып чыккан иҗат декларациясендә генә язылып калмады, ул «Октябрь» членнарының иң яхшы әсәрләрендә дә ачык чагылды. «Октябрь» членнарының азчылык өлеше «Сулф» («Сул фронт» — ред.) группасына аерылгач (20 апрель, 1924), «Октябрь» членнарының җыелышы да бертавыштан түбәндәге карар кабул итте:

«Сулф» үзенең бөтен адымнары белән әдәбиятның пролетариат революциясендә уйнаган ролен билгеләүдә ялгышлык эшләде. Сулфчылар чыгу белән «Октябрь»нең сан ягыннан сафлары сирәкләнсә дә, революцион эшче-крестьян сәнгатен тудыруга дәрте кочәюгә, әдәбияттагы позициясе ныгуга сәбәп булачак. Сулф, футуризм алымнарын гына пролетарныкы санап, кастовый оешмага әверелсә, «Октябрь» күмәге үзенең идеологиясе белән дә, әдәби-иҗат эшләренең тирәнәя баруы белән дә, буржуазия идеологиясенә каршы көрәшнең нык оешкан отряды булачак».

1924 елның 22 июнендә үткәрелгән җыелышта бу мәсьәлә кабат тикшерелде. Җыелышта «Октябрь»нең 16 члены, Уфа партия мәктәбеннән килгән 12 экскурсант, әдәби түгәрәкләрдән 20 вәкил бар иде. Сөйләгән иптәшләр «Сулф»ны эшче-крестьян язучылары арасына таркаулык кертүдә гаепләп чыктылар. Җыелышта «Октябрь»нең линиясен дөрес дип табарга һәм, Коммунистлар партиясе членнарының төрле әдәби күмәкләрдә эшләвенең зарарлы булуын искә алып, сулфчыларга «Октябрь»гә кайтырга тәкъдим итәргә, «Сулф»ның бу тәкъдиме белән риза булган членнарының гаризаларын «Октябрь»дә карау өчен кабул итәргә, дигән карар кабул ителде.

Һәм чынлап та «Сулф»ның иң талантлы членнары яңадан «Октябрь»гә керделәр, ә соңрак бергәләп Пролетариат язучыларының татар ассоциациясен (Татарская ассо-

циация пролетарских писателей — ТАПП — ред.] оештырдылар. Бу ассоциациянең геп көчләре Татарстан совет язучылары союзын оештырды...

*11 октябрь, 1956 ел.*

---

Бу өзек Хәсән Хәйринең «Очерки развития современной татарской литературы» дигән кульязмасы турында язылган эчке рецензиядән алынды. Матбугатта беренче тапкыр басыла.

Хәсән Хәйринең бу хезмәтен Татарстан китап нәшрияты, «Современная татарская литература» исеме белән, 1957 елда аерым китап итеп бастырып чыгарды.

## КЕШЕЛӘР ДӘ ЯҢА, ҖЫРЛАР ДА...

...Матур әдәбиятта күчеш — преемственность дигән хасият бар. Кешеләр дә яңа, җырлар да яңа. Тик бу җырларның иҗтимагый моңы үткәнгә тамырланган. Ул тарих белән бәйләнгән. Ләкин бу бәйләнеш аңа яңаны тудырырга, үз чорының тормышын шәүләләндерергә комачауламый. Бездә Тукай белән Бабичтан һәм бер кисәге Дәрдмәнд белән Сәгыйть Рәмиевтән күчкән аһәңнәр, иҗтимагый лирикага бәгланышлы кайбер аккордлар юкмыни!

Алыгыз Такташның «нәләт»ле, «гыйсъян»лы чорын. Монда татар әдәбияты белән аз гына таныш булган кеше дә Сәгыйть Рәмиев гармониясен, ләкин аңарга караганда көчлерәк бирелгән кормасын таныр.

Алыгыз Бурнашны. Тукайның варисы [Тукай стиленә иярүче] булу өчен никадәрле тәҗрибәләр ясамады!.. Бурнашта да без Тукай гармониясен, ләкин йомшаграк, ясалмарак эшләнгән охшауларны күрәбез.

«Пәйгамбәр сөннәте» булсын дигәндәй, өченче мисалга Кәрим Әмирине китереп кыстырыйк. Монда вакыты-вакыты белән Дәрдмәнд чаткылары чәчрәмәдеме! Ул хәзер дә әле шул чаткыларның эзен кырып бетерә алмый.

Менә шушы күренештә шигъри ташкыннарның табышмагы. Элек тудырылган эштән файдалы якларын күчереп тә, шуның белән бергә үз тирәңә, хәзерге барышыңа пар булып төшердәй яңалыкны тезү сере ята. Сез пароход барган вакытта артыннан калган дулкыннарын күргәнсездер. Менә шавылдап, күбекләнеп бер дулкын чыкты. Аның артыннан икенчесе, өченчесе. Ни өчендер ул дулкыннарның күләме, бөтерелгән урыннары, бәрелгән көчләре, түгәрәкләнеп китеп әкрен генә тынулары бер төсле була. Тик пароход кинәт борылган чакта яки каршыдан буксир-фәлән узып киткәндә генә ул дулкыннарның тышкы килбәтләре үзгәрә.

Матур әдәбиятта да әнә шулай. Тормыш корабы кинәт борылганда яки икенче тормышның барышы моңа килеп бәрелгәндә, әдәбият дулкыннарының килеше үзгәрә. Көчләре зурая — су төбендәге, яр кырыендагы юшкыннарны куптарып болганчык төскә кертәләр. Соңыннан, бәрелешү кискенлеге тына барган саен, дулкыннар сафлана-лар — тавышлары да тәртипсез котыру, дуылдау формасыннан билгеле бер система буенча шаулаган моңга, көйгә әверелә.

Ике әдәби стихиянең әлегәчә әреләнгән бәйләнеше — укучының үзе аркылы да, аның тормышлы сюжетка, иҗтимагый лирикага сусавы аркылы да өскә калка. Бу хәл фәнгә дә каршы түгел. Мисал урынында пролетариат укучыны алып тикшерик: аның эш белән үрелгән тормышы — баштанаяк сюжетлы. Ягъни көндәлек барышындагы хәрәкәтләр, вакыйгалар, уйлар белән тулы. Шуңа күрә ул әдәбияттан да шуның шәүләсен эзли. Ул шушы фактларны, ягъни тормышны иҗтимагый тойгылар, җанлы образлар белән биргән шигырьне эзли...

...Безнең хәзерге әдәбиятыбызда һәм эшче, һәм крестьян укучыларын тәрбияләрлек көчләр байтак:

Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Толымбай, Исәнбәт, Ш. Усманов, Бурнаш, Афзал Таһиров, Кәримов, Туфан, Максуд, Юлтый һәм башкалар. Алар бары да шул отрядның солдатлары.

Без монда аларның байтагына, бәлки, тукталырбыз, бәлки, юк. Мәсьәләнең уп ягы куелган сорауларның ничек чишелүенә карый.

Башлыйк Такташтан.

Ул инде:

> Сиңа биреп җырларымны
> Калыйм мәллә монда, югыйсә,—

дип моң гына, тымызык кына зәңгәр күзләрен дә киләчәккә төбәп алды. Ләкин ни булса да Такташ — бөтен шагыйрь. Үзенең әллә никадәрле кимчелекләренә (күбебездә очрый торган кимчелекләргә) карамастан, көчле мәктәп тудырырлык бөтен шагыйрь.

Ул, бәлки, үзенең шагыйрьлек гомеренә нык перспектива сыза алмагандыр. Бәлки, кайсыбер моментларда аягын «шап» иттереп басарга да кыймыйдыр. Анысы икенче мәсьәлә. Безне башка ягы, бүгенге тормышны җырлый алу ноктасы кызыктыра. Хәзерге тормыш вак-төяктән, бөек азатлык теләгенә табан борылган очсызкырыйсыз винтлардан җыела. Укучының инстинкты — үз тормышына бәйләнгән, үз йөрәгендә чәчәк аткан әнә шул «вак-төякләр»не эзли. Шуның шигъри калыпка салынганын табарга тырыша. Үтелгән елларның, кичәге гомерләрнең дә шулай ук бүгенгечә итеп җырлануын сорый. Укучыга ярау өчен заманнарны әнә шулай итеп үрә белергә, кызыктырырлык сюжет, җанлы кешеләр белән аралаштыра белергә кирәк. Такташ — үзенә чордаш башка талантлы язучылар белән шул юлда уңышлы адым атлаучыларның берседер.

Хәзер инде, революциянең унынчы елында, кайбер шагыйрьләр кебек һаман «таңнар», «тимерләр», «каннар», «кызыллык» турында конкретсыз җырлар җырлау, чынлап та, килешмәс иде. Такташ ул «бәла»дән сиксән проценты белән котылды дияргә ярый. Ул киләчәкне һәм хәзергене төзүче тере кешеләргә — Зөбәйдәләргә, Әүхәдиләргә, Шәйхи бабайларга, тормыштагыча нык күрсәтелгән яшь буынга, хәзерге авылдагы агай-энеләргә күчте. Хәзер инде аңарда илаһи тавышлар да, томанлы фетнәләр дә, буш залда япа-ялгыз «нәләт» кычкырулар да сизелми. Аның хәзер киң итеп ачылган авызы, елмайган бите, нindидер хәйләкәрлек, шаянлык белән ярым кысылган күзләре генә ялтырый. Һәм шул авыздан, шул биттән, шул күзләрдән ирекле-ирексез:

> Бүген урам буйлап үткән чакта,
> Очраттым мин аның бересен,
> Ал галстук таккан, янар күзле,
> Киләчәкнең тимер кешесен! —

дигән сүзләрне укыйсың. Чынлап та ал галстугы бар, чынлап та янар күзле, чынлап та тимер кебек бу кеше — киләчәкнеке!

Такташ та бу кешедән калышмаска тиеш. Тимер кебек янар күзле укучыларга әле бик күп азык, яхшы азык кирәк.

Күчик Туфанга.

Татар әдәбиятында кем тарафыннандыр «тудырылып үтерелгән» имажинистлык образларын тырпайтып, дулап, ташкынланып чыккан бу талант башта ук усал сүзләргә, әрсезлеккә юмарт иде.

Крейсер, титан, набат, вулкан, дикапут, дезинфекция, шрапнельләр... белән башта ук ми тамырларын «туфанайтып», паркетка «ми чәчеп» котны алды. Туфанның беренче шигырьләре чынлап та җиңелдән түгел. Алар тимердән эшләнгән бик авыр бер нәрсәгә, дикапутка, крейсергә охшыйлар. Мондый шигырь озынрак булса, укучының башы чынлап та «шпал күк шыгырдый» башлый. Куе тавышы, чыңгырдап торган сүзләр, дүрт кыйблага эленгән күп тармаклы перспектива чынлап та күзләрне талдыра. Ләкин Туфанга рәхмәт әйтерлек тә бар. Ул кыска гына җөмләләр белән кыска гына шигырьләр язгалый. Бу вакытта аны укучы да яратып каршы ала. Туфан соңгы чакта менә шушы юлга, укучы белән якынаю юлына борылды. Борылып яхшы итте.

«Аягүрә үлеп булыр микән», «Урал эскизлары», «Җырланмаган җырлар», хәтта «Козырь туз»ы да — әнә шул борылышның матур билгеләре. Туфан элекке дорфалыгыннан никадәр ераклашса, шулхәтле яхшы. Үзе өчен дә, укучы өчен дә яхшы. Чөнки аны хәзер сөеп кенә укучылар бар. Һәрбер яхшы шигырь чыккан саен бу катлау калыная, үсә. Газета өчен тиражның кирәклеге никадәр зур булса, язучылар өчен аңардан битәр зуррак. Тираж киму — үлем билгесе. Андый талант озакка бара алмый. Тиражны киметмәс өчен укучыларның соравын тәэмин итә белергә кирәк. Туфан хәзер моны төшенгән. Шаять инде кулыннан ычкындырмас!

Безнең башлар
Давылларда,
Данлы давылларда гомер итәләр:
Һәр икәүнең гомере — тиңсез роман,
Һәр берәүнең көне — хикәя.

дип әйтерлек көч тапкан Туфан, әнә шул давылларда гомер итүчеләрне тиңсез романнарга кертә алырмы, юкмы дип шикләнү бик үк ярап бетмәс. Әмма шул теләкне үткәрергә тиешлеге турында ике сүз булырга мөмкин түгел. Үтәргә тиеш, дибез. Чөнки Туфан үзенең тойгысы белән, шигырьләренең ритмикасы белән укучыга, бигрәк тә пролетариат укучыга якынлашып бара. Аның шигырьләрендә көчле антитеза, сизгер фәлсәфә парчалары ярылып яталар. Шуның өстәвенә шатлык, күтәренкелек тамгалары һәрбер шигыренә кырылмаслык эз салганнар...

*1927 ел.*

---

Бу өзекләр К. Нәҗминең «?.. ?.. ?.. (Мәсьәләне кую урынында)» исем астында «Кызыл Татарстан» газетасының 1927 елгы 12, 13, 16, 18 февраль саннарында басылып чыккан һәм вакытында шактый бәхәсләр уяткан мәкаләсеннән алынды. Мәкалә К. Нәҗминең моңарчы чыккан бер җыентыгына да кертелмәгән.

Гали Халит

# ХАЛЫКЧАН ҺӘМ ТОРМЫШЧАН СӘНГАТЬ ӨЧЕН

Безнең әдәби-эстетик фикер тарихын өйрәнү мәсьәләсе хәзерге әдәбият белемебезнең көн тәртибенә куелды инде. Әдәбият тарихын һәм бигрәк тә аерым язучыларның иҗатын тикшерүгә багышланган хезмәтләрдә бу мәсьәләнең конкрет якларына игътибар еш очрый башлады. Әмма шулай да аның үзәгендә торган төп проблемалар эзлекле, системалы рәвештә күз алдына китерелүне һәм гомумиләштерелүне көтеп яталар әле. Болар арасыннан аеруча халыкчанлык һәм тормышчанлык, реализм һәм романтизм тирәсендә күтәрелгән фикерләр егерменче йөз башындагы әдәби хәрәкәтебезнең иң олы мәсьәләләре икәнлеген әйтергә кирәк. Без бу мәкаләдә әнә шул мәсьәләләргә игътибар итәргә теләдек.

## 1

Егерменче йөз башындагы татар язучыларының байтагы теге я бу уңай белән үзләренең әдәби-эстетик фикерләрен әйтеп яки язып калдырганнар. Беренче итеп Г. Тукайны алып карыйк. Әдәбият юлына аяк басу белән үк шагыйрь халыкчанлык һәм миллилек мәсьәләләренә игътибарын юнәлтә. Аның «Хиссияте миллия» (1906) һәм «Шигырьләребез» (1907) кебәк беренче мәкаләләрендә үк шушы ике мәсьәләгә җавап бирергә омтылыш бар иде. Тукайча, әдипнең, художникның милли хисе изелгән халыкка хезмәт итү теләгеннән аерылгысыз булырга тиеш. «Хиссияте миллия» мәкаләсенең эчтәлеге тулысы белән шуны раслый. Шулай итеп, Тукай татар әдәбиятының һәм сәнгатенең төп демократик рухын халыкчанлыкта таба. Үткәндәге татар әдәбиятына әнә шундый бик әһәмиятле сыйфатның җитмәвен күреп, «Шигырьләребез» исемле мәкаләсендә шагыйрь болай ди: «Суфи Аллаһеяр вә Утыз-Имәни хәзрәтләре бертөрле назымлырак[1] шигырь сөйли белмешләр исә дә, тик тасауыф (суфичылык) бабында гына сөйләгәннәр. Әгәр ул әфәнделәр дөньяга вә аның халкына да бераз илтифат итеп дөньядан киткән булсалар, хәзерге көндә исемнәре тагы да артык хәер илә зикер ителер иде». Бу очракта инде Тукай, бик аңлаешлы итеп, татар поэзиясенең дөньяга, чынбарлыкка һәм халыкка якын килергә тиешлегенә басым белән сөйли. Димәк, әдәбиятның тормышчанлыгын

[1] Назымлы — ритмлы, көйле мәгънәсендә. (Моннан соң аерым сүзләргә аңлатмалар җәяләр эчендә биреләчәк.— Г. Х.).

яклый. Моннан, һич тә икеләнмичә, Тукайның башлангыч эстетик карашларында ук инде татар поэзиясенең миллилеген халыкчанлык һәм тормышчанлык белән бәйләнештә аңларга омтылыш сизелеп торды, дигән нәтиҗә ясарга була. Аның бу омтылышы рус язучыларыннан Крылов, Пушкин, Лермонтов, Кольцов һәм Л. Толстойга булган мөнәсәбәтләреннән дә ачык күренә. Тукай бу язучылар иҗатында нәкъ халыкчанлык белән тормышчанлыкның югары үрнәкләрен тапты. Шагыйрьнең моннан соңгы бөтен иҗат юлы шул принципларны эзлекле үстерү һәм баету юнәлешендә барды. Болар һәммәсе бергә аның эстетик карашларында реализмны яклау көчле булуы турында сөйлиләр. Ләкин моннан Тукайның башка иҗат методларына һәм әдәби юнәлешләргә мөнәсәбәте гел кире булды, дигән нәтиҗә чыкмый әле. Бер үк дәрәҗәдә дияргә мөмкин, ул романтик Пушкинны һәм Лермонтовны да, Байрон һәм Гейнены да, Нәвои һәм Низамины да якын күрде. Аның бу даһиларга мәхәббәтен классик романтизм эстетикасына теләктәшлегеннән аерып карау мөмкин түгел, әлбәттә. Шул рәвешчә, Тукайның эстетик карашларында һәм иҗат практикасында ике зур башлангычның — реаль һәм идеаль поэзиянең, төгәлрәк алганда, реализм белән романтизмның бер-берсенә якынлашуы, синтезы барлыкка килде. Бу синтезда, һичшиксез, халыкчанлык һәм тормышчанлык принциплары өстенлек итте.

Тукай эстетик карашлары белән якынлык һәм уртаклык тагын да Ф. Әмирхан фикерләрендә күренде. Тукай шикелле үк, ул да татар әдәбиятының халыкчан һәм тормышчан булырга тиешлеген беренче шарт итеп куйды. 1907 елда ук инде «Габдулла Тукаев шигырьләре» дигән рецензиясендә ул һәр милләтнең шагыйрьләре «шул халыкның кайгы вә шатлыкларын үзләренә вә башкаларга дөрес сурәттә аңлатучы» булулары турында язган иде. Беренче нәүбәттә халык уй-тойгыларын ачык, тулы һәм дөрес итеп чагылдыра алуы белән шагыйрь үз талантының дәрәҗәсен күрсәтә дигән критерий иде ул. Ф. Әмирхан, барыннан да элек, чынбарлыкка иҗтимагый-объектив караш булырга тиешлекне аңлап фикер йөртте: «Хакыйкатьтә тормыш алай ике генә катлы нәрсә түгел! Кешеләр, аларның рухани тормышлары; сыйныфлар, аларның тормышлары — һәммәсе шулкадәр күп төрләргә, күп фиркаләргә аерылалар ки, аларны озак вакытлар хосусый өйрәнгәннән соң гына яхшы аңлап җиткерә алсаң да куанырга кирәк әле». («Мәдрәсәләрдә әдәбият дәресләре». 1913.) Шуңа күрә аның әдәбиятка да шушы ук позициядән карарга омтылышы сизелде. Ул тормышны өстән генә, тик «милли күзлек» аша гына чагылдыруны каты тәнкыйть итте. Аныңча, әдәби әсәр нигезендә яткан төп идея иҗтимагый тормышка объектив, дөрес караштан үсеп чыгарга тиеш. Менә шул хакыйкатьне искә алмый язылган әсәрләргә Ф. Әмирханның мөнәсәбәте бик кискен булды. Бу яктан, мәсәлән, аның Я. Вәли драмасына бәясе бик характерлы: «Мондый олуг темалар,— диелә аның бер рецензиясендә,— хосусан, бөтен бер халыкның, хәтта бер мәмләкәтнең халәте икътисадиясеннән (экономик хәлләреннән) килгән күренешләр хакында язылган драмалар социаль характерда язылырга вә асыл сәбәп булган яманлык, төрле тарафларыннан вә сәбәпләре белән тәфтиш ителеп (тикшерелеп), укучы күз алдында тәрсим ителергә (сынландырылырга) тиешләр. Әмма «Ачлык кушты» драмасы нәкъ шушы нәрсәләрдән мәхрүм... Менә шуңар күрә дә минем бу теманы милли драмаларга гына сыймый торган бик зур нәрсә диясем килә». («Ачлык кушты». 1908.) Ф. Әмирхан 1909 елгы 25 февраль хатында да шушы ук фикерләрен дәвам иттерә: «Язарга да, ләкин дөньяда бер үк мисалы булмаган, берәүгә дә бер җәһәттән дә охшамаган типлар язарга? Ул бит минем Ярулла Вәли булып китүем дигән сүз. Ул бит, хәяттән алынган нәрсә язмыйча, «Җанлы җеназа»лар язу дигән сүз!»[1]

Әсәрнең эчтәлеге һәм геройлары тормыштан алынган булырга тиешлекне Ф. Әмирхан игътибар үзәгенә куеп сөйләде. Шул яктан аның тагын Закир Һадиның «Җиһанша хәзрәт» әсәренә рецензиясе дә кызыклы. «Монда Һади әфәнде татар мәгыйшәтенең ничек үзеннән-үзе «зур ишан хәзрәтләр» китереп чыгара икәнен бик дөрес вә матур тасвир иткән...— ди ул.— Моның белән бәрабәр, Һади әфәнде китабының күп җи-

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1961 ел. 1 сан. 107 бит.

рендә объективизм саклап, ифрат вә мөбаләгаләрдән (арттырып җибәрүләрдән) ерак торадыр. Татар матбугатында бу сыйфат хәзергә кадәр бик аз табылганлыктан, шаян тәкъдир мәхассиннәреннән (игътибарга лаек эшләрдән) берседер». («Җиһанша хәзрәт». 1908).

Безнең әдәбиятта ул вакытларда нык сизелгән дидактизм һәм натурализм кебек күренешләрне куып чыгару өчен көрәшкәндә, Ф. Әмирхан реализм позициясеннән торып эш итте. Аның критерийлары әдәби әсәрнең тормыш чынбарлыгына сәнгатьчә никадәр якын булу-булмавыннан чыгып алындылар. Бу моментка, мәсәлән, С. Рәмиевнең «Низамлы мәдрәсә» комедиясе уңае белән язылган рецензиясендә дә игътибар ителгән иде. Чынбарлыкның иҗтимагый әһәмиятле ягын күрә һәм чагылдыра белүне таләп итү белән бергә, Ф. Әмирхан әдәби геройны типиклаштыруның да мәгънәсен билгели. Бу урында Г. Камалның «Беренче театр»ына карата фикерләре гыйбрәтле: «Галиәсгар әфәнде бу әсәрен хосусый бер гаиләнең мәгыйшәтеннән алып язган булса да, урта буржуаз класcның психологиясен бик яхшы төшенгәнлектән, комедиянең каһарманнарына бик оста сурәттә гомумият бирә вә, шулай итеп, бу кыска комедиясен гомуми, ярым «мөтәрәкъкый» купецларыбызның мәгыйшәт вә дингә назарларының (караш-ларының) бик тугры көзгесе итеп чыгарадыр». («Беренче театр». 1908.)

Димәк, Г. Камал комедиясендәге геройларның типиклыгы аларның урта татар сәүдәгәр сыйныфы психологиясенә хас сыйфатларны дөрес һәм тулы чагылдыруында икән. Бу, һичшиксез, реалистик типиклаштыру концепциясе булып, Г. Камал иҗатының бик әһәмиятле ягын ачу иде.

Ф. Әмирханның төрле уңай белән әйтелгән фикерләрен әнә шулай бер ноктагарак җыеп караганда, нәкъ реализм әдәбиятына тапкыр принципларның беренче планга куелуы күренә: объектив мөнәсәбәт җирлегендә чынбарлыкның иҗтимагый мәгънәсен тотып ала белү һәм шуңа нисбәтән геройларның, характерларның үз хәрәкәтен, үз үсешен, мөстәкыйль яшәешен күрсәтү, аларның чынбарлык закончалыклары нигезендә ачылуы — менә шундый иде ул принциплар. «Ачлык кушты»ның каһарманнары күбрәк үз телләре белән түгел, бәлки мөәллифнең (авторның) теле белән сөйлиләр. Шуңар күрә картиналары мәгыйшәттән алынса да, каһарманнар мәгыйшәттән алынмаган дияргә мәҗбүр булынадыр»,— дип язды Ф. Әмирхан югарыда искә алынган бер рецензиясендә. Әдәби геройның автор рупоры түгел, ә үз теле белән сөйләүче типик характер булу мәсьәләсен реалистик әдәбиятның бик әһәмиятле сәнгатьчә принципларыннан берсе итеп санавын Ф. Әмирхан Ш. Мостафаның «Фәүзия» хикәясенә рецензиясендә дә әйтте: «Каһарманнарыннан күп фәлсәфә сату таләп итмичә, мәгыйшәтне үз килешеннән үзгәртми күрсәтүне» тәкъдим итте ул бу әсәр авторына. Ф. Әмирханның туры мәгънәсендә критик реализмны яклавын да аның фикерләре арасында очрату кыен түгел. Бигрәк тә Гогольгә багышлы мәкаләсендә ул («Гоголь бәйрәме». 1909) бу рус язучысының бөеклеген аның тормышка тәнкыйть аша каравы белән бәйләп аңлаткан иде.

Гомумән, егерменче йөз башындагы татар әдәбиятын алдынгы дөнья әдәбияты традицияләре һәм эстетик принциплары яктылыгында алга җибәрү теләге куплләгән әдипләребезнең дикъкатен җәлеп итте. Рус һәм Европа классик язучылары мирасының зур тормыш вә халык белән бәйле булуын аңлап бәяләгән мәкаләләрнең татар матбугатында куплап басылуы да очраклы хәл түгел иде. Аларның берсендә, мәсәлән, Лев Толстой «әсәрләре чын тормыштан алынып, тормышның бер төрлесе генә булмый, бәлки һәр сыйныф вә һәр классның төрле типлары вә төрле картиналары күрсәтелгән була» [1],— диелде. Икенчесендә Лермонтов «үзенең Байрон каһарманнары илә шушы яшь Россияне ул вакыттагы Николай дәвере дип мәшһүр, иң кысынкы вә тар рамкалы дәверләрнең тырнагыннан котылырлык итеп тәрбияләде» [2],— дип расланды. Өченчесендә исә Тарас Шевченко, «безнең кебек мәхкүм бер халык эченнән чыгып, үзен һәм сүзен шул халык кайгысын ачык вә ачы рәвештә ифадә итү (әйтү), шулай итеп, аңа җиңеллеккә юл ачу хакында корбан

[1] «Эльислах» газетасы. 1908 ел. 42 сан.
[2] «Аң» журналы. 1914 ел. 18 сан. 335—336 битләр.

итте»[1],— диелде һәм, ниһаять, дүртенчесендә инде: Гейненың «урынлы, искиткеч көчле сатирасы да — иске тормышка каршы ачылган сугыштыр»[2],— кебек фикерләр әйтелде. Болар шул ук вакытта татар язучылары яклаган эстетик фикерләрнең төп юнәлешен билгеләгән мисаллар итеп тә каралырга тиеш. Рус һәм дөнья әдәбият фәне казанышларын истә тотып, татар әдәби-эстетик фикерләрендә дә бик әһәмиятле теоретик мәсьәләләр күтәрелә башлады. Рус тәнкыйтендә, беренче буларак, Белинский киң итеп яктырткан идеаль һәм реаль поэзия концепциясенә игътибар артты. Бу концепциядән килеп, татар әдәбиятындагы реаль һәм идеаль башлангычларның урынын, әһәмиятен билгеләү юнәлешендә фикер йөртелде. Мондый фикерләр, һичшиксез, безнең әдәбиятта реализм һәм романтизм арасындагы тирән бәйләнешне, аларның синтезын аңларга омтылыш яралганлыгын да күрсәтә иде.

Гомумән алганда, әдәбиятның акрынлап «хыялдан хакыйкатькә, күк галәменнән җир тормышына таба» тарихи процесс кичерүе, «тормышның дөрес көзгесе булу» дәрәҗәсенә ирешә алуы турындагы карашлар татар әдәби тәнкыйтендә дә урын алдылар. Менә шуннан чыгып: «Хакыйкый әдәбият булса, тормышның, һичбер алдамый-нитми, бөтен яхшы вә яманын ачык итеп күрсәтә торган көзге булырга тиеш»[3],— дигән нәтиҗә ясалды.

Күп кенә татар классикларының нигездә реаль поэзия (әдәбият) концепциясен алгарак куеп фикер йөртүләренә без берникадәр игътибар иткән идек инде. Монда мәсьәләнең төп куелышы реализмга бәйле икәнлеге шиксез. Дөрес, һәр очракта да реаль поэзия концепциясен гел туры мәгънәсендәге реализмга гына кайтарып калдырырга ярамый. Аның эчтәлегендә әле гомумән әдәбиятның чынбарлык, заман тормышы һәм халык белән бәйләнешен таләп итү мәгънәсе дә бар. Шуңа күрә прогрессив романтизм тарафдарлары да реаль поэзия концепциясен үзләренә чит күрмәделәр. Һәм, киресенчә, реаль поэзия тарафдарлары идеаль поэзияне, конкретрак әйткәндә, романтизмны да кире какмадылар, әмма алар аның җирдән, конкрет тормыштан һәм җанлы реаль кешедән аерылганына теләктәшлек тә итмәделәр.

Шул ук реаль һәм идеаль поэзия концепциясе белән тыгыз бәйләнештә, әдәбиятта типиклык нидән гыйбарәт, дигән сорауга да җавап бирелде. Әдәби әсәр «бер-беренә иң мөһим нокталарда охшаган берничә күренеш яки бер горуһ (төркем) кешенең барысында да табыла торган гомуми сыйфатларны ала да шул сыйфатларны күренешләрдән булган бер күренеш яки кешеләрдән булган бер кеше кыяфәтенә кертә вә шул кыяфәткә үзе җан бирә, аны тәмам терек бернәрсә итеп ясый... Менә шушы кыяфәтне аурупалылар (европалылар) «тип» дип атыйлар... Типларны шагыйрьләр тормыштан алалар. Адәм балаларының бу дөньядагы тормышы җәннәтел фирдәвес тә булмаганга күрә, анда якты вә күркәм яклар да вә караңгы, былчырак яклар да бар. Шуңар күрә аның шигырьгә ике ягы да керә»[1],— шикелле фикерләр инде очраклы булмадылар. Ләкин, шуның белән бергә үк, егерменче йөз башы татар тәнкыйтендә сәнгатьчә объективлыкны һәм типиклыкны автор тенденциозлыгыннан, идея позициясеннән тәмам битараф итеп карарга теләүләр дә ачык сизелеп калды: «Әдәбият нәфисә дөнья эшләрен үзенә асла гарыз (һич максат) итә алмый. Әдәбият нәфисә яхшылыктан, яманлыктан катгый назар (кискен караш) белән тормышны вакыйгъдагы көенчә безгә күрсәтә дә бирә. Безне яхшылыкка да, яманлыкка да өндәми. Теләсәк — яманлыкка әверелеп китәбез,— анысы инде безнең эш»[2]. Әдәби әсәр һәм әдәби герой язучының шәхси, субъектив ниятләреннән бөтенләй ирекле булырга яки алардан читтә торырга тиеш, дигән мондый таләп, әлбәттә, художникның идея тенденциозлыгын инкарь итүгә һәм «сәнгать — сәнгать өчен» дигән карашка китереп чыгара иде.

---

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 1960 ел. 69 бит.

[2] Ф. Сәйфи-Казанлы. Тәрҗемә бабында тәҗрибәләр. «Аң» журналы. 1914 ел. 4 сан. 85 бит.

[3] Җ. Вәлиди. Татар әдәбиятының барышы. Оренбург. 1912 ел. 9 һәм 84 битләр.

---

[1] «Аң» журналы. 1913. 7 сан. 118 бит.

[2] «Аң» журналы. 1912 ел. 1 сан. 13 бит.

Болар икесе дә ахыр чиктә сәнгатьнең һәм әдәбиятның иҗтимагый идея функциясен кире кагу гына булырга мөмкин.

## 2

1905—07 елгы рус революциясе чигенгәннән соң, бигрәк тә 1908 елдан башлап, татар әдәбияты тирәсендәге тәнкыйть фикерләре үсә, катлаулана барды. Бу — табигый хәл иде. Революция вакытында күтәрелеп калган әдәби хәрәкәтне һәм фикер уянышын туктату мөмкин түгел иде инде.

Беренче рус революциясеннән соң татар язучылары арасында үткәннең тәҗрибәсен аңлау, кабаттан күздән кичерү һәм бүгенгегә, киләчәккә караш ташлау көчәйде. Әлбәттә, мондый карашларның күпчелек өлеше милли культура һәм сәнгать мәсьәләләренә бәйләнгән иде. Бу яктан караганда, замандаш әдипләре арасында бигрәк тә Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик карашлары торган саен эзлекле һәм системалы булып мәйданга чыгуы күзгә бәрелде. Әйтергә мөмкин ки, нәкъ аның әдәби тәнкыйть эшчәнлегендә социалистик революция алдыннан булган катлаулы чорның үзенчәлекле эстетик концепцияләре принципиаль һәм каршылыклы яклары белән чагылып калды. Шул замандагы әдәби хәрәкәтебезнең торышына карата да, аерым язучылар иҗаты уңае белән дә һәм махсус рәвештә әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышлап та, Г. Ибраһимов байтак җитди фикерләр әйтте, кызу гына бәхәсләр кузгалуга сәбәпче булды. Шундыйлардан берсе итеп, аның 1913 елда Оренбургта басылган «Татар шагыйрьләре» дигән очеркларын санарга мөмкин. Монда Г. Тукай, С. Рәмиев һәм Дәрдмәнд кебек шагыйрьләр турында бик кыю фикерләр язылган иде.

Бу китапта Тукай өченче шагыйрь буларак тикшерелсә дә, безнең аны беренче итеп телгә алуыбыз очраклы түгел. Г. Ибраһимов 1910 елда «Татар матбугаты» исемле мәкаләсендә: «Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле һәм галәбәле (иң күренекле) рольне мөхтәрәм Тукаев уйный. Шул дәрәҗә ки: татар шагыйре диелүгәчә укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүт була» (күз алдына баса),— дип, зур бер дөреслекне икърар иткән иде. Ләкин бу фикерләрдән соңгы берничә ел эчендә аның хосусан Тукайга һәм гомумән татар поэзиясенә мөнәсәбәте кискен үзгәреш кичерде. «Татар шагыйрьләре» — әнә шундый үзгәрешнең гаҗәп каршылыклы булган һәм авторның үзен байтак вакытлар дәвамында шәхси яктан да авыр хәлгә куйган мисаллардан берсе. Чөнки Тукай шәхесен ихтирам иткән һәм аны татар поэзиясенең кояшы дип санаган күп кенә әдипләр Г. Ибраһимовның замандаш шагыйренә мөнәсәбәте кинәт үзгәреп китүен авыр кабул иттеләр. Алай гына да түгел, хәтта аны бөтенләй кире кактылар, килешергә теләмәделәр. Социалистик революциядән соң да әле Ф. Бурнаш һәм башка күренекле язучыларның Г. Ибраһимов белән булган шәхси һәм әдәби мөнәсәбәтләрендә шул фактның кире тәэсире үзен сиздереп торды.

Соңгы еллардагы тәнкыйтьтә, Г. Ибраһимовның эстетик карашларын тикшергәндә, аеруча бер тезиска басым ясап сөйләү күзгә ташлана. Ул да булса, егерменче йөз башы татар әдәбиятында нык сизелгән дидактизмга, үгет-нәсихәтчелеккә һәм натурализмга каршы көрәш мәсьәләсе. «Ибраһимов матбугатка чыккан елларда,— ди М. Хәсәнов,— әдәби тәнкыйть алдында әдәбият мәйданын күп төрле чүп-чардан тазарту, халыкның эстетик зәвыгын үстерү, укучыларда чын сәнгать әсәрләрен халтурадан аера белү сәләтен тәрбияләү бурычлары тора иде. Һәм ул, җиң сызганып, шуларны үтәү эшенә керешә дә» [1].

Мәсьәләнең болай куелышы нигездә дөрес, әлбәттә. Чыннан да, 1905—07 елгы революциядән соң татар әдәбиятының алдынгы вәкилләре үткәннең искергән бер традициясе булган үгет-нәсихәт әдәбиятына һәм стиленә һөҗүм башладылар. Әдәбиятның бурычы — коры акыл сату һәм әхлакка өйрәтү түгел, ә тормышны һәм кешенең уй-тойгыларын сәнгатьчә сурәтләү дип аңлау тамыр җәйде. Бу, һичшиксез, татар әдәбиятында һәм тәнкыйтендә эстетик фикер үсешенең бер әһәмиятле сыйфатын күрсәткән яңалык иде. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал кебек әдипләрнең карашларында мондый

[1] М. Хәсәнов. Галимҗан Ибраһимов. Тормыш һәм иҗат юлы. 1964 ел. 65—66 битләр.

тенденция бик ачык гәүдәләнде. Г. Ибраһимов та шул тенденциягә теләктәшлек итте. Ул да татар әдәбиятын чын мәгънәсендә алдынгы һәм югары сүз сәнгате итеп күрергә теләде, шуның өчен көрәш башлады. Тукай иҗатының беренче елларындагы дидактизмга һәм тел чуарлыгына аның әнә шул позициядән торып һөҗүм итүендә, әлбәттә, билгеле бер хаклык бар. Ләкин Тукай иҗатына мөнәсәбәтендә шуның белән генә чикләнеп, шагыйрьнең аннан соң зур сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән поэзиясен Г. Ибраһимовның күрми үтүе артык тенденциозлык һәм субъективлык булды. Аның эстетик карашларында Тукайга мөнәсәбәттә генә түгел, гомумән әдәбиятны, сәнгатьне аңлауда икенче төрлерәк критерийларның өстенлек ала баруы күренде. Ул критерийларның байтак өлеше сәнгатьтәге идеаль һәм субъектив башлангычларны романтик рухта аңлауга кайтып кала иде. Әлбәттә, алар кинәт кенә килеп чыкмадылар, ә язучының элеккерәк язылган мәкалә һәм әдәби әсәрләрендә сизелә башлаган карашлары торган саен ачыграк, калкурак төс алуыннан гыйбарәт иде. Мәсәлән, аның «Әдәбият мәсьәләләре» (1910) дигән мәкаләсендә мондый юллар бар: «Ул (шагыйрь. *Г. Х.*) безгә нәзик вә мәэссир (тәэсирләндерүчән) хисләр, гали моң, матур ләүхәләр (сурәтләр) түксен! Безгә гади күренгән нәрсәләрне бөтенләй башка итеп күз алдыбызга салсын. Шуның өчен дә истигъдатлары (талантлары) икърар кыйлынган (танылган) олуг шагыйрьләрнең хакыйкый шигырьләрендә табигатьнең моң, мәэссир вә матур манзаралары, үзенең хиссияте шәхсиясе, әүлахы руханиясе (рухи сурәтләре) мөһим урын тоталар». Нәкъ шушы фикерләр «Татар шагыйрьләре»нең үзәк бер концепциясе булып әверелә дә инде. Ә бу концепция, әйткәнебезчә, үзенең асылы белән романтизмга барып тоташа. Шагыйрь, художник кеше рухының башкаларга билгеле булмаган яшерен, нечкә сыйфатларын чагылдырырга һәм аның сәнгатьчә таланты тумыштан ук булырга тиеш, дигән караш алга этәрелеп, моның нигезендә романтизм яклаган субъективизм, шәхесне идеаллаштыру ята. Г. Ибраһимов фикеренчә, Тукай поэзиясе мондый сыйфатлардан мәхрүм. Ул җырлаган уй-тойгылар аның үз шәхси, субъектив дөньясыннан түгел, ә һәркемгә билгеле дөньядан — гавам[1], халык арасыннан килә. Тукайның, ди Г. Ибраһимов, «менә мин» дип аерырлык җан вә йөрәге юк. Гүя аның җан вә йөрәгә мөмтаз (үзенә хас) шәхсиятлелектән мәхрүм яратылган. Аның һәммә тойгысы, һәммә әфкяре (фикерләре), мәелләре (теләкләре) артык гомум, артык гам» (халыкныкы).

Ә менә С. Рәмиев белән Дәрдмәнд бары үзләренә хас уй-тойгыларын гына җырлыйлар. Аларның күпчелеккә, гавамга аңлашылмаулары, мин-минлеккә (индивидуализмга) һәм төшенкелеккә бирелүләре һич кимчелек яки гаеп түгел, ә шагыйрьлекләренең үзенчәлеге, оригиналь сыйфаты гына. Мондый карашка объектив бәя бирсәң, реалистик-халыкчан поэзия белән романтик-индивидуалистик поэзияне кара-каршы куеп, Г. Ибраһимов соңгысын яклый дигән нәтиҗә чыгару һич кыен булмаячак. Ләкин Г. Ибраһимовның Тукайга мондый мөнәсәбәте аның иҗатындагы халыкчанлыкны һәм реализмны кире кагудан түгел, ә үзенең романтик карашларын ничек тә булса расларга һәм өстен итәргә теләвеннән килә иде.

Гомумән караганда, Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре»ндә һәм аннан соңгы мәкаләләрендә язучының үтә индивидуаль йөзе, үз стиле булырга тиешлеген яклавы, беренчедән, моңа кадәр татар әдәбиятында нык сизелгән дидактизмның бик шаблон, стандарт һәм төссез стиленә каршы булса, икенчедән, ул романтик шәхеснең үзенчәлегенә, гадәттән тыш булуына басым ясарга теләү белән дә бәйләнгән иде.

Шагыйрьнең, сәнгатьнең тормышка һәм халыкка мөнәсәбәте мәсьәләсендә дә Г. Ибраһимов бер ноктада гына туктап калмады. Бик тиз арада аның бу карашларында да тирән үзгәрешләр барлыкка килде. Ә болар үз нәүбәтендә язучының алдынгы татар һәм рус әдәбияты традицияләренә, тәҗрибәләренә аеруча игътибар итә башлавыннан һәм революцион-демократик идеалларының ачыклана баруыннан аерылгысыз иде. Бигрәк тә «Татар шагыйрьләре»ннән соң чыккан мәка-

[1] Гавам, гам, гаммә — халык төшенчәләрен романтикларның русчадагы толпа (гомумән халык) мәгънәсендә куллануларын исгә тотарга кирәк.— *Г. Х.*

ләләрендә Г. Ибраһимов рус классик әдәбиятының тормыш һәм халык белән бәйләнешенә нык игътибар итеп сөйләде: «...Халыкка якынлыгы, тик халык өчен яшәве, халык йөрәгеннән туып, аның авыр хәятына бер нур, бер җиңеллек бирүне үзенә вазифа итеп алган булучылыгы белән рус әдәбиятының бөтен дөньяда мөмтаз вә мөстәсни (үзенчәлекле һәм аеруча) урын тотканлыгы мәйдандадыр,— диелгән иде аның 1913 елгы бер мәкаләсендә.— Рус әдәбиятыннан үз кайгысына бер җиңеллек көтә. Шуңа күрә дә хәзер башка халыкларда бик киң урын тоткан «сәнгать өчен — сәнгать» мәсләген рус моңарчы аңлый алмады, әле дә аңламый һәм аңламас та. Чөнки ул аңа табигате белән үк салих (теләктәш) түгел. Аның һәр әдибе иң элек үзен халыкның угылы итеп хис кыла, язу дигән сүздән рус хәятының авыр яраларына шифа эзләү дигән мәгънәне аңлый»[1]. Монда, гаҗәп бер ачыклык һәм төгәллек белән, рус әдәбиятының ни өчен халыкчан булуы турындагы сорауга җавап бирелгән.

«Шагыйрь һәм халык» проблемасын да Г. Ибраһимов үз эстетик эзләнүләренең үзәгенә куярга омтылды. Дөрес, моны аңлауның үзенчәлекле романтик төсмерләре бар иде. Әмма аның асыл мәгънәсе шул ук демократик, реалистик әдәбият җирлегеннән үсеп чыкты, һәм Г. Ибраһимов аны үз әдәби-эстетик ышанычларының бер теоретик терәге итеп формалаштыра алды. Бу яктан аның Т. Шевченкога багышланган «Каһарман шагыйрь» (1914) дигән мәкаләсе аеруча әһәмиятле. Бу мәкаләдә «шагыйрь һәм халык» проблемасының искиткеч җанлы мисалы, бөек бер образы күз алдына бастырылган.

Шул рәвешчә, Г. Ибраһимов эстетик фикерләрендә әдәбиятның, сәнгатьнең үсеше һәм роле мәсьәләсен язучының, художникның халыкка, заманга, азатлыкка һәм тормышка мөнәсәбәте белән бәйләнештә карарга омтылыш көчәя барды. Хәтта яңа сәнгать методының төп юнәлешен билгеләгән критерийларны табарга теләү дә шул ук ноктага төбәлгән иде. Һичшиксез, бу урында Г. Ибраһимов карашлары татар әдәбияты һәм тәнкыйте дөньясында барган үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнештә булдылар. Мәсәлән, шул ук «шагыйрь һәм халык» мәсьәләсен алып карасак кына да, бу бәйләнешнең күпме тирән икәнлеген конкрет күрә алырбыз. Тукай үлгәннән соң, аңа багышлап, байтак мәкалә һәм истәлекләр басылды. Аларның күпчелегендә шагыйрьнең халык белән бәйләнеше, аның ни өчен халык шагыйре булуы турындагы фикерләр үзәк урынны алды. Әйтергә мөмкин ки, нәкъ Тукай шәхесе һәм иҗаты тирәсендә «шагыйрь һәм халык» проблемасы үзенең бөтен принципиальлеге белән куелып, күпләрнең игътибарын билгеләде. Мисал өчен Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди һәм Г. Газиз мәкаләләрен генә искә төшерү дә җитә. Боларда, Тукай үлгәннән соң беренче мәртәбә дияргә мөмкин, аның халык шагыйре булуы яхшы ук тулы һәм төгәл бәяләнде, Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре»ндәге концепциясен кабул итмәү күзгә бәрелеп торды. «Татар шагыйрьләрен»нән соң Г. Ибраһимовның «шагыйрь һәм халык» мәсьәләсенә карашы үзгәреп китүен бигрәк тә Тукай мирасы тирәсендәге фикер көрәшеннән һич тә аерып карап булмый. Тагын да Г. Ибраһимовның һәм художник, һәм тәнкыйтьче буларак кыюлыгы шул иде: бигрәк тә унынчы еллардан соң татар әдәбиятына үтеп керә башлаган эстетлык һәм индивидуализм настроениеләренә каршы халыкчанлыкны яклау белән бергә, ул реализм турында да үз фикерләрен ачык итеп әйтергә омтылды. Аның 1915 ел башында басылган бер мәкаләсендә шундый юллар бар: «Мөхәррир я матур вә мәгънәле хыял язсын, яки үзенең тугры тасвиры белән тормышның авыр җәрәхәтләреннән берен укучы алдына ачып салып, халыкны шул хакта уйларга, авыр язмышны җиңеләйтү турында чаралар күрә башларга — һич булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга салырга мәҗбүр итсен! Әдәбияттагы реализмның бердәнбер әһәмияте фәкать шул ноктадандыр»[1].

Мондый карашларның өскә чыга баруы, әлбәттә, Г. Ибраһимовның фәкать үз шәхси әдәби-фикри үсеше, эволюциясе булып кына кала алмый иде. Монда,

---

[1] «Йолдыз» газетасы. 1913 ел. 17 март саны.

[1] «Тормыш» газетасы. 1915 ел. 27 февраль саны.

беренчедән, язучының алдынгы әдәбият тәҗрибәсен тагын да тирәнрәк итеп аңлавы уңай роль уйнаса, икенчедән, ил өстенә, халык өстенә төшкән тарихи авырлык һәм фаҗигаләр дә хәлиткеч тәэсирләрен ясадылар. Беренче империалистик сугыш еллары аның субъектив-романтик иллюзияләрен бик нык какшатты. «Сәнгатькәр (художник) йөрәгеннән халык йөрәгенә тугрыдан-тугры юл салу»[1] кебек зур мәсьәлә аны да борчый иде. Болар һәммәсе Г. Ибраһимовның торган саен Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Камал һәм Ш. Камал кебек реалист әдипләр иҗатында нык тамырланган эстетик карашларны яклап, уртаклашып фикер йөртүе турында сөйләде.

Шуның белән бергә үк, Г. Ибраһимовның әдәбиятны, сәнгатьне аңлавы тагын да катлауланып һәм каршылыклары кискенләшеп үсүендә дәвам итте. Бу яктан аның 1915 елда басылган сәнгать «Альбомы»на («Сәнаигы нәфисә мәҗмугасы»на) язган кереше алдынгы татар әдәби фикеренең көчле бер теоретик чагылышы, эстетик декларациясе булды дияргә мөмкин. Бу әсәр, тарих искиткеч авыр һәм канлы фаҗигаләр кичергәндә, сәнгатьнең язмышы, аның үткәне һәм киләчәге турында борчылып уйланулар белән үтәдән-үтә сугарылган иде.

«Альбом»да Г. Ибраһимовның игътибарын җәлеп иткән мәсьәләләрдән берсе — сәнгатьнең кешe тормышында ни өчен, нинди ихтыяҗ аркасында барлыкка килүе. Аның фикеренчә, сәнгать әсәре кешегә, аның аңына һәм тойгысына табигатьнең һәм тормышның тәэсир итү нәтиҗәсе булып, сурәт формасында мәйданга чыга. Ләкин язучы моңа иҗтимагый-тарихи факторлардан килеп карау дәрәҗәсенә күтәрелмәгән иде әле. «Сәнаигы нәфисәнең асыл туышы — нәштә шулай эчке теләк буенча табигый рәвештә килеп чыгадыр. Анда тышкы максатлар булмый, ул бернәрсәгә хезмәтфәләи теләми, ул — сәнгатькәрнең рухани галәменең матди сурәттә гәүдәләнүеннән гыйбарәт» («Альбом», 18 бит). «Әдәбият исә адәмнең хисси вә хыялый әләнүдән, боларның азык сорауларыннан туды. Адәм табигатендә аһәң вә музыкачылык бар. Назымның (шигырьнең) тууы, шөбһәсез, табигатебездәге музыка куәтеннәндер»[1], кебек карашлар Г. Ибраһимов эстетик фикерләренең нигезендә яталар әле. Болай сәнгатьне художникның саф рухи теләкләрен чагылдырган субъектив күренеш иттереп чикләү шул ук романтизмга кайтып кала. Алай гына да түгел, мондый карашны реализмга чит башка әдәби агымнар да кире какмыйлар. Ләкин дә Г. Ибраһимовның романтик идеализмы сәнгатьнең, әдәбиятның һич тә иҗтимагый ролен инкарь итүгә юнәлтелмәде. «Альбом»га язган кереш мәкаләнең буеннан буена сәнгатьнең кеше тормышындагы әһәмиятенә игътибар итәргә омтылыш һәм сәнгать әсәренең барлыкка килүендә реаль җирлек булуын төшендерергә теләү сизелеп тора: «Хәят вә табигатьтәге көчләрнең бәрелешүеннән вөҗүткә (барлыкка) килгән нинди булса бер хадисә (вакыйга) сәнгатькәрнең йөрәгендә бер тәэссер (тойгы) уйгата. Бу тәэссер — туачак сәнаигы нәфисә әсәренең орлыгыдыр» («Альбом», 18 бит).

Шулай да, Г. Ибраһимовның «Альбом»дагы мәкаләсе авторның гына түгел, гомумән алдынгы татар әдәби-эстетик фикеренең билгеле дәрәҗәдә үсешен күрсәтү белән бергә, анда әле романтизм концепцияләренең үзәгендә торган сәнгать культы, ягъни сәнгатьне, әдәбиятны идеаллаштыру кебек карашлар да ярылып ята иде: «Миллиятнең тамырларын халык йөрәгеннән мәңге суырылмас мәртәбәдә тирәнәйтә алу — тик милли музыка, милли сәнаигъның могҗиз (сихерле) куәте аркылы гына мөмкиндер» («Альбом», 29 бит). Һәр халыкның сәнгатен аның тик үзенә генә аңлашыла торган серле дөньясы дип карау, милләт язмышын шул серне саклый яки саклый алмау белән генә чикләү, әлбәттә, мәсьәләнең зур тарихи-иҗтимагый ягын әле төшенеп җитмәүне күрсәтә иде.

Шуңар да карамастан, Г. Ибраһимов эстетик фикерләрендә безнең демократик әдәбиятка хас халыкчанлык принциплары өскә чыкты. Бу халыкчанлык критик реализм традицияләрен романтик идеаллар белән баету, рухландыру, үстерү

---

[1] Г. Ибраһимов. Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз. «Альбом». («Сәнаигы нәфисә мәҗмугасы»). Казан. 1915 ел. 14 бит.

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият дәресләре. Казан. 1916 ел. 78 бит.

мәгънәсендә күз алдына китерелде. Нәкъ шул халыкчанлык идеаллары җирлегендә критик реализм белән прогрессив романтизмның эстетик уртаклыгын, якынлыгын табарга омтылыш та ята иде. Әнә шундый омтылышта инде без социалистик революция алдыннан татар әдәбиятында урын алган романтик реализмның яралгылары бар иде дип уйлыйбыз.

Татар әдәбиятында романтизм булырга һәм үсәргә тиеш дигән караш торган саен көчәйде. Әлбәттә, мондый караш та бер төрле генә булмады. Әгәр дә Г. Ибраһимов шикелле әдипләр романтизм белән реализм арасындагы якынлыкны эзләү юнәлешендә барсалар һәм актив романтизмны алга этәреп, аның дөнья әдәбиятындагы прогрессив традицияләрен кабул итүне кирәк тапсалар, кайбер әдипләр исә Көнбатышка бәйләнеше, теләктәшлеге булмаган «Көнчыгыш романтизмы»ннан һич тә аерылмаска тиешле саф «милли романтизм» турында да сөйләделәр. Мәсәлән, Н. Думави чыгышларында шундый тенденцияләр ачык сизелде. Хәзерге чорда татар культурасының язмышы Көнчыгыш беләнме әллә Көнбатыш беләнме бәйләнгән, дигән сорау тирәсендәге бәхәсләргә кушылып, Н. Думави татар әдәбиятында «Көнчыгыш (шәрык) рухы» өстенлек итәргә һәм шул рух милли романтизмның да асылында ятарга тиеш, дигән караш белән чыкты. Аның фикеренчә, борынгы үзенчәлек һәм патриархаль иркенлек рухы татар әдәбиятында да романтизмга азык бирәчәк [1].

Фәнгә, акылга һәм, ниһаять, цивилизациягә чит хыял дөньясына чумган, шунда үзенең милли сафлыгын һәм үзенчәлеген табарга тиешле идеалистик сәнгать концепциясе, әлбәттә, татар әдәбиятындагы романтизмның актив юнәлешенә, андагы реализмга каршы килеп, ул рус һәм Европа әдәбиятларындагы югары художестволы казаныш-традицияләрнең ролен инкарь итүгә һәм, ахыр чиктә, декадентлык сазлыгына алып бара иде. Шуңар күрә татар әдәбиятының алдынгы вәкилләре мондый карашлар белән килешә алмадылар. «Шәрыкка да материализм керәчәк. Материализм хөкем сөргән җирдә иске шәрыкка урын юктыр» [1]. «Безнең әдәбиятыбыз да гареп эзенә төште. Гомуми мәдәният агымыннан аерылып, үзебезгә бер юл тотуның мәгънәсезлеге ачык мәгълүм булганга, табигый, моңа шатланабыз гына» [2],— диделәр алар һәм тарихи чынлыкның, заруриятнең котылгысыз икәнлеген раслыдылар.

1912—1917 еллар арасында күтәрелеп киткән милли хәрәкәт идеяләре әдәбиятта күбесенчә романтизмга бәйләнештә калку булып гәүдәләнде. Бу очракта инде татар культурасының, әдәбият һәм сәнгатенең үзенчәлеген тәэмин итү һәм үстерү өчен кирәкле җирлекне, барыннан да элек, романтизм белән бәйләп карау тагын да көчәйде. Г. Газиз, мәсәлән, Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романына язган рецензиясендә: «Хәзер безнең милли хисебез куәтләнгән, милли музыка, халык җыры вә музыкасына әһәмият биргән, үзебезнең үткән көннәребезне артыбызга борылып карый башлаган бер заманыбыз,— бездә ник романтизм булмасын?» [3] дигән иде. Шул рәвешчә, романтизм — милли азатлык идеяләренең сәнгатьтәге төп бер гәүдәләнеше итеп карала башлады.

Бигрәк тә унынчы еллар дәвамында татар әдәбиятында зур гына урын алган табигать, мәхәббәт һәм музыка культы да романтизмның бик характерлы эстетик билгесе буларак күтәрелеп, активлашып китте. Бөтен дөнья романтизмының яратылышыннан ук килә торган бу культ гадәттә милли азатлык идеалы белән рухланган шәхеснең эчке гармониясен, иреген һәм бөтенлеген күрсәтә торган сыйфат итеп күз алдына китерелде. Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» һәм «Табигать балалары» кебек әсәрләрен генә алып карасагыз да, табигать, мәхәббәт һәм музыка культының никадәр зур роль уйнавын ачык тоярсыз. Хәтта реализм позициясендә нык басып торган М. Гафури шикелле язучы да нәкъ шул елларда бу романтик культка теләктәшлек итүдән һәм аның белән мавыгудан читтә кала алмады.

---

[1] Н. Думави. Шәрыктан гарепкә мөнәсәбәте белән. «Аң» журналы. 1916 ел. 9 сан. 158 бит.

[1] «Аң» журналы. 1916 ел. 4 сан. 69 бит.

[2] Г. Ибраһимов. Әдәбият дәресләре. 60 бит.

[3] «Аң» журналы. 1913 ел. 11 сан. 191—192 битләр.

Мондый фактларда күп кенә милли әдәбиятлардагы романтизмга охшашлык, уртаклык чагылып, гомумән татар әдәбиятының үсешен билгеләгән зур бер тенденция урын алса да, шул ук вакытта аның байтак каршылыклы һәм милли чикләнгән булуын да истә тотарга кирәк. Андарда социаль башлангычны миллилек исәбенә сыекландыру, төссезләндерү көчле булып, заманның зур тарихи процессыннан читтәрәк тору куркынычы да бар иде. Чынбарлыкның каршылыкларын һәм драмаларын чагылдыру әдәбиятның төп бурычы дип караган язучылар, әлбәттә, мондый тенденцияләргә каршы чыктылар. Чөнки зур тарихи чынлыктан читләшү безнең әдәбиятта, Ф. Әмирхан сүзләре белән әйтсәк, «әшсез, фикерсез, истибдат (изү, кысу) вә әхлаксызлык белән гомерләрен уздырган ханнарны мактап вә ул заманнарда бөтен татар әллә нинди бер рәфаһияттә (рәхәтлектә) булган шикелле итеп, шул вакытларны сагынып утыру» шикелле, тупас һәм мәгънәсез милләтчелек чиренә юл куйды («Үги балалар». 1908).

Югарыда сөйләнгәннәрне тулаем алганда, егерменче йөз башындагы татар әдәби-эстетик фикерләренең күпчелек өлешенә халыкчанлык белән тормышчанлыкны һәм реализм белән романтизмны милли әдәбиятның төп юнәлешләре итеп карарга омтылыш хас булды, дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Әмма бу омтылышта башлыча өч тенденция барлыгы да төсмерләнде: болар — туры мәгънәсендә реализмга юнәлеш, реализм белән романтизмның якынлыгын табарга теләү һәм фәкать милли романтизмны гына өстен итәргә тырышу кебек тенденцияләр иде. Әдәби-эстетик агымнар буларак, аларның өчесе дә үзара тыгыз мөнәсәбәттә мәйданга килделәр, бер-берсенә теге я бу төстә тәэсир иттеләр һәм каршылыкка да керделәр. Менә шул процесста өстенлек алып, җиңеп чыгарга тиешле һәм заманга лаеклы иҗат методы өчен көрәш татар әдәбиятының төп юнәлешен билгеләде.

≈≈≈≈≈≈

# ҺАДИ ТАКТАШ ҺӘМ АНЫҢ ЧОРЫ

Татар совет поэзиясенә нигез салуда һәм аны үстерүдә Һади Такташ гаять зур роль уйнады. Ул Тукайдан соң үз шигъри мәктәбен булдырган иң зур шагыйрьләрнең берсе иде. Шагыйрь иҗаты еллар үтү белән үзенең тәэсир көчен киметми генә түгел, ә, киресенчә, заманның рухи тормышына һаман саен тирәнрәк үтеп керә бара. Такташ традициясендә инде берничә буын татар шагыйрьләре үсеп чыкты. Әле бүгенге көндә дә күп кенә яшь шагыйрьләр әдәбиятка Такташ поэзиясе тәэсирендә киләләр. Илебезнең төрки телләрдә сөйләшүче башка милләт язучылары да Такташ иҗатының үзләренә уңай йогынты ясавын әйтәләр.

Татар әдәбият белеме һәм тәнкыйте Такташ поэзиясе белән элек-электән кызыксына килгән. Шагыйрь вафат булганнан соң гына да аның тормышы һәм иҗаты турында берничә зур монография басылып чыкты. Әгәр Такташка багышланган беренче хезмәтләр нигездә материал туплау рәвешендәрәк булсалар, соңгы еллардагы тикшеренүләрдә шагыйрь иҗатына тирәнрәк үтеп керергә, аны төрле яктан колачларга омтылу сизелә. Бу омтылыш Хатип Госман («Такташ поэзиясе», 1953 ел; «Егерменче еллар татар поэзиясе», 1964 ел) һәм Гали Халит хезмәтләрендә аеруча ачык күренә. Гали Халитның «Шагыйрь, чор, герой»[1] дигән яңа китабы озак еллар буе эзләнүләрнең дәвамы булып тора.

Г. Халит хезмәте моңарчы без күреп ияләнгән монографияләргә охшамаган. Монда Такташ биографиясен сөйләп чыгу да, аның иҗади юлын этапларга бүлеп, шуларны бер-бер артлы күзәтү дә юк. Автор Такташ иҗатындагы герой һәм иҗат алымы проблемасын сайлап ала да шуны егерменче еллар татар поэзиясе җирлегенә куеп тикшерә. Авторның төп игътибары чын мәгънәсендә җитди һәм катлаулы проблемаларга төбәлгән. Дөрес, кайберәүләрдә хезмәтнең артык гыйльми, академик тел белән язылуы ризасызлык та тудырырга мөмкин. Ләкин шунысы бәхәссез: мондый тикшеренүләрнең дә яшәргә хакы бар. Ул гына да түгел, алар әдәбият белеме өчен зарури.

Г. Халит Һади Такташ поэзиясен шагыйрь яшәгән катлаулы чор белән тыгыз бәйләнештә тикшерә, дидек. Хезмәттә шагыйрь үз чорының әдәби тормышыннан аерылгысыз итеп бирелә, шул ук вакытта аның үз замандашларының эстетик яктан үсешенә йогынты ясавы да ачык күрсәтелә.

Галим Такташ поэзиясенең егерменче еллар башындагы чорына аеруча зур урын биргән. Бу очраклы хәл түгел. Такташның башлангыч иҗаты хисләргә бай булуы, дәртлелеге, кызыклы әдәби образлары һәм үзенчәлекле ритмикасы белән аерылып тора. Менә шуңа күрә дә алтмышынчы еллар уртасында һәм җитмешенче еллар башында әдәбиятка килгән яшь шагыйрьләребез Такташ иҗатының башлангыч чорына күбрәк игътибар итәләр. Такташ иҗатының башлангыч чоры турында сүз чыккач, романтизмга бәйләнешле бәхәсләргә тукталып китмичә булмый. Г. Халит китабында да бу мәсьәләгә зур урын бирелгән. Романтизмны мөстәкыйль иҗат методы дип расларга һәм аны ерак үткәннәргә генә кайтарып калдырырга тырышучы кайбер галимнәрдән үзгә буларак, Г. Халит романтизмны социалистик реализм методының да аерылмас бер кисәге итеп

---

[1] Гали Халит. Шагыйрь, чор, герой. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1971. 183 бит.

карый. Моны распагаңда автор, гомумтеоретик төшенчәләр белән генә чикләнмичә, гыйсьянчылык агымын да тикшерә. Бу агым Г. Халитнең эзләнүләр барышындагы уйлап чыгаруы гына түгел. (Кайбер тәнкыйтьчеләр галимгә шундый гаеп тә ташлыйлар.) Гыйсьянчылык дип йөртелгән бу күренешне тулырак һәм тирәнрәк итеп тикшерү нәкъ менә Г. Халит хезмәтләрендә күзәтелә. «Шагыйрь, чор, герой» китабында автор гыйсьянчылыкның егерменче еллар татар поэзиясендәге романтик агым икәнлеген ышанычлы итеп раслый.

Г. Халит бу агымның нигезендә иске дөньяга каршы килешмәүчән көрәш, бөтен кануннарны, тираннарны, шаһларны һәм аллаларны юк итәргә омтылу ята дип аңлата һәм, безнеңчә, галимнең бу фикере нигезле. Гыйсьянчылык көрәшендә суллык авырулары, анархистик һәм нигилистик рухтагы чакырулар, кайчакта хәтта сыйнфый көрәш урынына вак буржуаз революционлыкны алга сөрүләр дә булмады түгел. Шундый чакларда алар иҗатында бунтарьлык, пессимизм, шәхескә чиктән тыш инану һәм газаплану авазлары өстенлек итте. Автор бу агымның катлаулы, каршылыклы булуына күз йоммый. Ләкин ул егерменче еллар шагыйрьләре, шул исәптән Такташ иҗатының үсеш юлын бары тик «реакцион» гыйсьянчылык йогынтысыннан арыну рәвешендә генә барды дип караучылар белән дә бәхәскә керә. Без Г. Халитның гыйсьянчылык — яшь татар совет әдәбияты үсешенең закончалыклы һәм табигый этабы иде, диган фикере белән килешергә мөмкин дип саныйбыз. Авторның ышандырырлык дәлилләренә караганда, Такташ бу агымны «җиңеп чыккан» гына түгел, ә шушы агымнан үсеп чыккан шагыйрь.

Г. Халитның һ. Такташ һәм башка гыйсьянчы шагыйрьләр иҗатындагы лирик герой проблемасы турындагы фикерләре аеруча кызыклы. Автор К. Нәҗми, М. Максуд, Г. Кутуй, Н. Исәнбәт, М. Җәлил һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләрен чагыштырып, гыйсьянчы геройга хас булган кайбер гомуми, уртак үзенчәлекләрне аерып карый. Бу герой, кагыйдә буларак, чиктән тыш киеренке, трагик хәлләрдә яши. Аның хисләре соң чиккәчә киеренке, гиперболалаштырылган. Гыйсьянчы герой хәтта тышкы кыяфәте белән дә гадәти түгел, ниндидер демонга охшаган. К. Нәҗми үзенең героен читлекне җимереп чыккан арыслан белән чагыштыра, ә М. Максуд канга сусаган бүрегә охшата. Такташның шушы елларда язылган бер шигырендә геройның йорт-җире дә, әти-әнисе дә, сөйгән яры да юк. Такташ иҗатының башлангыч чорындагы шартлы герой аңлы пролетарийның реаль һәм конкрет образыннан ерак тора әле.

һ. Такташ һәм башка гыйсьянчы шагыйрьләр үз геройларының кабатланмас яңа булуын кабат-кабат тәкрарлыйлар. Ләкин Г. Халит ышанычлы дәлилләр белән шуны раслый: бу герой һич кенә дә күктән иңмәгән, ә кыяфәтен бераз үзгәртеп революция алды елларында татар романтик поэзиясеннән генә күчеп килгән икән. Моны шул чор әсәрләрендәге шартлы трагизмнан, беркадәр сәхнәләштерелгән сөйләмнән, юри соң чиккәчә тартылган хисләрдән дә күрергә була. Г. Халит Такташ һәм егерменче еллар башындагы байтак кына башка шагыйрьләрнең В. Маяковский иҗаты һәм пролеткульт поэтикасы тәэсиренә нык бирелүләренә күз йоммый. Шуңа да карамастан, дип басым ясап әйтә автор, гыйсьянчылык ул безгә читтән кергән агым түгел, ә шул чор һәм милли җирлек тудырган мөстәкыйль эстетик күренеш. Г. Халит һади Такташ иҗатының үзенчәлеген һәм яңалыгын нәкъ әнә шунда күрә дә.

Бу урында шунысын да әйтеп китәргә кирәк: автор Такташның үз чорындагы әдәби хәрәкәткә булган мәхәббәтенә һәм шул хәрәкәтнең закончалыкларына төп игътибарын юнәлтсә дә, безнең карашыбызча, шагыйрьнең башлангыч иҗат чорындагы үзенә генә хас булган үзенчәлекләрен һәрвакытта да тәгәл үк ачып бетерми. Ә бит егерменче еллар башында иҗат иткән шагыйрьләр бер-берсеннән бик нык аерылып торалар. Аларның һәрберсенең үзенә генә хас булган иҗади үзенчәлеге, язу алымы, образлар системасы бар. Инде Такташка килсәк, ул шул елларда иҗат иткән шагыйрьләрнең иң үзенчәлеклесе, иң талантлысы.

Авторның Такташ иҗатының борылыш чоры, бигрәк тә аның соңгы чоры турындагы эзләнүләре татар әдәбият белемен шактый тулыландыра. Мәсәлән, «Гасырлар һәм минутлар» поэмасына анализ ясаганда, автор аны Маяковскийның һәм Чаренцның шул ук темага багышланган поэмалары белән чагыштыра һәм яңа герой, яңа сурәтләү чаралары эзләгәндә татар шагыйренең мөстәкыйль юл белән баруын раслый. Галимнең «Мәхәббәт тәүбәсе», «Киләчәккә хатлар» һәм шагыйрьнең пьесаларына кара-

та булган фикерләре дә кызыклы. Монда авторның тикшеренүләре узган чор белән генә чикләнеп калмый, ә бүгенге көнгә дә карый. Татар шигыренең ритмик һәм интонацион мөмкинлекләре турында сөйләгәндә, галим Такташ белән бүгенге яшь шагыйрьләрне янәшә куеп тикшерә.

Г. Халит китабы, әлбәттә, кайбер җитешсезлекләрдән дә азат түгел. Кайбер урыннарда ул, коры сөйләүдән качарга тырышып һәм бик күп фактлар санап китәргә теләмичә булса кирәк, үз фикерләрен ышанычлы мисаллар белән дәлилләми. Шуңа аның кайбер фикерләре һавада асылынып калалар, нигезсез булып тоелалар.

Такташ иҗатындагы яңа алым турында фикер йөрткәндә автор бу турыда элек әйтелгән фикерләргә дә үзенең карашын тулырак күрсәтсә, әйбәт булыр иде. Ә бит чын мәгънәсендә фәнни һәм тирән фикер бары тик элек әйтелгән фикерләр белән янәшә куйганда гына яңа гыйльми ачыш булып яңгырый.

Ләкин бу җитешсезлекләр генә хезмәтнең гомуми дәрәҗәсен төшерә алмыйлар, әлбәттә. Г. Халит китабы татар тәнкыйть һәм эстетик фикеренең үсеен һәм татар әдәбият белемендә чын мәгънәсендә фәнни методологиянең җитлегүен тагын бер мәртәбә раслый.

**Рафаэль МОСТАФИН.**

# КАРЛЫГАЧЛАР САНЫ ИШӘЯ

Татарстан китап нәшрияты яшь шагыйрьләрнең коллектив җыентыкларын бастырып чыгаруны дәвам иттерә. «Беренче карлыгачлар» сериясенең нәүбәттәге сериясендә без тагын унике яшь автор белән очрашабыз. Алар арасыннан Эдуард Мостафин, Булат Сөләйман, Фәннур Сафин, Разим Вәлиуллин, Роберт Миңнуллин, Фәнзаман һәм Илсөяр Ганиеваларның исемнәре поэзия сөючеләргә таныш инде. Газета-журнал битләрендә матур-матур шигырьләре һәм җырлары басылган әлеге өметле яшьләр белән кулга-кул тотынып, поэзиягә Әнәс Исхаков, Әдхәт Синегулов, Эльмира Шәрифуллина, Зиннур Мансуров һәм Марсель Галиевлар килә. Шунысы күңелне куандыра, аларның һәркайсының укучыга әйтер сүзе, башкалар белән уртаклашуны сорый торган нинди дә булса фикере бар. Тормыш материалын алар үзләренчә кабул итәргә, шигырьдә аны үзләренчә чагылдырырга тырышалар. Фәннур Сафин, мәсәлән, шигырьдәге вакыйга-күренешләрне лирик геройның эчке кичерешләре, җиңелчә моңга төренгән хис-тойгылары ярдәмендә тасвирларга ярата. Аның шигырьләренә җыйнаклык, гадилек, табигыйлек хас. Бу егетнең кайсы гына шигырен укыма, анда тормышчан гади картиналар күз алдына килеп баса. «Төн» шигырендә ул «миналардан калган чокырда» түмле йокыга талган чәчәкләрне күреп сөенә, икенче бер шигырендә исә «илләре булып та туган илгә кайтмый йөргән кешеләргә охшаган болытлар»га карап тирән уйга чума. «Палуба буйлап йөгерәм» шигыре дә Фәннур үзе эзләп тапкан образлы юллар белән тәмамлана:

> Дебаркадер моңсу гына
> Дулкыннарда тирбәлә.
> Сары комнарга капланып
> Елыйлар күк көймәләр.

Илсөяр Ганиева, Роберт Миңнуллин, Эльмира Шәрифуллина шигырьләре дә Фәннур Сафин шигырьләре белән аваздаш яңгырыйлар. Бу авторлар нигездә туган җир, яшьлек, мәхәббәт темаларына мөрәҗәгать итәләр. Аларның шигырьләрендә кайчандыр ата-бабаларыбыз гомер кичергән җирнең мөкатдәс булуы, шул җирдә чәчәк аткан яшьлегебезнең матурлыгы, мәхәббәт утында янган йөрәкләрнең шатлык-моңнары гәүдәләнә. Укучыларга моңарчы җырлар авторы буларак билгеле булган Илсөяр Ганиева шигырьләренә җыентыкта аеруча киң урын бирелгән. Әмма поэтик яктан ул шигырьләрнең бөтенесе дә бер үк дәрәҗәдә эшләнмәгән. «Кайтыгыз, торналар», «Урал ягына», «Салкын ташлар», «Зәңгәр күзле җырчыга», «Икмәк», «Тугайларым», «Мирас», «Чишмә», «Беләзегем» шикелле уңышлы, күңел җылысы салынып язылган шигырьләр арасында «Туган ягыма», «Хыял», «Салкын кыя булып калмасын», «Аңлашыла», кебек бер-берсен кабатлаган гомуми шигырьләрнең дә булуы авторның үз иҗатына карата бик үк таләпчән булмавы турында сөй-

ли. Бер үк нәрсәне кабатлаулар Эльмира Шәрифуллина шигырьләрендә дә нык сизелә. «Унсигез яшь» һәм «Егерме яшь» шигырьләре исемнәре белән генә түгел, эчтәлекләре белән дә бер-берләренә бик якын торалар. Роберт Миңнуллин шигырьләре күңелне хис-тойгыларга нигезләнеп язылган булулары белән үзләренә җәлеп итәләр. Моны бигрәк тә «Син», «Икәү», «Казан төне», «Син Агыйдел кызы хәзер», «Сәер йөрәк» шигырьләренә карата әйтәсе килә.

Тормыш үзе бәхет кебек,
Кайгылар юк та сыман.
Икәүләп кереп барабыз
Бәхетебез тупсасыннан,—

ди ул «Икәү» шигырендә. Мондый матур чагыштырулар — бу авторның башка шигырьләре өчен дә уртак булган сыйфатларның берсе. Шигырь язу техникасын ул яхшы белә. Әмма киләчәктә аның шигырьләренең тематик диапазонын киңәйтү турында ныклап уйланырга кирәк.

Әйтеп үткәнебезчә, соңгы елларда поэзиябезгә өметле адымнар белән килүчеләр арасында Булат Сөләйман да бар. Үзе әйтмешли, Иртыш буйларының буйчан таллары белән ярышып үскән, Себер тайгаларын, Казагыстан далаларын, Тянь-Шань тауларын кичкән бу яшь шагыйрь үзенең шигырьләрендә безне шул якларның кырыс табигате, кешеләренең тормыш-көнкүреше һәм эшләре белән таныштыра. Кирәк вакытта шагыйрь, үзе туып-үскән җирләрне искә алып, моңлана, сагышлана да белә. «Китүләре бигрәк авыр икән» шигыреннән лирик геройның туган якларын чиксез яратуын, йөрәге белән аннан һичкайчан да аерыла алмавын тоясың.

Булат Сөләйманның иҗат мөмкинлекләре киң. Бүгенге көндә ул Мәскәүдәге М. Горький исемендәге Әдәбият институтында читтән торып укый. Анда алган теоретик белемнәрен иҗат эшенә җиккәндә, ул, һичшиксез, һәркайсыбыз кызыксынып укырлык әйбәт шигырьләр иҗат итә алачак.

Яшь әдипләр эзләнү чоры кичерәләр, каләмнәрен поэзия жанрының төрле өлкәләрендә сынап карыйлар. Фәнзаман, мәсәлән, лирик шигырьләр белән берләттән, алга барышыбызга комачаулый торган төрле кимчелекләрне фаш итеп, үткен-үткен юмористик шигырьләр дә яза. Аның «Дөнья булгач», «Аз булса да ярап тора» дигән шигъри фельетоннарында тормыштагы ямьсез күренешләр, аларны тудыручы ваемсыз яисә тәмам шомарып җиткән, һәр эшнең «җаен белергә» өйрәнгән бәндәләр тәнкыйтьләнә. Ләкин юмористик рухта язылган кайбер шигырьләрендә Фәнзаман моңарчы инде башкалар тарафыннан әйтелгән һәркемгә таныш нәрсәләрне тагын бер тапкыр кабатлаудан уза алмый. Әдхәт Синегуловның иҗат мөмкинлекләре исә аның юмористик шигырьләрендә тулырак ачыла шикелле. «Менә, малай, мин сиңа әйтим», «Сачтараштa бер кыз күрдем», «Шул иргә ярап кара», «Юдылар түбәтәйне», «Ял итә-итә-итә» шигырьләрен укыганда Әдхәтнең бу җыентыктагы «Татарстан кышы», «Гашыйкмын», «Кул кычыту», «Сүзләремдә каты мин», «Еллар» кебек гомуми шигырьләре ничектер тоныкланып, төссезләнеп кала. Күрәсең, яшь авторның каләме әле үзенең төп юнәлешен табып җиткермәгән.

«Беренче карлыгачлар» сериясенең һәр китабында яшь шагыйрьләрнең рәсемнәре бирелә, кыска гына итеп язылган сүз башында аларның һәркайсы укучыларны үзенең тормыш юлы, киләчәккә булган иҗат планнары белән таныштыра. «Уй-хисләремне, тормышның нәфис, усал нюансларын зуррак масштаблы итеп күрәсем, шигъри авазлар итеп җирдәшләремә җиткерәсем килә»,— ди Разим Вәлиуллин. Шул теләгенә ирешү өчен кулына каләм алган Разимның шигырьләренә хәзергә конкретлык, табигыйлек һәм хисләр муллыгы җитенкерәп бетми. Әнәс Исхаков һәм Марсель Галиев шигырьләренә карата да шуны үк әйтергә кирәк. Аларның һәркайсының шигырьләрендә оста тотып алынган тормышчан вакыйгалар, буяуларга бай картиналар бар. Ләкин, ашыгучанлык һәм тәҗрибәсезлек бәласедер, күрәсең, ул вакыйгалар һәм картиналар шигырьдәге төп фикерне ачып бирү өчен ярдәм итмиләр.

Вакытлы матбугат битләрендә күп кенә шигырьләр бастырган Эдуард Мостафинның бу җыентыкка кергән иҗат үрнәкләре аның каләменең үткенләнә, камилләшә баруы турында сөйли.

Әйе, поэзиябезгә, канатларын үзләренчә кагып, тагын бер төркем яшь карлыгачлар килә. Аларның саны елдан-ел ишәя, тулылана бара. Киләчәккә зур иҗади өметләр белән караучы бу яшь каләмнәрнең әсәрләрен поэзия сөючеләргә даими рәвештә тәкъдим итеп баруны хуплаудан башка сүз әйтеп булмый.

Рәшит ГӘРӘЙ

Шәмси Хамматов.
Шәех Зәбиров

# МАТБУГАТ ҺӘМ ЯЗУЧЫ

Бу ике төшенчә бер-берсеннән аерылгысыз яши. Кайсы гына газета-журналны актарып карасак та, анда политика һәм экономиканың күп төрле мәсьәләләренә караган мәкалә һәм корреспонденция, зарисовка һәм репортаж, заметка һәм информация белән бергә очерк яки шигырь, фельетон яки хикәя, мәсәл яки поэма, әдәби тәнкыйть һәм библиография, хәтта күләмле роман, повесть һәм пьесадан өзекләр очратабыз. Язучыларыбыз әдәби әсәрләре белән генә түгел, ә очерклары, иҗтимагый тормышыбызның төрле якларын яктырткан публицистик язмалары белән газета-журналларда әледән-әле чыгыш ясыйлар.

Вакытлы матбугат һәм әдәбият тарихы шуны дәлилли: безнең күренекле язучыларыбыз еш кына газета-журналларны чыгаруда турыдан-туры үзләре катнашалар, язучы-журналист буларак, эшче һәм авыл хәбәрчеләрен оештыралар, теге яки бу матбугат органында махсус һәм үз хәбәрчеләр булып эшлиләр. Газета публицистикасын үстерүдә язучыларның йогынтысы гаять зур. Үз чиратында газета һәм журналлар әдәби сүз осталарының иҗат тормышына үтеп керәләр, аларның эшчәнлеген киң яктыртырга, әдипләргә юнәлеш бирергә омтылалар. Вакытлы матбугат сүзе язучының идея-политик һәм әдәби-эстетик карашларын формалаштыруда, иҗат стилен билгеләүдә җитди роль уйный. Кыскасы, язучының газета-журналлар белән элемтәсе — безнең матбугатның һәм әдәбиятның күркәм традициясе, бердәм иҗат эшчәнлегендә ирешелгән матур казанышы.

Тарихка күз салыйк. 1905 елгы беренче рус революциясенә чаклы татар телендә чыккан вакытлы матбугат булмый. Шулай да рус һәм башка милләтләрнең матбугаты белән таныш булган, газета-журналларның әдәбият һәм сәнгатьне үстерүдәге, барыннан да бигрәк, халыкка аң-белем бирүдәге әһәмиятен аңлаган прогрессив язучылар татар телендә газета-журнал чыгару өчен җитди омтылыш ясап караганнар [1].

Гомерен халкыбызны агартуга, аңа культура хезмәте күрсәтүгә багышлаган галим, язучы, педагог, татарлардан беренче журналист-энциклопедист Каюм Насыйриның, ярым журнал характерындагы еллык өстәл календаре чыгарып тәҗрибә туплагач, татар телендә газета чыгарырга йөрүе халкыбызга мәгълүм.

Татар телендә беренче драма әсәре язган Габдрахман Ильяси, язучы һәм публицист Заһир Бигиев үткән гасырның 80—90 нчы елларында шулай ук газета чыгарырга омтылыш ясап карыйлар. Төрле сылтаулар табып, патша хөкүмәте аларга да рөхсәт бирми. Бары тик 1905 елда революция ясаган халык кына матбугат иреге яулап ала. Культура тормышындагы мондый яңалыкны татар язучылары шатланып каршылыйлар,

[1] Карагыз: М. Гайнуллин. «Татарская литература и публицистика начала XX века». Казан. 1966 ел. 113—119 битләр.

«җиң сызганып» газета-журналлар чыгару эшенә керешәләр, аларда әдәби әсәрләре, әдәби-тәнкыйть, публицистик мәкаләләре, рецензияләре белән катнашалар. В. И. Ленинның 1905 ел революциясенең иң кызган чагында язган «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» исемле мәкаләсендә әйтелгәнчә, үзләрен культура, әдәбиятка багышлаган интеллигенция изге максатка — көрәшкә күтәрелгән миллионнарга хезмәт күрсәтә. Менә шуннан бирле татар язучыларының эшчәнлеге һәм иҗаты турыдан-туры вакытлы матбугат белән тыгыз бәйләнештә үсә.

«Коеп куйган поэт кына түгел... дипломат, политик, общественный деятель дә» булган, «күзе күпне күрә, колагы күпне ишетә торган» [1] бөек шагыйрь Габдулла Тукай, үз заманының «серләрен» бик оста ачып биргән драматург Галиәсгар Камал, XX йөз башында татар әдәбиятында әдәби әсәрләре, реалистик тәнкыйте һәм ялкынлы публицистикасы белән танылган Фатыйх Әмирхан татар телендә демократик эчтәлекле газеталар, журналлар чыгара башлауда бик зур хезмәт куйлар. Мәсәлән, «Уралец» типографиясендә наборщик, фальсовщик, корректор булып эшли башлаган Г. Тукай Уральскида 1905 ел ахырында «Фикер» газетасын оештыруда актив катнаша һәм аның беренче саныннан ук үзенең шигырьләрен, хикәя, фельетоннарын, политик-иҗтимагый темаларга язган публицистик мәкаләләрен бастыра. Шулай ук татар телендә беренче рәсемле, юмористик-сатирик «Уклар» журналын оештырыша һәм аңа редакторлык итә. Журналдагы күп кенә мәкалә-язмалар һәм шулай ук иллюстрацияләрнең күбесе Тукай каләме белән языла һәм эшләнә. Казанга килгәч, Г. Тукай «Әльислах» газетасына языша башлый һәм, үзе әйткәнчә, «сөйгән газета вә идея»сенә «хезмәт итү» теләге белән янып яши» [2].

Бөек Тукай реакциянең иң төшенке елларында да татар ирекле матбугатының традицияләрен дәвам иттерә, публицист һәм фельетончы буларак чыгыш ясый. Аның публицистикасы политик үткенлеге һәм тирәнлеге белән аерылып тора. Реакция караңгылыгында адашып калганнарга үзенең яктылыгы белән юл күрсәтүче «Яшен» исемле көлкеле журналны Г. Тукай белән Г. Камал чыгара башлый. Г. Камал, Ф. Әмирхан ярдәмендә «Ялт-йолт» журналын чыгару эшенә керешеп, рәсми рәвештә җаваплы секретаре булса да, чынында исә Г. Тукай аның редакторы вазифасын башкара. Тәнкыйтьче Г. Халит әйткәнчә, 1905 ел революциясеннән соң татар матбугатында Тукай шикелле иң кыю һәм көчле публицист, татар җәмәгатьчелегендә ерата йогынты ясаган һәм халыкның тирән мәхәббәтен яулап алган икенче бер популяр шагыйрь һәм язучы булмый [1].

Классик драматург, талантлы сүз остасы, татар демократик культурасының төрле өлкәләрендә гаять зур һәм нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Галиәсгар Камал да татар телендә демократик газеталар һәм сатирик журналлар чыгаруда зур тырышлык күрсәтә. Ул 1905 елгы революция чорында Казанда татар телендә чыга башлаган беренче газета булган «Казан мөхбире»ндә эшли. Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, Г. Камал ярдәмендә Х. Ямашев һәм Г. Коләхметов бу басманы большевистик идеяләрне пропагандалауда файдаланалар. Бу газетада Г. Коләхметов самодержавиенең җимерелүе котылгысызлыгын аллегорик рәвештә чагылдырган «Уалган мол» хикәясе, М. Гафури политик үткен шигырьләре белән, Ш. Камал авылдан хатлары белән чыгыш ясый.

«Азат» газетасын оештыруда Г. Камал актив катнаша. Аннары Г. Коләхметов һәм Х. Ямашев ярдәмендә Г. Камал үз нәшерендә һәм редакторлыгында «Азат халык» исемле газета чыгара башлый, анда якын дуслары Х. Ямашев һәм Г. Коләхметов тарафыннан хәзерләнгән һәм большевистик идеяләрне пропагандалый торган күп кенә мөһим мәкаләләрнең дөнья күрүенә булыша. «Азат халык» үзенең иң беренче саннарыннан ук социал-демократларның көрәш программаларын татар халкына җиткерә. Гали-

---

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. 4 томда. I том. Кереш мәкалә. 21—22 битләр.
[2] Карагыз: Г. Тукай. Әсәрләр. IV том. 214 бит. (Г. Тукайның 1908 елның 23 июнендә Ф. Әмирханга язган хаты.)

[1] Карагыз: Г. Халит. «Габдулла Тукай». (XX йөз башында татар әдәбияты» дигән китапта. Казан. 1954 ел. 138 бит.)

эсгар Камалның исеме жандармерия өчен дәһшәтле исемгә әйләнә. Журналистлык эшендә революцион көрәшкә чакырганы өчен, аны ике тапкыр каты хөкемгә тарталар. Якын дуслары һәм җәмәгатьчелек ярдәме белән генә ул төрмәгә утырудан һәм крепостька ябылудан котылып кала.

Ул, беренче буларак, татар культура дөньясында рәсем эшен дә башлап җибәрә. Үзе чыгарган һәм редакторы булган «Яшен»дә, Г. Тукай секретарьлык иткән «Ялт-йолт» журналында һәм башка газеталарда Г. Камалның татар буржуа җәмгыятендәге тискәре, социаль зарарлы күренешләрне тәнкыйть иткән 200 гә якын карикатурасы басылып чыга [1].

Шулай ук язучылардан Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ш. Мөхәммәдов, М. Галәү, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ш. Әхмәдиев Октябрь революциясенә чаклы дәвердә татар матбугатының үсешенә әһәмиятле өлеш кертәләр. Шагыйрь М. Гафури газета-журналларга бик актив язышa. М. Гали, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Ш. Бабич, Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт кебек яшь талантлар үзләренең беренче әдәби әсәрләре, мәкалә-хәбәрләре белән вакытлы матбугат аша халыкка танылa башлыйлар.

Тагын шунысы мөһим: 1907 елда социализм идеяләрен пропагандалаучы, ленинчыл «Искра», «Вперед», «Пролетарий», «Новая жизнь» традицияләрен дәвам иттерүче татар телендә беренче большевистик «Урал» газетасы барлыкка килә. Шушы газетаны оештыручы беренче татар большевигы, ленинчы публицист-журналист Хөсәен Ямашев була.

Х. Ямашевның якын дусты, татар пролетар әдәбиятының тәүге үрнәген биргән, ленинчыл «Искра» газетасын укып тәрбияләнгән марксист әдип Г. Коләхметов үзенең публицистик мәкаләләре, әдәби әсәрләре белән татар хезмәт ияләрен большевистик идеяләр рухында сугаруга зур өлеш кертә. «Азат», «Азат халык» газеталарында Г. Коләхметовның большевикларның шул чордагы тактикасын аңлаткан мәкаләләре чыгуы шуны раслый. Х. Ямашев һәм Г. Коләхметов алдынгы фикерле татар язучыларын революцион эшкә тарталар, алар эшли торган вакытлы матбугатны большевистик идеяләрне пропагандалауда файдаланалар. Менә шундый эшчәнлек нәтиҗәсендә татар язучыларының үзләрен дә большевистик рухта тәрбияләүгә, татар әдәбиятында һәм публицистикасында пролетар юнәлешнең үсеп китүенә йогынты ясыйлар.

Беренче рус революциясе нәтиҗәсендә дөньяга туган, пролетар революциясе идеяләрен, В. И. Ленин хезмәтләрен милли телгә тәрҗемә итеп пропагандалаган, һәм, ниһаять, «Искра» кабызган очкынны сүндермичә дәвам иткән большевистик матбугатта прогрессив татар язучылары мөһим эш эшлиләр. Аларның эшчәнлегендә без ленинчыл традициянең йогынтысын күрәбез.

Бөек Октябрь көннәрендә туган вакытлы матбугат һәм яңа тормыш өчен көрәшкә күтәрелгән татар язучылары революциягә чаклы формалаша башлаган бу традицияне эчтәлеге һәм формасы ягыннан тагын да баета төшеп дәвам итәләр. Яңа шартларда газета-журналларның язучылар белән тыгыз бәйләнешен булдыруда большевиклар партиясенең даими кайгыртучанлыгы хәлиткеч роль уйный.

Ленинчыл «Искра» һәм башка барлык большевистик газеталар алдынгы язучыларның иҗат эшчәнлекләре турында мәкаләләр бастыра, сәнгатьчә сүзне эшчеләр сыйныфы интереслары өчен көрәштә файдалана. Мәсәлән, «Искра» газетасының секретаре Н. К. Крупская пролетар язучы М. Горькийның «Искра»га язуын сорый [1]. В. И. Ленин «Новая жизнь» газетасы өчен язган «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» дигән атаклы мәкаләсендә социализм идеясенә һәм хезмәт ияләренә теләктәшлек күрсәтүче язучыларны большевиклар белән хезмәттәшлек итәргә һәм бер сафта көрәшергә, аларны матбугат органнарында катнашырга чакыра. Газета-журналлар, нәшриятлар алдына социал-демократик эшчеләр хәрәкәте белән әдәбиятның тыгыз бәйләнешен булдыру өчен ник, төрле яклы, төрле рәвешле оештыру эшен алып бару кебек бөек һәм игелекле бурыч куя [2].

---

[1] Карагыз: Г а л и э с г а р  К а м а л. Әсәрләр. 2 томда. Таткнигоиздат. 1950 ел. I том. 23 бит.

[1] Карагыз: «Из истории Московской организации ВКП(б) (1894—1904)» М. 1947. 92 бит.

[2] Карагыз: «Новая жизнь» газетасы. 1905 ел. 13 ноябрь. № 12.

В. И. Ленин язучыларга һәм публицистларга язган хатларында аларның матбугат органнары белән элемтәләрен ныгытырга, газета битләрендә шигырьләр, проза әсәрләре, әдәби-тәнкыйть мәкаләләре белән киңрәк катнашырга киңәшлеге турында искәртә [1].

Юлбашчының һәм партиянең игътибарын даими сизеп торган язучылар, шагыйрьләр үзләренең әдәби әсәрләре белән дә, оештыру эшчәнлекләре белән дә вакытлы матбугатка ярдәм итәләр. Бу хезмәттәшлек Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында аеруча киң җәелеп китә. Рус әдипләре М. Горький, А. Серафимович, В. Маяковский, Д. Бедный үрнәгенә ияреп, татар язучылары да вакытлы матбугат эшендә актив катнашалар, кайберсе татар совет газеталарын оештыруда башлап йөриләр.

Октябрь революциясеннән соң фронтта һәм тылда күп санда татарча матбугат барлыкка килә. Әмма бу басмаларга җитәкчелек итәрлек һәм аларда эшләрлек әзерлекле журналистлар аз була. Шунлыктан партия идеология эшенең иң җаваплы өлкәсенә каләмнәре белән яшь Совет властена хезмәт итәргә әзер торучы әдипләрне тарту чараларын күрә. Шуңа күрә беренче совет газета-журналларын оештыру эше күп очракта политработникларга һәм язучыларга йөкләнә. Халык арасында танылган әдипләр вакытлы матбугатта эшләргә киң тартыла [2].

Үзен «пролетариат революциясенең солдаты» дип санаган Г. Ибраһимов, М. Вахитовның турыдан-туры булышлыгы белән, Үзәк мөселман комиссариаты органы булган «Чулпан» газетасын оештыруда (ул 1918 елның 18 январенда Петроградта чыга башлый) якыннан катнаша, чынлыкта татар телендәге беренче совет газетасының редакторы вазифасын башкара.

Казанда татар телендә чыгарылган беренче совет газетасы «Эш»нең («Социалистик Татарстан» газетасының башлангычы булган «Эш» газетасы 1918 елның 12 мартында чыга башлый) беренче редакторы итеп язучы һәм журналист Ш. Әхмәдиев билгеләнә.

1918 елларда татар телендә хәрби газеталар да барлыкка килә. Шундый газеталарның беренчесе һәм иң күп таралганы — Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең рәсми органы «Кызыл Армия». Мәскәүдә чыкканда аңа Мулланур Вахитов редакторлык итә, ә Казанга күчерелгәч, аның чыгуына хәрби коллегиянең политбүлек начальнигы, язучы Ш. Усманов зур булышлык күрсәтә. Коллегиянең даими хезмәткәрләре Г. Ибраһимов, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, С. Сүнчәләй, Ф. Сәйфи-Казанлы, И. Казаков, Ш. Әхмәдиев бу газета белән даими бәйләнештә булалар. «Кызыл Армия» редакциясендә Сембер шәһәреннән чакыртып китерелгән шагыйрь һәм драматург Ф. Бурнашның редактор, Оренбургтан килгән шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләйнең хәбәрче, Фатих Әмирханның сотрудник булып эшләве матбугат битләренең олы көрәш мәйданы булуы турында сөйли. Газетада үз әсәрләре белән М. Гафури, Г. Камал, С. Кудаш, Б. Рәхмәт, К. Әмири, К. Нәҗми һ. б. актив катнашалар. Эчтәлеге ягыннан иң бай саналган бу газетада дистәгә якын шагыйрь, әдип үсеп чыга. Газета һәр санында диярлек башлап язучылар иҗатына урын бирә [1].

Фронт газеталары бик күп яшь язучыларны әдәбият дөньясына алып чыга. Көнчыгыш фронттагы 1 нче армиянең политбүлек органы булган «Кызыл йолдыз» газетасында Муса Җәлил беренче шигырьләрен бастыра. Ш. Камал, Д. Юлтый һәм башкалар язышып тора. Казан, Уфа, Оренбург, Самара, Пермь, Сембер һ. б. шәһәрләрдә, фронтларда чыга торган газеталарда дистәләрчә әдип тәрбияләнә. Иң мөһиме — бу чордагы газеталар язучыларны революцион чынбарлыкка актив катнаштыра, аз вакыт эчендә революцион чыныгу мәктәбе узарга шартлар тудыра. Кыскасы, матбугат татар совет язучыларын яңа тормыш төзү эшенә, дошманга каршы көрәшкә туплый.

«...Бездә әдәбият кытлыгы,— дип яза «Эш» газетасы үзенең редакцион мәкаләсендә,— шикәр кытлыгыннан мең өлеш куәтле... Татар пролетариатын шикәрсез чәй эчү харап итмәсә дә, әмма рухани

[1] Ленин әдәбият турында. Казан 1960 ел. 10 бит.

[2] Карагыз: Т. Насыйров. «Совет властеның беренче елларында татар вакытлы матбугаты». («Совет әдәбияты» журналы. 1956 ел. № 9.)

[1] Карагыз: А. Яхин. «Үзәк мөселман хәрби коллегиясе һәм татар язучылары». («Совет әдәбияты» журналы. 1959 ел. № 10.)

ачлык харап итүе мөмкин» [1]. Бу фикерне тагын да ачыклап һәм тирәнәйтә төшеп, кабатлый: «Халыкка икмәк берлә су никадәр кирәк булса, хәзерге көндә рухи азык та шулкадәр кирәк» [2]. «Күрербез: заманалар тынычлангач, татар халкы, бөтен халыклар кебек үк, көчле туфан шикелле һиҗаплы вә шау-шулы хәятка биреләчәк. Аның эченнән зур сәнагъләр, шагыйрьләр, рәссамнар, артистлар, музыкантлар вә галимнәр килеп чыгар» [3].

Киләчәккә зур ышаныч белән караган «Эш» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасы шул чактан ук югары идеяле һәм сәнгатьчә көчле язылган әдәби әсәрләр тудыруга игътибар итә, татар язучыларының иҗади эшчәнлегенә тиешле юнәлеш биреп, алдынгы әдәби көчләрне революция һәм халык файдасына эшкә җигә.

Республика партия газетасының редакторлары булып төрле вакытларда язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Ф. Бурнаш, Ф. Сәйфи-Казанлы, күренекле әдәбиятчы-тәнкыйтьче Г. Нигъмәти эшлиләр.

Язучыларның совет вакытлы матбугатын үстерүгә керткән өлешен күрсәтү өчен берничә мисал китерик.

«Татарстан хәбәрләре» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасының ул чордагы йөзен, эчтәлеген билгеләүдә зур роль уйнаган Ф. Бурнаш 1922 елда «Татарстан хәбәрләре» битләрендә генә дә 129 мәкалә бастыра. Моннан тыш аның кайбер редакцион мәкаләләрнең дә авторы булуын әйтергә кирәк. Ә бит Ф. Бурнаш шул ук вакытта партиянең Татарстан өлкә комитеты органы «Безнең байрак» газетасы редакциясенә җитәкчелек итә. «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналында, соңрак «Чаян»да редактор. Газетага кушымта төсендә чыга башлаган бу басмаларда да Ф. Бурнашның күп санлы мәкаләләре, хәбәрләре басыла [4].

Язучы-журналистның бу чордагы эшчәнлеге турында М. Бурнашева болай дип искә ала: «Фәтхи абый бу елларны бик күп эшләде. Редактор, ТатЦИК члены, башка бик күп партия һәм җәмәгать эшләрен башкара. Газетага кергән һәр материалны игътибар белән укый, аннан кайткач, киләсе номерларга баш мәкалә яза. Рус газеталарыннан кирәкле материалларны үзе тәрҗемә ясый. Шигырьләр яза, татар театры өчен пьесалар иҗат итә. Тукай әсәрләренең җыентыгын төзүне дә, татар совет шагыйрьләренең беренче китабын әзерләүне дә аңа тапшырдылар. Иртән без йокыдан уянганда, әле ул ятмаган була иде» [1].

«Известия ТатЦИКа» (хәзерге «Советская Татария») газетасы аның эшчәнлеге турында 1923 елда бик хаклы рәвештә: «Иптәш Бурнашев хәзер дә татар журналистлары арасында беренче урынны алып тора», дип язды.

* * *

Партиянең XI съезды (1922 ел, март — апрель) «Матбугат һәм пропаганда турында» дигән резолюциясендә, «капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсүе нигезендә халыкның вак буржуаз катламнарына гына түгел, хәтта пролетариатның аеруча артта калган өлешенә дә буржуаз йогынтының көчәюе котылгысыз» булуын әйтеп, бу йогынтыга каршы агитация-пропаганда эшен көчәйтергә кирәклеген һәм массаларга тәэсир итү, аларга коммунистик аң бирү һәм оештыру өчен көрәштә матбугатның иң куәтле коралларыннан берсе булуын күрсәтә. Матбугат шушы бурычны уңышлы үти алсын өчен газеталарга игътибарны көчәйтү, аларны хәзерлекле партия кадрлары белән ныгыту бурычын көн кадагына куя, коммунист журналист өчен газета эшен төп партия эше итеп карарга куша [2].

Партиянең Татарстан өлкә комитеты 1922 елның маенда «Татарстан» газетасының «мәгънәви ягын көчәйтү өчен», башка коммунист журналистлар белән беррәттән, Г. Ибраһимовны да газетага «даими язышучы» итеп беркетә һәм аңа

---

[1] «Эш» газетасы. 1919 ел. 31 январь.
[2] «Эш» газетасы. 1919 ел. 7 март.
[3] «Эш» газетасы. 1919 ел. 5 февраль. «Әдәбият мәсьәләсе» исемле мәкалә.
[4] Карагыз: «Социалистик Татарстан». 1968 ел. 14 январь. А. Әхмәдуллинның «Талантлы журналист, редактор» исемле мәкаләсе.

[1] «Социалистик Татарстан». 1968 ел. 11 февраль. «Иҗади дуслык» дигән мәкалә.
[2] Карагыз: «КПСС съездлар, конференцияләр һәм Үзәк Комитет Пленумнары резолюцияләрендә һәм карарларында». Казан. 1956 ел. 7 нче басма. I кисәк. 692—698 битләр.

әдәби-иҗтимагый темаларга язу эшен йөкли.

Г. Ибраһимов партия кушканны намус белән үти. Әдип газетаның сыйфатын яхшырту, аны идея һәм профессиональ яктан ныгыту, тормыш таләпләренә якынайту буенча зур эш башкара. Татарстанда партия матбугаты әле яңа гына туып килгән бер вакытта өлкән буын татар язучыларын һәм журналистларын бу газета тирәсенә туплый, аларның талантын һәм бай иҗат тәҗрибәсен социалистик матбугат оештыруда файдалана. Язучы үзе дә матур үрнәк күрсәтә. «Татарстан»ның 1925 елда Татарстан республикасының бишьеллыгына багышлап чыгарылган санында Г. Ибраһимовның шул вакыттан соң газетада 26 мәкалә һәм 23 фельетон — барлыгы 49 материал белән чыгыш ясавы хәбәр ителә. Бу елларда язучының журналистлык эшчәнлеге «Татарстан» газетасы белән генә чикләнми. Ул «Эшче», «Кызыл Армия», «Кызыл яшьләр» һәм башка газеталарда да актив катнаша. Г. Ибраһимов публицистиканың барлык жанрларында да диярлек яза. Баш мәкалә һәм әдәби тәнкыйть мәкаләсе, пропагандистик мәкалә һәм рецензия, матбугат күзәтүе һәм заметка, репортаж һәм корреспонденция, ачык хат һәм памфлет — аның публицистик мирасында барысы да киң урын ала.

Революциядән соң Татарстанда чыга башлаган беренче мәгариф, әдәбият журналлары да турыдан-туры аның катнашы белән барлыкка киләләр. Г. Ибраһимов «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары»), «Мәгариф» (хәзерге «Совет мәктәбе») журналларын оештыручы һәм аларның беренче редакторы да була.

Г. Ибраһимов яшь язучылар, журналистлар хәзерләүгә зур игътибар бирә. Республикада эшче һәм авыл хәбәрчеләре хәрәкәтен җәелдерүдә ул турыдан-туры катнаша. 1923 елда «Эшче» газетасының бишьеллык юбилее уңае белән язган мәкаләсендә Г. Ибраһимов эшче хәбәрчеләр белән эшләүне газетаның иң мөһим һәм кыйммәтле сыйфаты итеп карый. Эшче хәбәрчеләрнең матбугатта кон-тон ныграк, кыюрак катнашуларын «зур эш, тарихи эш» итеп саный. Г. Ибраһимовның газета-журналлар өчен гаять әһәмиятле булган бу эшчәнлегендә дә большевистик матбугатның ленинчыл традицияләре дәвам итүен күрәбез.

Коммунистлар партиясе әле Октябрь революциясенә чаклы ук, тәҗрибәле әдипләрне матбугатка тарту белән бергә, эшчеләр арасыннан язучылар, шагыйрьләр, журналистлар тәрбияләүне кайгырта. Бу матур традиция Октябрьдан соң тагын да киң колач белән җәелеп китә.

Бу чорда язучыларның махсус оешмалары булмаганлыктан, партия куйган бурычларны үтәү күпмедер дәрәҗәдә матбугат органнарына йөкләнә. Менә шул юнәлештәге эшчәнлекне без татар матбугатында да бик ачык күрәбез.

Атаклы драматург, талантлы журналист-публицист Г. Камал утыз елдан артык дәвам иткән журналистлык эше дәверендә журналистлар, язучылар тәрбияләп үстерүгә зур тырышлык куя.

— Минем беренче хәбәрләремне, очерк һәм хикәяләремне Галиәсгар ага укыды, ул аларны матбугатка чыгарды, яңаларын язарга дәртләндерде,— ди күренекле язучы һәм публицист Афзал Шамов [1].

Совет власте елларында Галиәсгар Камал — татар журналистикасына аеруча зур өлеш керткән язучы. Октябрьдан соң оештырылган большевистик матбугатта да Г. Камал актив катнаша. Ул «Кызыл Байрак», «Эш», «Кызыл көрәшче», «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан» һәм «Кызыл Татарстан» газеталарында иң авыр йөкне тартып бара. «Эш» газетасында ул шагыйрь-декламатор да, художник та булып эшли. Бу газетаның иң беренче исеме Г. Камал кулы белән язылган булуы да бик кызыклы. Редакция сотрудникгы буларак, ул секретарьлык эшен дә үти, экспедитор булып газета таратуны да кайгырта.

Газетадагы эшчәнлеге турында Г. Камал болай дип язды: «Гражданнар сугышының кызган чагы. Деникин, Колчак һәм башка ак бандалар яшь Совет иленә төрле яктан һөҗүм итәләр. Шуңа күрә дә мин, кыска әсәрләр (шигырьләр) язып, көннең кадагына сугып барырга тиеш идем. Ул вакытларда мин икешәр көн өйгә кайтмыйча, редакциядә куныл эшли идем» [2]. Хәтта шундый чаклар була, коллективка эшләргә авыр вакытларда атналар буе газета әдип өендә әзерләнә.

---

[1] Карагыз: «Социалистик Татарстан» газетасы. 1968 ел. 1 март. «Иң беренчеләрдән» исемле мәкалә.

[2] Галиәсгар Камал. Әсәрләр. 2 томда. II том. 19 бит.

* * *

30 нчы еллар татар әдәбияты яңа күтәрелеше белән үзенчәлекле. Социалистик реализм язучылардан иҗат активлыгын арттыруны, тормышны тирәнтен өйрәнүне таләп итә. Шул бурычларны үтәү йөзеннән язучыларның социалистик төзелеш белән бәйләнешләрен көчәйтүдә конкрет чаралар күрелә. Илебезнең төрле төзелешләрендә, завод-фабрикаларында, колхоз-совхозларында булу нәтиҗәсендә, Г. Камал, Ш. Камал, М. Гафури, Һ. Такташ, Х. Туфан, Н. Баян, Ш. Маннур, Ә. Фәйзи актуаль темаларга күләмле әсәрләр язалар, ялкынлы публицистик мәкаләләр, очерклар, юл язмалары белән матбугатта чыгыш ясап, газета-журналларга заман сулышы белән бөркелгән сәнгатьле рух өстиләр. Үз чиратында газета-журнал редакцияләре күренекле язучыларның иҗат командировкаларын оештыра.

Нибары 30 яшькә сузылган гомерендә татар совет поэзиясендә тирән идеяле гүзәл мирас калдырган трибун шагыйрь Һ. Такташны тәрбияләүдә вакытлы матбугат та зур роль уйный. Газета аның өчен иҗади үсү мәктәбе була. Һ. Такташ «тормышны социализмча яңартып коруның һәм кешелекне үзгәртүнең гаять куәтле коралы» [1] булган каләме белән вакытлы матбугатта актив катнаша, шактый вакыт төрле редакцияләрдә эшли. Ул Оренбургта чыга торган «Юксыллар сүзе» газетасы, Ташкентта «Белем йорты» исемле журнал редакцияләрендә җаваплы секретарь, Казанга килгәч, төрле вакытларда «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә әдәби сотрудник, соңрак «Чаян», «Октябрь яшьләре», «Авыл яшьләре», «Азат хатын» журналлары редакцияләрендә җаваплы секретарь булып эшли, бер үк вакытта «Яңалиф» журналының редколлегиясе члены да була. Һ. Такташ бу матбугат басмаларының идея-художество сыйфатларын күтәрүгә күп хезмәт куя.

Вакытлы матбугатта эшләү Такташны политик атмосфераны бик яхшы сизә торган шагыйрь итә, политик зирәклеген үткенли. Үз чорының актуаль мәсьәләләрен тирәнрәк аңларга, тормыш көрәшләренең асылын, типик үзенчәлекләрен дөрес тотып алырга өйрәтә. Бу исә ахыр чиктә вакыт узу белән дә әдәби-политик кыйммәтен югалтмый торган озын гомерле әсәрләр иҗат итүгә китерә. Шагыйрь газетада чыккан гади факттан да гомумиләштерү көченә ия булган әсәрләр иҗат итү сәләтенә ирешә.

Үзен шагыйрь генә түгел, ә тулы хокуклы журналист та дип [1] санаган Муса Җәлилнең вакытлы матбугат белән бәйләнеше, газета-журналлар редакцияләрендәге эшчәнлеге «Киләчәккә хатлар» авторыныкына бик охшаш.

Оренбургта чыга торган «Мөхбир» газетасы редакциясендә корректор булып эшләгән абыйсы Ибраһим Җәлилов аша илдәге төрле яңалыклар белән танышып барган Муса өчен матбугат яшьтән үк бик якын булып китә. Шуңардан үрнәк алып, 1917—18 елларда Хөсәения мәдрәсәсендә укыганда үз классында газета да чыгара башлый. Бу газетаны нинди-дер кызык өчен, эш юктан бер мавыгу өчен генә чыгарылган дип булмый. Сабакташларыннан бер башка өстен торган, яхшы укуы өстенә, пьесалар язып күрсәткән кечкенә Муса газетаның тормыштагы көченә, тәэсиренә төшенгән, күрәсең.

Ибраһим Җәлилов истәлегендәге бер фактка игътибар итик. 1918 елның апрель башларында төнлә Дутов шайкасы көтмәгәндә шәһәргә һөҗүм итеп, казармада йоклап яткан берничә кызылармеецны кылыч белән тураклап чыга. Бу фаҗигале хәл турында «Мөхбир» газетасы яза, шәһәр халкы бик нык нәфрәтләнә. Муса бу җан тетрәткеч вакыйганы газетадан укып кына калмый, корбан булган солдатларның мәетен абыйсы белән барып карый. «Шуннан кайткач,— дип искә ала И. Җәлилов,— Муса, бик нык нәфрәтләнеп, бер мәкалә язды. Класс күләмендә Муса редакторлыгында чыга торган бу газета аның мәкалә һәм шигырьләре белән тулы була иде» [2].

Шагыйрь, үзе язганча, 1922 елның көзендә Казанга килгәч, «Татарстан» газетасы редакциясенә күчереп язучы булып

---

[1] Һ. Такташ. «О себе». «Красная Татария» газетасы. 1931 ел. 24 май.

[1] Карагыз: Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. Казан. 1956 ел. 3 том. 421—422 битләр. М. Җәлилнең 1942 елның 3 апрелендә тәнкыйтьче һәм язучы Г. Кашшафка язган хаты.

[2] Муса турында истәлекләр. Казан. 1964 ел. 6 бит.

карә»[1], бу елларда шигырьләре газета һәм журналларда бер-бер артлы чыгып тора. «Татарстан» газетасы редакторы булып эшләгән Ф. Бурнаш аңа зур булышлык күрсәтә. Аның вакытлы матбугат белән элемтәсе ныгый. 1927 елда Мәскәүгә килгәч, ул инде турыдан-туры матбугат органнарында эшли башлый. Бу елларда «Кечкенә иптәшләр» журналының редакторы, «Яшь эшче» журналының редколлегия члены була, аннары «Октябрь баласы» журналына җитәкчелек итә. Шагыйрь бу басмаларны массовый итәргә, пионерларны журнал чыгару эшенә тартырга, алар арасыннан язучылар, хәбәрчеләр хәзерләргә тырыша. Моңа «Октябрь баласы» журналы хәбәрчесе Фазлыев Галигә 1929 елда язган хаты дәлил. «Журналга хәбәрче-язучы булып катнашырга... теләвеңне бик шатланып каршы алабыз,— дип яза Муса Җәлил.— Шулай кирәк. Без сиңа булышырбыз...

Эшне алып барырга уңай булсын өчен үз тирәңә актив җыйна. Шул тирәдә «Октябрь баласы» дуслары (бала хәбәрчеләр) түгәрәге төзеп җибәр. Ул түгәрәккә без эш кулланмалары язып җибәрербез. Түгәрәк журналга хәбәрчеләр җыярга, аларның әйберләрен тикшереп, карап журналга җибәрергә... тиеш»[2].

М. Җәлилнең 1933—1934 елларда «Коммунист» газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшләгәндә яшь язучылар һәм хәбәрчеләр тәрбияләүгә игътибары аеруча арта. Яшь язучыларның әсәрләренә рецензияләр яза, иҗатлары турында мәкаләләр белән газета-журналларда чыгышлар ясый, хатлар аша киңәшләр бирә.

Вакытлы матбугатта эшләгәндә ул өлгереп җиткән әдәби-тәнкыйтьче булып чыгыш ясый. Гомумән, «Муса Җәлил әдәби тәнкыйть өлкәсендә бай мирас калдырды. Бу мираста без киң күләмле мәкаләләр дә, кечкенә рецензияләр дә күрәбез. Муса Җәлил халык иҗаты турында да яза, рус һәм Европа язучыларының әсәрләренә бәя бирен килә, балалар әдәбиятына әледән-әле күзәтүләр ясый, театр һәм опера постановкалары, концертлар турында рецензияләр бирә. Тәрҗемәләрнең сыйфаты һәм классик мирастан өйрәнү кирәклеге турында фикер йөртә»[1].

Бөек Ватан сугышы алдыннан ул аеруча «Кызыл Татарстан» газетасында әдәби-тәнкыйть, публицистик мәкаләләре, рецензияләре белән катнаша. Партиянең Казан шәһәр комитеты кушуы буенча бу газетаның еллык эшенә күзәтү дә әзерли. Шушы газетаның иң актив авторы итеп санагангадыр, Бөек Ватан сугышы башлангач, үзен фронтка «Кызыл Татарстан» газетасының хәрби хәбәрчесе сыйфатында җибәрүләрен сорый, «ана теленнән башка, башкорт, казакъ, үзбәк һ. б. кончыгыш телләрендә иркен сөйләшә алганлыктан, «милли частьларда», «Язучы һәм журналист буларак», файда китерергә теләк белдерә»[2].

Ниһаять, 1942 елның 5 апреленнән ул фронт газетасында хәрби хәбәрче-сөштыручы вазифасын башкарырга тотына.

* * *

Татар укучылары, Бөек Ватан сугышының беренче көненнән үк, гражданнар сугышы дәверендәге кебек, акыл-йөрәкләре кушканча, кулларына корал алып фронтның алгы сызыгына китәләр. Һ. Такташчарак әйтсәк, шигърият көрәштә туа, ә шул көрәшкә хезмәт итәргә тиешле. Шулай булгач, шагыйрьнең җырны икенче чиратка, иртәгә эшләнәчәк эшләр чиратына калдырырга намусы, вөҗданы кушмый. Дошманны тизрәк җиңү уе белән ашкынган язучы, юк вакытын бар итеп, иҗат итә, бөек көрәшкә рухи өлеш өсти һәм чын мәгънәсендә фидакарьлек, батырлык күрсәтә. Әйе, фидакарьлек, батырлык! Чөнки аңа гади солдатка караганда икеләтә, өчләтә тырышлык куярга туры килә.

Ике фронтта — ил азатлыгы һәм әдәбиятның югары идеяле, сәнгатьчә нәфислеге өчен көрәшүче язучыларның уртак фикерен чагылдырып, Ф. Кәрим бу гражданлык тойгысын Г. Кашшафка 1943 елның 24 июлендә язган хатында бик ачык һәм гади итеп әйтеп бирә: «Миңа сугыш

[1] М. Җәлил. Сайланма әсәрләр. 3 томда. 1956 ел. I том. 4 бит.

[2] Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. Казан. 1956 ел. 3 том. 392 бит.

[1] Гази Кашшаф. «Муса Җәлил». Казан. 1961 ел. 179 бит.

[2] Карагыз: шунда ук. 245—246 битләр. (Муса Җәлилнең 1942 елның 20 январенда Александр Фадеевка мөрәҗәгать итеп язган хатыннан.)

уты эчендә кайнап язган әйберемне сугыш беткәч өч елдан соң чыгаруның кызыгы юк. Минем сугыш барган вакытта мылтыгым белән дә, каләмем белән дә илемә, халкыма туктаусыз хезмәт итәсем килә...» [1].

Язучылар ут эчендә «мылтык түтәсенә салып язган» әсәрләренең калын-калын китап булып чыгуын көтмичә, беренче итеп хәрби газеталарда һәм тылдагы халык көнендә укый торган вакытлы матбугатта чыгаралар. Өстәвенә, аларның күбесе фронт газеталары редакцияләрендә редактор һәм хәрби хәбәрче-оештыручы булып эшли.

Муса Җәлил солдат язмышын газета хәбәрчесе булып башлый, газета эшчесе булып тәмамлый. Гадел Кутуй фронтта журналист постында вафат була, дивизия газетасы редакторы Нур Баянның гомере хәрби бурычны үтәгәндә өзелә.

Бөек Ватан сугышы чорында татар телендә унбишләп исемдә газета чыга. Аларның һәркайсында диярлек татар язучылары эшләп, редакцияләр узган данлы юлны уза. «Ватан намусы өчен» газетасы редакциясендә шагыйрь капитан Әхмәт Ерикәй, драматург майор Риза Ишморат, «Совет сугышчысы»нда шагыйрь-хикәяче, тәрҗемәче майор Мәхмүд Максудов — редактор урынбасарлары; «Ватан өчен» газетасы редакциясендә язучылар, шагыйрьләрдән Х. Госман, Ш. Мөдәррис, «Ватан намусы өчен»дә — Г. Хуҗи, М. Садри, З. Шәһиморатов, Г. Бакиров; «Алга, дошман өстенә»дә — Ш. Маннур, А. Шамов, А. Әхмәт, Ф. Басыйров; «Сталин байрагы»нда — И. Гази, Ә. Фәйзи; «Ватан өчен сугышка»да — Г. Әпсәләмов, Гиз Габидуллин (Гиз Эль-Габид) «Фронт правдасы»нда — Ә. Фәйзи, «Кызыл сугышчы»да — Р. Баһау; «Кызыл Армия»да — Г. Кутуй, И. Гази, Г. Галиев; «Фронт хакыйкате»ндә — Ш. Мөдәррис, Г. Насрый; «Тревога»да — М. Мавлюков; «Сталин сугышчысы»нда — Г. Әпсәләмов, Гиз Габидуллин; «Суворовча кысрыклау» газетасы редакциясендә А. Шамов, А. Әхмәт, Ф. Басыйров хәрби хәбәрчеләр булып эшлиләр.

Сугыш вакытында Төньяк-көнбатыш фронтта чыга торган «Ватан өчен» газетасы редакциясендә озак вакытлы иҗат командировкасында булып, үзенең очеркләры, хикәяләре белән газетада актив катнашып кайткан М. Әмир, фронтовик язучылар «сугыш шартлары таләп иткән көндәлек авыр бурычларны башкару белән беррәттән, әдәбиятыбыз тарафыннан йөкләнгән зур һәм мактаулы бурычны да башкарып киләләр. Үзләренең бөтен иҗат көчләрен тулысы белән фронтка биргән бу каләм ияләре, иң алгы сафларда сугышучы татарлар белән янәшә торып, ут астында алар белән танышалар, алар күрсәткән геройлыкларны газета битләре аркылы бөтен фронтка җәелдерәләр»,— дип язды [1].

Тылдагы матбугат, әдипләрнең әдәби әсәрләрен үз битләрендә чыгарып, бердән, халыкны патриотик рухта тәрбияләсә, икенчедән, әдәбиятның, язучыларның үсүенә дә ярдәм итә. Бөек Ватан сугышы чорында «Кызыл Татарстан» газетасы, «Совет әдәбияты» журналында барлык фронтовик язучылар да катнашалар диярлек. Тылда яшәүче әдипләрдән, мәсәлән, Г. Разин (Г. Бәширов), М. Әмир — «Ватан өчен» газетасы редакциясенә, Г. Иделле — «Ватан намусы өчен», Ф. Хөсни — «Сталин байрагы», Х. Хәйри «Совет сугышчысы» газеталары редакцияләренә озак вакытлы командировкаларга барып кайтып, фронт һәм тылдагы матбугатта очерклар, язмалар, публицистик мәкаләләр белән чыгалар. «Кызыл Татарстан» газетасына, «Совет әдәбияты» журналына К. Нәҗми, Г. Кашшаф, Ф. Хөсни, Г. Бәширов аеруча күп язалар.

Күренекле татар язучысы Ш. Камал Ватан сугышының беренче көннәрендә үк, М. Горькийның көчле публицистик чыгышы рухында язылган, «Без җиңәрбез!» [2] исемле ялкынлы мәкаләсе белән халыкның игътибарын бер максатка — дошманны тар-мар итүгә туплауда булыша. Аның «Кызыл Татарстан» газетасына «Дошман бетерелергә тиеш» исемле, үләр алдыннан язган соңгы мәкаләсе дә шул хис белән сугарылган [3]. «Кызыл Татарстан» язучыларны матбугатка кыю тарта. Мәсәлән, ул 1945 елның 9 май

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1958 ел. № 2. 79—80 битләр.

[1] «Кызыл Татарстан» газетасы. 1943 ел. 5 май. «Фронттагы язучылар» исемле мәкалә.

[2] Карагыз: «Совет әдәбияты». 1941 ел. № 7.

[3] Карагыз: «Кызыл Татарстан». 1942 ел. 24 декабрь.

саңында дүрт язучының — Ә. Ерикәй, Ә. Фәйзи, Т. Гыйззәт, Ә. Юнысның поэтик әсәрен, К. Нәҗми, М. Әмир, Г. Иделле, С. Фәйзуллинның күләмле публицистик мәкаләләрен, Ә. Айдарның нәсерен басып чыгара. Газетаның башка саннары да публицистик язмаларга, шигырь, очеркларга бай.

Басым ясап шуны әйтергә кирәк: Бөек Ватан сугышы чоры матбугаты әдәбиятка яңа көчләр китерә, партиябезгә яңа каләм осталары тәрбияләргә ярдәм итә. Г. Әпсәләмов, Ш. Мөдәррис, А. Расих, Х. Мөҗәй һ. б. вакытлы матбугат битләрендә аеруча танылып үсеп китәләр.

Бөек Ватан сугышы чоры матбугатында, гражданнар сугышы елларындагы кебек, нәсер сугышчан жанрга әверелә. Хикәяләрдә публицистик рух көчәя. Сугышчының психологик кичерешләрен, уй-фикерләрен җанлы эпизодларда тасвирлаган кыска очерклар, публицистик язмаларның аеруча үсеп китүе бу чор вакытлы матбугатына бик хас. Әдәбиятның оператив жанрыннан саналган очеркларда актуаль мәсьәләләр үз вакытында яктыртыла, фронттагы һәм тылдагы вакыйгалар җанлы образлар, конкрет детальләр аша укучыларга җиткерелә. Хәрби очерклар Бөек Ватан сугышының документаль күнделегә ролен үтиләр. Бу жанрны үстерүдә А. Шамов, К. Нәҗми, Г. Бәширов, Х. Госман, Ш. Мөдәррис, М. Садри, И. Гази, М. Әмир, Г. Иделле, Ә. Ерикәй, Г. Әпсәләмов, Ш. Маннур, А. Әхмәт һ. б. күп көч куялар.

Очеркларга һәм язмаларга тартым хәрби көндәлекләр шулай ук газета-журналларда еш күренә. Г. Кутуй, Ш. Маннур, Г. Иделле, соңгы чорда Г. Бакиров, Г. Галиев язмалары шул фикерне раслый. Аеруча татар совет публицистикасы үзенчәлекле жанр буларак үсеп китә. Сугышның беренче көненнән башлап язучылар дошманга карата халыкта нәфрәт тәрбиялиләр, җиңүгә бетмәс-төкәнмәс ихтыяр көче уяталар. Язучылар һәм шагыйрьләр катнашында язылган татар халкының фронтовик сугышчыларына, сугышчыларның тылдагы үз халкына язган хатлары — ялкынлы публицистиканың гүзәл үрнәге. Фронт газеталары ярдәмендә чын мәгънәсендә журналистларыбыз, язучыларыбыз үсеп чыга. Алар, газета редакцияләрендә эшләп, сугышчыларыбызны патриотик рухта тәрбияләүдә зур эш эшлиләр. Газеталарны җанлы һәм эчтәлекле итү өчен сугышчыларның үзләрен матбугатка киң тартырга кирәклеген яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә фронтта чыга торган һәр татар газетасы редакциясе каршында штаттан тыш хәбәрчеләр группасы оештырыла, дошман адым саен куркыныч янап торган ут эчендә дә хәбәрчеләр белән киңәшмәләр үткәрелә. Бу эштә дә язучылар оештыру үрнәге күрсәтәләр. «Ватан намусы өчен» исемендәге фронт газетасы редакциясендәге шундый эшчәнлек турында язучы Госман Бакиров көндәлегендә болай язып уза: «Газетабыз үз тирәсенә йөзләрчә актив хәбәрчеләр туплый алды, аларны үстерде, тәрбияләүдә төп чараларның берсенә әйләнде»[1].

Икенче яктан, язучылар, турыдан-туры фронт белән бәйләнештә булып, үзләренең иҗат эшләрен киң җәелдерделәр. Мәсәлән, драматург Р. Ишморат дәһшәтле сугыш елларын чагылдырган әсәрләре өчен материалны шушы чорда туплый. Шагыйрь Г. Хуҗиның «Россия», «Яу күрке», «Гражданин, солдат, шагыйрь» кебек поэмаларын һәм күп кенә шигырьләрен татар сугышчылары яратып укыйлар. М. Садри иң яхшы поэмаларын, ялкынлы шигырьләрен ут эчендә иҗат итә. Ялкынлы яшь шагыйрь Ш. Мөдәррис «Ватан өчен» газетасында чыккан «Тупчы Ваһап» дигән талантлы поэмасында солдатларның әкиятләргә сыймаслык батыр кодрәтен җырлый. З. Шаһиморатов, Г. Рамазанов, Гали Ибраһимов кебек язучылар шул газеталарда каләмнәрен чарлыйлар. Шулай ук шагыйрь С. Баттал, язучы А. Расих, яшь шагыйрьләрдән М. Хөсәен, Ә. Маликов, хикәячеләрдән С. Сабиров, Ә. Айдар, яшь язучылардан М. Гаяз, И. Закиров фронт газеталарында актив язышып, әдәби осталыкларын камилләштерә баралар. Газеталар аларның үсүе өчен зур булышлык күрсәтә, язучыларга иҗат эшләрен дәвам итү өчен уңай мөмкинлек тудыра.

Барысын бергә җыйнап әйткәндә, вакытлы матбугат тыныч төзелеш елларында да, сугыш чорында да язучылар өчен тормышны өйрәнү, иҗади осталыкларын камилләштерү мәктәбе булып тора. Совет язучысының стиле — ил язмышы белән яшәү әнә шулай туа.

---

[1] «Казан утлары» журналы. 1968 ел. № 8. 95—103 битләр.

## Шәүкәт Галиев

### Эш кушып булмый...

— Савыт-сабаны ю! — дисәң:
— Юдым! — ди Гәүһәр.—
Юдым инде, киптерергә
Куйдым! — ди Гәүһәр.

— Keләм...— диеп авыз ачсаң —
Кагып өлгерткән.
Кушарга эш тә калмаган,
Өйдә эш беткән.

— Кибеткә бар, алайса! — дим.
— Кайттым инде,— ди.
— Бер конфет ал! — дим.—
Икене
Каптым инде! — ди.

...Терекөмеш бөртеге кебек
Тиктормас шундый —
Эш кушар хәл юк Гәүһәргә,—
Өлгереп булмый!

### Светофорның өч сүзе

Урамнарны
Күзәтеп,
Ваемсызны
Кисәтеп,
Чатта тора
Светофор,
Сакта тора
Светофор.

Янып тора
Өч күзе,
Күреп тора
Ич безне,
Әйтеп тора
Өч сүзне:

— Кузгалма! — ди
Кызыл күз.
— Сабыр! — дия
Сары күз,
— Ярый! — дия
Яшел күз.

Без дә аңа
Карыйбыз,
Күзебезне
Алмыйбыз,
Ни әйткәнен
Аңлыйбыз:

— Кузгалма! — ди
Кызыл сүз,
— Сабыр! — дия
Сары сүз,
— Ярый! — дия
Яшел сүз!

## Мактаныша малайлар...

Мактаныша малайлар —
Мәхмүт, Нәгыйм, Рамайлар.

Мәхмүт әйтә болай дип:
— Минем әби уңган бик,
Минем әби кулай бик —
Әйткәнемне дә кәтми,
Чалбарны да үтүкли.
Күлмәкне дә үтүкли!

— Минем әби дә бик шәп,
Барын да бирә эшләп,—
Диеп Рамай кушыла
Шундук Мәхмүт дусына.

Нәгыйм дә ялгап китә:
— Бабакайга кем җитә —
Яратып эшли бик тә,
Ботинкамны чистартып,
Китерә ялтыратып!

Күрдем мин малайларны,
Мактанган Рамайларны.
Тыңладым, абайладым —
Шәп икән әбиләре,
Шәп икән бабайлары!..

## Бииләр бармаклар

Гармунның телләре
Шоп-шома, ап-аклар.
Бииләр телләрдә,
Бииләр бармаклар.

Авышып уң якка,
Авышып сул якка,
Сикереп я алга,
Чигенеп я артка,

Һай оста, һай җитез
Тыпырдый бармаклар,
Сизми дә калалар —
Кушыла аяклар;

Бииләр, бииләр,
Сагынган икәннәр —
Гармунның теләдәй
Сыгыла иданнәр!

## Минем абый шигырь ятлый...

Бүлмә буйлап
Атлый-атлый
Минем абый
Шигырь ятлый:
— Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән...
...Кәҗә белән...

Шунда җиткәч
Туктап кала,
Әйтеп бирә
Әнкәй аңа:
— ...Менә кәҗә карап тора тәрәзәдән...

Сөенеп абый
Ялгап китә,
Үзе дә тиз
Атлап китә:
— Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә... кәҗә...

Абый хәлен
Яхшы аңлап,
Дәү әнием
Китте ялгап:
— Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

Абыем да
Шулай диеп,
Кабатлады
Башын иеп:
— Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә...

Бер ялгышып,
Бер кабатлап,
Абый һаман
Йөри ятлап.

Ә бит инде
Мин дә беләм,
Телисезме,
Сөйләп бирәм:
— Безнең кәҗә бигрәк тату Гали белән,
Менә Гали карап тора тәрәзәдән.
Кәҗә аны чирәм белән кунак итә,
Гали рәхмәт укый: сакалын селкетә.

Ник көләсез,
Ялгыш мәллә,
Дөресе ничек,
Яле, сөйлә?

## Бурыч

— Синең, Борис,
Бурыч бар ич!
— Дөрес, Варис,
Менә бурыч
Сиңа бер уч —
Бәтте бурыч!
— Әптечи!

## Өч тиенгә...

Әнисе шәһәргә бара,
Ильяс озатып кала.
Әнисенең учына ул
Өч тиен акча сала.

Бөгә-бөгә бармагын
Санап китә аннары:
— Мылтык,
кылыч,
ат,
кирәк ал!
Ал әкият китабы!
Самолет,
танк,
фонарь ал,
Ал матур карандашлар!
Алырсың калган акчага
Тагын сыбызгы да шар!

## Салкын аваз

«Р» авазы
Булган айлар —
Салкын алар.
Берәм-берәм
Санап карыйк,
Бергә-бергә
Сынап карыйк...

Январь, январь —
Ява карлар,
Туңа җанвар.
Февраль, февраль —
Җилләр өрә,
Кар себерә.
Март — март инде,
Шарт, шарт инде!
Апрель, апрель —
Кыш чигенә
Акрын-акрын...

«Р» авазы
Булмаса, җай —
Нинди җылы,
Мәсәлән — май!

Кошлар җыры,
Кояш нуры —
Июнь җылы,
Июль җылы,
Август җылы!

Сынагансың
Син дә гел —
Салкын сулый
Сентябрь.
Октябрь да
Ноябрь,
Икесенә
Бәя бер —
Битләреңне
Өтәдер,
Яңадан кыш
Җитәдер.
Менә сиңа
Декабрь!

Әйе, сәбәп
Бер генә —
Салкынайта
«Р» гына!..

## Бер гөмбә...

Гайса урманда
Күрде бер гөмбә.
Карый — бүтән юк,
Бары бер генә.

Бер генә булгач,
Нигә ул алсын,
Бер гөмбә белән
Нишләп була соң?

Күбрәк булыр! — дип,
Атлады ары,

Тагын да ялгыз
Гөмбә очрады...

Шулай көнозын
Эзләнеп йөрде.
— Гөмбә юк,— диеп
Буш кайтып керде.

Әйтми калдырды
Бары тик шуны —
Иптәшләренең
Кәрзине тулы...

## Мөдәррис Әгъләмов

### Студент кунагы

Әйдә, апа, урын тапсаң
Түрдән үт!
Бер хатыңны алган идем
Күптән үк...
Язып сала алмадым шул
Җавапны,
Ул хат никтер уйларымны
Таратты...
Ошаган икән үзеңә
Шигырьләр,
Ярый инде, алай артык
Түгелләр.
Әйдә, апа! Түргә атла,
Тарсынма.
Хәзер юнәтеп алабыз
Барысын да.
Кием элгеч? Ә ул безнең
Күршедә!
Урындык? Ах,
онытканмын —
Кешедә!
Хәзер чабам, хәзер табам
Барысын да.
Өеңдә йөргән кебек йөр,
Тарсынма!..
Киләсеңне язган булсаң
Бер очтан,
Акча алган булыр идем
Бурычка...
Нәрсә? Акча бирәсеңме?
Кирәкми...
Дөрес, йомырка тавыкны
Өйрәтми...
Очтым, апа! Барып кайтам
Кибеткә...
Ничек бармыйсың туганың
Килеп тә...
Әйбәт булды әле, апа,
Килүең...
Ач карынга яза идем
Мин бүген...

Менә, укый тор, бер кочак
Шигырьләр...
Алар минем күк тәртипсез
Түгелләр...
Әй, нигә торам соң һаман
Бәйләнеп,
Очтым гына... Хәзер кайтам
Әйләнеп...

1967

## Шагыйрь хакында...

Корьән әйтә: «Нинди гөнаһ кылма,
Кайчан кылма, нинди рәвештә? —
Бөтенесен терки юлын-юлга
Иң өстендә ике фәрештә».

Ничә тапкыр сәрхушланып йөрдең
Хәйям авыз иткән хәмердән,
Ничә тапкыр качып, читкә чыктың
Ходай язып куйган әмердән...

Фәрештәләр теркәп, язып торыр,
Һәммәсенең төгәл исәбе...
Өлешеңә яки оҗмах булыр,
Я булырсың тәмуг кисәве.

Тик шагыйрьгә кагылмыйдыр болар
Шагыйрь халкы бит ул беркатлы...
Көнен-көнгә язып, теркәп куяр
Җирдә үзе кылган гөнаһны.

Белмим, көндез нәрсә кичерәдер,
Төнлә инде арган рәвештә
Шагыйрь язганнарны күчерәдер
Ашыга-ашыга ике фәрештә.

1970

## Буйдак булсаң...

Бүгенге төн шундый гүзәл, шундый яшь,
Шундый сылу, үлеп гашыйк булырлык.
Кинәт кенә кагылды тымызык җил
Төште сикереп бер чәчәктән бер орлык;
Икенчесе, өченчесе сикерде...
Бу җиһанга исең китеп торырлык —
Бүгенге төн шундый сылу, шундый яшь,
Шагыйрь булсаң
үлеп гашыйк булырлык!

1970

### «КАЗАН УТЛАРЫ»Н ТИКШЕРҮ

Татарстан язучылар союзы идарәсенең сентябрь башларында булып узган киңәйтелгән утырышы «Казан утлары» журналын тикшерүгә багышланган иде.

Журналның 5—8 саннарында басылган повесть һәм романнар турындагы сүзне Ф. Хөсни башлады. Без хәзергә ике зур әсәр хакында фикер йөртә алабыз, диде докладчы, аның берсе «Тын елга буенда» (роман), икенчесе — «Ялыкмаслар» (повесть). С. Рафиковның «Тын елга буенда» романы — әһәмиятле, кирәкле әсәр. Автор тормыш объектын яхшы белә, теле тулаем әйбәт. Әсәрдә гыйбрәтле эпизодлар, реаль образлар шактый. Романның кимчелеге — персонажлар арасындагы мөнәсәбәтләрнең мотивлаштырылып җитмәгән булуы. Аннан соң характерлар һәм вакыйгалар үсешендә беркадәр логикасызлык сизелә. Ф. Хөсни Б. Камаловның «Ялыкмаслар» әсәренә нигездә уңай бәя бирде.

Докладчы Ш. Маннур поэзия әсәрләре хакында сүз алып барды. Журналда басылган шигырьләрнең эстетик көче дә, идея эчтәлеге дә тиешле югарылыкта икәнлеген әйтте. Ләкин шуның белән бергә, диде докладчы, шигырьләр тематик яктан ярлырак, поэзия әсәрләрендә кеше образы, бүгенге көннең Зөбәйдәләре, Алсулары юк, кеше образын бөтен тулылыгы белән сурәтләү өчен поэма жанрына мөрәҗәгать итү кирәктер. Ахырдан Ш. Маннур аерым авторларның шигырьләренә тукталды. Аларның уңышлы һәм кимчелекле якларын күрсәтте.

Хикәя һәм очерклар, публицистик язмалар хакында И. Низамов чыгыш ясады. Ул хикәяләргә нигездә уңай бәя бирде, публицистика әсәрләренең дә уңышлы якларына тукталып, кайбер очеркларда геройларның катлаулы проблемаларны бик ансат хәл итүен, тормыш конфликтлары артык шомартылып, гомумиләштереп бирелүен күрсәтеп үтте.

Драматургиягә анализ ясаган докладчы Р. Ишморат Н. Исәнбәтнең «Аулак өй» әсәрен дә, Т. Миңнуллинның «Кем сызган» һәм Х. Вахитның «Күк капусы ачылса» комедияләрен дә яхшы әсәрләр рәтенә кертте.

Х. Госман һәм Н. Гыйззәтуллин әдәби тәнкыйть турында чыгыш ясап, әдәби тәнкыйтькә соңгы вакытта талантлы һәм тирән белемле яшьләр килүен әйттеләр. Журналга кергән тәнкыйть мәкаләләренең күбесе мавыктыргыч итеп язылган, кызыклы, материалга бай дип билгеләнделәр. Журналның һәр санында чыгып килә торган бәләкәй рецензияләрнең авторы куелмавын, гадәттә, әсәрләрнең уңышлы яклары гына әйтелүен искәртеп үттеләр.

Р. Даутов иң яхшы тәрҗемә әсәрләрен генә тәкъдим итәргә кирәк дигән фикер әйтеп, журналда басылган тәрҗемәләрнең кимчелекләрен күрсәтте. Уңай якларын санап чыкты.

Ахырдан журналның баш редакторы Г. Ахунов чыгыш ясады. Ул 1972 елда журналга 50 яшь тулачагын әйтте һәм юбилей елында эшләнәчәк эшләр белән таныштырды. Журналга тәкъдим ителгән фәнни әсәрләрнең гыйльми булулары гына түгел, аңлаешлы булулары да шарт, диде. Киләчәктә бәләкәй рецензияләр урынына «Китап күзәтү» бүлеге булачагын, киләсе елның беренче санынннан даими рәвештә язучыларның әдәби мираслары бирелә башлаячагын һәм журналда басылган кече жанрдагы иң яхшы әсәрләрнең ел ахырында бүләкләнәчәген әйтеп үтте.

Йомгаклау сүзе белән Язучылар союзы председателе З. Нури чыкты.

## ЯҢА ПРОГРАММА ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ

РСФСР Мәгариф министрлыгы милли мәктәпләр институтының Татарстан филиалында эшләүче фәнни хезмәткәрләр әдәбият укыту мәсьәләләре хакында республикабызның төрле районнарында һәм шәһәрләрендә әледән-әле лекция укыйлар. Соңгы елларда яшь буынны туган әдәбият материаллары нигезендә тәрбияләүгә аеруча зур әһәмият бирелә. 1971 елда бу мәсьәләне пропагандалау РСФСРның төрле өлкәләрендә үткәрелгән татар теле һәм әдәбияты укытучыларының семинарларында да актуаль яңгыраш тапты. Куйбышев өлкәсенең Камышлы зонасында (январь), Пермь каласында (март) әдәбият укытучылары филология фәннәре кандидаты, доцент А. Әминевнең «Татар әдәбияты укыту процессында хезмәткә ихтыяҗ тәрбияләү — мөһим патриотик бурыч», филология фәннәре кандидаты Г. Әдһәмованың «Коммунистик әхлак тәрбиясендә әдәбият дәресләренең урыны һәм роле», «IV класста әдәбиятны предметлап укыту методикасы» дигән темаларга сөйләгән лекцияләрен тыңладылар.

Чуваштанның Батыр районында укытучыларның белемен күтәрү институты методисты Ф. Исламовның «Татар әдәбияты укыту процессында интернациональ тәрбия мәсьәләләре» һәм «Класстан тыш эшләр үткәрүдә татар әдәбияты бай чыганак» дигән лекцияләре дә республиканың татар теле һәм әдәбияты укытучыларында зур кызыксыну уятты. РСФСРның милли мәктәпләрендә туган тел, рус теле һәм әдәбиятларын яңа программа буенча укыту мәсьәләләренә багышланып, Грозный шәһәрендә үткәрелгән фәнни-практик конференциягә илебезнең төрле ягыннан делегатлар җыелды. Конференциянең пленар утырышында Татарстан делегациясе җитәкчесе, милли мәктәпләр институтының Татарстан филиалы мөдире, педагогия фәннәре кандидаты Г. А. Жданова үзенең котлау речен кунакларга сәлам һәм истәлекле бүләкләр тапшыру белән башлап җибәрде. Конференциянең Туган тел һәм туган әдәбият укыту секциясендә милли мәктәпләр институты Татарстан филиалының өлкән фәнни хезмәткәре Б. Мифтаховның «Татар телен яңа программа буенча укыту мәсьәләләре» һәм Г. Әдһәмованың «Татар телен яңа программа буенча укытуның башлангыч нәтиҗәләре» турындагы лекцияләрен секциядә катнашучы күп төрле милләт вәкилләре зур игътибар белән тыңладылар, татар мәктәпләренең эш проблемалы укыту һәм татар әдәбиятының үсеше, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, М. Җәлил традицияләренең ни рәвешә дәвам итүе белән кызыксындылар.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ГОМУМИ ҖЫЕЛЫШЫ

Сентябрь аенда Татарстан язучыларының гомуми җыелышы булып, сүз СССР язучыларының V съезды йомгаклары һәм язучылар алдына куелган бурычлар турында барды.

Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Зәки Нури үзенең докладында Татарстан язучыларының эшенә бәя биреп, каләм осталарын ирешелгән уңышлар белән генә канәгатьләнмәскә, киләчәктә тагын да тырышыбрак эшләргә, әдәби әсәрләренең санын арттыру белән бергә, сыйфат ягына да нык игътибар бирергә чакырды. Докладчы шулай ук иҗат секцияләренең эшен тагын да активлаштырырга кирәклеген әйтте. Язучыларның V съезды куйган таләпләргә туры килерлек, тирән эчтәлекле, югары идеяле, бүгенге көн геройларын сурәтләүче әсәрләргә киңрәк мәйдан бирергә кирәк, диде. Татарстан язучылар союзы Әлмәт бүлегенең җаваплы секретаре, шагыйрь Равил Фәйзуллин чыгышы нефть ягы әдипләренең иҗатын яктыртуга багышланган иде. Равил Фәйзуллин яшь прозаикларга һәм яшь драматургларга язучылар оешмасы тарафыннан да, өлкән әдипләр һәм тәнкыйтьчеләр тарафыннан да игътибар җитмәвен әйтте. М. Горький һәм Г. Тукай премияләре лауреаты, шагыйрь Сибгат Хәким әдәбиятның милли һәм интернационал үзенчәлекләре турында сөйләде. СССР язучыларының V съездында әйтелгән, хәзерге заманда рус әдәбияты милли әдәбиятларга йогынты ясаган кебек, милли әдәбиятлар да үз чиратларында рус әдәбиятына тәэсир ясыйлар, дигән фикерне куәтләп, язучыларны иҗат эшенә тагын да игътибарлырак, тагын да таләпчәнрәк булырга чакырды. Әсәр халыкның мең еллык тарихыннан, мең еллык культурасыннан, көнкүрешеннән чыгып язылса гына чын мәгънәсендә әдәби әсәр була ала һәм шундый әсәрләр генә озын гомерле, диде. Тукай премиясе лауреаты, шагыйрь Хәсән Туфан чыгышында да әдәби әсәрләрнең сыйфатын яхшырту мәсьәләсе алгы планга куелды. Язучы София Радзиевская чыгышының нигезенә яшь буынны коммунистик рухта тәрбияли торган әсәрләр күбрәк булсын иде, дигән фикер са-

лынды. Тәнкыйтьче Гази Кашшаф бүгенге әдәби тәнкыйтьнең бурычлары турында сөйләде. «Казан утлары» журналының баш редакторы, язучы Гариф Ахунов та бүгенге әдәби тәнкыйть мәсьәләләренә тукталды. Тәнкыйтьчеләр алдында торган актуаль проблемалар хакында сөйләде. Әдәби тәнкыйтьнең әле һаман да тиешле югарылыкка күтәрелеп җитмәвен, заманнан, бүгенге тормыштан шактый артта калуын һәм шуңа күрә күп кенә яңа әсәрләргә объектив бәя бирелмәвен билгеләп үтте.

Җыелышта язучы Ә. Еники, галим Х. Хисмәтуллин, тәрҗемәче С. Ибраһимова һ. б. иптәшләр дә сөйләде. КПССның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. М. Мусин зур чыгыш ясады. Партиянең Казан шәһәр комитеты һәм Бауман район комитеты вәкилләре катнашты.

Җыелыш СССР язучыларының V съезды карарларын бертавыштан яклады, аларны тормышка ашыру өчен көчләрен аямыйча эшләүне һәр язучының төп бурычы итеп куйды.

## КҮРЕНЕКЛЕ БИБЛИОГРАФ

Озак еллар буена Татарстан китап палатасының җитәкчесе вазифасын үтәгән күренекле библиограф Ә. Б. Булатовка быел 70 яшь тулды. Ә. Булатов озын һәм мактаулы тормыш юлы узган кеше: эшче, укытучы, редактор, Мәскәү Дәүләт тарих музеенда нумизмат. Гражданнар сугышы елларында ул Кызыл гаскәрдә хезмәт итә. Бөек Ватан сугышы чорында халык ополчениесе сафына баса. Татарстан китап палатасы директоры булып эшләү дәверендә Ә. Булатов татар библиографиясен үстерүгә күп көч куя. Республикабызның 1941—1949 еллардагы «Периодик басмалар елъязмасын» төзи, «Газета һәм журналлар елъязмасы» да 1955 елда аның инициативасы белән басыла башлый. «В. И. Ленин әсәрләре һәм аның турындагы әдәбият татар телендә. 1917—1966» дигән кыйммәтле күрсәткечне әзерли. Совет чорында Татарстанда басылып чыккан китапларның җыелма каталогын төзү эшенә җитәкчелек итә (якынча 1400 исемдә). Татарстанда басылып чыккан рус телендәге журналларның җыелма каталогын төзи. Бу тынгысыз кеше татар әдәбиятын җыеп библиографияләштерү эшен пенсиягә чыкканнан соң да (1968) дәвам иттерә. Ул Татарстан язучылар союзы, СССР фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты китапханәләрендә эшли. Ә. Булатов, фәнни атеизмның халык университеты ректоры һәм СССР журналистлар союзы члены буларак, зур җәмәгать эше алып бара. Библиография өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әхмәт ага Булатовка берничә мәртәбә хөкүмәт бүләкләре бирелде.

## РУС СЕКЦИЯСЕНДӘ

Татарстан язучылар союзының рус секциясендә отчет-сайлау җыелышы булды. Секция бюросының яңа составына Т. Журавлев (председатель), Ю. Белостоцкий (секретарь), Г. Паушкин, М. Скороходов, В. Воздвиженскийлар сайланды.

## ИСТӘЛЕКЛЕ ОЧРАШУ

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында журналистлар, язучылар, китап нәшрияты, радио һәм телевидение хезмәткәрләре КПСС Үзәк комитеты органы «Коммунист» журналының культура бүлеге редакторы урынбасары В. А. Дмитриев белән очраштылар. Сүз КПССның XXIV съезды карарлары яктылыгында совет әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүнең кайбер әһәмиятле проблемалары хакында барды.

## КОНКУРС ЙОМГАКЛАРЫ

«Сельская новь» журналы иң яхшы очеркларга конкурс үткәргән иде. Журналның баш редакторы иптәш А. Куликов ТАССР язучылар союзына җибәргән хатында «Алма исе» очеркы өчен Р. Кутуйга беренче бүләк бирелүе турында хәбәр итте.

## СҮРИЯ ЯЗУЧЫЛАРЫ БҮЛӘГЕ

Татарстаннан бер төркем язучылар һәм сәнгать эшлеклеләре быел җәен Сүриядә булган иде. Алар анда Сүрия язучылары белән очраштылар, истәлекле бүләкләр алыштылар. Бу сәяхәттә катнашкан драматург Х. Вахит Татарстан язучыларының гомуми җыелышында татар язучыларына сүрияле дуслар җибәргән бүләкне — гарәп халык көе язылган шкатулканы тапшырды.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Язучы Г. Минский Кама автогиганты төзүчеләре янында булып кайтты. Ул анда

әзичеләр, «Кама таңнары» газетасы каршында оештырылган әдәби берләшмә членнары белән очраштылар.

* * *

ТАССРның халык артисты, композитор З. Хәбибуллин, шагыйрьләр Г. Латыйп, Р. Гатауллин, Р. Әхмәтҗанов Мамадыш районнары авылларында уникә очрашу үткәрделәр.

* * *

Югары уку йортларындагы комсомол работникларының республика семинары үзенең чираттагы утырышын Казан авиация институтының «ИКАР» дип аталган яшьләр-спорт лагеренда үткәрде. Совет әдәбияты үсеше мәсьәләләренә багышланган бу утырышта шагыйрьләрдән Р. Харис, Г. Рәхим, Н. Беляев катнашты.

## АРТИСТЛАРЫБЫЗ ЧАЛЛЫДА

Кама автомобиль заводы төзелешендә уздырылган музыкаль фестиваль көннәрендә ТАССРның халык артисты, Тукай бүләге лауреаты И. Шакиров концертлары аеруча зур уңыш белән барды. ТАССРның атказанган артисты, нәфис сүз остасы Ф. Йосыпов, баянчылар Н. Курамшин, В. Усманов катнашында «Идел» электр-музыка кораллары ансамбле чыгышларын тамашачылар яратып кабул иттеләр.

## ХУДОЖНИКЛАР СЪЕЗДЫ

Актерлар йортында Татарстан художникларының I съезды булды. Съездда Татарстан художниклары союзы идарәсе председателе Х. Г. Якупов отчет доклады белән чыкты. Фикер алышулардан соң республикабыз художникларын РСФСР художниклар союзы идарәсе секретаре С. П. Ткачев һәм тугандаш республикалардан килгән вәкилләр кайнар котладылар. Татарстан язучылары исеменнән котлау сүзе белән Язучылар союзының җаваплы секретаре Р. Харисов чыкты. Съезд Татарстан художниклар союзы идарәсенең яңа составын сайлады. Идарәнең председателе итеп РСФСРның халык художнигы Х. Г. Якупов сайланды, секретарь итеп Б. С. Яхнинель расланды.

## ЯҢА ТӨЗЕЛЕШЛӘРДӘ

Октябрь башларында республикабызның иҗат көчләре — язучылар, композиторлар, художниклар, артистлар, кино, радио һәм телевидение хезмәткәрләре, журналистлар илебезнең бөек төзелешләреннән берсе — КамАЗда булдылар. Кызыл почмакларда, клубларда әдәби-музыкаль кичәләр үткәрделәр. Яр Чаллы шәһәренең «Чулпан» кинотеатрында, Түбән Кама шәһәренең музыка училищесында зур кичәләр уздырдылар. КамАЗ, Түбән Кама химкомбинаты җитәкчеләре, район-партия работниклары белән очрашып, кызыклы һәм файдалы әңгәмәләр алып бардылар.

# 1971 ЕЛДА ЖУРНАЛ БИТЛӘРЕНДӘ БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

## ПРОЗА

Г. Афзал. **Ферзь гамбиты.** Хикәя. № 1.
Г. Ахунов. **Чикләвек төше.** Повесть. № 10.
З. Воскресенская. **Караңгы төндә.** Хикәя. № 1.
А. Вергазов. **Тәнкыйтьче.** Хикәя. № 7.
Ә. Баянов. **Ут һәм Су.** Роман. № 9, 10, 11, 12.
Р. Батулла. **Көтелмәгән кунак.** Хикәя. № 12.
Г. Бәширов. **«Иске будильник» көйсезләнә.** Повесть. № 1.
И. Гази. **Табылдык китап. Сарбай — сары эт.** Хикәяләр. № 5.
М. Гапаров. **Тургай.** Хикәя. № 7.
Б. Гани. **Изге эш.** Хикәя. № 2.
М. Зарипов. **Җәйге командировкада.** Хикәя. № 5.
Д. Зөбәерова. **Куш өянке шаһит.** Хикәя. № 10.
Р. Исаев. **Җор малай.** Хикәя. № 7.
Б. Камалов. **Ялыкмаслар.** Повесть. № 8, 9.
У. Кукзод. **Дөя кайдан килеп чыккан.** Хикәя. № 2.
В. Нуруллин. **Ул яшәргә тиеш иде.** Хикәя. № 8.
Т. Миңнуллин. **Кульяулык.** Хикәя. № 9.
Җ. Мостафин. **Күк тулпар.** Хикәя. № 1.
В. Монасыйпов. **Казан кешесе.** Хикәя. № 9.
Г. Мөхәммәтшин. **Ике әби бәрәңге ала.** Хикәя. № 8.
Г. Мөхәммәтшин. **Табылдык хатлар.** Хикәя. № 9.
Г. Мөхәммәтшин. **Җыелыш.** Хикәя. № 10.
Ф. Мөхәммәдиев. **Мәгърифәт урыны** Хикәя. № 2.
С. Рафиков. **Тын елга буенда.** Роман. № 2, 3, 4, 5, 6.
С. Сабиров. **Фирдәвес.** Хикәя. № 11.
Сорбон. **Төш.** Хикәя. № 2.
И. Салахов. **Карлыгач.** Хикәя. № 8.
С. Сөләйманова. **Безнең апай — королева.** Хикәя. № 3.
С. Сөләйманова. **Йолдызларга йодрык.** Хикәя. № 6.
И. Туктар. **Җөмләләр.** № 6.
Ә. Фазылҗанов. **Без кемнән ким.** Юмореска. № 6.
Р. Ханнанов. **Инсафлы килен. Гыйльми нәтиҗә.** Хикәяләр. № 6.
Н. Ходза. **Сүз бирдеңме — сүзеңдә нык тор.** Хикәя. № 1.
Ф. Хөсни. **Кем кемне җиңә!** Хикәя. № 4.
Ф. Хөсни. **Мәйдан.** Повесть. № 7.
Ф. Хөсни. **Ташландык.** Хикәя. № 11.
М. Хәбибуллин. **Икмәк кадере.** Повесть. № 1.
Ә. Хәкимов. **Гомер.** Хикәя. № 5.
Г. Хәсәнов. **Иман.** Этюд. № 7.
М. Хәсәнов. **Дулкыннар ярга тәгәри.** Хикәя. № 4.
А. Шамов. **Мәхәббәт трагедиясе.** Повесть. № 3.

Ә. Шәмин. Өметле шайтан. Хикәя № 6.
Ф. Шәфигуллин. Җан Али. Хикәя. № 9.
Ф. Шәфигуллин. Диалоглар. № 2.
С. Әдһәмова. Нәфисә апа. Хикәя. № 2.
Г. Әпсәләмов. Карт. Хикәя. № 2.
Г. Әпсәләмов. Идел хикәяте. Повесть. № 12.
К. Җусупова. Иске рәис. Хикәя. № 7.

## ПОЭЗИЯ ӘСӘРЛӘРЕ

М. Абрамчик. Оста. Шигырь. № 4.

Ш. Алишева. Еллар үтә... Берәүгә. Шигырьләр. № 3.

Ф. Ансори. Юлда. Шигырь. № 2.

А. Антонович. Яз белән саубуллашу. Шигырь. № 3.

Н. Арсланов. Сагышларым. Каурый каләм белән. Күзләр. Әгәр шагыйрь... Далаларым. Тәгәри гомерем арбасы... Пилигрим. Агыйделдә, айлы төндә. Үтенеч. Шигырьләр. № 5.

Н. Арсланов. Партияле кеше диләр мине. Карпат итәгендә. Гади бер фәлсәфә. Байрон рухы. Язгы тамчылар. Кобзарь янында. Табигать белән тартышканда. Мин бик риза. Илһамга. Мәрцишор. Минем балдыз. Хафиз газәлләре. Гомәр Хәйям робагыйлары. Шигырьләр. № 9.

Г. Афзал. Җирем. Болыннарда билдән үлән... Иртә генә таңнан... Туган илем..: Кеше күңеле... Бөгелмә аэропортында. Мин яшь әле... Юллар сутәбез... Өченче кызым тугач. Чиллә. Төн астында кыюлык. Иялэнгән бөркет. Портрет. Заман белән бәхәс. Шигырьләр. № 5.

С. Баттал. Чирмешән якларында. Поэма. 3, 4.

К. Булатова. Шушы яктан, шушы туфрактан без. Февраль. Пушкин белгән... Бишек җыры. Шигырьләр. № 3.

А. Байзуллаев. Зәңгәрсу кыялар. Шигырь. № 3.

Ә. Бикчәнтәева. Күзгә моңнар. Җилләрең, бураннарың. Шигырьләр. № 3.

Б. Бедюров. Тулган ай әкияте. Шигырь. № 3.

А. Буланов. Багана. Күнекте. Зарлана. Мактанды. Яраталар. Качты. Ал да гөл. «Соавтор». Шигырьләр. № 9.

Р. Вәлиев. Әнкәйгә хат. Шигырь. № 3.

Р. Вәлиев. Авылда туй. Шигырь. № 11.

Габдел Ваһһап Әл-Баяти. Ленин. Шигырь. № 4.

Гавханкар. Таң тимерчеләре. Шигырь. № 4.

А. Гаврилов. Эзләр. Шигырь. № 3.

Гауссу Диавара. Халыклар юлбашчысы. Шигырь. № 4.

Ш. Галиев. Бәрәңге турында. Тормыш тозы. Кайчак:.. Үсә дә китә.... Күнегелгән... Кара юллар була... Борчулар йөрәкне таласа... Артык имин көн... Әмер булсын иде... Тизрәк җитсен:.. Җәй әле... Җәйнең соңгы көне... Язын... Елмайдың да киттең... Үкенмәскә... Таныш түгел... Текәлеп карыйм:... Мин омтылган максат... Күңелем.:. Шигырьләр. № 6.

Р. Гатауллин. Ышандылар. Шигырь. № 3.

Ф. Галиева. Җиргә ак юрган түшәп... Юртак атың булса... Күзләреңнән алып... Шигырьләр. № 9.

Ә. Гыйззәтов. Күз яшьләре. Бала йоклый. Яңгыр малай. Беренче кар. Хатлар әйтсен. Шигырьләр. № 1.

Ф. Гыйззәтуллина. Эшләмәсәң әгәр... Үкенерлек ялгышларың булса. Югалтырмын кебек... Бәхетнең ниндие насыйптыр... Йөк бавымда. Җиңеп кайту хакына. Кылган чәчле кызкай — бала чак. Шигырьләр. № 1.

Ф. Гыйззәтуллина. Сайлаган юлымнан... Гомерләр бар... Туган көнемдә. Шигырьләр. № 10.

Р. Гәрәй. Гөрләп кабынып төсле. Исемеңне язсын бутәннәр. Карлыганнар каралган. Кем уйлаган... Ут йотып кайтып килэм. Олы һөҗүм шулай башланды. Шигырьләр. № 10.

Р. Закиров. Яшим әле... Буразналар сызам... Дуслык. Чалт аяз булса да бүген көн... Ялга кайткач. Һаман котәсең... Шахтер сүзе. Мәхәббәт турында җыр. Кошлар юлы. Кайвакыт төн буе поездда... Манара. Инде вакыт. Шигырьләр. № 2.

Зөлфәт. Керә вакыт байракларын җәеп. Шигырь. № 4.

Зөлфәт. Хәрәкәттә йөрәк. Авыр... Кичер. Күпердә. Фатыйма. Юралмаган төш. Тынлык. Көлү-елау. Кайтмый калган. Сүз. Шигырьләр. № 8.

Зөлфия. Җил. Сагыш. Үземә. Йөрәгем калды сездә. Айлы төн. «Түрдән узыгыз». Һавада... Минем таңым. Кайда сәламең! Шарлавык. Шигырьләр. № 7.

М. Калмыкаев. Сагыну. Шигырь. № 3.

М. Каноат. Разлив. Шигырь. № 2.

А. Каххори. Елмаю. Шигырь. № 2.

А. Комендантас. Төн. Шигырь. № 3.

Г. Латыйп. Мәскәү яны. Иртәдән үк... Аның гомере... Гөлгенә. Җырчы чыршы. Туры килдек. Шигырьләр. № 9.

М. Львов. Безнең Атлантида. Госпитальдә. Минем татар телем. Өстәлемдә — Җәлил. Билгесез солдат. Казан вокзалында... Хәким дустым... Ир кешеләр. Шигырьләр. № 9.

М. Мазунов. Яшь каләмдәшкә. Хәлимә. Ак күгәрченнәр. Шигырьләр. № 7.

Ш. Маннур. Күңел дәфтәреннән. Шигырьләр. № 12.

Ш. Маннапов. Бер мәкаль бар... Йолдызлар. Яңа фатирга күчтек. Шигырьләр. № 11.

М. Миршакар. Бөркет. Шигырь. № 2.

Р. Мингалимов. Күзгә төндә. Сәбәп. Ул шулайдыр әле... Төзәтеп тә булмый. Кәрчык. Күптән болай... Юл бирегез. Кәз. Ташлар. Шигырьләр. № 8.

Р. Миңнуллин. Үзгәрешләр. Шамун Фидаига. Татар хатыннары. Шәһре Болгарда. Сагындыра. Элегия. Пират исемле эткә. Шигырьләр. № 10.

Э. Мостафин. Югалган углан монологы. Без бәхәстә. Сулар ага да ага... Мин ант иттем... Юеш канатларын кагып... Скрипка елый. Шигырьләр. № 7.

К. Мостафин. Эпиграммалар. Пародияләр. № 5.

К. Мостафин. Алиһәләр. Бала чактан бирле... Йөз дә беренче хикмәт. Поши. Җыр турында баллада. Тормыш — лотерея, дигән... Шәфәкъ... Син оныткан ап-ак яулык... Шигырьләр. № 8.

М. Ногман. Умырзая. Киек казлар китә. Төн патшасы. Шигырьләр. № 8.

З. Насыйбуллин. Йомычка. Озынборын. Карачкы. Турылык. Мин-минлек. Ике килми. Саран. Бала «гаебе». Ике фикер. Бүкән. Алтын сүз. Битараф. Шигырьләр. № 6.

З. Насыйбуллин. Булды еллар... Һәйкәл янында. Безнең көнгә карый Спартак. Үлем түшәгендә... Кара аккош. Шулай булды. Шигырьләр. № 10.

З. Нури. Коры куык. Китмә, Кыш бабай. Характеристика. Ялгыш юл. Үземне күрдем төштә. Җепсез йомгак. Аяктан екты. Шигырьләр. № 5.

З. Нури. Лирика һәм юмор. Шигырьләр. № 12.

И. Пиняев. Кен килер. Шигырь. № 1.

У. Раҗаб. Сукмак. Шигырь. № 2.

Ә. Рәшитов. Дусларга. Яшьлек белән саубуллашканда. Шигырьләр. № 9.

Г. Рәхим. Моңлы бер җыр. Шигырь. № 3.

М. Садри. Кояш кызлары. Шигырьләр циклы. № 4.

К. Сибгатуллин. Туу. Юл башы. Әманәт. Заман котә. Йөз дустың юкта... Мәҗнүн. Киткәндә. Шигырьләр. № 2.

Д. Сирай. Карагачлар. Шигырь. № 4.

Д. Сирай. Төндә. Дәвам итәбез. Кар сулары акты. Нигез. Шигырьләр. № 11.

А. Старостин. Мин Себер, тундра улы. Бүлмәм минем... Шигырьләр. № 3.

Г. Сәгыйров. Минутлар... Ашыгам сиңа. Кайсыгыз анда... Син миңа яхшылык эшләдең. Элегия. Ишәк. Шигырьләр. № 6.

М. Турсунзода. Кояш белән хатын-кыз. Шигырь. № 2.

Х. Туфан. Кармәт эскизлары. Шигырьләр циклы. № 11.

А. Тяпаев. Ленин янында. Шигырь. № 1.

Е. Уткин. **Ат сакларга чыга малайлар. Үз үре бар җирдә кешенең. Тегермән.** Шигырьләр. **№ 11.**

Х. Файзулло. **Җилгә әйтә агач.** Шигырь. **№ 2.**

Р. Фәйзуллин. **Вакыт. Сөйли. Ни генә дә җиткесез... Космополит түгел... Идел ага. Туры дустың улмы... Этюд. Бу сөю... Булчы, зинһар... Хиссият илендә икәү... Соңгарган шаһит... Сигезьюллыклар.** Шигырьләр. **№ 1.**

Р. Фәйзуллин. Шигырьләр. **№ 11.**

М. Фәйзуллина. **Җәйнең тынлыгы. Нәни поши.** Шигырьләр. **№ 3.**

Р. Харисов. **Яфраклар.** Шигырьләр циклы. **№ 1.**

Р. Харисов. **Яралар.** Шигырьләр циклы. **№ 11.**

М. Хәкимова. **Энҗе бөртеге.** Шигырь. **№ 2.**

С. Хәким. **Барын да мин... Республикам турындагы декрет. Без давыллы бер чор кешеләре... «Сибелә чәчәк». Тирәлдә уйда-күңелдә. Урман еша... Яңгыр явып үтте... Яз килә... Өнкәй... Төштә нәрсә күргәнлегеп... «Яшәү белән үлем арасында»... Мәҗлесләрдә шагыйрьләр... Союз түгел.** Шигырьләр. **№ 1.**

С. Хәким. **Кырыгынчы бүлмә.** Поэма. **№ 12.**

Р. Хәлиуллина. **Төсләр. Түгим әле... Гөлләрем-сөмбелләрем.** Шигырьләр. **№ 3.**

М. Хәсәен. **Мәхәббәттә янса йөрәкләр...** Сонетлар. **№ 9.**

М. Шабаев. **Җикән камыш.** Шигырьләр. **№ 7.**

Ф. Шәфигуллин. **Яшьлек. Таныш түгел эткә. Кою цехында. Онытмам сине. Каеннар. Исеңдәме.** Шигырьләр. **№ 8.**

З. Шаһбазов. **Кайтмадыгыз.** Шигырь. **№ 3.**

Л. Шерали. **Соңгы җыр.** Шигырь. **№ 2.**

В. Щекачев. **Мостафа авылында. Шагыйрьнең сеңелесе.** Шигырьләр. **№ 5.**

И. Юзеев. **Юк, мин яши алмыйм алай... Хушыгыз! Мин китәм еракка!.. Бәрәңге чәчәге. Үз-үзеңне эзләп табыйм диеп... Аннан бирле күпме печән үсте... Заман агышыннан калуларын... Яшьтәшләре бар да яуга киткән... Йокыга талды арып кайткан... Балалыкка кире кайтыйм әле... Йөзек кашы. Мин сине нигә яратам!** Шигырьләр. **№ 2.**

И. Юзеев. **Манеэрда шагыйрь бара... Һәр нәрсәгә карыйм... Шагыйрьләр нигә картаймый! Дуска. Шушы урамнардан атлап... Бер сүз. Хыяллар. Иптәшләре җаза бирделәр дә...** Шигырьләр. **№ 10.**

Юзил. **Сонет турында сонет. Илһам килгәндә һәм киткәндә. Яңа җырчы. Төкле аягың белән! Мәсәл геройларының сөенече. Аркозо. «Идел»гә. Вера Минкинага.** Шигырьләр. **№ 6.**

Ф. Яруллин. **Ат сайладым.** Шигырьләр. **№ 12.**

М. Әгъләмов. **Уйна, курай! Таулар. Исәнмесез, өлкәннәр! Ай туганда. Иман. Казан. Каз өмәсе. Туй. Мин шундый җыр язмак булдым... Җырчы картым.** Шигырьләр. **№ 1.**

М. Әгъләмов. **Студент кунагы.** Шигырьләр. **№ 12.**

Р. Әхмәтҗанов. **Бүген тормыш танымады мине... Сугыштан кайталмаган егет сүзләре. Ак җиптән... Мин күренмәм...** Шигырьләр. **№ 5.**

Роберт Әхмәтҗанов. **«Мин — Сонгми!» Бала чак кышы. Романс.** Шигырьләр. **№ 11.**

Х. Әюпов. Атлар. **Шигырьләр. № 12.**

## СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Х. Вахит. **Күк капусы ачылса.** Комедия. **№ 7, 8.**

А. Гыйләҗев, А. Яхин. **Шамил Усманов.** Драма. **№ 2.**

Т. Миңнуллин. **Кем сызган!** Пьеса. **№ 6.**

## ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Р. Бернс. **Тауларда минем йөрәгем. Сәфәрче төн кунган йорт. Финдлей. Син мине ташладың... Кырларның яңгыр, карларын... Җыр. Җыр.** Шигырьләр. **№ 10.**

Ван Дай. **Солдат курткасы.** Шигырь. **№ 11.**

Хоанг Тхи Минь Кхань. **Кочсезләнеп тала бара.** Шигырь. **№ 11.**

Те Хань. Ленин һәм Аппассионата. Шигырь. № 11.
Фам Хо. Тәҗрибәсез бал корты. Шигырь. № 11.
То Хыу. Яшел күлмәк. Вьетнам кызына. Шигырьләр. № 11.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Р. Миңнуллин. Казан төне. Төнге дөнья... Кояш. Беренче кар. Күз тимәсен... Саллар ага. Шигырьләр. № 1.

Ф. Сафин. Музей ачтым. Юлда. Һаман шулай... Бер елганың ике ярында. Карт атменәр. Шигырьләр. № 6.

## БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Р. Батуллин. Курай уйный бер малай. Әкият. № 5.

Ш. Галиев. Мәче дөньясы. Тукран сые. Кар бүрек. Поши. Куяннар кайда! Таган. Ботка. Бурыч. Шигырьләр. № 4.

Ш. Галиев. Эш кушып булмый. Шигырьләр. № 12.

М. Газизов. Балан. Тап әле. Шигырьләр. № 6.

З. Гомәрова. Кайсы берлек. Илгизнең диңгезе. Җәй. Яратам сары балны. Шигырьләр. № 9.

З. Туфайлова. Яфрак ява. Трай. Яңа мәктәп. Кыш килде. Шигырьләр. № 9.

Х. Халиков. Кояшбикә челтәре. Барый. Нишләдем мин! Әле төште хәтергә. Әллә инде бәләләр... Бәбкә саклаганда. Шигырьләр. № 7.

Ф. Яруллин. Бәйрәмдә. Шигырьләр сөйли Марат. Искәндәрнең киңәше. Шигырьләр. № 6.

## БҮГЕНГЕ ӘДӘБИЯТ ТУРЫНДА МӘКАЛӘЛӘР

Ч. Айтматов. Яшь буын иҗаты. № 7.
И. Гази. Съезд каршылаганда. № 3.

## ӘДӘБИ БӘЙРӘМНӘР

### Һади Такташның туувына 70 ел

Н. Юзиев. Яңа матурлык җырчысы. № 1.
Һади такташ хатлары. № 1.

### Гомәр Бәшировка 70 яшь

Г. Ахунҗанов. И туган тел... № 1.

### Сәрвәр Әдһәмовага 70 яшь

Г. Бакиров. Мәкалә. № 4.

### Г. Афзалга 50 яшь

Р. Фәйзуллин. Халыкчан шагыйрь. № 5.

### Гафур Коләхметовның туувына 90 ел

Ә. Кәримуллин. «Яшь гомер» драмасы һәм патша цензурасы. № 5.

### Ибраһим Салаховка 60 яшь

С. Рафиков. Үрләргә кыю атлый. № 8.

### Әдип Маликовка 50 яшь

Р. Төхфәтуллин. Кояшны юлларда каршылап. № 8.

### Кави Нәҗминең тууына 70 ел

Н. Гыйззәтуллин. Язучы һәм көрәшче. № 12.
К. Нәҗми. Автобиографиядән өзекләр. № 12.

### Г. Әпсәләмовка 60 яшь

Г. Мөхәммәдова. Гуманизм җырчысы. № 12.

### С. Хәкимгә 60 яшь

С. Хәкимнең Т. Галиуллин белән интервьюсы. № 12.

### Зәки Нурига 50 яшь

Ә. Маликов. Утта чыныккан дуслык. № 12.

### Ю. Әминовка 50 яшь

А. Гыйләҗев. Ак нур белән. № 12.

### Нәҗип Җиһановка 60 яшь

Ил белән бергә. № 1.
Ю. Корев. Үзенчәлекле талант. № 1.
Ү. Саттаров. Горурланабыз. № 1.

### Л. Украинканың тууына 100 ел

Л. Украинка. Өмет. Кайчагында... Бөтен җирдә... Юлым. «Моңнар» дигән циклдан. Җиңү. Шигырьләр. № 1.

## ОЧЕРК. ПУБЛИЦИСТИКА

А. Айнетдинов. Ватан сугышы һәм язучылар. № 2.
К. Зарипов. Юллар чатында. № 8.
В. Гудкова. Эзләнү азимуты. № 8.
Н. Ихсанов. Һәрвакыт юлда. № 1.
Р. Максудов. Шәйморза кешеләре. № 10, 12.
А. Малов. Тәвәккәллек. № 8.
М. Насыйбуллин. Эзләр кая илтә. № 11.
Ф. Насыйров. Профессор Гыйләҗетдинова. № 11.
Г. Паушкин. Чаллы җирендә. № 9.
Т. Сәгыйтов. Галимулла аганың истәлекле көне. № 7.
Ә. Рәшитов. Өченче очрашу. № 11.
К. Фәсәхов. Сүзе алтын, эше ялкын. № 6.
М. Хәмитов. Тынгысыз кеннәр. № 1.
Р. Хисмәтуллин. Тирәннән чыккан шытымнар. № 9.
М. Хөснимәрданов. Югары нокта. № 3.
С. Шакир. Дападагы совхозда. № 5.

## КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

Ю. Белостоцкий. Корыч канатлар. № 4.
М. Елизарова. Кешеләр аңа ышана. № 3.
Г. Лотфи. Уникенең берсе. № 4.
А. Мөслимов. 3309 номерлы мандат иясе. № 1.
Р. Хәйретдинов, Г. Кәримов. Комиссар каны. № 7.

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

Ә. Галиев. Керәшен татарлары җыры. № 10.
М. Госманов. Шәкерт дәфтәре — җырлар бишләре. № 6.
Н. Исәнбәт. Аулак өй. № 5.
И. Надиров. Херлеккә өндәүче моңнар. № 2.
Д. Рамазанова. Пермь татарлары иҗаты. № 7.
С. Сүнчәләй. Уеннар. № 11.

## ХАЛЫК ТАЛАНТЛАРЫ

Р. Сабирҗанов. Бер җирдә юк андый ак каеннар. № 7.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Т. Галиуллин. Хезмәт кешесенең рухи дөньясы. № 11.
Н. Дәүли. Бизәк өчен түгел, кирәк өчен. № 7.
Р. Мостафин. Кеше һәм сугыш. № 5.
Р. Мостафин. Традицияләрне үстерик, тирәнәйтик. № 10.
Ф. Миннуллин. Үсеш баскычлары. № 10.
Һ. Мәхмүтов. Сәет Шәкуров драмалары. № 2.
Ф. Урманчиев. Халыкның күңел көзгесе. № 6.

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

М. Бакиров. Шигырь тарихына сәяхәт. № 9.
Э. Нигъмәтуллин. Тәҗрибә һәм белем алмашып. № 8.
И. Нигъмәтуллина. Җил җыламый. № 4.
Р. Фәтхуллина. Уңай герой эзләү юлында. № 11.
Г. Хантемирова. Беренче адымнар. № 7.
Ф. Хатипов. Эпик жанрлардан повесть. № 3.
Г. Халит. Бездә ирекле шигырь бармы! № 5.
Г. Халит. Тизләтелгән әдәби үсеш һәм иҗат методлары. № 9.
Г. Халит. Халыкчан һәм тормышчан сәнгать өчен № 12.

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Ш. Абилов. Мәүла Колый хезмәтләренең яңа кульязмасы. № 6.
М. Гайнуллин. Габдрахман Сәгъди. № 7.
М. Госманов. Хөсәен Фәезхан улының бер хыялы. № 3.
К. Дәүләтшин. Чорлар аша. № 6.
С. Латыйпова. Борынгы кульязмалар һәм Ибраһим Хәлфин эшчәнлеге. № 7.
Ф. Мостафин. Муса Җәлил — татарча балалар журналларын оештыручы.
Ә. Нәҗип. Уртак хәзинә. № 2.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

И. Абдуллин. Кеше һәм яз. № 9.
Г. Ахунҗанов. Телебезнең фразеологик сүзлеге. № 7.

Г. Ахунҗанов. Үз теле, үз өлкәсе. № 11.
Р. Вәлиев, Р. Хәйретдинов. Яшь Ульянов турында яңа китап. № 3.
Р. Гәрәй. Карлыгачлар саны ишәя. № 12.
Ф. Миннуллин. Кечке уйлар. № 9.
Р. Мостафин. Кеше һәм табигать. № 11.
Р. Мостафин. Һади Такташ һәм аның чоры. № 12.
М. Мәһдиев. Чишелеш... нульгә бетми. № 7.
Х. Мәхмүтов. Җәүһәрләр сандыгы. № 2.
А. Әхмәдуллин. Читлектәге кош бәхетлеме! № 9.
Ш. Әхмәдуллин. Иртәгәге көнгә атлаганда. № 4.
Ш. Әхмәдуллин. Уйланырга кирәк. № 8.
Н. Хисамов. Дәрдемәнд шигырьләре рус телендә. № 1.

Бәләкәй рецензияләр. №№ 1, 3, 4, 5, 6, 9.

## ЯЗУЧЫ КӨНДӘЛЕГЕННӘН

Ш. Маннур. Һаман да истә. № 5, 6.
Ә. Маликов. Куриль чәчәкләре. № 8.
С. Хәким. Күңелдән юылмаган эзләр. № 11.

## ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

М. Садри. Нури Арсланов портретына берничә сызма. № 3.
М. Садри. Кочле ихтыяр җырчысы. № 7.

## СӘНГАТЬ

Л. Елькович. График публицистиканың сугышчан жанры. № 9.
Г. Зәйнашева. Бәхетле гомер. № 11.
И. Илялова. Эзләнүчән, тынгысыз актриса. № 4.
И. Илялова. Актерның иҗат юлы. № 10.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Ә. Булатов. Сәйфелгабит Мәҗитов. № 6.
Б. Галиев. Төсле тавыш сәнгате. № 1.
М. Глухов. Нагайбәкләр янында. № 4.
И. Гәрәй. Нинә «кара» бар! № 6.
С. Писарева, Д. Бәһаутдинова. Музейның әдәби филиалында. № 7.
Җ. Фәйзи. Халык җәүһәрләре. № 4.
В. Хангилдин. Татар халкының исем-фамилияләре һәм аларның кулланышы. № 11.
М. Юсупов. Сүриядә очрашулар. № 7, 8.
М. Һади. Китабеннас фи хаккылхавас. № 6.

## ЯКТАШЛАРЫБЫЗ СӘЯХӘТТӘ

Р. Мостафин. «Оҗмах»ка сәяхәт. № 2, 3, 4.
А. Скрыпник. Могҗизаның кире ягы. № 10.

## ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

Ф. Камалова. Салих Сәйдәшев һәм театр. № 9.
А. Хәсәнова. «Азат хатын» журналы чыга башлауга 45 ел.
Л. Хәмиди. Шагыйрьнең беренче бюсты. № 10.
С. Әдһәмова. Ул шагыйрь иде. № 1.

## АЛАР БЕЗДӘ БУЛГАННАР


В. Климентовский. **Бер генә килсә дә. № 3.**
В. Климентовский. **«Сәләтсез» студент. № 5.**
В. Климентовский. **Даими һәм эшлекле элемтә. № 9.**


## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ


Д. Гыйманова. **Гөлсем Болгарская. № 11.**
Б. Камалов. **Драматургиябезнең горурлыгы. № 10.**
Г. Кашшаф. **Фәхри Әсгат. № 10.**
**М. Мозаффаров. № 3.**
Ш. Сарымсаков. **Сәхнәгә багышланган гомер. № 11.**
А. Әхмәт. **Хөрмәтле язучыбыз. № 10.**

**Безнең сафка. № 2, 9.**

**Дусларча шаярулар. № 1, 4, 10.**

**Кайвакыт шулай була. № 4.**

**Полякча кинаялэр. № 8.**

**Укучы сүзе. № 6.**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—12.**

«Казан утлары» журналының икенче санында басыла:

**М. Мәһдиев. Фронтовиклар.** Роман.

**М. Әмир. Балыкчы ялганнары.** Повесть.

**М. Зарипов. Пани Сирена.** Хикәя.

**Г. Афзал, Р. Гатауллин, Р. Гәрәй** h. б. **шагыйрьләрнең** шигырьләре.

**Р. Вәлиев. Каурыйлар чыныкканда.** Чаллы автозаводы төзелешеннән очерк.

**Муса Җәлил иҗатыннан яңа документ.**

**С. Чанышевның Мирхәйдәр Фәйзи турындагы истәлеге.**

**Мәдәният тарихына караган материаллар, әдәби мирас, яңа китапларга рецензияләр h. б. материаллар.**

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 70010